www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

Айдар МЕТШИН. Түбән Кама — туган йортыбыз. ....................................................................37

ШИГЪРИЯТ, ДРАМАТУРГИЯ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Разил ВӘЛИЕВ. Без — мәңгелек туган җир белән. *Шигырьләр*. ..................................................3
Зөлфәт ХӘКИМ. Ля бемоль. *Ике пәрдәле драма*. ...........................................................................9
Фәрит ИМАМОВ. Мәхәббәт талисманы. *Фантастик бәян*. .........................................................42
Рифкать ИМАЕВ. Минем җанда — үзгә кояш. *Шигырьләр*. .........................................................83
Ралия КӘРИМОВА. Ташлы туфрак. *Документаль бәян*. ...............................................................86
Марс ХАФИЗОВ. Шатланып туймый күңел. *Шигырьләр*. ..........................................................114
Алмаз ХӘМЗИН. Бармагыңнан үбәр идем... *Бәян*. .......................................................................116
*100нче бит:* Зөлфәт ХӘКИМ. Янгын чыккач соң булыр. ..............................................................100

ПУБЛИЦИСТИКА

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Бу хыяллар нигә якты дисәң... *Очерк* ...................................................136
Фәтхулла АБДУЛЛИН. «Җидегән чишмә»ләргә йөзек салдым... .......................................................142

ТҮБӘН КАМА ПЕДАГОГИКА КӨЛЛИЯТЕНӘ — 35 ЕЛ

Люция ГАЛӘВЕТДИНОВА. «Балаларны... башка заман өчен укытыгыз». ............................144

СӘНГАТЬ

Ильтани ИЛЯЛОВА. Яшь шәһәрнең яшь театры. ..................................................................146
Алмаз ХӘМЗИН. Маэстро. ...........................................................................................................153
Рөстәм ГАЛИЕВ. Рәссам. ................................................................................................................159
Эльмира ЗАКИРОВА. Эльмира Кәлимуллина: «Мин — Түбән Кама кызы!». .......................162

ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘРДӘ

«Кама таңнары» әдәби берләшмәсе иҗат әһелләренең шигырьләре
*(Фәтхулла АБДУЛЛИННЫҢ кереш сүзе белән)*. .......................................................................165

ЮМОР

Илдар ХӘЙРУЛЛИН. Гаилә кризисы. ..........................................................................................174
Инсаф КАШАПОВ. Аптырар дип уйлама... ..................................................................................175

ШАЯН СӘХИФӘ

Уены-чыны бергә. Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде. ..........................................................176

АК ҖИЛКӘН

Ләйсән ХӘЕРОВА. Кояш халкы. *Хикәя*. ....................................................................................178
*Бәләкәйләр:* Рөстәм ГАНИЕВ. Бәләкәй Рөстәм. ........................................................................185
Хикәя яза аласызмы? Вәсилә ФӘЙЗЕТДИНОВА хикәяләре. .........................................................189
«Казан утлары» архивыннан. ......................................................................................................134
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. .........................................................................................190

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Екатерина Анисимова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1268).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 31.08.2016, график буенча 31.08.2016.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ М-2275. Тираж 4550.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210, П2365 (физик затлар өчен), 16262, П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2016 ел



Разил
Вәлиев

# БЕЗ – МӘҢГЕЛЕК ТУГАН ҖИР БЕЛӘН

## Җидегән

*Түбән Кама шәһәрендә мәшһүр
«Җидегән чишмә» берләшмәсен
оештырган каһарман якташларыма*

Аваз килә ерак-ераклардан,
Җан авазы, –
Чорлар дәшәме?
Атом бүлгән чорда фида җаннар
Ил кайгысын бүлеп яшәде.

«Милләт», диеп утка керде алар,
Ә кемнәрдер кабер казышты...
Ут эчендә бүген Тукай теле,
Ут эчендә татар язмышы.

Офыкларны баскан кара төтен
Бер таралыр микән җил белән?
Халыклар һәм илләр адашканда,
Маяк булды безгә «Җидегән».

Бүлгәләнде кавем, илләр, җирләр,
Бүленмим тик патша тәхете...
Безнең хыял – тәхет яулау түгел,
Безнең хыял – халык бәхете.

Бәхет эзләп халкым җирләр гизгән,
Татар һәрчак төпкә җигелгән.
Җиңелгәнне алдап була икән
Орден-медаль, тәти җим белән...

---

Разил ВӘЛИЕВ (1947) – *Татарстанның халык шагыйре, прозаик, публицист, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Дүрт томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә чыккан күпсанлы китап авторы. Казанда яши.*

Җиде юлны кушкан Җидегән бу –
Күпме язмыш монда кавышкан!
Тетри заллар, тетри мәгъруր җаннар
«Без мәңгелек!» дигән тавыштан.

Без – мәңгелек, бары бергә булсак,
Без – мәңгелек туган җир белән.
Ялгыз чакта җанлы йолдыздай без,
Бергә чакта – шанлы «Җидегән».

## Моңлы ядкарь

*Мәшһүр әдип Рабит Батуллага*

Күптән инде, күптән очрашкан юк...
Җыя иде безне Батулла...
Ул көннәрдән бары ядкарь калды, –
Үткәннәргә юл юк кайтырга.

Күптән инде бергә дулаган юк,
Кабынган юк, дөрләп янган юк.
Үз илеңдә үзең хуҗа булып,
Мәйданнарда батыр калган юк.

Күптән инде, күптән елаган юк.
Зиратларда яшьләр сыккан юк.
Йодрык төйнәп, нәфрәт сүзе сөйләп,
Урамнарга ярсып чыккан юк.

Күптән инде, күптән адашкан юк,
Гөнаһ кылган, азган-тузган юк.
Черек күлнең шомлы бакчасыннан
«Карурман»ны җырлап узган юк.

Күптән инде, күптән дуслар белән
Җыелган юк, корбан чалган юк.
Әйтерсең лә иманыбыз камил,
Әйтерсең лә җирдә ялган юк.

Күптән инде, күптән Обком да юк,
Дәүләт тә юк, көткән ил дә юк.
Ядкарь булып калды татлы хыял,
Узды еллар, сорап, теләнеп.

Күптән инде, күптән, ирек даулап,
Чатырларга байрак элгән юк.
Тукай әйткән: татар йоклагандыр...
Уянырмы берчак? Белгән юк...

Күптән инде, күптән очрашкан юк...
Үткәннәргә кире кайту юк.
Хыяллардан корган дәүләтемдә
Батулла бар, әмма Бату юк!

## Тик минеке

Җилләрдән мин сафлык таләп иттем,
Болытлардан аклык сорадым.
Хаклык эзләп, пакьлек эзләп җирдә
Тирәнәйде маңгай сырларым.

Күңелемә кайгы-сагыш төшсә,
Ак чәчәкләр җирдә эзләдем.
Офыкларга карап котә торгач,
Сагышларга мандым күзләрем.

Аклык эзләп гомер иткәнгәме, –
Ап-ак булды чигә чәчләрем.
Шатлыгымны җилгә сибеп йөрдем,
Тик кайгымны җиргә чәчмәдем.

Моннан ары күзне күккә төбәп,
Буш хыяллар белән йөрмәмен.
Минем бәхет – тик минеке булыр, –
Туктамасын гына йөрәгем.

## Минем дошманым

Төн үткәнче күңлем бакчасының
Шиңә калса бары бер гөле –
Таң атуга минем дошманыма
Бу турыда инде билгеле.

Әллә кайдан читтән күреп тора,
Барган чакта юлда адашсам.
Тик күрми ул, аяз төндә әгәр
Йолдызларга кадәр мин ашсам.

Кешеләргә әйтер, кайгылы, дип,
Сөенечтән әгәр еласам.
Тик кул сузмас, дулкыннарга чумып
Кичкән чакта кайгы елгасын.

Ул һәрвакыт көләч, шаян булыр,
Ачуланмас һич тә, каргамас.
Итагатьле, тыйнак сүзләр сөйләр,
Тик күземә туры карамас.

...Дошманыма карап юлга салам,
Үзгәртәм мин тормыш агышын.
Ул булмаса, каян белер идем:
Кайсы дөрес, кайсы ялгышым.

## Мин соң кемгә эндәшим?

*Нигә без һаман хокуксыз,*
*Нигә без һаман да ким?*
*Тукай Гаязга эндәшкән,*
*Мин соң кемгә эндәшим.*

Ркаил Зәйдулла

*(дусларча шаяру)*

Шигърияттә битараф юк,
Һәрбер шагыйрь көндәшең.
Син биектә – күктә бүген,
Син җиһанга эндәштең.

Эндәштең – күкләр күкрәде,
Җиһан койды күз яшен.
Син чорлар белән сөйләштең,
Һәрбер сүзең – ут, яшен.

Барлап чыктың бөекләрне,
Табалмадың тиңдәшең...
Син тарихка, син халыкка,
Син милләткә эндәштең.

Тукай Гаязга эндәшкән,
Син шигырьгә эндәштең.
Шигырь – синең татлы төшең,
Шигырь – ачы күз яшең.

## Көз

Аягүрә йортлар елап тора...
Кызганалар бугай дөньяны.
Көз китергән сары күлмәк киде
Җир шарының менә бу ягы.

Саубуллашмый-нитми кошлар китте,
Кошлар китте кояш артыннан.
Кошлар халкын уйлап басып тордым,
Чапкан чакта төшеп атымнан.

Җир нарасый, сабый бала кебек,
Юынды да һаман юынды.
Чистармады, ләкин пычрагыннан...
...Мин югалттым бугай юлымны.

Мине ташлап аргамагым качты,
Чабып китте дала ягына...
Ияренә менгермәсә дөнья,
Асылынып барыйк ялына!

Кабат кайтмас яфракларын сагынып,
Бар агачлар ятып елады.
Агачларга кушылып мин еладым,
Сагындым да үткән елларны.

Урамнарда йөрдем дәрвиш кебек...
Ай урамда йөзә, ай арган.
Боз астында катып калыр кебек...
Айны кудым пычрак сулардан.

Кышны уйлап моңсуланып йөрдем
Каурыйларын койган казлардай.
Бар өметем минем кышта инде...
Кыш артында чөнки язлар бар.

## Авылга кайту

Ашыктырып этә иңнәремнән
Туган якка буран.
Өянкеләр авыл башынача
Каршы чыгып торган.

Карт өянке, давылдандыр инде,
Каерылган, сынган.
Күтәрелеп килә алсу кояш, –
Җир йөрәге сыман.

Ал кояшка таба йөзне тотып,
Күпме юллар үттем!
Дөньяда тик безнең авылдадыр
Ипи исле төтен.

Олы хисләр, олы омтылышның
Туган якта башы.
Шушы җирдә туган хыялларым
Шунда чынга ашты.

Туган авыл – соңгы станция...
Кайтам сине уйлап,
Ике рельс кебек ялтыраган
Чана юлы буйлап.

## Туфан Миңнуллинга

Син татарның алтын баганасы,
Без дусларың – терәү.
Туфаннар бар, Миңнуллиннар бик күп,
Тик синдәе берәү.

## Индус Таһировка

Ул татарның чишмә башын таба,
Бүгенгесен күрә, ахырын.
Күрәзәче түгел, Алла түгел,
Ул тарихчы, галим Таһиров.

## Миркасыйм Госмановка

Башта кырын карадылар,
Ул, дип, Кытай татары.
Татарга чын тарих язды,
Ул – чын Тукай татары.

## Әбрар Кәримуллинга

Ул татарның бар китабын
Эзләп табып санаган.
...Милләтнең асыл затлары
Чыга икән Сабадан.

## Хәйдәр Бигичевка

Гасырлардан күкрәп аваз килә,
Җырлый күкрәп, җырлый тын гына...
Бәгырендә аның Тукай рухы,
Аның җаны тоташ моң гына.

## Бераз Тукайчарак

*(сәяси шигырь)*

Кандидатлар бигрәк тату сайлау белән,
Сайлаучының тормышларын җайлау белән.
Кандидатлар вәгъдә белән кунак итә,
Халык рәхмәт укый: сакалын селкетә.

## Син татарның күңел түрендә

*Татарстанның халык,*
*Россиянең атказанган*
*артисткасы Дания Нуруллинага*

Каян килгән сиңа бу сыйфатлар,
Өлге итеп һәркем алырлык, –
Коръәннәрдән күчкән асыл сыйфат –
Алтыннардан кыйммәт «сабырлык»?

Каян килгән сиңа илаһилык, –
«Алиһә» дип зурлап әйтерлек...
Күңелеңдә, юкса, ачы язмыш,
Унөч яшьтән бирле ятимлек.

Каян килгән сиңа иман, кыйбла, –
Сынаганда сынмый түзәрлек?
Саклагандыр сине безнең өчен
Ходай үзе – Рухи гүзәллек!

Каян килгән сиңа миһербанлык? –
Дус кайгысын бүлдең иң элек...
Бар бәладән саклый кебек сине
Кешеләргә кылган игелек.

Каян килгән сиңа нурлы караш? –
Күзләреңдә бәхет күренә...
Син – татарның биек сәхнәсендә,
Син – татарның күңел түрендә.



Зөлфәт Хәким

# ЛЯ БЕМОЛЬ

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ ДРАМА

К А Т Н А Ш А Л А Р :
Надир – музыка уен коралларын көйләүче.
Сафия – консерватория студенты.
Әсәд – Сафиянең әтисе.
Рәүфә – Сафиянең әнисе.
Бәхтияр – эшмәкәр, продюсер.
Эшче һәм башкалар.

**БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ**

**1**

*Уртача җиһазланган фатир. Түрдә пианино тора. Ә с ә д белән Р ә ү ф ә чәй эчәләр.*

Ә с ә д . Сафия һаман кайтмый. Шалтыратмый да ичмаса.

Р ә ү ф ә *(сәгатькә карап)*. Имтиханын гына бирә алсын инде берүк.

Ә с ә д . Курсларында аңа тиңнәр юк, дисең бит.

Р ә ү ф ә . Сәләтле кешедән нык көнләшәләр. Аяк чалулары ихтимал.

Ә с ә д . Ничек итеп?

Р ә ү ф ә . Хөсетләр алар чараны табалар.

Ә с ә д . Бәхтияр шунда микән?

Р ә ү ф ә . Янындадыр. Тынычландырып, куәт биреп торадыр.

Ә с ә д . Имтихан вакытында куәт бирүче кирәкме соң ул?

Р ә ү ф ә . Кире сүз әйтмәсәң, күңелең булмый инде синең. Бу Бәхтиярны Ходай үзе биргәндер инде безгә.

Ә с ә д . Яши-яши күрербез.

Р ә ү ф ә . Андый ярдәмчесез данлыклы җырчы булу авыр, бәлки мөмкин дә түгелдер. Бәхтияр ярдәме белән безнең Сафия җырчы буларак бөтен дөньяга танылачак.

Ә с ә д . Кызыбыз җырга гашыйк, күңеле җырлы-моңлы аның. Ә син алдан ук аны дан-шөһрәт казану юлына юнәлтергә телисең.

Р ә ү ф ә . Талант белән генә булмый. Акча да кирәк. Менә тиздән узачак конкурста беренче урынны алгач, чит ил конкурсларына әзерләнә башлар.

---

Зөлфәт ХӘКИМ (1960) – *драматург, прозаик. Дистәдән артык китап, 50гә якын пьеса һәм күпсанлы җырлар авторы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Ә с ә д . Әле монда беренче урынны аламы-юкмы...

Р ә ү ф ә . Ала, нишләп алмасын. Беренчедән, аның кебек җырлаучы безнең тирәдә бүтән юк. Икенчедән, Бәхтияр үзе оештырган конкурста беренче урынны үзенекенә бирми кемгә бирсен.

Ә с ә д . Һаман чалыш-молыш юл белән, хәйлә белән эш итү ягында син.

Р ә ү ф ә . Нинди хәйлә?! Ә кызыбыз шундый талантлы була торып, башка берәү блат белән беренче урынны алса, гадел булырмы? Дөньясы шундый – йә син, йә башка кеше! Бу конкурска да акча күп кирәк, чит илгә чыкканда – бигрәк тә. Шуңа күрә Ходайга рәхмәт инде Бәхтиярның кызыбыз белән танышуына. Карале, туган көненә нинди пианино бүләк итте.

Ә с ә д . Сәгать ничә? *(Сәгатькә карый.)* Тиздән пианино көйләүче мастер киләчәк. Бик шәп настройщик дип телефонын бирделәр. Иртәнге якта шалтыраткан идем, биштән соң киләм, диде.

*Ишек кыңгыравы зеңгелди. Ә с ә д ишекне барып ача. Чәчәк бәйләме тотып Б ә х т и я р керә.*

Б ә х т и я р . Исәнмесез! *(Әсәд белән кул биреп күрешә.)* Сафия кая? *(Чәчәкне Рәүфәгә тоттыра.)*

Р ә ү ф ә . Имтиханда. Син дә шундадыр дип уйлаган идек.

Б ә х т и я р . Эшләрем тыгыз булды да, консерваториягә баралмадым. Бушагач, шалтыраттым – Сафиянең телефоны җавап бирми. Кайткандыр дип уйладым да сезгә чаптым. Нишләп болай озак икән? Әллә... Ник телефоны җавап бирми, шуңа аптырыйм.

Ә с ә д . Имтихан вакытында телефоннарны сүндерәләрдер.

Б ә х т и я р . Әйе шул. Ярый, алайса мин аның янына консерваториягә киттем. *(Чыгып китмәкче була.)*

*Шулвакыт канатланып С а ф и я кайтып керә. Кычкырып җырлый. Әнисен кочаклый, аннары әтисен кочаклап ала. Кулларын Бәхтиярнең иңнәренә куеп сикергәләргә тотына.*

Р ә ү ф ә . Булдымы, бирдеңме?

Ә с ә д . Ник, күрмисеңмени? Аяклары җиргә тими бит.

Б ә х т и я р . Шигем юк, бишледер?

*Сафия, биш бармагын тырпайтып, зал буйлап кычкырып җырлап йөри.*

*Ул җырлаганда, Н а д и р керә һәм тыңлап тора. Надир җыйнак кына чемодан тоткан.*

С а ф и я *(җырын тәмамлап, кычкырып)*. Бишле! Педагогым хәтта елап та алды. Мәскәүдән килгән профессор: «Бесподобный вокал!» – диде! *(Надирны күреп, сискәнеп китә.)* Ай, бездә тагын кемдер бар. *(Барысы да борылып Надирга карап торалар.)*

Н а д и р . Исәнмесез!

Ә с ә д . Исәнмесез.

Н а д и р . Ишек кыңгыравына бастым, ишетмәдегез. Ишегегез ачык иде, кердем.

Ә с ә д . Сез настройщиктыр?

Н а д и р . Әйе.

Ә с ә д . Кызыбызның пианиносын көйләргә кирәк иде.

С а ф и я . Мин вокалдан бишле алып кайттым да сөенечтән җырлап күрсәттем. Хәтта сезнең керүегезне дә сизмәгәнбез.

Н а д и р . Училищеда укыйсызмы?

С а ф и я . Консерваториядә.

Н а д и р *(пианиноның капкачын ачып)*. Каян алдыгыз инструментны?

Р ә ү ф ә *(Бәхтиярга ымлап)*. Егетем туган көнгә бүләк итте. *(Бөтерелеп ала.)* Мине барлык укытучылар мактадылар – шулхәтле төгәл, интонированно җырлыйм, диделәр.

Н а д и р . Нишләптер хәзер җырлаганда дитонация ясадыгыз. Өйдә ничек җырласаң да ярый дипме, әллә шатлыктанмы?

Сафия *(кинәт боегып)*. Әле генә җырлаган романста фальш ясадыммы?

Надир. Әйе.

Сафия. Кайсы төшендә?

Надир. Берничә урында кирәкмәгән подъездлар ясадыгыз, ә куплетлар азагында икесендә дә төгәл җырламадыгыз. «Ре» урынына беренче куплет азагында «до диез» яңгырады, ә икенче куплетны «ми бемоль» белән тәмамладыгыз.

Сафия *(борчылып)*. Сез чын әйтәсезме?

Надир. Чын әйтәм.

Сафия *(әнисенә карап)*. Имтиханда дөрес җырладым мин.

Рәүфә. Аптырагансың икән, өйдә ничек җырласаң да ярый ул.

Бәхтияр. Әле Сафияне ялгыш җырлауда бер дә гаепләгәннәре юк.

Надир. Мин аны гаепләмәдем бит. Сез миңа комачаулыйсыз. *(Барысы да читкәрәк китеп, Надирга карап торалар. Надир, кылларын тарттырып, пианиноны көйли.)*

Рәүфә. Сезнең камертоныгыз юкмыни?

Надир. Миңа камертон кирәкми.

Рәүфә. Ә ялгышсагыз?

Надир. Ялгышсам да, сез аны ишетмәссез. Пианиноны көйләү авыр түгел. Яртышар тоннан ары бүленми бу инструмент. Гәрчә кайберәүләрнең колагы чирек тонны, сигездән, хәтта уналтыдан бер өлешне ишетсә дә. Мин көйләп бетерим инде. *(Надирны пианино янында калдырып зал почмагына китәләр.)*

Әсәд. Син, кызым, кеше сүзеннән коелдың да иңдең. Имтиханыңны биреп кайткансың бит инде бишлегә.

Рәүфә. Әйтмә дә. Имтихан алучылар пианино көйләүчедән акыллырактыр әле.

Сафия *(Надирга карап)*. Моның абсолютный слух микәнни?

Бәхтияр. Фатирдан фатирга әйбер ремонтлап йөрүчеләр шундый дорфа булалар инде алар. Игътибар итмә.

Әсәд. Сатып алганда ук көйли торган сервислары юк идемени?

Бәхтияр. Кызганычка каршы, юк иде шул. Затлы кибет булса да, настройщиклары юк.

Әсәд. Димәк, настройщик – штучный специалист.

Рәүфә. Шул сирәк һөнәрче булганга, килеп керү белән кызымның җырлавыннан гаеп эзләргә тотынды да инде ул.

Әсәд. Гаеп эзләмәде инде. Әйтте генә. Моңарчы Сафияне гел мактадык, башкалар да күккә чөйделәр. Тәнкыйтьне дә кабул итәргә кирәк. Хәер, тәнкыйть тә булмады бит әле монда.

*Надир пианино клавишларына бер-бер артлы басып чыкканнан соң, әле генә Сафия җырлаган романсны уйнап ала.*

Надир. Тәртип.

Әсәд. Күпме түлисе?

Надир. Шул, алдан сөйләшкәнчә.

Әсәд *(акча биреп)*. Пианиноны көйләү авыр түгел, дидегез. Ә нинди уен коралын көйләве авыр?

Надир. Үзеңнең күңелеңдәгеен.

Әсәд *(бер мәлгә уйланып)*. Үзеңнең күңелеңдәгеен... Шәп әйттегез!

Надир. Сау булыгыз! *(Чыгып китә.)*

Сафия *(сүренкеләнеп)*. Кәефемне бетерде бу кеше.

Бәхтияр. Син бигрәк теләсә кемнең сүзенә игътибар итәсең. Һәрбер настройщикның, электрикның, сантехникның сүзенә колак сала башласаң...

Рәүфә. Чыннан да, кем соң әле ул шул хәтле!

Әсәд. Әйтмә дә! Берничә нотаны дөрес алмаса, ни булган?! Кызым, җырны тыңлаганда, кайсы нотаны кайсы якка чалшайтканны тыңламыйлар, җырлаучының җан авазын тыңлыйлар.

Бәхтияр. Ә кем белгән – дөресен әйттеме настройщик, юкмы. Бәлки, ул хаклы түгелдер, бәлки, төп-төгәл җырлагансыңдыр.

Рәүфә. Әйдәгез, чәй эчик әле. Бүген бәйрәм – кызым имтиханны бишлегә биргән.

Сафия *(кул селтәп)*. Әй...

*Надир керә. Аңа аптырап карап торалар.*

Надир. Мин инструментымны онытып калдырганмын. *(Пианино өстеннән ачкычын алып чемоданына тыгып куя.)*

Бәхтияр. Кире керү – начар билге.

Надир. Кем өчен начар – кире керүче өченме, өйдәгеләр өченме?

Бәхтияр. Гомумән. Кире керү яхшыга түгел. Син пианиноны дөрес көйләдеңме соң, төгәл итепме?

Надир. Әйе.

Бәхтияр. Камертонсыз көйли алганыңны ничек тикшереп була?

Надир. Тюнер сыман әйберегез бармы?

Сафия. Юк.

Надир. Алайса, әнә, телефон трубкасын колагыңа куй – аның гудогы «ля бемоль» тональлегендә.

Бәхтияр *(ачуын яшермичә)*. Син шундый талантлы кызны үпкәләттең. Аның җырлавына хәтта профессорлар шаккаталар. Гафу үтенергә теләмисеңме?

Надир. Андый теләгем юк. Ләкин минем гафу үтенүем нindидер йогынтыга ия икән... *(Сафиягә таба борыла.)* Гафу итегез, сылу зат. Сезнең фальшны ишетеп әйтүем өчен гафу итегез.

Бәхтияр. Синең гафу үтенүең дә мыскыл иткән сыман яңгырады.

Надир *(кинәт кырысланып)*. Ә син һәр яңгыраган аваздан мыскыллау, кимсетү ишетмә. Кайгырмагыз. Чиста «ре» нотасын алган булсагыз да, аның төгәл «ре» булуында шик калачак. Нота чиксез бүленә. Аны барыбер ишетмиләр. Бер тонны, ярты тонны, чирек тонны әле кемдер ишетә. Ә бит сигездән бер тонны, уналтыдан берне ишетү турында хәтта хыялланмыйлар да. Имтихан алучылар, алай-болай әгәр дә сез нотаны сигездән бер өлешенә югарырак яки түбәнрәк алган булсагыз, барыбер ишетмиләр.

Сафия. Димәк, мин имтихан биргәндә дә фальш җибәргән булуым ихтимал?

Надир. Булырга мөмкин. Аны кем белгән.

Бәхтияр. Әй-әй, башны катырма. Син үзеңнең гыйлемлелегеңне күрсәтмәкче буласың, ахрысы.

Надир. Кем алдында? Синең алдыңдамы? *(Текәлеп карап тора.)* Йөзең таныш. Син җыр фестивальләренең спонсоры түгелме?

Бәхтияр. Әйе, мин инде берничә ел рәттән җыр фестивальләре, конкурслар уздырам. Төп бизнесым башка юнәлештә булса да, эстрадный рынок мине нык кызыксындыра.

Надир. Эстрада, чыннан да, базарга әйләнде инде ул.

Бәхтияр. Эстрадабызны күтәрүгә минем кебек кешеләр ярдәм итәргә тиеш. Менә Сафиянең промоуторы мин хәзер. Аны рекламалап, чит илләргә алып чыгып, дөнья күләмендә популяр җырчы итәргә исәбем бар. Кыскача гына үзем турында әйттем һәм минем белән бүтән «йөзең таныш» дигән фразалар белән сөйләшмә, яме.

Надир. Беренчедән, мин синең белән сөйләшергә теләмәдем, үзең башладың. Икенчедән, мин фәкать синең тональностька гына төштем. Өченчедән, кыскача гына үзем турында әйтеп үтәм алайса. Син уздырган җыр бәйрәмнәрендә мин дә катнашам.

Бәхтияр. Кем булып?

Надир. Мине тавыш режиссёрлары ярдәмгә чакыралар. Акустиканы көйләргә. Мин сезнең ул тусовкаларыгызны күреп шаккатам. Ярар, андагы тавышсыз фонограмщик җырчылар,

анда яңгыраган төссез, тәмсез җырлар мине бигүк аптыратмый. Мине әнә шул базарны үстерүчеләр, ягъни сез шаккатырасыз. Бөтенләй сәнгатьтән ерак булган кеше, музыкаль слухы булмаган килеш эстрадага тыгылырга тиеш микән син?

Р ә ү ф ә . Туктагыз әле, оештыручы ул үзе специалист булмаска да мөмкин.

Н а д и р . Әмма сәнгатьтә түгел.

Б ә х т и я р . Нәрсәдән чыгып минем слухым юк дидең әле син?

Н а д и р . Концертка берничә көн кала син үзең анда бөтен нәрсәне тикшереп йөрисең. Шунда синең музыканы ишетмәгәнең күренә. Концерт программасына заставкалар әзерләгәндә, аларның берсен дә белмәвең аңлашылды. Ә бит ул заставкалар бөтен дөньяга танылган көйләрдән төзелгән иде. Син бөтенләй музыкаль слухсыз кеше.

Б ә х т и я р *(үзен көчкә кулга алып)*. Син үзеңне бөтен кешедән, хәтта миннән дә өстен итеп күрсәтергә максат куйдың, ахрысы.

Н а д и р . Синең алдыңда мин гыйлememне күрсәттем ни, күрсәтмәдем ни. Музыканы, җырны син кеше кул чапканга карап кына бәяли аласың. Син бу сылуның җырлавын мактаганда да, җаның белән аңлап мактамыйсың. Дөресен әйткәндә, туташның консерваториядә укый торып, андый тусовкаларда йөрүе гаҗәпләндерә.

Б ә х т и я р . Ансында инде синең эшең юк.

Р ә ү ф ә . Мондагы концертларда катнашуы ул бер репетиция чоры кебек кенә – киләчәктә зур сәхнәгә менәр өчен.

Ә с ә д . Туктагыз әле... Исемегез ничек?

Н а д и р . Надир.

Ә с ә д . Надир әфәнде, барыбер килешәсездер – Бәхтияр оештырган җыр бәйрәмнәре бик кирәк.

Н а д и р . Сүз дә юк, кирәк. Ләкин сәнгатьне үстерү максаты белән оештырылырга тиеш алар.

Б ә х т и я р . Ә без нинди максат белән йөрибез?

Н а д и р . Сезгә акча кирәк, шул бәйрәмнәр сылтавы белән түрәләргә күренү кирәк, андагы кызлар кирәк, сәнгать кешеләре өстеннән влач кирәк. Сиңа сәхнә үзе кирәк – аннан берьюлы күп кешегә күренергә мөмкин... Үзең җырлый-бии белмәсәң дә, меңләгән кешеләр кул чапкан җырчы өстеннән хакимлек итү сиңа ләззәт тә бирә, халык алдында да дан казанасың. Синең бөтен кайгың – концертка Президент килер микән, Премьер килер микән, фәлән-фәләнеч килер микән дигән уй. Эстрада өчен кайгыручы кеше түрәләрнең күңелен күрү турында түгел, концерт затлы булуын уйларга тиеш.

Р ә ү ф ә *(тавышын күтәреп)*. Туктагыз әле, сез ноталарны ишетә белгәч тә, кем нишләргә тиеш икәнне өйрәтергә хакыгыз бар дип уйлыйсызмыни?

Н а д и р . Юк, мин моңа җавап кына бирдем. Җан авазы яңгыраган тарафларга мондый кешеләр керергә тиеш түгел. Җыр, моң – сезнең өлкә түгел, бигайбә. *(Чыгып китә.)*

Р ә ү ф ә . Бигрәк кырыс кеше булып чыкты бу.

Б ә х т и я р . Избалованный. Минминлеге артык зур.

Ә с ә д . Ярар, менә пианиноны көйләде бит әле.

Р ә ү ф ә . Без бит беребез дә белми – дөрес көйләгәнме, юкмы.

Б ә х т и я р . Бәлки, әле ул жуликтыр.

Ә с ә д . Миңа аның телефонын бер зур кеше бирде, бик мактады.

С а ф и я *(уйга калып)*. Телефон гудогы «ля бемоль», диде. Кызык... *(Телефонны алып колагына куя, пианино янына бара, клавишка басып карый.)* Әйе, «ля бемоль».

Б ә х т и я р . Сафия, без бүген кая барабыз?

С а ф и я . Мин бик арыдым. Беркая да барасым килми. Ял итәм.

Б ә х т и я р . Алайса мин иртәгә көннең икенче яртысында килермен.

С а ф и я . Ярар.

Б ә х т и я р . Сау булып торыгыз. *(Чыгып китә.)*

Ә с ә д . Кызым, сезнең планнарыгыз нindирәк соң?

С а ф и я . Телевидениегә интервью бирергә, студиядә җыр яздырырга. Радиога җырны ротациягә куясы бар. Бәхтияр барысы өчен дә түли.

Р ә ү ф ә . Менә бит, аның ярдәме белән син зур йолдыз булачаксың. Көз көне булачак фестивальдә ул сине беренче итәчәк, аннары ил күләменә алып чыгар, чит ил эстрадасына аяк басарга ярдәм итәр.

Ә с ә д *(уйчанланып)*. Дөресен әйткәндә, миңа настройщик әйткән сүзләр ошады. Җыр өлкәсендә асылы белән сәнгатьтән ерак булган кешеләр идарә итәргә тиеш микән? Хәер, заманы шундый – һәр өлкәдә елгыр, комсыз, оятсыз кешеләр кереп яшәешне үз кулына алалар.

Р ә ү ф ә . Син кызыңның киләчәге турында кайгыр. Популяр җырчы булгач, ул балда-майда йөзәчәк, киләчәге аллы-гөлле булачак. Бәхтияр кебекләр теләсә кемгә ярдәм итмиләр, Ходай биргән бәхет бу безгә.

С а ф и я . И әни, аның белән, әлбәттә, җиңел, бөтен проблемалар җайлы хәл ителә. Әмма миңа сәнгать тирәсендәге ыгы-зыгылар ошамый. Настройщик хаклы.

Р ә ү ф ә . Сез нәрсә, атагыз белән алдан сүз куешып, үзегезгә үзегез каршы киләсезме? Хәзерге заманда промоутерлар, спонсорлар ярдәме белән генә аякка басарга мөмкин.

С а ф и я . Мин ятып торыйм әле. *(Йокы бүлмәсенә кереп китә.)*

Р ә ү ф ә . Син ичмаса кызыңның язмышына кагылышлы мәсьәләләрдә оригиналь булырга тырышма. Үз киреңне сукалап зур урыныңны югалттың бит инде.

Ә с ә д *(кинәт усалланып)*. Мин үз урынымны югалтмадым һәм беркайчан югалтмаячакмын. Мин завод директоры вазифасын гына югалттым. Һәм һич кенә дә үкенмим. Промоутор, спонсор... Нинди сүзләр өйрәндең бит син дә, ә! Син – кечкенә генә заводның баш механигы бүлегендә гап-гади инженер булып эшләп, станокларның сызымнарын сызып утырган хатын, әллә нинди жаргонда сөйләшә башладың.

Р ә ү ф ә . Яңа заман, яңа сүзләр, нишлисең бит. Синең кебек гел агымга каршы көрәшеп яшәү дөрес түгел икәнне мин күптән аңладым. Турысын әйтеп, дөрес сүзләр сөйләп, кирәгеннән артык күп күреп, бәжекләнеп яшәмәсәң, инде әллә кайларга менгән булыр идең.

Ә с ә д . Тормыш миңа каршы көрәшкәнгә күрә шундый мин. Тоз күзле, җансыз-кансыз кешеләр заманы килде. Менә бу настройщик дөрес әйтте – һәр нәрсәдән, һәр күренештән, һәр кешедән выгода алырга омтылучылар тантана итә. Елгырлар заманы, аңламаган килеш эшкә тотынучылар, акча, мал артыннан куучылар заманы...

Р ә ү ф ә *(хыялланып)*. Әле тормыш алда. Бәхтияр белән кызым өйләнешеп үз тормышларын көйләп җибәрерләр. Кызыбыз – зур йолдыз, киявебез әүкатлы бизнесмен булса, киләчәгебез өчен кайгыбыз булмас.

Ә с ә д . Киләчәгебез кызыңның йолдыз булуына, киявеңнең бай булуына барып терәлсә дә әйбәт булмас.

Р ә ү ф ә . Менә бит әле, эшеңнән алдылар...

Ә с ә д . Эшсез калмам. Завод директоры буларак, миңа бер генә дә шелтә ишетелмәде. Үз сүземне, үз фикеремне әйтүем өчен генә гаепли алалар мине. Мин үземне пианино көйләп киткән егет сыман хис итеп куйдым әле. Аңа да җиңел түгелдер ноталарның кешеләр ишетмәгәнен ишетеп яшәү.

Р ә ү ф ә . Син гомер буе артык күп

нечкәлекләрне күреп, үз сүзеңне әйтүче булдың шул. Әнә теге фальшны ишетүче настройщик берничә минут эчендә Сафияне дә, Бәхтиярны да үпкәләтте. Күп ишетү, күп аңлау ярыйдыр, ләкин фальшка каршы көрәшеп бу дөньяда алга китү мөмкин түгел.

Ә с ә д . Әмма тирә-яктагы нәҗес белән гармониядә яшәү дә күңелсез шул.

Р ә ү ф ә . Настройщикның сүзләре нык тәэсир итте Сафиягә. Балакаемның хәтта йөзе сулыгып калды.

Ә с ә д . Әйтәм бит, Сафия гел мактауга күнекте, бер дә битәрләгәннәре булмады, нык иркәләнде. Андый гына әйтүләрне дә кабул итә белергә кирәк. Өйрәнер. Тормыш өйрәтә ул.

Р ә ү ф ә . Ичмаса кызыңа карата кырысланма!

## 2

*Шул ук күренеш. С а ф и я пианинода салмак кына уйный. Р ә ү ф ә диванда тыңлап утыра.*

С а ф и я *(уйнаудан туктап)*. Нотаның ярты тоны чирек тонга бүленә алуын күзаллап була, ә чирек тонның тагын бүленгәнен ишетүче юктыр инде.

Р ә ү ф ә . Колак ишетмәгән өлешләргә бүленүе аның ник кирәк?

С а ф и я . Алайса төгәл җырларга омтылырга кирәк микән дигән сорау туа. *(Паузадан соң.)* Фальшны ишетүчеләр бар шул.

*Ә с ә д кайтып керә. Папкасын телефон янындагы утыргычка куя.*

С а ф и я . Әти, ничек уйлыйсың, нишләп ярты тонны урталайга бүлмәгәннәр икән?

Р ә ү ф ә . Юк белән баш катырма инде.

Ә с ә д . Кызым, аны тагын-тагын бүлә башласаң, бик озын пианино ясарга кирәк булыр иде – өйгә сыймаслык итеп.

С а ф и я . Әйткәнеңдә логика бар. Димәк, бу инструмент уртача алынган, уртача ишетүче кешеләр өчен генә.

Ә с ә д . Ә тормыш, гомумән, уртача алынган, уртакул кешеләр өчен җайланган. Пианиноны көйләп киткән егеткә әниеңнең дә, Бәхтиярның да ачуы килде, алар настройщикны шундук өнәми башладылар. Син дә, кызым, үпкәләдең аңа. Ә бит ул синең берничә урында фальш җибәргәнеңне генә әйтте.

С а ф и я . Мин үпкәләмәдем.

Ә с ә д . Башкалар ишетмәгәнне ишетүе аркасында аңа күпме кеше үпкәлидер дә, күпме кеше аны күралмыйдыр.

С а ф и я . Нишләп инструментлар көйләп йөри икән ул, музыка буенча укытучы булып эшләми икән?

Ә с ә д . Ә инструментларны кем көйләр?

Р ә ү ф ә . Син ул настройщикны чистый Алланың кашка тәкәсе урынына күрдең инде.

С а ф и я *(үпкәле тавыш белән)*. Колагы яхшы ишетсә дә, музыкада үзе тупицадыр әле. Барыбызның да кәефен җимереп чыгып китте... Чыннан да, карагыз әле, һаман тора салып шуны искә алабыз. Бәхтиярга авыр сүзләр әйтте... *(Тагын әкрен генә пианинода уйный башлый.)*

Ә с ә д . Сүз күтәрә алмау да начар сыйфат. Ул аңа дөресен әйтте.

Р ә ү ф ә . Бер-берсенә гел дөресен әйтә башласалар, кешеләр үзара сугышып, берсен-берсе үтереп бетерерләр иде.

Ә с ә д . Юк! Киресенчә, гармония булыр иде кешеләр арасында. Бер-берсенә купшы, төче комплиментлар әйтеп, лаек булмаган килеш мактап,

кешеләр бер-берсенә начарлык кына эшлиләр. Бу – бер-берсен алдауның бер техник алымы.

Сафия *(клавишларга каты басып)*. Син мактаган мастер пианиноны дөрес көйләмәгән. Пианиноны тагы да төгәлрәк көйләргә кирәк.

Әсәд. Кит аннан!

Сафия. Төзек түгел. Менә, строить итми. *(Клавишларга баса.)*

Рәүфә *(борчылып)*. Нишлибез?

Сафия. Тагын чакырырга кирәк.

Әсәд. Чын әйтәсеңме, кызым?

Сафия *(үҗәтләнеп)*. Пианино көйле түгел!

Әсәд. Көйләвендә шигең бармыни?

Сафия. Әйе. Мин аермачык ишетәм – төзек түгел.

Рәүфә. Шикле кеше ул. Тагын шуны чакырабызмы?

Сафия. Шуны, шуны. Акчаны аңа түләдек бит. Үзе белән йә камертон, йә тюнер алып килсен.

Әсәд *(телефоннан шалтырата)*. Алло! Надир! Бу – Әсәд абыең. Кенәген пианинобызны көйләп киткән идегез. Сафия әйтә, имеш, көйләнеп бетмәгән, ди. Кайчан килә алырсыз икән? Берәр сәгатьтәнме? Бик әйбәт. Без өйдә.

*Ишек кыңгыравы зеңгелди. Әсәд барып ишекне ача. Бәхтияр керә. Кулында чәчәк бәйләме.*

Бәхтияр. Хәерле көн!

Әсәд *(кул биреп)*. Сәлам, сәлам.

Рәүфә. Исәнме, Бәхтияр.

Сафия. Исәнме. Уз әйдә. *(Бәхтияр аңа чәчәкне бирә.)*

Бәхтияр. Сафия, хәзер студиягә музыкантлар килә. Синең җырга аранжировканы бергәләп ясарга булдылар. Син әзерме?

Сафия. Хәзер пианиноны көйләүче киләчәк. Ул килеп киткәч кенә студиягә барам.

Бәхтияр *(аптырап)*. Кичә көйләмәгәнмени?

Рәүфә. Синең шикләнүең урынлы булган – дөрес көйләмәгән.

Бәхтияр. Аның җулик икәне чыраена чыккан. Шуңа бик кәефсезме син?

Сафия *(боегып)*. Әллә тагы. Җан тыныч түгел.

*Әсәд белән Рәүфә, аларның икесен генә калдырып, күрше бүлмәгә чыгып китәләр.*

Бәхтияр. Фестивальдә илле җырчы катнашачак. Бик авыр булачак оештыруы.

Сафия. Җырчылар шулкадәр күп. Мине эстрадага кертергә маташып йөрмәсәң дә була инде.

Бәхтияр. Ярар, ярар, синең мондый шаяруың бер дә кызык түгел. Барыбер сиңа беренче урын булачак.

Сафия. Алай гадел түгел бит, Бәхтияр. Алдан инде хәл итеп куйгансыз икән, нигә ул конкурсларны оештырып торырга? Син үзең яраткан, үзеңнең күңелеңә хуш килгән җырчыларны гына күтәрәсең булып чыга бит. Ә кемдер бик талантлы җырчы була торып та, синең күңелеңә хуш килмәсә, димәк, ул бу конкурста уңышка ирешмәячәк.

Бәхтияр. Бөтен җирдә шулай. Мин уйлап чыгарган кагыйдәләр, принциплар түгел бит бу.

Сафия. Миннән шәбрәк җырлаучы булса?

Бәхтияр. Барыбер иң шәбе син булачаксың.

Сафия. Ә бит дөресен әйткәндә, миңа караганда матуррак җырлаучы берничә җырчы катнашачак анда. Син җырлау осталыгына карап билгеләмәссеңмени җиңүчеләрне?

Бәхтияр. Мин сине яратам, Сафия. Минем сине иң югары урында күрәсем килә. Үзем оештырган конкурста яраткан кешемне күтәрү гаепмени?!

Сафия. Ярый, мин беренче булдым ди... Ә икенче, өченче урыннарны

син нинди принциплар, нинди сыйфатлар буенча билгеләячәксең? Тамашачының кул чәбәкләве буенчамы?

Б ә х т и я р *(иреннәрен юкартып)*. Кичә миңа настройщик әйткән сүз бит бу.

С а ф и я . Шулаймыни?..

Б ә х т и я р . Мин җырны аңламыйм дип уйлыйсыңмы?

*Ишек кыңгыравы зеңгелди.*
*Күрше бүлмәдән Ә с ә д чыга.*

Ә с ә д . Настройщик килгәндер. *(Ишекне барып ача.)*

*Н а д и р керә.*

Н а д и р . Исәнмесез.

Ә с ә д . Исәнмесез.

Б ә х т и я р *(чәнчүле тавыш белән)*. Абсолют слух белән дә абсолют нәтиҗәгә килмәскә мөмкин икән, ә.

*Надир, клавишаларга, басып, пианино төзеклеген тикшерә. Рәүфә чыгып Надирга нидер әйтмәкче була, Әсәд аны беләгеннән тотып күрше бүлмәгә алып китә. Бәхтиярның телефоны зеңгелди.*

Б ә х т и я р *(телефонын колагына куеп)*. Әйе. Бушатмый торыгыз. Башта үзем килеп тикшерәм – документларны, тегесен-монысын. Хәзер. Ярты сәгатьтән мин шунда булам. *(Телефонын кесәсенә тыга.)* Сафия, сәхнә безәр өчен җиһазлар алып кайтканнар. Мин шунда булырга тиеш.

С а ф и я . Ярар. Мин тиздән үзем студиягә барырмын.

Б ә х т и я р . Алайса, җиһазларны кабул иткәч, мин синең яныңа студиягә килермен. Пока! *(Чыгып китә.)*

Н а д и р *(Сафиягә таба борылып)*. Пианино төзек. Сезгә көйсез булып тоелган гына.

С а ф и я *(чак кына усалланып)*. Бәлки, аның көйсез икәнен мин генә ишетәмдер. Бәлки, сезнең колагыгыз ул дәрәҗәдә үк нечкә ишетмидер?

Н а д и р . Мин тюнер алып килдем. Һәр клавишны тикшерә аласыз.

С а ф и я . Ә тюнерлар яртышар тонга гына бүленгән инструментларны тикшерергә ясалган. Алар инде чирек тонга ялгышканны тотмыйлар.

Н а д и р . Мин тоям чирек тоннарны. Аннары... инструменттагы клавишлар барыбер ярты тоннардан ары бүленми.

С а ф и я . Ә нишләп мин сезнең слухка ышанырга тиеш? Теге көнне фальш җибәргәнменме, юкмы – моны ничек исбатлый аласыз?

Н а д и р . Аны исбатлау кирәкми. Миңа да аны исбатлау кирәкми. Сезнең үзегезгә бигрәк тә. Сез җырларга гына тиеш. Сез чын күңелдән, җан авазы белән җырлыйсыз. Тавыш тембрыгыз искиткеч матур. Кешенең күңелен ике нәрсә күрсәтә – күз карашы һәм тавыш тембры. Бик якты күңелле, җылы җанлы кеше сез.

С а ф и я *(кинәт йомшарып)*. Сез сәер кеше.

Н а д и р . Пианино төзек.

С а ф и я *(тып-туры карап)*. Ә мин сезне юри чакырттым. Сезгә ачу итеп.

Н а д и р . Ачу итеп?

С а ф и я . Әйе. Сез минем җырлауда фальш сизгәч, мин дә сезнең эшегездә гаеп тапкан булып кыландым.

Н а д и р . Ник кирәк булды бу сезгә?

С а ф и я . Белмим.

*Ә с ә д пәйда була.*

Н а д и р . Ноталарны төгәл алмау бар инде ул. Ник минем әйткәнемә шулкадәр хәтерегез калды? Гомумән, җырны ноталап тикшерү дөрес түгел. Җырлаганда кайвакыт ноталар белән билгеләп булмас авазлар ишетелә. Елауны нотага салып булмый. Ә моңлы җыр елаудан башланган. Әнә, әтиең монда чыкканда, ишек шыгыр-

дады. Башта аермачык «до диез» иштелде дә «ля»га хәтле глиссандо белән күтәрелде. Ник андый тавыш чыгара ишек? Кеше ноталар уйлап чыгармаган булса, мин ишек шыгырдавының тонына игътибар итәр идемме?

Әсәд. Син, энем, бик сәләтле кеше, шуңа ишетәсең син аны. Син әйтмәсәң, әле мин ишекнең шыгырдаганына да игътибар итмәгән булыр идем. Күптән майларга тиеш идем мин аны, онытылган, аннары күнегелгән.

Надир. Миннән дә яхшырак ишетүчеләр бардыр. Әмма иң сәләтле кеше дә чикле итеп яратылган. Үзеңнән дә сәләтлерәк булу мөмкин түгел. Ноталар язу, төрле системалар буенча эш итү – болар барысы да шартлы нәрсәләр, кирәк, әмма төптән уйлаганда, әһәмиятле түгел. Җан газабын нинди нотага салмак кирәк?!

Әсәд *(уйга калып)*. Җан газабын...

*Рәүфә пәйда була.*

Әсәд. Рәүфә, чәй китер әле. *(Рәүфә чәй әзерли башлый.)* Ә нигә аны нотага салырга? Җан газабы нотага салмыйча да кирәгеңне бирә ул. Утыр әле, утыр, чәй эчәбез хәзер. *(Өстәл янына утыралар.)*

Надир. Җырны да нотага салу зарур түгел. Музыкантлар өчен партитураны язарга кирәктер... Фәкать техник яктан кирәк ул. Ә җырның үзен кәгазьгә ничек кенә төгәл төшерергә маташма, барыбер җырчының интонациясен, сулышын язып куя алмыйсың.

Әсәд. Тынычландыңмы инде хәзер, кызым?

Сафия. Фальш җибәрүне акларга маташу түгелме соң бу?

Надир. Юк. Камил рәвештә тотрыклы тон була алмый.

Рәүфә *(чәй ясап)*. Шулай булгач, кызым, башыңны катырып утырма. Сине талантлы дигәннәр икән, зур җырчы булачагыңны әйткәннәр икән, ярдәм итүче иптәшең бар икән – җырла да җырла.

Сафия. Камил тон булмауны ничек аңларга? *(Чәй эчәләр.)*

Надир. Вибрация төп-төгәл булалмый. Колак ишетмәгән дәрәҗәдә барыбер як-якка тайпыла ул. Табигатьтә, гомумән, төгәл фиксация юк, булса да ул мизгелләр эчендә генә. Һава температурасын үлчәп әйтсәң дә, ул төп-төгәл булалмый. Төсләрнең чиген билгеләү мөмкин түгел. Салкын белән җылының арасы кайда – кем төгәл әйтә ала?

Рәүфә. Музыка бит башка нәрсә...

Әсәд. Рәүфә, ишекне майларга кирәк, шыгырдавының атасы-анасы юк ди, ноталары чалош-молыш икән. Надир энем, чыннан да шулай. Менә инде аңлашылган нәрсәләрдә дә җавап бирмәслек сораулар туа. Предметлар атомнарга, электроннарга бүленгәннән соң да бүленәләр бит, аннан да тирәнгәрәк бүленүләр дәвам итәдер, аны күрүгә генә ирешә алмыйбыздыр. Электричествоны «поток отрицательно заряженных частиц» дип аңлатабыз, ә ничек алар шундый тизлек белән, нинди көч тәэсирендә хәрәкәткә киләләр – беркем белми. Мин күптән түгел бер галимнән сорадым: мәйтәм, ялкынның молекуляр структурасын билгели аласыңмы? Бу уйга калды. Ялкын ул – плазма, ди. Мин әйтәм, мин аны син әйтмәсәң дә беләм. Ялкын материаль нәрсә – утын агачының кислород белән кушылу процессы булса да. Материаль булгач, аның молекуляр структурасын язып бир миңа. Ә ул аны беркайчан белмәячәк.

Рәүфә. Музыканың монда ни катнашы бар?

Надир. Әсәд абый әйберләрнең, төшенчәләрнең асылына барып җитә алмау турында әйтә ул.

Әсәд. Без сөйләшкән арада син, Рәүфә, бар ишекне майла әле.

Рәүфә. Артык тирән казынып, кирәгеннән артык аңларга тырышып, күңелгә шом гына керә түгелме?

Әсәд. Тирән казынучылар, неч-

кәлекләрне аңлаучылар цивилизацияне ясадылар.

Н а д и р . Әйе, цивилизация барлыкка килде. Әмма дөньяның асылын, аерым әйбернең нәрсә икәнлеген, кешенең үзенең кем икәнен аңлатучы юк. Музыкада да тавышны тоннарга чиксез бүлергә мөмкиндер, бәлки, әмма моңа ирешеп булмый, ирешкән сурәттә дә музыканың асылын аңлата алмаячак.

С а ф и я . Музыканың асылын аңлап булмыймы?

Н а д и р . Минемчә, юк. Күз яшенең химик составын аңлатып була, әмма аның асылына төшенү мөмкин түгел.

Р ә ү ф ә . Ничек инде?! Кайгыдан елау бар, шатлыктан елау бар, кино караганда, сентиментальлеккә бирелү бар.

Н а д и р . Бу – сәбәпләр, Рәүфә апа. Ә асылына төшенү мөмкин түгел.

Ә с ә д . Менә шушылай фәлсәфи темаларга сөйләшкәч, мин үзем эшләгән берләшмәгә дә икенче күзлектән карый башлыйм. Кайвакыт цехларыбызда сузылып-сузылып яткан пластик торбаларга карыйм да, бер генә уй килә: бөтен эшебез, бөтен гомеребез ниндидер бер торба буйлап әллә кая чыга да оча. Шуның белән вәссәлам. «Ни мәгънә?!» – дигән бер сорау эленеп тора баш миендә.

*Б ә х т и я р килеп керә, нык дулкынлана.*

Б ә х т и я р . Мин иртәрәк бушадым да килергә булдым. Студиягә бергә барырбыз.

С а ф и я . Бүген студиягә бармасам ярыймы?

Б ә х т и я р . Нишләп алай?

С а ф и я . Илһамым юк. Җыры да әллә нинди.

Б ә х т и я р . Ярар, иртәгә язылырсың. Пианино ничек?

Н а д и р . Тәртиптә.

Б ә х т и я р . Сафия төзеклегендә шикләнгән иде.

Н а д и р . Шикләнү ярый... чама белән.

Б ә х т и я р . Мин пианиноны көйле алуыңда шикләнәм.

Н а д и р . Мә, тюнер. Тикшер. *(Кесәсеннән тюнер чыгара.)*

С а ф и я . Пианино көйләнгән. *(Тюнерны ала, әйләндергәләп карый.)*

Н а д и р . Шунысы кызык: кешегә ышанмыйлар, тюнерга ышаналар. Кешегә ышанмыйча, кеше ясаган әйбергә ышану бар.

Ә с ә д . Әйе шул. Кешегә ышанмау, кешедән шикләнү – үзе дөрес булмаган кешеләргә хас. Мин, Бәхтияр, Сафия, хәзер әле сезне күздә тотып әйтмим. Мин җитәкчеләребезгә турысын әйткәч, урлау, алдау мисалларын китергәч, үземнән шикләнәләр, үземнән гаеп эзләргә маташалар.

Н а д и р . Кызык бу дөнья – кешеләр бөтен җирдә гармония табарга телиләр, тәртип эстиләр. Ә үзләренең кылган гамәлләре – гел диссонанс кына. Бөтен нәрсә структуралы булырга тиеш дип, кеше һәрнәрсәне тәртипкә китерергә, көйләргә тели. Әмма үзенең яшәеше – гел диссонанс.

Р ә ү ф ә . Кеше гармониягә омтылганда ялгыша, адаша кайвакыт...

Н а д и р . Ә бит гармония хакына җирдә күпме кан, күз яше. Күпме фаҗига туа.

С а ф и я . Ә музыкадагы гармония...

Н а д и р . Нәрсә ул музыкадагы гармония? Нәрсә ул матур көй? Синең фибраларыңа аваздаш, тәңгәл булганга гына матур ул. Аккордтагы берничә нота колакка ятышлы булып яңгырый икән, сезне кызыксындырмыймы – нишләп менә бу ноталар бергә аһәңләшә, башкалар түгел? Мәсәлән, нишләп «До мажор» аккордында «до», «ми», «соль» ноталары катнаша? Нишләп «Фа мажор»да «фа», «ля», «до» ноталары? Кем аңлатыр? Физикага төртелеп кала. Ә физика барыбер метафизикага барып тоташа.

С а ф и я . Абсолют төгәл җырлауга омтылу кирәкме икән соң алайса?

Н а д и р . Күңелеңдә фальш булмаса, ничек җырласаң да матур

яңгыраячак. Күңел халәте дә тотрыклы түгел, мизгел саен кыймылдый, үзгәрә. Бер үк җырны җырлаганда, төрле чакта төрлечә. Эчке кичерешне төп-төгәл итеп тасвирлау мөмкин түгел – әйткән сүз белән дә, көй белән дә. Синең уй-фикерең, хис-кичерешең башкаларга ишетелсә, ул инде фальш. Шуңа күрә, бер дә аптырама, Сафия, җырла гына.

Бәхтияр. Менә сез монда акыллы сүзләр белән гәпләшәсез. Ничек казынсаң да, җырчыны халык үзе сайлап ала. Халыкка нинди нотаның нишләгәне кызык түгел. Халыкка җырчы үзе кызык.

Надир. Продюсерлар кемне тәкъдим итә бит халыкка – бу заманда зур рольне шул уйный. Тәкъдим итүчеләрнең зәвыгы нинди бит.

Бәхтияр. Менә мин Сафияне күтәрергә маташам, нәрсә, шәп җырчы түгелмени?

Надир. Сүз бит башка нәрсә турында бара. Дөрес җырлап, төзек коралда уйнап, профессиональ, камил дәрәҗәдә концерт куелды ди... Аның тирәсендә күпме ямьсез ыгы-зыгы, күпме матавык, күпме пычрак башланышлар... Нәрсә кыйммәт – җандагы гармонияме, әллә ыгы-зыгы аша куелган бер концертмы?

Әсәд. Имәнгеч күренешләр һәркайда җитәрлек инде ул. Теге темага кайтасым килә. Менә син, Надир энем, тотрыксызлык турында әйткән идең. Әйе, нотаның үзен бер мизгелгә генә тотып буладыр, үтеп барышлый гына. Чөнки бу дөньяда барыбер бөтен нәрсә бер үк законнарга буйсына. Төн белән көн арасында сызык сызып аерып буламы? Бөтен нәрсә тирбәлеп, кыймылдап, хәрәкәтләнеп тора. Төсләр турында да дөрес әйттең. Баллы тәм кайчан башлана, тозлының башы кая? *(Көлеп куя.)* Шигырь килеп чыкты. Тотрыксызлык һәр нәрсәдә – правосудиедә, кеше белемен бәяләгәндә. Идеаль кешенең булмавы да мисал була ала. Тормыш үзе тотрыксыз тирбәлеп торган нәрсә, бернәрсә дә бер мизгелдән ары китми. Чөнки бүгенге син иртәгә инде башка кеше. Принциплар бер үктер, әмма синдә инде әллә нинди үзгәрешләр була. Шуңа күрә нота да гел бер урында кадалып тора торган нәрсә түгелдер.

Бәхтияр. Тюнерларны, камертоннарны тикмәгә уйлап чыгармаганнардыр бит.

Әсәд. Бәлки, шул ниндидер мизгелләрне тотып алыр өчен эшлидер аларны кеше.

Надир. Миңа калса, үлчәп була торган нәрсә – вак нәрсә. Үлчәрлек әйбернең кыйммәте зур түгел. Тасвирлап бирерлек нәрсә – пүчтәк. Көйләп була торган нәрсә әһәмиятле булалмый. Сатып ала торган әйбернең бәһасе юк. Сатып булмый торган, үлчәп булмый торган, аңлатып булмый торган, үз көеңә салып булмый торган нәрсәләр кыйммәтле бу дөньяда.

Бәхтияр. Алайса ник инструментларны көйләп йөрисең?

Надир. Тамагымны туйдырыр өчен. Ярый, сау булыгыз! Уңышлар сезгә!

*Надир чыгып китә.*

Әсәд *(сокланып)*. Мощный кеше бу!

Сафия. Мин фестивальдә катнашмыйм. *(Торып, табын янынннан китә.)*

Бәхтияр *(сискәнеп)*. Син нәрсә!

Рәүфә *(куркып)*. Кызым, тилердеңме әллә! Алда сине Мәскәү көтә, аннары чит илләргә чыгарсың.

Сафия. Алга таба күз күрер. Бәхтияр, мин студиягә бармыйм.

Бәхтияр. Ник?

Сафия. Бик примитив җыр бит ул. Барыбер беренче урынны миңа бирәчәкләр дип, андый затсыз җыр җырлыйсым килми.

## 3

*Шул ук күренеш. Бер атна вакыт узган. Рәүфә үзе генә. Бәхтияр килә.*

Бәхтияр. Исәнмесез. *(Еш-еш сулый.)*

Рәүфә. Исәнме, Бәхтияр. Уз әйдә.

Бәхтияр. Сафия тагын өйдә түгелме?

Рәүфә. Иптәш кызына кунакка киткән иде.

Бәхтияр *(бусарынып)*. Берничә көн инде Сафиянең телефоны җавап бирми. Студиягә йөрми. Әзерләнергә кирәк, репетицияләр аз булды. Фестивальдә катнашасы бар, киләчәк турында уйларга кирәк.

Рәүфә. Инде көн саен тукыйм мин аңа бу турыда. Баштарак эстрада йолдызы булам дип канатланып йөргән иде. Аңа әнә теге пианино көйләүче нык тәэсир итте. Сафия кеше сүзен йөрәгенә якын алучан. Соңгы вакытта настройщик әйткәннәрне торымнан-торымга кабатлап куя. Аның атасы да шул настройщик сүзләрен еш искә ала. Аннары икәүләшеп аның әйткәннәрен анализлап утыралар.

*Сафия кайтып керә.*

Бәхтияр *(хафаланып)*. Сафия! Мин сине югалттым. *(Рәүфә күрше бүлмәгә кереп китә.)* Шалтыратам, телефонын җавап бирми.

Сафия *(ваемсыз)*. Батарейкасы утырган.

Бәхтияр. Концертка күп калмады, вакыт аз...

Сафия. Мин, катнашмыйм, дидем бит инде.

Бәхтияр. Сафия! Син нәрсә! Шулхәтле акча вкладывать иткәннән соң...

Сафия. Син шундук акча турында әйтәсең.

Бәхтияр. Соң, акчаны җилгә очыру да ахмаклык. Нәрсә булды, нишләп шул арада үзгәрдең син?

Сафия. Мин тусовкалардагы фальшны ишетәм. Мин бу заман кешесе түгел, ахрысы. Ошамый миңа андый чуар ыгы-зыгы.

Бәхтияр. Син миңа карата да салкынайдың. Мин сине шушы берничә көн эчендә шундый сагындым. *(Кызның кулын тота.)*

Сафия *(кулын алып)*. Мин синең тирән яратуыңа шикләнәм.

Бәхтияр. Нишләп? Әле күптән түгел туй турында, ак күлмәкләр турында хыялланып йөрдең.

Сафия. Мин хәзер дә хыялланам.

Бәхтияр. Шулай булгач...

Сафия *(Бәхтиярның күзләренә карап)*. Ярата беләсеңме икән син?

Бәхтияр. Ни дигән сүз инде бу?

Сафия. Фестивальдә катнашачак җырчыларга мөнәсәбәтеңне күргәч, җырларны тыңлаганда үзеңне тотышыңа игътибар иткәч, миндә шундый сорау туа башлады.

Бәхтияр *(югалып кала)*. Аңламадым.

Сафия. Син – собственник. Милекче. Син талантлы кешеләрне үзеңнең мәнфәгатьләрең өчен үз астыңда тотарга телисең, җыр ятратканга түгел.

Бәхтияр. Нишләп әле мине җыр яратмый дип уйлыйсың?

Сафия *(читкә китеп)*. Әй, юк, аңлата алмыйм... Яратасыңдыр... Әмма җырны аңлап, җаны белән тоеп яратучы белән болай гына яратучы арасында аерма бар бит.

Бәхтияр *(авызын кыйшайтып)*. Мин аңлый башладым. Теге настройщик әйткән фикерне кабатлыйсың түгелме?

Сафия. Шулаймыни? *(Кинәт борыла.)* Без төрле дөнья кешеләре, Бәхтияр.

Бәхтияр *(Сафия янына атылып)*. Без бер үк дөнья кешеләре! Әллә ниләр уйлап, төпченеп, әллә ниләр чыгарма!

С а ф и я . Минем чын җыр дөньясында яшисем килә. Минем җырлыйсым килә.

Б ә х т и я р . Соң, мин шуның өчен тырышам түгелме?! Ярар, минем слухым юк ди. Ләкин мин әллә нинди слухлы кешеләр эшли алмаганны майтара алам. Син бит күрәсең, күпме җырчы, күпме композитор, шагыйрьләр, музыкантлар минем авызыма гына карап торалар, кайберләре колым булырга да әзерләр.

С а ф и я . Талантлы кешеләр арасында мескеннәре дә күп шул. Музыкаль слухлы булу музыкант булыр өчен генә кирәк түгел. Музыкаль кеше бөтен нәрсәне төптән аңлый. Ләкин, гадәттә, ялган, хәйлә дигән хисләрне аңламый. Дөресрәге, аңларга теләми. Һәм ул аңа хас түгел. Плюстырмы бу, минустырмы, белмим. Музыкаль слухлы кеше белән слухсыз кеше музыканы төрлечә тыңлый, төрлечә кабул итә. Дөньяны да, мәхәббәтне дә.

Б ә х т и я р *(көлемсерәп)*. Моны син кайсы китаптан укыдың әле?

С а ф и я . Соңгы көннәрдә шулай уйлый башладым. Мин сәхнәгә омтылып, танылган җырчы булырга теләп, бер сорауны үземә бирергә онытканмын.

Дан казанырга теләү кешедә нәрсәдән туа икән? Җитешсезлекләр комплексыннанмы? Дан-шөһрәткә сусаучы мин-минлегеме? Акча, байлык кирәктәнме? Бу турыда соңгы берничә көндә мин күп уйландым. Минемчә, данга омтылу – асылда мәхәббәт эстәү. Кеше үзен ратуларын тели.

Б ә х т и я р *(кызып-кызып)*. Мин сине бик яратам! Белсәң иде ничек ятратканымны! Сиңа нәрсә җитми? Ни кирәк? Мин синең өчен барысына да әзер. Минем бөтен нәрсәм бар, мөмкинлекләрем, акчам, дусларым, элемтәләрем... *(Карап тора.)* Музыкаль слухым юк дип әйтмәкче буласыңмы?

С а ф и я *(көлемсерәп)*. Син дә настройщик әйткән сүзне гел искә аласың. Сиңа да ул нык тәэсир иткән, ахрысы.

Б ә х т и я р . Слухым юклыкны ул әйтмәсә дә белә идем мин. Шуннан? Детонацияләр, диссонанслар, имеш... Тормыш үзе аңлап булмый торган шау-шулы, сезнең тел белән әйткәндә, дисгармония. Шул бака туена колак салып нечкәлекләрен ишетә башласаң, акылдан язарсың.

С а ф и я . Ә тирән ишетүче настройщикка шушы диссонанслы дөньяда яшәве ничек авырдыр, күз алдыңа китерәсеңме?

Б ә х т и я р . Белмим. Аның күңеле мине кызыксындырмый. Әйе, мин авазларны абсолют слухлы кешеләр кебек ишетмим. Минем күңелдә тәртип. Мин – уңышлы эшмәкәр. Һәрбер кеше нәрсәдә булса да, ничек тә чикләнгән. Ә менә артык нечкә тоючыларның, тирән казып төпченүчеләрнең күңелендә бардак. Чөнки андый кешеләр табигать куйган чикләрне инкарь итәргә маташалар, керергә ярамый торган тарафларга үтеп кермәкче булалар. Талантлы кешеләр шуңа күрә бәхетсез булалар да инде.

С а ф и я . Мине талантлы, диләр. Мин дә бәхетсез булырмын микән?

Б ә х т и я р . Мин сине талантың өстенә бәхетле итәчәкмен.

С а ф и я . Бәхетле булыр өчен күп вакыт кирәктер. Сабыр, түземле кешеләр бәхеткә ирешәдер. Тусовкаларда кайнап, конкурсларда беренче урынны алам дип тырмашып, көрәшеп бәхеткә ирешәләр микән? Бәхетле булырга сарыф ителәсе вакытны без кирәкмәгән утлы-балкышлы, арзан-кырын балкышлы ыгы-зыгыларга әрәм итмибез микән?

Б ә х т и я р . Вакытны да сатып алырга мөмкин. Һәрнәрсәне сатып алып була. Бәхетле булу – бәхетле булырга вакытың бар дигән сүз.

С а ф и я . Әгәр дә бәхеткә лаек булсаң...

Б э х т и я р. Лаеклы син, лаеклы. Син дә бәхеткә лаеклы булмасаң, нәрсә була инде ул!

С а ф и я. Бәлки, бәхеткә лаеклы булу үзе бәхеттер, мин генә тоймыймдыр, аңламыймдыр.

Б э х т и я р. Әлбәттә. Бик шәп әйттең. Син бәхетле, чөнки син бәхеткә лаеклы. Ләкин мин бәхеткә лаеклы, шуңа күрә мин инде бәхетле дип өйдә кул кушырып утыру да ярамый, бәхетнең башка берәүгә очып китүе ихтимал. Синең, Сафия, Бәхтиярың бар. Син шуны әле һаман акылың белән аңлап бетермисең. Янында мин булу – ул инде син уңышка ирештең, киләчәгең якты, бәхетле дигән сүз.

С а ф и я. Димәк, мине табигать биргән сәләтем бәхетле итә алмый, кемдер язмышымда катнашса гына, бәхеткә ирешәчәкмен?

Б э х т и я р. Нигә сиңа мондый сораулар? Кемнең берүзе генә бәхетле булганы бар?! Әйдә студиягә.

С а ф и я. Бармыйм.

Б э х т и я р. Ник?

С а ф и я. Барасым килми.

Б э х т и я р. Нишлисең килә?

С а ф и я. Үзем генә уйланып утырасым килә.

Б э х т и я р. Чиргә сабышасың бит уйланып. Иртәгә примеркага барырга кирәк, концерт күлмәгеңне иң яхшы тегүчеләр әзерләп ята.

С а ф и я. Андый кыйммәтле күлмәкләрне алдан ук киеп чыгу кирәк микән?

Б э х т и я р. Ә кайчан кияргә соң аны?

С а ф и я. Башта гади генә киемнән җырлап, халыкның мәхәббәтен яуларга кирәк. Аннары ялтыравыклы күлмәк кисәң дә ярый. Гомумән, җырлаучы ялтыравыклы киемнән булырга тиеш микән?

Б э х т и я р. Сафия, менә нәрсә... Син уйланып утыр, әмма озак түгел, яме. Мин иртәгә тегүчене күлмәгең белән монда үзем алып килермен. Киреләнүдән туктарга кирәк. Синең карьера ясыйсың бар. Популяр булмасаң, җырчы булуның ни кызыгы бар?

С а ф и я. Ә син каян беләсең: җырлаганда кеше нинди халәткә керә? Популяр булмаган кешенең җырлавы, бәлки, ихласрактыр...

Б э х т и я р *(ачуын көчкә тыеп)*. Ярый, иртәгә мин сиңа шалтыратырмын. Телефоныңны, зинһар, сүндермә. *(Чыгып китә.)*

*Сафия, моңаеп, пианино янына барып утыра, әкрен генә уйный. Р ә ү ф ә кайтып керә.*

Р ә ү ф ә. Кызым, син өйдәмени? Ательега, студиягә, тагын әллә кайларга барырга тиеш түгел идеңме соң син?

С а ф и я. Әйе.

Р ә ү ф ә. Нәрсә булды сиңа, кызым? Конкурска әзерләнергә тиеш бит син.

*Ә с ә д кайтып керә.*

Ә с ә д. Хәерле көн барчагызга да.

Р ә ү ф ә. Хәерле булса иде ул.

Ә с ә д. Хәерсез көн булмый. Кешеләр үзләре аны хәерле белән хәерсезгә бүләләр.

Р ә ү ф ә. Синең фәлсәфәң генә житмәгәние монда.

Ә с ә д. Предприятиедәге хәлләрне күргәч, философка әйләнми мөмкин түгел.

Р ә ү ф ә. Син гомер буе философ булдың. Шуңа күрә туйдылар синнән, шуңа читкә этәрәләр. Төпченүчене, казынучыны, күп күрүчене беркайчан коллектив үз итми.

Ә с ә д. Соңгы җөмләңдә хаклык ята. Башка җөмләләрең исә бернинди мәгънәгә ия түгел. Мин үзгәрмәдем. Кирәк дип тапмадым. Ә син яшәешкә ияреп үзгәрә башладың. Кызыңны, яхшы тәрбия биргәннән соң, «бозык» юлга кертмәкче буласың!

Р ә ү ф ә . Нинди бозык юлга? Кызымны йолдыз итеп күрү бозык юлга басумыни? Син завод директоры була торып та рәхәт яши алмадык. Синең башимәс булуың, күп күрүең, күп ишетүең аркасында. Кызымның йолдыз булуы иң зур хыялым минем хәзер.

Ә с ә д . Иң зур ялгышу – дөньяга бәхетле булырга, балда-майда йөзәр өчен килдем дип уйлау!

Р ә ү ф ә . Бәхетсез булып, мескен хәлдә яшәү рәхәтмени?

Ә с ә д . Рәхәтлекне, бәхетне нәрсәдә күрәсең бит.

Р ә ү ф ә . Тормышның вак-төяген күреп, юк-бар белән булашып яшәүче ул үзе дә бәхетле булалмый, башкаларны да бәхетле итә алмый.

Ә с ә д . Әйе, мин вакчыл кеше, әмма гаделлеккә хилафлык килгәндә генә кабына миндә вакчыллык. Минем артык нечкә анализлавым сине бәхетсез иттеме? Начар яшисеңме? Алга таба синең бәхетле булуың-булмавың кызыңның эстрада йолдызы булуга бәйле икән, мин сине котлыйм, сөекле хатыным – докатилась. Соңгы вакытта минем кимчелекләрне күп күрәсең. Бу вакчыллыкка кермиме? Мин эшемдә гадел, башимәс булдым, пүчтәк кешеләр белән көрәшеп узды күп вакытым, әмма гаиләдә мин андый булдым дип әйтеп булмый.

Р ә ү ф ә . Юк, гаиләдә син андый ук түгел, әмма эшеңдәге һәрвакыт өйгә кайтты. Синең күп күрүеңнән, күп белүеңнән, күп ишетүеңнән нинди файда булды – кешеләргә, гаиләңә, үзеңә?

Ә с ә д . Күп күрүчеләр, күп ишетүчеләр, күп аңлаучылар – һәрвакыт җайсыз булдылар. Шул җайсыз кешеләрне кемнәр яратмый – шуңа игътибар иткәч, мин үземнең кешелекнең затлы өлешенә керүемне аңлыйм.

Р ә ү ф ә . Нормаль кешеләргә яшәргә комачаулаучыларны яратмыйлар... Әнә, хәзер кызыңны игә китерә алмый җәфаланам әле.

Ә с ә д *(кыланыбрак)*. Кызым, балакаем, тәтием минем, нишләп киреләнәсең? *(Сафия көлә.)*

Р ә ү ф ә . Шаярып торма, кызың белән әйбәтләп сөйләш.

Ә с ә д . Кызым, нәрсә булды?

С а ф и я . Булмады. Минем конкурска әзерләнәсем бар! Сез миңа комачаулыйсыз.

Ә с ә д . Киттек, киттек. *(Әсәд белән Рәүфә күрше бүлмәгә кереп китәләр.)*

*Сафия пианинода уйный башлый. Туктап уйга бата. Атасының блокнотын алып, Надирның телефон номерын эзли. Телефонга карап тора. Пианино янына утырып тагын уйга кала. Аннары, сикереп торып, шкаф тартмасыннан келәшчә алып килә. Пианиноның капкачын ачып, бер кылны келәшчә белән кисеп өзә – кылның яңгырап өзелгәне ишетелә. Капкачны япкач, келәшчәне урынына илтеп куя һәм клавишларга басып карый. Берничә клавиш аваз чыгара, берсенә кат-кат баса – тавыш чыкмый.*

С а ф и я *(үзалдына)*. Дүртенче октавадагы «ля». *(Кычкыра.)* Әти!

Ә с ә д *(күрше бүлмәдән чыгып)*. Әү, кызым.

С а ф и я . Әти, теге настройщикны тагын чакыр! *(Рәүфә дә пәйда була.)*

Ә с ә д . Ник?

С а ф и я . Пианиноны рәтләсен.

Р ә ү ф ә . Ник, төзек, диде бит инде. Тюнер калдырды бит. Кая әле. *(Шкафтан тюнер алып килә, клавишларга баса.)* Менә бит – до, ре, ми, фа, соль, ля. Төзек бит, төзек. Мин кичә тикшереп карадым, төзек пианино.

Ә с ә д . Дөрес әйтте ул – күңелдәген көйләү авыр. Пианинода да түгел хикмәт, музыкада да түгел, ә үзегезнең башыгызда нәрсәнедер тарттырасы бар.

Р ә ү ф ә . Нишләп әле «сез», дисең? Кызың көйсезләнә бит, мин түгел.

Ә с ә д . Музыкага мәхәббәтне

исбатларга маташасың син. Алай булмый ул, алай фәтвасы юк аның. Дулкын булып, җил булып коендырып кына алырга тиеш ул. Ә шуның турында уйлап, инструмент төзеклегенә кадалып, имтихан турында уйлап, фестивальдә нинди күлмәк тектерим дип... Белмим, белмим.

С а ф и я . Әти, Надирны чакыр.

Ә с ә д . Инде ике тапкыр көйләде бит.

С а ф и я . Бер кылы өзелде. *(Клавишка баса, тавыш чыкмый.)* Менә, дүртенче октавада «ля» яңгырамый.

Р ә ү ф ә . Ул егеттән баштук шикләнгәнием мин.

Ә с ә д . Шулай каты тарттырды микәнни? *(Блокнотын актара.)* Надир... *(Телефон номерын җыя.)* Алло, Надир энем, бу Әсәд абыең әле. Нихәл? Минем өйдәгеләр көйсезләнә, көйләп киталмассың микән?! Пианиноның бер кылы өзелгән, диләр. Гаҗәп, дисеңме? Кайчан киләсең? Хәзер үк булса, бик әйбәт булыр иде. Кайсы кыл?.. Кызым, кылның кайсысы өзелде?

С а ф и я *(әтисеннән трубканы алып)*. Исәнмесез. Дүртенче октавадагы ля. Өзелергә тиеш булмаган, ә менә өзелде бит. Юк, клавишта түгел хикмәт, капкачны ачып карадым, кыл өзелгән. Ярар. Көтәбез. *(Телефонны сүндереп әтисенә бирә.)*

*Музыка.*
*П ә р д ә .*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### 1

*Шул ук күренеш. Ә с ә д белән Р ә ү ф ә чәй эчәргә утыралар.*

Р ә ү ф ә . Сафия студиягә дә йөрми башлады, Бәхтияр белән дә аралары әллә ничек, аңлап булмый.

Ә с ә д . Үзләре аңлашырлар.

Р ә ү ф ә . Бәхтияр күпме акча түгә, бүләкләр ташый, Сафиягә болай ук киреләнергә ярамый.

Ә с ә д . Акча түгә, бүләк ташый дип Сафия аның янында йөгереп йөрергә тиеш түгелдер бит. Сатып алып кына яраттыра алсаң иде икән ул.

Р ә ү ф ә . Бәтияр белән аның киләчәге якты, кайгысыз булачак.

Ә с ә д . Киләчәк ул байга да, ярлыга да бер битен, бер артын күрсәтә.

Р ә ү ф ә . Син Бәхтиярга ягымлы түгел, бәлки, шул да роль уйныйдыр.

Ә с ә д . Кызымны сәхнәгә чыгарыр өчен акча түгә дип, бүләк ташый, күлмәк тектерә дип, мин ул молокососка авызымны гел ерып торырга тиешме?

Р ә ү ф ә . Менә бит тагын ни дип утырасың. Нәрсәсе белән күңеленә хуш түгел соң ул, ә?

Ә с ә д . Бәхтияр безнең предприятиене үз кулларына алган маңкортларның берсен хәтерләтә. Бөтен кыланмышлары, сөйләшүе, кыяфәте умырыр өчен, башкаларны алдар өчен, баер өчен, башкалар өстеннән хакимлек итәргә йөрүче икәнен күрсәтә. Алар белән мин үз заводымда көрәшеп туйдым инде.

Р ә ү ф ә . Яңа буынны барыбер җиңә алмыйсың.

Ә с ә д . Бәлки шулайдыр. Мине шунысы гаҗәпләндерә: нишләп акчалы кеше аңламаган нәрсәне дә аңлыйм дип уйлый икән? Нишләп акчалы кеше бөтен җиргә тыгылып фикер әйтергә маташа икән? Нишләп акчалы кеше белмәсә дә беләм дип уйлый икән? Нишләп кешеләр өстеннән хакимлек итә алам дип уйлыйлар икән?

*Ишек кыңгыравы зеңгелди. Әсәд барып ишекне ача. Н а д и р керә.*

Н а д и р . Исәнмесез.

Ә с ә д . Исәнме, Надир. Шелтәләп каршы алмакчы идем, үзеңне күргәч, авыр сүз әйтергә тел әйләнми.

Н а д и р *(елмаеп)*. Нинди гаебем бар?

Р ә ү ф ә . Пианиноның кылы өзелде.

Н а д и р *(клавишларга басып)*. Дүртенче октавада мин бер кылны да тарттырмаган идем.

Р ә ү ф ә *(кырыс)*. Ник өзелде соң ул?

Н а д и р . Сузып тарттырылган нәрсә кайчан да бер өзелә инде ул. *(Пианиноның капкачын ачып карый.)* Чабып бара торган нәрсәнең кайчан да бер бәрелүе ихтимал. Суда агып барган нәрсә бата ала. Очып барган нәрсә җиргә барып төшәргә мөмкин.

Р ә ү ф ә *(читкә карап)*. Өебездәге философтан да туйган.

Ә с ә д *(Надирның эшен күзәтеп)*. Нишләп өзелде икән бу кыл?

Н а д и р . Материал арыган. Кыллар арасында иң беренче булып менә монысының чыдамлыгы беткән. *(Өзелгән кылны күрсәтә.)*

Ә с ә д . Миңа охшаган икән бу кыл. Хәер, мин өзелмәдем, сынмадым. *(Кинәт кайнарланып.)* Мине кистеләр, тартып өзделәр, йолкыдылар, кубардылар. Кырт иттереп кистеләр мине! Юк, миңа охшаган дип әйтеп булмый...

Н а д и р . Сезгә охшаган, сезгә. Сезне кискәннәр. *(Кылны яктыда карый.)* Бу кылны да кемдер кисеп өзгән. Менә, күрәсезме, келәшчә белән кискәннәр, ахрысы.

Ә с ә д *(күзләрен чекерәйтеп)*. Чыннан да... Кем эше икән бу?

Н а д и р . Кем эшедер, анысы миңа кагылмый, мин яңа кыл алып килдем, хәзер шуны тарттырып куярмын.

Ә с ә д . Сәер, бик сәер.

Н а д и р . Нәрсәсе сәер – кылның өзелүеме, әллә кылны өзүләреме?

Ә с ә д *(пауза тотып)*. Шуны уйлап куйдым әле. Кеше ясаган әйбер ватылмыйча, киреләнмичә тормый, әйеме. Шуңа күрәдер инде дөньяда бөтен нәрсә структуралаштырылган, системаланган.

Н а д и р . Ләкин системадагы һәрнәрсә каршы тора, ычкынырга тели, шулай түгелме?

Ә с ә д . Коллективта да шулай бит. Абсолют аһәңлек була алмый. Шуңа коллективтагы мөнәсәбәтләрдә фальш күп.

Н а д и р . Ул фальшлар да системадан котылырга теләүдән түгел микән?! Ә гаделлеккә омтылу системалашырга теләүдән түгелме соң? Парадокслар өстенә парадокс, Әсәд абый, ә!

Ә с ә д *(үз уйларында казынып)*. Система дип, астыртын гына шул системага каршы эшлиләр. Мин шуларга каршы көрәшәм.

Н а д и р . Бер акыл иясе әйтмешли, системага омтылу теләге намус аз булудан килә. Намуссызлар һәрвакыт системага омтылалар. «Воля к системе есть недостаток честности», – дигән ул.

Ә с ә д . Шәп әйттең! Ай шәп әйттең! Менә кем белән сөйләшәсем килә. Төгәл нотаны тотып булмаган кебек гаделлекне дә төгәл билгеләү мөмкин түгелдер, бәлки. Гаделлек тә кемдер өчен булса, шундук икенче берәү өчен гаделсезлек булырга мөмкин. Әллә, чынлап та, гомер буе казынып, юкка көчемне сарыф иткәнменме икән?

Н а д и р . Алай димәгез. Иң кечкенә масштабларга бүлеп, микрога үтәргә теләү – асылны аңларга тырышу.

Ә с ә д . Әмма аңлап булмый бит. Җиһан чиксез, микрокосмос та чиксез. Ләкин чиге бардыр дип ышанасы килә.

Н а д и р *(эшеннән туктап)*. Булды бу. Көйлисе генә калды. *(Куйган кылны тарттырып көйли. Клавишка баса, пианино яңгырый.)*

Ә с ә д . Күпме түлисе?

Н а д и р . Тәмле чәегез бармы?

Ә с ә д . Бар.

Н а д и р . Бер чынаяк каты чәй сездән.

Ә с ә д . Рәүфә! Чәй әзерлә, зинһар.

*Р ә ү ф ә чыгып чәй әзерли башлый. Күрше бүлмәдән С а ф и я чыга.*

С а ф и я . Исәнмесез.

Н а д и р . Исәнмесез. *(Елмая.)* Минем әле моңарчы бер үк пианино белән болай озак маташканым юк иде.

Ә с ә д . Мин фикеремне әйтеп бетермәдем. Җиһанның да чиге бардыр дип ышанасы килә. Чөнки чикле нәрсә генә гүзәл була ала. Һәрнәрсәнең чиге бар, шуңа аның матурлыгын күреп, тәмен татып була. Картина чиксез зур булса, аның шедевр икәнен аңлап булмас иде. Чәчәк тәмамланган чикләр белән матур итеп яратылган, әгәр дә чәчәк күз карашы тоталмаслык зур булса, аның матурлыгын күреп булмас иде. Әсәрнең азагы булмаса, ул әсәр булмый. Йорт, бакча – алар да чикле булса гына ямьле. Ниһаять, кеше гомере... Әгәр кеше мәңге яшәсә, аның гомере гомер булмас иде, кызыгы да, яшәвенең яме дә булмас иде.

*Ә с ә д белән Н а д и р чәй өстәле янына утыралар. Сафия әнисенә чәй әзерләргә булыша, аннары өстәл янына килеп утыра.*

Н а д и р . Килешмим. Күккә карагач, аның матур икәне күренә, гәрчә чиксез булса да. Мәңгелекнең дә чиге юк. Мин үзем үтеп барган, вакытлы, юкка чыга торган, мизгел эчендә генә яшәгән нәрсәләрне кабул итә алмыйм.

С а ф и я . Ә бит «проходящая нота»лар кайвакыт бик матур яңгырыйлар.

Н а д и р . Ә ул ноталар төгәл, конкрет ноталарны эзләп баручылар бит. *(Чәй эчәләр.)*

Ә с ә д . Син үзеңә үзең каршы килә торган кешегә охшагансың, Надир энем.

Н а д и р . Әйе. Шуңа күрә мин тормышымның бәхетле мизгелләрен тота алмыймдыр. Бәлки, тота алмаганга бәхетле түгелмендер. Мизгелне башка мизгел алыштыру мине куркуга сала. Миндә аңлатып булмаслык Вакыт чире бар. Мизгел белән хушлашуны авыр кичерәм. Кешеләр белән, әйберләр белән, төрле төбәкләр белән аерылышу, хушлашу миндә җан газабын тудыра. Мәңгелеккә сусау яши миндә. Мәңгелектән башка бернәрсәне дә ярату мөмкин түгел. Мәңгелек булмаса – берни булмый. Мизгел мәңгелеккә барып тоташса гына тулы була, мизгел вакыт өлеше түгел, мәңгелекнең өлеше булса гына мәгънәгә ия.

*Б ә х т и я р керә, тыңлап тора.*

Ә с ә д . Ахыр чиктән башка, тәмамлана торган формалар булмаса, бернәрсәнең дә яме булмас иде бит.

С а ф и я . Әйе, музыканың, җырның азагы булмаса, ул гүзәл җыр була алыр идеме? Аннары, сез яшәешнең күләгәле ягын гына күзәтүчегә охшагансыз.

Н а д и р . Бәлки, сез хаклыдыр, Сафия. Тормыш ул тирән трагизм белән сугарылган. Шуңа күрәдер мин классицизмны яратмыйм – камиллек чикләнгән нәрсәләрдә ята дигән иллюзиясе өчен. Камиллеккә чиксезлектә генә ирешергә мөмкин. Җырның гүзәллеген чиксез рәвештә арттырырга мөмкин. Камиллекнең чиге юк. Җырның көен үзгәртүнең чиге юк. Тоннарны чиксез рәвештә бүлергә мөмкин, аңа әле кеше ирешә генә алмый. Темпны чиксез арттырып, чиксез акрынайтып була.

С а ф и я . Ләкин кабул итәр өчен аның барыбер чиге кирәк бит.

Н а д и р . Чикләр куйгач, инде мәңгелек турында, абсолют камиллек турында да сөйләшмәскә кирәк.

Ә с ә д . Без төрле нәрсәләр турында сөйләшәбез шикелле...

Н а д и р . Чиксезлек һәм мәңгелеккә омтылышны тәмамланган камиллек иллюзиясе белән томаларга тырышалар. Ниндидер формага ирешү һәрвакыт чагыштырмача гына була ала. Формага керү ахыргача тәмамланган дигән сүз түгел. Бу дөньялыкта реальләшү фәкать мәңгелеккә һәм чиксезлеккә омтылуның символлары гына.

*Рәүфә Бәхтиярны абайлап йөгереп килә.*

Р ә ү ф ә *(абаланып)*. Бәхтияр! Исәнме. Бәхтияр килгән бит. Күрмисезмени?

Б ә х т и я р . Ишек бикле түгел иде, шуңа күрә кыңгырауга басып тормадым, кердем. *(Салкын елмаю белән.)* Комачауламадыммы?

Р ә ү ф ә . Ничек инде син комачауларга мөмкин?! Кил, утыр. Монда кызып-кызып сөйләшәләр, сине күрми дә торабыз.

Б ә х т и я р . Исәнме, Сафия. *(Табын янына килеп утыра.)*

С а ф и я . Исәнме.

Б ә х т и я р . Әңгәмәгез бик катлаулы шул. Ә бит бернәрсә дә мәңгелек түгел.

Ә с ә д . Әмма кайберәүләр мәңгегә килдем дигән сыман кыланып яшиләр.

Н а д и р . Мәңгелек ул Рух өчен кирәк. Матдилек вакытлыча нәрсәләргә табына. Чын ирешү – мәңгелеккә ирешү.

Ә с ә д . Шулаен шулай да... Тормыш, чынбарлык җиргә тартып төшерә шул. Кемнәргәдер ярап, яраклашып яшәргә туры килә.

Б ә х т и я р . Кешеләр белән эшләгәндә, шунсыз булмый. *(Әсәдкә көлемсерәп карый.)* Син – шәхси амбицияләреңне яшерми торган кеше... Яшерен-батырын түгел, завод директоры вазифасыннан сине шуның өчен азат иттеләр бит. Шундый кеше инде син... Агымга каршы көрәшүче – обречён. *(Чәй йотып куя.)*

Н а д и р *(Бәхтиярга усал караш ташлап)*. Әсәд абый, бу кемегез сезнең?

Ә с ә д . Сафиянең егете.

Н а д и р . Мин синең исемеңне онытам гел... Кем әле син?

Ә с ә д *(Бәхтиярның катып калуын күреп, үзе җавап бирә)*. Бәхтияр.

Н а д и р *(җикереп)*. Бәхтияр! Сафиянең егете булсаң да, синең олы кеше белән алай сөйләшергә хакың юк!

Б ә х т и я р *(усалланып)*. Ә син кем әле мине өйрәтергә?

Ә с ә д . *(Надир өчен җавап бирә)*. Бу минем кунагым, затлы кунагым – Надир. Бәхтияр, Надир, егетләр, зинһар, кызмагыз әле.

Б ә х т и я р . Мин бит авыр сүз әйтмәдем. Кешеләр ике төп төргә бүленә – беренче төр кешеләр дөньясы белән аһәңдәшлектә яши, икенче төре, музыкантлар термины белән әйткәндә, дисгармониядә яши. Есть два основоположных типа людей – тип, находящийся в гармоническом соотношении с мировой средой, и тип, находящийся в дисгармоническом соотношении.

Ә с ә д . Син хаклыдыр да бит... Ләкин нәҗес белән ничек гармониядә яшәргә мөмкин!

Б ә х т и я р *(көлеп)*. Син борчылма. Эшемнән алдылар дип кайнарланма, өзгәләнмә. Мин бар бит. *(Чырае кинәт җитдиләнә.)* Поддержу – и морально, и материально. Ким-хур итмәм. Акчага кытлык кичермәссез.

Ә с ә д *(Бәхтиярга ачулы караш белән карап)*. Ә мин синең ярдәмеңә мохтаҗ түгел. Мине цех нәчәлниге итеп куярга җыеналар. Мин анда эшләп тә яхшы хезмәт хакы алачакмын, директор кебек үк булмаса да.

Б ә х т и я р *(чәй йотып)*. Берүзең

көрәшеп бернишләп булмый. Ялгыз көрәшче нишли ала?

Н а д и р . Дөресен әйтә ала.

Б ә х т и я р . Ә каян беләсең син – нәрсә дөрес, нәрсә ялган?

Ә с ә д . Надир – башкалар ишетмәгәнне ишетүче кеше. Карап торуга гади генә кеше шикелле, әмма гаҗәпләнергә дә урын бар... Гомумән, башкалардан аермалы буларак, хакыйкатьне аңлаучылар да очрый дөньяда.

Б ә х т и я р . Үзең тудырмаган системада хакыйкать лозунгларын күтәрүдән ни мәгънә? Ирекле булам дип коллективыңа хилафлык килсә, әлбәттә, сине яратмаячаклар.

Ә с ә д . Ә бит тирәннән карасаң, ирекле булу – алдамаска, ялган сөйләмәскә хокуклы булу.

Б ә х т и я р . Ә кем әйтергә тиеш – кем хаклы, кем хаклы түгел? Менә бу настройщикның дөрес ишетүен кем билгели?

Ә с ә д . Аның дөрес ишетүе билгеләнгән инде.

Б ә х т и я р *(әле Әсәдкә, әле Надирга карап)*. Сез бик дуслашкансыз, ахрысы.

Ә с ә д . Әйе, безнең уртаклыклар күп булып чыкты.

Б ә х т и я р . Төпчелү, вакчыллану, иң кечкенә материяләрнең асылына төшенәм дип казынуны сезнең уртаклыгыгыз?

Н а д и р *(кинәт кызып)*. Син Сафиянең әтисе белән аның йортында ник алай дорфа сөйләшәсең, агач тел?!

Б ә х т и я р *(кыҗрап)*. Ә син миңа тавышыңны күтәрмә! Мин синең каян ничек чыкканыңны белештем. Синең анаңны урманда ташлап киткәннәр. Ул сукыр булган. Сине ул кемнән тапкандыр, билгеле түгел. Урманнан сезне авылга куганнар. Анаң үлгәч, сине асрамага алганнар... Ничек музыка өлкәсенә керә алгансыңдыр син...

Ә с ә д *(өнсез калып торганнан соң, Бәхтиярга нәфрәт белән карап)*. Ә синең ни хакың бар кешенең язмышында казынырга?!

Б ә х т и я р *(Рәүфәгә карап)*. Теләсә кемне йортыгызга кертмәсәгез, үзегезгә тынычрак булыр. Башкалар ишетмәгәнне ишетү, юк-барда казыну – бәлки, фаҗигале биография галәмәтедер?..

Ә с ә д . Миңа да төрттерден шикелле...

Б ә х т и я р . Юк, юк, сиңа түгел...

Ә с ә д *(усал елмаеп)*. Бәхтияр, ә бит синең беҗеклегең имәнгечрәк.

Р ә ү ф ә *(кычкырып диярлек)*. Әсәд!

Ә с ә д *(хатынына йодрык күрсәтеп)*. Тыныңны чыгарма! *(Бәхтиярга таба иеленкеери.)* Синең вакчыллыгың, Бәхтияр, сөйләп бетергесез. *(Кычкырып көлеп куя.)* Машинасына утыргач, җиде-сигез тапкыр замечание ясамый калмый. Вакчыл! Ботинкадагы карны, машинага утырганда, аякларны бер-берсенә кагып коярга кирәк икәнне миңа ярты сәгать аңлаттың син бер тапкыр. Машина ишеген каты япма дип теңкәгә тия. Утырмыйм мин синең машинага бүтән! Рәүфәнең исә күзе тонган – Бәхтияр кызымны кеше итәчәк, дөньяга танытачак, ди. *(Бармагы белән Бәхтиярга төртеп.)* Кызыңны моңа кияүгә бирсәң, бетте баш, ул синең кызыңның җелеген суырачак. Ул Сафияне берьюлы ике аягын бер-берсенә кактырып, шул ук вакытта ике кулын бер-берсенә чәбәкләттерәчәк!

С а ф и я *(кычкырып)*. Әти!

Ә с ә д . Син дә тик кенә утыр, кызым! Арада иң нык казынучысы син, кызым! Тик кенә утыр! Синнән дә шикчел, мнительный кеше юк! Ә анаңның беҗеклеген сөйләргә сүз генә җитмәс.

Б ә х т и я р *(каушап)*. Мин сиңа үпкәләмим. Чама белән вакчыллану ярый ул. Кешеләр һәрвакыт тәртипне тәртипсезлеккә караганда өстенрәк күрделәр. Кешенең табигатенә салынган инде ул...

Н а д и р . Сез – тәрипсезлектән файдаланып баючылар, хәзер инде, баегач, тәртип кирәк була башладымы?!

Б ә х т и я р *(теш араларыннан сытып)*. Син – «без роду и племени»! Монда кеше рәтендә утырган буласың!

Ә с ә д *(әкрен генә урыныннан күтәрелеп)*. Не смей Надирга андый сүз әйтергә! Мокыт!

Б ә х т и я р *(сикереп тора)*. Син нәрсә...

Ә с ә д *(ярсып)*. Пошёл вон!

Б ә х т и я р *(күзләрен акайтып)*. Нәрсә-ә-ә?!

Ә с ә д . Пошёл вон! Бәдбәхет! Спонсор, промоутор, бизнесмен! Калын кесәле маңкорт! Хайван!

Р ә ү ф ә *(ачыргаланып)*. Ул – Сафиягә шулхәтле ярдәм иткән кеше.

Ә с ә д . Моның ярдәменә мохтаҗ булырга язмасын. Якты күңелле кешенең генә ярдәме фәтвалы була! Ярлы кешенең юмартлыгы гына ихлас күңелдән булырга мөмкин! Пошёл вон! Зараза!

*Бәхтияр чыгып китә.*

Н а д и р *(торып)*. Минем гаебем булса, гафу итегез. Сау булыгыз. *(Чыгып китә. Рәүфә диванга капланып елый, Сафия йокы бүлмәсенә кереп кача. Әсәд, бар ишеген ачып, коньяк шешәсен ала, зур фужерга яртылаш салып, эчеп куя.)*

**2**

*Надир яши торган йорт. Иске шкаф, кыршылган өстәл, чалыш аяклы караватт, берничә урындык – өйдә башка җиһаз күренми. Н а д и р кемнеңдер кереп килгәнен сизеп сагая, тыңлап тора. С а ф и я керә.*

С а ф и я . Исәнме.

Н а д и р . Исәнме.

С а ф и я . Телефоның җавап бирми.

Н а д и р . Ә адресымны каян белдең?

С а ф и я . Әти тапкан. Үз йортың белән яшисең икән.

Н а д и р . Бу йортка йөз ел.

С а ф и я . Миңа менә шушындый иске йортлар ошый.

Н а д и р . Тиздән сүтәчәкләр инде. Бу җирләрне кемдер сатып алырга йөри.

С а ф и я . Бик борчылдык синең өчен.

Н а д и р . Ник?

С а ф и я . Әллә тагы... Менә... сине күрәсем килде.

Н а д и р . Мин бик шат сине күрүемә. Өем генә шыксыз... Бу вакытлыча... Бу тирәдәге агачлар, куаклар аз булса да мин туып-үскән мохитне хәтерләтә.

С а ф и я . Син чынлап та ятим үстеңме?

Н а д и р . Бу дөньяда ятим булу мөмкин түгел, хәтта теләсәң дә. Кызыл Чишмә районында сал агызу әртиленең урман хуҗалыгы бар иде. Шунда аш пешерүче апа пристаньнан тугыз айлык ташландык кыз бала алып кайта. Ире урман кискәндә өстенә агач авып харап булган, ике улы да сугыштан кайтмаганнар. Ана күңеле балага мохтаҗ булгандыр инде. Тора-бара кызның тумыштан сукыр икәне аңлашыла. Дөньяны авазлар аша гына таный, аңлый. Сукыр булса да, әнкәсенең олы ярдәмчесе булып үсә, ятьмә үрү эшен оста башкара. Әнкәсе чирли башлый һәм озакламый вафат була. Урманга агач алырга килгән егет белән бу сукыр кыз арасында мәхәббәт кабына. Аларның мәхәббәтеннән мин туганмын. Такта ярдырганда, әтиемнең күкрәгенә такта бәреп, ул бүлнистә үлә. Әнкәй аш пешерүчеләрнең ярдәмчесе булып, ятьмәләр үреп мине үстерде. Перестройка башлангач, урман хуҗалыгы

таркалды. Миңа җиде яшь тулганда, без әнкәй белән Кайнар Чишмәдәге ташландык йортка барып урнаштык. Әнкәемне күңеле гел урманга тартты. Мин аны җитәкләп урманга алып бара идем. Аның иртә вафат булуы да урманны сагынудан. Мин ун яшьтә идем ул вакытта. Җәен көтү көттем. Авыл кешеләре булдыра алганча ярдәм иттеләр, ач-ялангач булмадым. Мәктәптә укыдым. Гармунда, курайда уйнарга өйрәндем. Урта мәктәпкә каладан килеп йөрүче музыка укытучысын пианинода уйнап шаккатырдым. Мәктәптәге иске пианинода үземнең уйнарга өйрәнүем аны таң калдырды. Ул миңа ноталар буенча башлангыч белем бирде. Белемем шуның белән тәмам.

С а ф и я . Синең нечкә слух әнкәңнең авазлар ярдәмендә дөнья белән аралашуыннандыр да.

Н а д и р . Бәлки. Ул бит миңа үземне белә-белгәннән бирле урман авазларының һәр төсмерен төшендереп, авазның нәрсә тавышы икәнен, ник алай яңгыраганын аңлата иде. Үзе ул хәтта аяк астындагы коры ботаклар сынуыннан да кем адымнары икәнен аңлый иде.

С а ф и я . Ни өчен барлык кешеләргә алай тирән ишетү язмаган икән?

Н а д и р . Ходай барлык кешеләрнең газаплануын теләмидер.

С а ф и я . Яхшы ишетү бәхетсез итәмени кешене?

Н а д и р . Башка төрлерәк булсам, яшәү ямен башкачарак татыр идем шикелле. Мин шунысы белән үземне бәхетсез түгел дип әйтә алам: үзем булып калырга вакытым бар минем. Бит хәзерге заманда кешеләрнең бәхетле булырга гына вакытлары бар, үз-үзләре булырга вакытлары җитенкерәми.

С а ф и я . Шулай да дөньяны артык тирән аңлау чынлап бәхетсез итәдер кешене.

Н а д и р . Дөньяны аңлау – аңа лаеклы булу дигән сүз. Бу дөньяга лаеклы булу бәхетме, юкмы, кем белгән. Мин күп уйлыйм бу нәрсәләр хакында. Парадокс өстенә парадокс килеп ята. Дөньяга лаеклы булыр өчен, аны аңларга тырышырга кирәк. Ә дөньяны башка кешеләр арасында, җәмгыятьтә генә аңларга мөмкиндер. Кешеләр белән аралашкач, котылгысыз рәвештә индивидуализм баш күтәрә һәм кеше – үзенә үзе максат икәне аңлашыла башлый. Миллионнарны бәхетле итәргә маташып карадылар бит инде – әнә, нәрсә килеп чыга.

С а ф и я . Синең психологияң этиемнекенә охшаган. Үз-үзеңдә казыну, вак-төякне артыгыннан күп күрү кешене адаштыра, хаталанырга мәҗбүр итә түгелме?

Н а д и р . Син, бәлки, хаклыдыр. Әмма үз-үзеңне аңлар өчен дә, тормышта урыныңны барлар өчен дә казынмыйча булмый. Кеше, кирәкме-юкмы, гомере буе казына, төпченә, әмма барыбер ни дөньяның, ни үзенең асылына төшенә алмый. Ахырына кадәр үзеңне аңлау – үлү дигән сүз. Әллә кайларга кереп киттек. Син мине гафу ит инде... Бәхтиярга каты бәрелдем... Әсәд абыйдан да элләкте аңа... Минем аркада килеп чыкты.

С а ф и я . Юк, юк, синең бер гаебең дә юк. Мин Бәхтиярны яратам дип ялгышканмын. Укуымдагы уңышлар, аның затлы бүләкләре, алда нинди алкышлар, балкышлар буласы башымны әйләндерде. Ә кеше булачак... Безнең арада кичеп чыккысыз ара бар иде инде. Сине күрү белән минем күзләрем ачылды.

Н а д и р . Ә мин теге көнне сиңа юри әйттем...

С а ф и я . Нәрсәне юри әйттең?

Н а д и р . Романсны җырлаганда берничә нотаны төгәл алмадың, фальш җибәрдең дип.

С а ф и я . Ник?

Н а д и р . Сезнең өйдә бәйрәм иде. Минем күңелемдә бәйрәмнәргә каршы хисләр яши. *(Уйга калып.)* Әнкәйне күмгәндә, 8 март бәйрәме иде, шуңадыр. Шулай да Бәхтиярдан яхшы түгел...

С а ф и я . Син – нечкә, йомшак күңелле кеше, шуңа аны кызганасың. Ә ул кызганырлык кеше түгел. Синең кызгануыңа мохтаҗ түгел дип әйтмәкче булам. Калын тиреле кеше ул, күңеле җәрәхәтләнгәндер дип уйламыйм.

Н а д и р . Ә син каты бәгырьле кеше икән. Ялгышасың. Бәхтиярның да күңелендә йомшак урыннар бар. Аңа да җан газабы хас. Әмма башкача, мәсәлән, минекечә түгел, синекечә дә түгел, башка хисләр, башка сәбәпләр буенча. Бәхтияр бу дөньяның тетрәндергеч авазларын ишетми дисеңме әллә? Ишетә. Әмма мин ишеткән авазлар түгел ул. Син ишеткән авазлар да түгел. Башка төрле авазлардан тирбәлә аның күңеле.

С а ф и я . Ә сине иң нык тетрәндергән тавыш нинди?

Н а д и р . Ерактан ишетелгән балалар тавышында шулхәтле көчле фаҗига яңгырый. Бер игътибар белән тыңла әле. Ерактан яңгыраган бала-чага тавышында булачак кайгылар төсмере бар. Бәлки, алар анда бик кызык, көлкеле уен уйныйлардыр, ә шулай да ерактан килеп иңгәндә, бала-чага тавышында киләчәктә көткән һәлакәт, ярдәмгә, коткаруга мохтаҗлык авазлары яңгырый.

С а ф и я . Сиңа ничә яшь?

Н а д и р . Утыз.

С а ф и я . Гаиләң...

Н а д и р . Мин өйләнгән идем дияргә дә була. Дүрт елга якын язылышмыйча гына тордык.

С а ф и я . Балаларыгыз бармы?

Н а д и р . Юк. Миннән бала табарга теләмәде. Ул миңа ачыктан-ачык әйтте: сиңа охшаса, балабыз мәңге бәхетсез булачак, диде. Үзенең дә минем белән интегәсе килмәде.

С а ф и я . Син ярата идеңме аны?

Н а д и р . Әйе. Ул да мине башта ярата иде. Сәбәп минем тышка чыккан сәерлекләремдә дә түгел. Ул мине монда, Җирдә яратты, ә мин исә без аның белән Мәңгелек кочагында очрашырбыз дигән инану белән яраттым. Минем сөю белән аның сөюен бер үк үлчәү белән үлчәргә мөмкин түгел.

С а ф и я . Берсекөнгә әнкәйнең туган көне. Кил безгә. Тәмле әйберләр пешерәбез.

### 3

*Бәхтиярның офисы. Б ә х т и я р телефоннан булачак концертлар турында кем беләндер кызып-кызып сөйләшә. Ә с ә д керә.*

Б ә х т и я р *(телефоннан)*. Алло! Анда VIP-персоналар өчен ничә урын каралган? Тагын унны өстәргә кирәк. Күпме акча сорый? Бу җырчылар бөтенләй комсызландылар. Безнең фестивальдә катнаштырган өчен җырчылар үзләре түләргә тиешләр! Безгә иң мөһиме – Президентны гала-концертка ничек тә булса китертергә иде. Ярый, кич белән очрашабыз бит әле. *(Телефонын сүндерә.)*

Ә с ә д . Исәнме.

Б ә х т и я р . Тыңлыйм. *(Креслосында киерелеп, Әсәдкә карап утыра.)*

Ә с ә д . Пианиноны кире алмадың... Мин аны балалар бакчасына тапшырдым.

Б ә х т и я р . Шуны әйтергә килдеңме?

Ә с ә д . Дөресен әйткәндә, мин сиңа үтенеч белән килдем. Надирдан үч ала күрмә инде. Аның бер гаебе дә юк.

Б ә х т и я р . Нишләп әле мин ул мескеннән үч алып түбәнсеним ди.

Ә с ә д . Ул юкка чыкты. Телефоны җавап бирми. Өе бикле.

Б ә х т и я р . Бик талантлы кеше буларак, чит илгә китмәде микән?..

Ә с ә д . Мин әллә ниләр уйлап бетердем инде.

Б ә х т и я р . Юк белән башыңны катырма. *(Өстәлдәге кнопкага баса. Йомышчы егет керә.)* Теге йомранны алып кер әле монда. *(Йомышчы чыгып китә.)* Свидание биш минут. *(Көлә.)*

Н а д и р керә. Өс киеме алама. Кулында юеш чүпрәк, чалбар балакларын сызганган, яланаяк.

Ә с ә д *(шаккатып)*. Надир! Син монда нишлисең?

Н а д и р . Менә... эшлим.

Ә с ә д . Кем булып?

Б ә х т и я р . Кем дип... Төрле эштә.

Ә с ә д . Аңламадым?!. Сине мәҗбүри эшләтәләрме әллә?

Н а д и р . Юк.

Ә с ә д . Син... Бәхтияр! Син аны үзеңнең тоткының иттеңмени?

Б ә х т и я р . Юк. Ул үзе теләп миңа эшкә керде.

Ә с ә д . Надир! Ташла чүпрәкне! Бу синең эшең түгел!

Н а д и р . Күп калмады инде. Тагын бер атна гына эшлисем бар.

Ә с ә д . Ник син аңа хезмәт итәсең соң?

Н а д и р . Бүләк иткән пианиносының хакын чыгарганчы эшлим.

Ә с ә д . Безгә бүләк иткән пианино бәясен түлисеңмени?! Син түләргә тиеш түгел бит аны! Ник болай түбәнсенәсең?! Мин ул пианиноны, балалар бакчасыннан кире алып, монда китерәм.

Б ә х т и я р . Кылы өзелеп төзәтелгән пианиноны кире алмыйм.

Ә с ә д . Кылны Сафия өзде. Пианино хәзер төзек бит инде. Син килеп алып китмәгәч, балалар бакчасына бүләк иттек. Күпмегә алган идең ул пианиноны?

Б ә х т и я р . Дүрт йөз меңгә.

Ә с ә д . Мин алып киләм сиңа дүрт йөз мең! *(Чыгып китә.)*

Б ә х т и я р . Нишлисең әле хәзер?

Н а д и р . Кунаклар бүлмәсенең стенасын кырам.

Б ә х т и я р . Пуля сызгыруының нотасын бигели аласыңмы?

Н а д и р . Әгәр дә ул пуля сиңа дип оча икән, аның нотасын билгеләргә өлгермисең.

Б ә х т и я р . Шаярып кына сорыйм. Курыкма. Әйт әле, син алга таба да настройщик булып, үз тормышыңны көйли алмыйча яшәргә җыенасыңмы? Гомумән, гомерең газапта узгач, ультразвукны ишетү кирәк микән?

Н а д и р . Акустик пианино алучылар кими. Бәлки, озакламый настройщиклар да кирәк булмас.

Б ә х т и я р . Аннары нишлисең? Ачтан үлмәссеңме?

Н а д и р . Үлмәм. Тамагымны туйдырырлык кына һөнәрләрем тагын бар әле минем.

Б ә х т и я р . Синең әлегә ике һөнәрең бар. Берсе – инструмент көйләү. Икенчесе – инструмент көйләгән арада кеше тормышын көйсезләү, кеше арасын бозу.

Н а д и р . Син Сафиягә пианино бүләк итмәгән булсаң, мин Әсәд абый белән дә, Рәүфә апа белән дә, Сафия белән дә, синең белән дә очрашмаган булыр идем.

Б ә х т и я р . Карале, колагыңа берәр нәрсә булса... Мәсәлән, чирләпме анда... Колагың ишетми башласа, сиңа барыбер булачак бит – нинди аваз нинди нотада яңгырый, шулаймы?

Н а д и р . Ни дигән сүз инде бу? Мин ишетмәсәм дә, ул аваз барыбер яңгыраячак бит.

Б ә х т и я р . Димәк, синең кирәгең дә шуның хәтле генә булып чыга.

Н а д и р . Мин ишетмәгәннән син ишетә башламаячаксың бит.

Б ә х т и я р . Үзеңне миннән өстен итәр өчен, слухым юклыкны файдаландың сыман килеп чыкты...

Н а д и р . Кайчан? Ничек?

Б ә х т и я р . Башыңны җүләргә салма.

Н а д и р *(көлемсерәп)*. Син ул – слухың юклыкны сизмәүләреннән файдаланып яшисең.

Б ә х т и я р . Ярар, телеңә салынма. Бар, эшлә. *(Надир ишеккә таба юнәлә.)* Телефон гудогы нинди нотада диден әле?

Н а д и р *(туктап)*. «Ля бемоль».

Б ә х т и я р . Нишләп имынны «ля бемоль» соң ул?

Н а д и р . Кем белгән. Нишләп кайгы кара төстә соң?

Б ә х т и я р . Ә син кайгының төсен ничек күрәсең?

Н а д и р . «Ля бемоль»не ничек таныйсың дип сора син.

Б ә х т и я р . Бар, бар, мудрец, анаңны сатыйм. *(Надир чыгып китә.)* Ля бемоль, ля бемоль. *(Телефон номерын җыя.)* МТС? Бәлки, сез миңа әйтерсез – телефон гудогының нотасы нинди? Белмисезме? Сез дә белмисез икән. «Ля бемоль» икән аның нотасы. Әйе, беләм, ләкин ник менә нәкъ шул нота икән – шуны беләсем килә. Мин инде кемнән генә сорамадым. Беркем белми.

*Шул ук күренеш. С а ф и я  керә.*

Б ә х т и я р *(сикереп тора)*. Сафия, аппагым! Мин синең киләсеңне белдем! Мин сине шундый сагындым. Тынычландыңмы инде? Фестивальгә әзерләнәбезме? *(Килеп, кызны кочакламакчы була.)*

С а ф и я *(артка чигеп)*. Мин сиңа пианино өчен акча алып килдем.

Б ә х т и я р *(җитдиләнеп)*. Ничек курыкмадың үзең генә килергә?

С а ф и я . Нишләп әле мин куркырга тиеш?

Б ә х т и я р . Ә мин беләм ник курыкмаганыңны.

С а ф и я . Ник?

Б ә х т и я р . Чөнки сине өзелеп яратканымны беләсең. Мин яратам сине!

С а ф и я *(бер кап акчаны өстәлгә куеп)*. Менә, монда төгәл дүрт йөз мең. Җибәр Надирны.

Б ә х т и я р . Ә-ә-ә, син Надирны коткарырга килдеңмени?

С а ф и я . Надирга эшләгәне өчен түләрсең дип ышанам. Шушылай түбән төшәргә оят түгелме? Син бит Надирны, мине түбәнсетмисең, син үзеңне пычрак ягыңнан күрсәтәсең.

Б ә х т и я р . Ай-яй рәхмәтсез кеше син. Мин сине барыбер яратам. Ә Надир үзе теләп миңа хезмәт итәргә тотынды.

С а ф и я . Ялган!

Б ә х т и я р . Акустик пианино алучы аз хәзер. Настройщикларның кирәге шуның кадәр генә. Ә аңа ашарга, яшәргә кирәк. Менә, миңа ялланды.

С а ф и я . Алдыйсың. Син мине борчымасын дип пианино хакын түләргә алынган ул. Синең алда минем бурычым калмасын дип, сиңа хезмәткә кергән.

Б ә х т и я р . Каян беләсең?

С а ф и я . Сизәм.

Б ә х т и я р . Шулай олы җанлы кеше дип уйлыйсыңмы аны?

С а ф и я . Кая ул? Минем аны күрәсем килә.

Б ә х т и я р *(кнопкага басып)*. Теге «Ля бемоль»не алып керегез әле.

*Надирны алып керәләр. Н а д и р пычрак киемнән, аягында күнитек, башында иске бүрек.*

Б ә х т и я р . Нишлисең әле?

Н а д и р . Кунак бүлмәсенең стенасын штукатуркалыйм.

С а ф и я *(тетрәнеп)*. Надир, синме бу?

Н а д и р *(тыныч, әмма боек)*. Исәнме, Сафия.

С а ф и я . Син монда нишлисең?

Б ә х т и я р . Әйт, әйт, дөресен әйт.

Н а д и р . Гаебемне танып, үзем хезмәт итәм. Сине, әтиеңне борчымасыннар өчен.

С а ф и я . Синең беркем алдында гаебең юк, бурычың да юк.

Н а д и р *(Бәхтиярга)*. Тагын бер тапкыр гафу ит мине. *(Сафиягә.)* Син дә гафу ит, Сафия.

С а ф и я *(кычкырып)*. Надир!

Б ә х т и я р *(елмаеп)*. Аның гаебе тагын ике миллионлык әле.

С а ф и я . Аңламадым.

Б ә х т и я р . Монда эшләп пианино хакын түли дә аннары ике миллионлык хезмәт итәчәк әле.

С а ф и я . Нинди ике миллионлык тагын?

Б ә х т и я р . Фестивальгә әзерләнәбез дип, дискыңны чыгарабыз дип, күлмәкләр тектерәбез дип, мин ике миллион расход тоттым. Бар, Надир, эшли тор. Менә бу дүр йөз меңне алып features аткач, миллион да алты йөз мең бурычың кала. *(Надир чыгып китә.)*

С а ф и я . Син аны мескен хәлдә калдырырга телисең. Үчне ник аңардан аласың соң син? Ник миннән түгел?

Б ә х т и я р . Ә мин сине яратам. Әле һаман минеке булырсың дип өметләнәм.

С а ф и я . Син кеше түгел!

Б ә х т и я р . Ә ул кешеме? Күрдеңме кыяфәтен? Күрдеңме күз карашын? Ник яши ул бу дөньяда? Аның ишеләр – дөнья бутаучылар! Шунысына аптырыйм: ничек шундый мескен кешеләр башкаларга комачаулый алалар?! Ул бу дөньяда яшәргә тиеш түгел. Ә син... синең кебекләр... Сез барыбер бездән ярдәм сорап киләчәксез! Бездән башка хәерчелеккә кереп батачаксыз!

С а ф и я . Менә, үзең ачыктан-ачык күрсәттең кем икәнеңне, нәрсә икәнеңне. Бик тә вакытында очрады безгә настройщик. *(Чыгып китә.)*

Б ә х т и я р *(кычкырып)*. Сафия! Сафия! Тукта!

**4**

*Надирның йорты. Анда бөтен нәрсәнең асты өскә килгән – ватып-җимереп яңадан төзекләндерү эшләре бара. Ә с ә д керә. Як-ягына карана. Эшчеләрне җентекләп күзәтә. Әрле-бирле йөри.*

Ә с ә д . Надир! *(Аңа Эшчеләр игътибар итмиләр.)* Надир! (*Бер Эшчегә мөрәҗәгать итә)*. Надир кая?

Э ш ч е . Хыту иты?

Ә с ә д . Надир – хозяин дома. Где он?

Э ш ч е . Ни знай.

Ә с ә д *(кычкырып)*. Надир! Бу йортның хуҗасы кая?

*Б ә х т и я р пәйда була.*

Б ә х т и я р . Монда мин. *(Елмая.)*

Ә с ә д *(сискәнеп)*. Бу – Надирның йорты. Син нишлисең монда?

Б ә х т и я р . Бу йортны ул миңа бүләк итте. Иҗат йорты ясыйм мин монда. Урыны шәп.

Ә с ә д . Нишләп сиңа йортын бүләк итсен ул?

Б ә х т и я р . Миңа ике ай эшләде, аннары йортын миңа бирде – шулай итеп, сезнең белән мин расчёт ясадым. Ә аның белән әле тулы расчёт ясыйсы бар.

Ә с ә д . Син һаман аны бимазалыйсың... Аның гаебе юк.

Б ә х т и я р *(тешләрен кысып)*. Мин яратам Сафияне! Ишетәсеңме, яратам!

Ә с ә д *(кайнарланып)*. Сафия беркайчан да синеке булмаячак! Сиңа берәр чара табалмам дисеңме әллә?

Б ә х т и я р . Минем закон бозганым юк.

Ә с ә д . Надир кайда?

Б ә х т и я р *(кычкырып)*. Надир!

*Тузанлы томан эченнән*
*Н а д и р пәйда була. Як-ягында*
*тыгыз гәүдәле ике егет басып тора.*

Ә с ә д *(шаккатып)*. Нишләдең син, Надир?!

Н а д и р *(тыныч кына)*. Гафу итегез мине. Минем аркада боларның аралары бозылды, ыгы-зыгы купты.

Ә с ә д . Болай ярамый, Надир. Барлык гаепләрне үз өстеңә ала башласаң... Каршы торырга кирәк, көрәшергә, сугышырга! Хәзер кая барасың?

Н а д и р . Авылга кайтып китәм. Андагы иске йортыбыз әле яшәрлек, диделәр. Кеше үзенең гаеп-хаталары өчен җавап тотарга тиеш. Бәхтияр белән мин расчёт ясадым. Ул сезгә акча сорап килмәс – мин тулысынча түләдем. Үз теләгем белән. Мине беркем дә мәҗбүриләмәде.

Ә с ә д *(ярсып)*. Нишләдең син, энекәш! *(Чыгып китә.)*

*Бәхтияр томан эчендә югала. Берничә кеше тимердән эшләнгән өстәл этеп китерәләр. Надирның кулларын артка каералар, авызын скотч белән томалыйлар. Берәү тиз генә Надирның беләгенә укол кадый. Надир шундук йокыга китә. Кинәт ут сүнә. «Шайтан алгыры! Ут сүнде!» – дигән тавыш ишетелә. Фонарь кабызалар. Фонарь яктысында шешәдән Надирның колагына кабалана-кабалана ниндидер сыекча салалар. «Күренми! Кырыйга түгәсең бит! Колагына сал», – дигән сүзләр ишетелә. Караңгылык. Шомлы музыка.*

**5**

*Сырхауханә. Палата.* Н а д и р *тәрәзәдән тышка карап тора. Буй-буй төстәге киемнән.* С а ф и я *керә – иңенә ак халат элгән, кулында ризык тутырук пакет. Надир аны күрми, һаман тәрәзәдән карап тора. Сафия эндәшә: «Надир!» Надир ишетми. Сафия кат-кат эндәшеп карый: «Надир! Надир! Надир!» Надир ишетми. Сафия, аптырагач, барып аның иңенә кагыла. Надир әкрен генә борыла һәм кызга елмая. Надирның ике якта да колак тирәләре җөйләнеп тора.*

С а ф и я *(моңсу елмаеп)*. Исәнме, Надир! Син бөтенләй ишетмисең икән.

Н а д и р *(сәер, каты тавыш белән)*. Исәнме, Сафия!

С а ф и я . Таптым бит сине, таптым. *(Елый.)*

Н а д и р *(бармагы белән Сафиянең күз яшенә кагылып)*. Ник елыйсың?

С а ф и я . Сине тапкан шатлыктан. Син ишетмисең... Мин врачлар белән сөйләштем... Кислота аз гына кергән колак эченә. Алар караңгыда туры китерә алмаганнар. Син ишетәчәксең, син, һичшиксез, ишетә башлаячаксың! Дәваланырга гына кирәк. *(Колак янындагы җөйләргә кул арты белән кагыла.)* Авыртамы?

Н а д и р *(каты тавыш белән)*. Син әтиеңә охшагансың, Әсәд абыйга. Атасына охшаган кыз бәхетле була ди. *(Елмая.)*

С а ф и я . Мин сиңа тәмле әйберләр алып килдем. *(Пакетларны караватка куя.)*

Н а д и р . Яңа пианино алмадыгызмы әле?

С а ф и я *(кычкырып)*. Алабыз, Надир, алабыз! Синең колакларың төзәлгәнне көтәбез. Пианиноны синең белән бергә алырбыз. Син аны көйләрсең. Ул иң дөрес яңгырый торган пианино булачак!

*П ә р д ә .*

# ТҮБӘН КАМА – ТУГАН ЙОРТЫБЫЗ



Туган йортың кайда булса, шунда гына җылы һәм рәхәт. Чөнки монда – йөрәккә якын кешеләр, кадерле дуслар, һәм аларның һәрвакыт күңелдә үз урыннары, түрләре бар. Бу – безнең гаилә, игелекле һәм уңайлы тыныч тукталыш. Быел үзенең ярты гасырлык юбилеен билгеләп үтүче, чагыштырмача яшь һәм күңелгә якын Түбән Кама күпләр өчен әнә шундый ватанга әверелде...

1966 елның 22 сентябрендә РСФСР Югары Советы Президиумы Указы белән Түбән Камага шәһәр статусы бирелде.


Гигантлар нәрсәдән башлана? Чирәм җирләрдән. Тагын – шушы җирләрне үзләштерүче кешеләрдән. Түбән Кама белән дә нәкъ шулай булды, бирегә үзләренең палаткаларда, баракларда яшәячәкләрен белеп торган беренче төзүчеләр килде. Әмма алар, бөтен кыенлыкларның вакытлыча икәненә нык ышанып, яңа тормыш башладылар, ә алда – алар төзиячәк куәтле җитештерү комбинаты һәм Татарстанда яшәүче күпләрнең хыялы булган гүзәл шәһәр иде. Хәзер алар барысы да яхшы, уңайлы йортларда яши. Әмма үзләренең беренче кечкенә бүлмәләрен, андагы чуен буржуйканы, агачтан ашыгыч кына әтмәлләп куйган өстәлләрен күпләргә аңлашылмаган җылы бер моң, сагыну белән искә төшерәләр...

Вакыт вак детальләрне аяусыз рәвештә җуя, ләкин бу кадәр киң күләмле киләчәкне берәү дә күз алдына да китермәгән чакта башланган беренче эш көннәренең хатирәләрен әлегәчә саклый...

Ә барысы да алардан – беренче төзүчеләрдән һәм төзелеш индустриясе базасын үстерүдән башлана бит. Ул чакта күп эшләрне кулдан башкарырга туры килә. Әмма барысы да зур дәрт белән эшли, чөнки булачак химия комбинаты продукциясенең төзелеп килүче шәһәргә дә, сәнәгать объектларына да һава кебек кирәк булачагын аңлыйлар. Түбән Кама объектларында республиканың күпсанлы төзелеш оешмаларыннан килгән төзүчеләр һәм монтажчылар эшли, һәм бу эш бик зур кыенлыклар белән бара. Эре сәнәгать үзәкләреннән еракта булу да үзен сиздерә, күп очракта, Камада навигация башланганчы, төзелеш үзен тиешле материаллар белән тәэмин итүчеләрдән киселеп тора диярлек, электр белән тәэмин итү челтәре дә көйләнмәгән.

Ниһаять, беренче җиңүгә ирешелә – 1967 елның 31 июлендә Түбән Кама химия комбинаты сафка бастырыла һәм әзер продукция чыгара башлый. Төзүчеләр эстафетасы куллanучыларга тапшырыла. Ә Түбән Кама комплексы сафка басуга, ил каучук җитештерү өчен кирәкле чимал белән тиешле күләмдә тәэмин ителә башлый. Шуның белән безнең республика Советлар Союзын каучукны чит илләрдән «челтерәп торган» валютага зур күләмдә сатып алудан коткара. Игътибар итегез, Татарстандагы бер зур комплекс ил өчен шундый зур могҗиза тудыра! Мондый хәлнең дөньяда һәм дөнья практикасында әле беркайчан да күрелгәне булмый һәм хәзер дә булганы юк.

Ул еллардагы хәбәрләр (хроника) Түбән Кама өчен генә түгел, ил өчен мөһим вакыйгалар белән тулып тора. Болар – дистәләрчә җитештерү объектларын төзү



УКАЗ
ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА РСФСР

203. О преобразовании рабочего поселка Нижнекамского Нижнекамского района Татарской АССР в город Нижнекамск республиканского (АССР) подчинения

Утвердить произведенное постановлением Президиума Верховного Совета Татарской АССР преобразование рабочего поселка Нижнекамского Нижнекамского района в город республиканского (АССР) подчинения с присвоением ему наименования - город Нижнекамск.

Заместитель Председателя Президиума
Верховного Совета РСФСР

За Секретаря Член Президиума
Верховного Совета РСФСР

Москва, 22 сентября 1966 года
д. № 731/10

12376н

һәм сафка бастыру. Изопрен каучук җитештерү объектын кору – Түбән Кама тарихындагы иң якты сәхифәләрнең берсе.

1967 елның башы тагын бер мөһим объектны – җылылык-электр үзәген (ТЭЦ) сафка кую һәм Түбән Камада шиннар җитештерү төзелешен башлап җибәрү белән билгеле.

Бу чор вакыйгаларына бәя биргәндә, төзелеш һәм монтаж мәйданчыкларында хакимлек иткән иҗади рух һәм энтузиазм атмосферасын билгеләп үтми булмый. Барысы да армый-талмый эшли, мәгълүм бер җырдагы: «Беләм, монда шәһәр булыр, беләм, гөлләр чәчәк атар», – дигән юллар күңелләрендә чакыру булып яңгырый.

Беренче объектларны төзү барышында төзүчеләрнең данлы хезмәт коллективлары оеша, аларның куллары белән шәһәр төзелә, химия комбинатының беренче төп көче сафка бастырыла. Хәзер Түбән Кама муниципаль районының төзелеш тармагында 311 оешма һәм 166 шәхси эшкуар гамәлгә куелган. Бу өлкәдә эшләүчеләрнең саны 17 меңгә якын.

50 ел эчендә Түбән Кама эре икътисади, сәнәгый үзәккә әверелде. Түбән Кама муниципаль районының икътисады – Татарстан Республикасындагы җитештерү куәтенең һәм җитештерелгән тулай продукция күләменең 23%ыннан артыграк санны тәшкил итә. Монда сүз беренче чиратта нефтехимия һәм нефть эшкәртү сәнәгате турында бара. Кичәге химия комбинаты, ә бүген «Түбән Кама нефтехим» иҗтимагый акционерлык җәмгыяте – илдәге синтетик каучук, пластиклар һәм этилен җитештерүчеләр арасында әйдәп баручы. Алар җитештерә торган продукциянең ассортименты Европа, Америка һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиянең 50 иленә, Төркиягә экспортлана торган 120 төрне үз эченә ала.

Түбән Кама шин комплексы да Россия Федерациясе һәм БДБ илләрендәге шин җитештерүчеләр арасында сәнәгатьнең эре предприятиесе.

Бүген Түбән Камада тагын бер зур төзелеш башланды, күләме буенча аны узган гасырның 60нчы елларындагы химия комбинаты төзелеше белән чагыштырырга мөмкин.

Татарстан икътисады үсеше өчен стратегик мәгънәгә ия булган һәм 2015 елда үзенең 10 еллыгын билгеләп үткән «ТАНЕКО» нефтехимия нефть эшкәртү заводлары комплексын төзүгә «Гасыр төзелеше» дигән исем бирелде. Бүген монда нефтьне тирәнтен эшкәртү заводын төзү дәвам итә.




Татарстан Республикасының нефть эшкәртү тармагында әйдәп баручы позицияләрне Түбән Каманың тагын бер куәтле гиганты – яңа буын комплексы, илнең заманча инновацион мәйданы – «ТАИФ-НК» били, ул нефть эшкәртү, бензин заводларын һәм газ конденсатын эшкәртү производствосын берләштерә.



*Бүгенге Түбән Кама шәһәренең бер күренеше.*

Бүген монда тагын бер яңа стратегик төзелеш – авыр калдыкларны тирән эшкәртү комплексы төзелеше алып барыла. Анда бөтен эш яңа технологияләргә нигезләнә, Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсеш программасын тормышка ашыруга һәм илнең НЭЗ (нефть эшкәртү заводларын) модернизацияләү программасын үтәүгә хезмәт итә. Җитештерү калдыксыз диярлек алып барылачак, ә нефтьне эшкәртү тирәнлеге 98,5% тәшкил итәчәк.

Шәһәрнең «Түбән Кама Нефтехим», «Татнефть-Нефтехим», «ТАИФ-НК», «ТАНЕКО» предприятиеләре ел саен җитештергән продукция күләме буенча Түбән Кама Россиянең шактый төбәкләреннән алда бара. Россиянең гомуми нефть продукциясе күләмендә республикабыз предприятиеләренең өлеше түбәндәге саннарны тәшкил итә: 78% плистирол, 50% полиэтилен, 44% синтетик каучук, 29% автомобиль шиннары.

ТР муниципаль берәмлекләре арасында Түбән Кама төп капиталга инвестицияләр җәлеп итү һәм үзе җитештергән товарларны чыгару-озату буенча 2 нче урынны били.

Түбән Кама муниципаль районы – Татарстан Республикасындагы һәм Россия Федерациясендәге аеруча динамик үсүче төбәкләрнең берсе. Куәтле сәнәгать потенциалына, шулай ук бай кешеләр капиталына ия буларак һәм Республика Хөкүмәтенең акыллы сәясәте ярдәмендә, район икътисади-мөһим күрсәткечләрнең тотрыклы үсеш темпларына ирешә. Эре сәнәгать предприятиеләренең урта һәм кече эшмәкәрлек үсеше, югары тормыш дәрәҗәсе Түбән Каманы инвесторлар өчен кызыклы итә.


Болар барысы да зур тизлек белән үз потенциалыбызны үстерергә, эчке инфраструктурабызны үзгәртеп корырга мөмкинлек бирә. Түбән Камада тормыш уңайлы һәм кызыклы булсын өчен, инде шактый эш башкарылган. Яңа микрорайоннар, социаль инфраструктура объектлары торгызыла, сыйфатлы юллар сузыла, шәһәрне киңкүләм яхшырту программалары тормышка ашырыла. Үсеше ягыннан Түбән Кама Россиянең бик күп шәһәрләреннән алда тора.

Бүген Түбән Кама муниципаль районы территориясендә ел саен 130 мең квадрат метр торак кулланугa тапшырыла. Бу – республикада дүртенче күрсәткеч.



*Тынычлык проспекты.*

Ярты гасыр эчендә Түбән Кама күпкә баерак тарихлы шәһәрләр дә ирешә алмаган гаҗәеп уңышларга ирешге. Бүген ул – бөтен Татарстанның икътисади плацдармы, «үсеш ноктасы» гына түгел, ә бәлки «Россия һәм Татарстанның иң төзек шәһәре», «Идел буеның мәдәни башкаласы» да... Түбән Кама үсә һәм ныгый, нәкъ менә 60нчы елларда безнең җиргә илнең төрле почмакларыннан килеп, биредә яшәгән һәр кеше өчен иң яхшы һәм



*Россиядә җитештерелгән һәр өч шина Түбән Камада чыга.*

кадерле булачак шәһәр төзергә алынганнарның хыялында туган калага әверелә бара!

Түбән Каманың данлы биографиясен исемнәре шәһәр тарихыннан аерылгысыз кешеләр төзегән. Мәсәлән, 1960 елның декабреннән химия заводының беренче директоры, 34 яшьлек Иван Алексеевич Санников үз вазифаларын үтәргә керешә. Ул эшли башлаганда, сәнәгать комплексы торгызылырга тиешле урында агачлар үсеп утыра һәм чиксез колхоз кырлары гына җәйрәп ята. Әмма Иван Алексеевич барлык хыялларның тормышка ашачагын аңлый һәм булачак гигант-заводны күзалдына да китерә.

1963 елның март аенда аны талантлы оештыручы Николай Васильевич Лемаев алыштыра, шәһәр һәм нефтехимия комбинаты төзелешенең төп этабы аның исеме белән бәйле. Ул 1985-1989 елларда СССР нефть эшкәртү һәм нефть химиясе сәнәгате министрлыгына, 1989-1990 елларда СССР химия һәм нефть эшкәртү сәнәгате министрлыгына җитәкчелек итә. Социалистик Хезмәт Герое.

Түбән Кама төзелешенең иң кызу чорында, 1963 елда, биредә 7 төзелеш-монтаж идарәсен берләштергән «Татэнергострой» тресты оештырыла. Бу «гадәти булмаган» хуҗалыкка Евгений Никифорович Королёв җитәкчелек итә, Түбән Камага нигез салучыларның берсе булган бу шәхес аңа гомеренең 40 елын багышлый. Аның исәбендә болай да үзе төзегән берничә шәһәр бар. Яшьлегендә ул Новосибирскидагы авыр машиналар төзү предприятиесе төзелешендә катнашкан. Аннары – Амурдагы Комсомольск, Калинин, Вышний Волочек, Торжок, Бежица, Енисейск һәм Түбән Кама шәһәрләре.

Кәрим Хәмидулла улы Вәлиуллин, Максим Николаевич Адылев, Николай Александрович Зеленов, Василий Игнатьевич Суздальцев, Фатих Миңнебай улы Хәйбуллин, Нәкый Шәйхетдин улы Әхмәтшин, Гамбәр Гафиулла улы Гафиуллин, Сәгадә Фатыйх кызы Вәлиева, Антонина Павловна Нехорошкова, Клавдия Ивановна Гончаренко, Гелий Иосифович Уралов, Фәрит Бәдретдин улы Баһаветдинов, Илдус Харис улы Садыйков. Бу шәхесләрнең һәм башка бик күп легендар түбәнкамалыларның исемнәре безнең шәһәрнең тарихында калачак!

Беренче төзүчеләрнең традицияләре дәвам итә. Түбән Камада элеккечә үк шимбә өмәләренә чыгалар, агачлар утырталар, чәчәк түтәлләре ясыйлар, яңа юллар һәм балалар бакчалары төзиләр, бәйрәмнәрне билгеләп үтәләр. Түбән Камадагы яңа буынга да шәһәр тарихында үз сүзен, үз хезмәтен калдыру мөмкинлеге бирелә. Шуңа күрә дә биредә зур эшләр кайный.

Түбән Кама элеккечә яшьләр шәһәре санала, биредә 273,5 мең кешенең дүрттән беренә якыны – 14тән 30 яшькә кадәрле яшьләр, һәм аларның саны елдан-ел арта бара.

Бу – Түбән Каманың традициясе, биредә зур төзелешнең беренче ике елында ук 78 никах теркәлә, 190 бала туа. Ә үзенең юбилеена Түбән Кама 150 меңенче бала тууын көтә.

Түбән Кама һәрвакыт сәнәгать шәһәре буларак кына үсми, төзелеш башланганда ук аның мәдәни ягына да зур игътибар күрсәтелә. Түбәнкамалылар яхшы музыка, иҗади кичәләр ярата һәм Бөтенсоюз комсомол төзелеше елларында бирегә күпсанлы артистлар һәм актёрларның килүе дә очраклы түгел.



*Түбән Кама – Россиянең иң эре сәнәгать үзәге.*

Яңа шәһәр һәм нефтехимия комбинаты төзелеше темплары бирегә 60нчы елларда килгән композитор Александра Пахмутова белән шагыйрь Николай Добронравовны «Смелость города берёт» дигән җырны язарга рухландыра.

Түбән Камада спорт шәһәре дә, танылган «Нефтехимик» хоккей дружинасы һәм шул ук исемдәге клуб бар. 12 балалар-яшьләр клубы спортның 20 төре буенча профессиональ спортчылар әзерли, аларның 2се – Олимпия резервы мәктәбе. Түбән Кама – дөнья чемпионнары ватаны, биредә берничә буын бөек спортчы тәрбияләнгән: Олимпия уеннарында катнашучылар – җиңел атлетика буенча халыкара класслы спорт мастеры Николай Афанасьев 1996 еда Атлантадагы уеннарда катнашкан; тагын бер җиңел атлет, Артём Мастров, 2000 елда Сиднейдагы Олимпиадада илнең җыелма командасы составында чыгыш ясый; җиңел атлетика буенча атказанган спорт мастеры Екатерина Волкова 2008 елда Пекиндагы Олимпия уеннарында бронза медаль ала; Марта Зәйнуллина – безнең танылган чаңгычы, 2014 елда ул да Сочидагы Паралимпия уеннарында бронза медальгә ия була; Шамил Садриев белән Ревал Садыйков – билбау көрәшендә, Ленар Фәйзлиев – бокс буенча дөнья чемпионнары.

Шәһәрнең 50 еллык алтын юбилее – аның киләчәктә тагын да колачлырак үсешкә ия булачагына нигез ул. Түбән Кама үсә, үзгәрә. Беренче чиратта, шәһәр юбилеена Чулманның яр буе яңартылачак. Бу искиткеч зур реконструкция проектын төзүдә түбәнкамалылар гына түгел, бөтен Россия архитекторлары катнашты. Августта яңартылган Шәһәр паркы ачылды. Бу проектны эшләгәндә, түбәнкамалыларның барлык теләкләре искә алынды: монда велосипед юллары, тротуарлар, фонарьлар, «җырлаучы» фонтаннар, эксклюзив күпер, балалар мәйданчыгы, амфитеатр, тренажёрлар барлыкка киләчәк, ә Түбән Кама телеманарасы Париждагы Эйфель манарасы кебек яктыртылачак.

Шәһәрне, гомумән, төзекләндерү буенча да зур эшләр башкарыла. Биредә быел беренче тапкыр ишегалларын ремонтлауның уникаль программасына старт бирелде. Шушы максатларда Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Түбән Каманың сәнәгать предприятиеләре ярдәме белән ярты миллиард сум акча бүлеп бирелде, 100дән артык ишегалдын ремонтлау күздә тотыла. Бу юнәлештә төп эшләрне юл хезмәте һәм идарәче компанияләр белгечләре башкарса, үз ишегалдында уңайлыкларны һәм матурлыкны анда яшәүче кешеләр үзләре булдыра. Төрле буын һәм профессия кешеләре зур һәм тату гаилә булып гомер иткән Түбән Каманың традицияләре әнә шундый, алар өчен Түбән Кама – уртак туган йорт.

**Айдар МЕТШИН,**
*Түбән Кама муниципаль районы башлыгы,*
*Түбән Кама шәһәре мэры*



Фәрит
Имамов

# МӘХӘББӘТ ТАЛИСМАНЫ

ФАНТАСТИК БӘЯН

Эшмәкәрләрнең халыкара форумы. Берничә көн барган бу олы киңәшмәнең соңгы көне. Төш вакыты җиткәч, тәнәфес игълан иттеләр. Делегатлар, сәгатьләр буе оеп утырган уңайлы кәнәфиләреннән торып, залга сибелде. Фойеның әле теге, әле бу почмагында, төркем-төркем җыелып, үзара әңгәмә коручылар күренә. Биредә кара-каршы торып, күзгә-күз карап сөйләшүләр киңәшмәләр залында рәсми төстә фикер алышуларга караганда үтемлерәк тә әле. Танышлыкны тагын да тирәнәйтергә теләгәннәр, беренче катның аргы башындагы кафе-ресторанга кереп, өстәл янында әңгәмә коралар. Мондый шартларда сөйләшү – үзара аңлашуга янә бер зур адым. Гадәттә, ул киләчәктә хезмәттәшлек итүгә нигез булып тора...

...Азаматның кәефе күтәренке иде. Шулай булмыйча соң, чит илләр белән хезмәттәшлекне киңәйтү буенча шактый эшлекле тәкъдимнәр керде. Алар Азамат җитәкләгән холдинг компаниясенә зур өстенлекләр вәгъдә итә. Сәүдә офыкларын тагын да киңәйтү, киләчәктә дөнья базарына чыгу мөмкинлеге дә тудыра. Төрдәш компанияләр белән көндәшлеккә бирешмәскә, үз аягыңда нык басып торырга ышаныч өсти...

Аның утырышлар залыннан чыгуын ярдәмчесе Динар көтеп тора икән. Азаматны күрүгә, янына ашыкты. Ярдәмчесенең, нәрсәдер әйтергә теләп, үзенә таба килүен ул бик үк ошатып бетермәде. Мондый чакта кая барырга, нәрсә эшләргә кирәклеген «хуҗа» үзе хәл итә. Форумдагы чыгышында нәкъ менә үзе шөгыльләнә торган бизнес тармагын үстерү буенча кызыклы фикерләр әйткән бер эшмәкәр белән күрешеп сөйләшермен, дип уйлап куйган иде ул. Мондый форсат тагын кайчан була әле? Азамат – киләчәккә карап эш йөртүче, заман кешесе. Шулай булмаса, яшь кенә килеш, хәзерге дәрәҗәгә ирешер идеме?! Илдә бармак белән генә санарлык иң бай катлау рәтендә йөри ич. Россиядә көнкүреш һәм электрон техника белән сәүдә итүче эре компаниянең хуҗасы ул. Олигарх диләр андыйлар турында! Байлыгы хәттин ашкан. Кем әйтмешли, җиде буынга җитәрлек...

Каршысына килеп, нидер әйтә башлаган Динарны: «Бераз гына сабыр итәргә туры килер, дускай, минем әле эшләрем бар», – дип читкәрәк тибәрергә

Фәрит ИМАМОВ (1960) – *язучы, журналист; «Югалган эзләр», «Дөньяның кеме юк...», «Күләгә» исемле китаплар авторы. Түбән Камада яши.*

уйлаган иде. Ләкин ярдәмчесенең үтә җитди кыяфәтен күргәч, кызыксынмыйча кала алмады:

– Нәрсә, балтаң суга төшкән кебек кыланасың? Берәр күңелсезлек килеп чыкмагандыр бит? Әллә тешең сызлыймы? – дип башлады ул сүзен, шелтәле тавыш белән.

Динарның йөзе җитди, шул ук вакытта бераз шомлы да иде. Якынрак килгәч, бу аеруча күзгә ташланды. Ул, үзенә аталган сорауга нәрсә дип җавап бирергә дә белмичә, «ык-мык» итте, каушап калды. Иң киеренке вакытларда да зирәклеген югалтмаган киңәшчесенең мондый халәтен һич аңларлык түгел иде.

– Э-э... ни... «Як-18» самолёты һәлакәткә... тарыган...

Динар бу сүзләрне әйткәндә, карашын яшерде. Форумдагы чыгышлар тәэсиреннән әле дә айнып җитмәгән Азамат колагына кергән сүзләрнең мәгънәсенә тиз генә төшенмәде:

– Аның нәрсәсенә гаҗәпләндең, хәзер көн саен бер самолёт мәтәлеп төшә, – дип башлаган иде, кинәт, аңышып, ярты сүздән бүленде һәм сораулы карашын ярдәмчесенә текәде:

– Ничек «Як» самолёты?.. Сөмбеләме?..

Динар «босс»ка күтәрелеп карады. Аның йөзендә үзен гаепле итеп сизү чалымнары чагылып узды:

– Мин сезнең кесә телефонына шалтыраттым, алмадыгыз. Әле моннан чирек сәгать элек кенә, хатыныгыз утырган «Як» самолётының хәбәрсез югалуы хакында, әниегез хәбәр итте... Ул сезгә дә шалтыратып караган...

Азамат, утырышлар залына кергәндә, кесә телефонын тавышсыз режимга куйган иде шул. Дөрес, берара, бил каешына беркетелгән күн футлярдан телефонының дерелдәвен тойган кебек тә булды. Тик чыгыш ясаучыларны мавыгып тыңлаганлыктан, ул хакта тиз онытты...

Мондый чакта озаклап уйлап торырга вакыт юк. Азамат – хәрәкәт кешесе. Аның шигаре: «Тимерне кызуында сук!» Юк, бу ордым-бәрдем эшләү дигән сүз түгел әле. Уйламыйча һич ярамый. Алга бурыч куеп, эшне эзлекле алып бару вакыйгалар агышын тизләтәчәк. Моның шулай икәнлеген Азаматка һөнәри сизгерлеге әйтеп тора. Ул – һәр адымын төптән уйлый торган кеше. Тик аның планнары да хәрәкәт иткәндә оеша. Һәрчак киеренке акыл хезмәте белән яшәүче Азамат өчен бу – ике икең – дүрт булган кебек үк гади нәрсә.

Беренче эш итеп ул, Свердловск шәһәренә шалтыратып, хәлгә ачыклык кертергә кирәк, дигән фикергә килде. Сөмбелә бүген, шәхси самолётына утырып, шул шәһәрдәге Инна исемле дустына – кайчандыр Мәскәү дәүләт мәдәният институтында бергә укыган курсташына кунакка очкан иде...

...Заманалар үзгәрә. Самолётлар да әкренләп шәхси кулларга күчә. Азамат шикелле калын кесәле кешеләргә, транспортның әлеге төреннән иркен файдалану гына түгел, аны сатып алу мөмкинлеге дә туды. Олигархлар, гадәттә, чит илләрдә эшләнгән самолётларны үз итәләр. Бүгенге көндә «Боинг»лар бик популяр. Әлеге лайнерларның бәяләре дә миллион долларлар белән исәпләнә. Андый очкыч алырга Азаматның да финанс мөмкинлеге бар. Тик «Боинг» кебек кадерле «уенчык» үзен акламаячак. Аек акыл белән фикер йөртеп, чыгымнарны киметеп, табышларны арттыруга йөз тотучы уңышлы бизнесмен өчен, очкыч иминлеге белән беррәттән, үзе җитәкләгән компаниянең финанс иминлеге дә әһәмиятле. Илдә демократлар хуҗа булып алгач, совет чорында тупланган дәүләт байлыгын хосусыйлаштырып, санаулы еллар эчендә генә миллионнарга, миллиардларга ия булучыларның балалары да «үзем тапкан

мал түгел, әтинеке җәл түгел» дигәндәй кыланалар. Андыйлардан аермалы буларак, Азамат үз көче белән түбәннән күтәрелгән миллиардер. Бу биеклеккә аны үҗәтлеге һәм искиткеч тырышлыгы күтәрде.

Азамат «Як-18» самолётын моннан ярты ел элек хатыны өчен махсус сатып алган иде. Каян ишеткәндер дә, күңеленә кем коткы салгандыр: чын самолёт штурвалы артына утырып, күктә очасы килде Сөмбеләнең. Очучы лицензиясенең юклыгы да комачауламады. Шәхси очучылыкка өйрәнү өчен Сөмбелә тиешле 120 сәгать дәрес һәм 42 сәгать очу практикасы узды. Шул исәптән, 10 сәгатен үзе штурвал артына утырып очып карады.

«Як» – ышанычлы самолёт. Җиңел самолётлар классына керүче «Як-18» күп еллар дәвамында совет авиаторларына тугрылыклы хезмәт иткән. Сынатмаган, гел макталган. Идарә итәргә җиңел бер моторлы бу моноплан, гадәттә, өйрәнүләр һәм күнегүләр өчен файдаланылган. Шуңа күрә очучылар, үзара сөйләшкәндә, шаярып, аны «оча торган парта» дип тә атыйлар икән. Күп кенә танылган очучылар авиациягә юлны нәкъ менә шушы самолётлардан башлаганнар. Дөрес булса, хәтта Юрий Гагарин да беренче мәртәбә очарга шундый «Як»та өйрәнгән, диләр.

Бүген иртән Азаматның сөекле хатыны Свердловск шәһәренә шул бер моторлы «Як-18» самолётына утырып очты. Дөрес, самолётта ул берүзе генә түгел иде. Мондый ерак арага хатынының беренче очышы. Әлегә тәҗрибәсе бик аз булганлыктан, авиаинструктор Фәнисне дә аның белән очарга күндерделәр. Барганда штурвал артына Фәнис утырса, кайтканда идарәгә Сөмбелә үзе күчәчәк, дип сөйләштеләр.

Фәнис – профессиональ очучы, тәҗрибәле авиаинструктор. Самолётларның төрлесендә очканы булган. Күпьеллык һөнәри тәҗрибәсендә төрлесен күрергә туры килгәндер. Ләкин теләсә нинди катлаулы хәлләрдән дә чыгу җаен тапкан, кыен шартларда да самолётын җиргә утырта алган очучы-ас ул.

Самолёт та ышанычлы, янәшәсендә тәҗрибәле инструктор да булгач, бернинди күңелсез хәлләр килеп чыгарга тиеш түгел иде дә бит... Ә бәлки бу хәбәр ялгышлыктыр, буталганнардыр, дип үзен юатты Азамат. Менә хәзер Иннага шалтыратыр да, бар да ачыкланыр. Бәлки, хафаланырлык нәрсә дә юктыр?!

Сөмбелә дус кызының телефон номерын биреп калдырган иде...

Инна, көтеп торган диярсең, трубканы бик тиз алды. Кыскача гына хәл-әхвәл белешүләрдән соң, Азамат төп мәсьәләгә күчте:

– Сөмбелә турында... – дип сүз башлаган иде, Инна аның сораштыруын да көтеп тормыйча, ашыга-кабалана үзе сөйләргә кереште:

– Сөмбеләнең самолёты, алдан билгеләнгәнчә, Мәскәү вакыты белән 9.20дә аэропортка төшәргә тиеш иде. Без ирем белән аларны каршыларга монда бер сәгать алдан килдек. Самолётны көткән арада, бер-ике мәртәбә Сөмбелә белән кесә телефоны аша элемтәгә кереп сөйләшеп алдым. «Очабыз. Барысы да тәртиптә», – диде. Соңгы сөйләшкәндә, аэропортка 20 минуттан төшәчәкләре турында хәбәр итте. Көттек – егерме минут та узды, егерме бише дә, ә алар һаман күренми. Кабат шалтыраткан идем, элемтә бөтенләй юк – «не доступен» күрсәтә. Аптырагач, аэропортның һава диспетчерларына мөрәҗәгать иттек. Алар үзләре дә аптыраштa. Берни аңламыйлар. Төшәргә ун минутлап кала, самолёт белән элемтә югалды, диләр...

– Сездә һава торышы ничегрәк соң? – дип әңгәмәне бүлде Азамат.

– Яхшы. Көн кояшлы...

Азамат бүтән нәрсә сораштырмады:

– Көтегез, бер-ике сәгатьтән анда булам, – диде дә элемтәне өзде.

***

Форумга җыелган эшмәкәрләр арасында шәхси очкычлары булганнар да бар, билгеле. Кайберләрен Азамат та белә иде. Шуңа күрә ул, әле форум төгәлләнгәнче үк, күптәнге танышы Николайның Свердловск шәһәренә илтеп куюын үтенде. Кайчандыр Азаматка үз үрнәгендә «Як» самолёты алырга киңәш иткән Николай – киң күңелле, башкалар хәленә керә белә торган кеше. Азамат әйтү белән күнде. Николайның самолёты торган аэропортка Динар машинасында бардылар.

2010 елга кадәр Россиядә шәхси самолётлар сатып алырга яисә алардан файдаланырга рөхсәт булмады. Акчалы кешеләргә дә бу мөмкин эш түгел иде. Хәзер кече авиация очышлары рөхсәт ителә һәм алар алдан хәбәр итү юлы белән гамәлгә ашырылганлыктан, һәр аэропортта да шәхси самолётлар өчен түләүле урыннар бүленгән. «Россия Федерациясендә һава хәрәкәтен оештыру буенча дәүләт корпорациясе» берләштерелгән предприятиесендә, күп каналлы телефон һәм Интернет челтәрләре ярдәмендә, шәхси самолётларның системалы очышлар планы булдырылган. Баштарак шәхси самолёт хуҗасы очышка кадәр өч көн алдан махсус рөхсәт сорарга тиеш булса, хәзер һава хәрәкәте белән идарә итү органнарына очыш алдыннан гына мөрәҗәгать итәргә дә була. Җиңел самолётлар «G» классындагы очышларга кертелә. Һәвәскәр очучы, моңа рөхсәт алу өчен, кече һәм җиңел авиациядә очарга өйрәнү буенча тулы уку курсы үтәргә тиеш. Николайның очучылык стажы ике ел. Ул да укып пилот таныклыгы алган. Самолёты белән үзе идарә итә. Бизнес өчен кирәкле техника, ди ул аны...

Аэродромга килеп, ангарга кергәч, авиатехник самолётны очышка әзерләгән арада, Николай Россия Федерациясендә һава хәрәкәтен оештыру үзәгенә Интернет аша заявка җибәрде. Метеорология һәм аэронавигация мәгълүматлары белән дә җентекләп танышып чыкты. Очышка рөхсәт алынгач, самолётлар күтәрелү һәм төшү полосалары турында да өстәмә мәгълүмат бирделәр. Ангардан чыгар алдыннан, Николай техниктан күпме күләмдә ягулык һәм май салынуы һәм аларның сортлары турында җентекләп сорашты, гомумән, самолётның очышка әзерлеге турында белеште. Уңай җаваплар гына ишетсә дә, үзе дә самолётын әйләнеп, тышкы яктан бер кат карап чыкты: бәрелгән урыннары юкмы, капот һәм люклар дөрес ябылганмы, ягулык-май аккан урыннар күренмиме, янәсе. Шассиларга да тибеп-тибеп алды. Хәтта кабина тәрәзәләренең чисталыгын да игътибар белән карады. Шуннан соң гына Азаматны кабинага чакырды. Әле моның белән дә эш бетмәгән икән. Кабинада Николай төп узелларны һәм приборларны бер кат күздән кичерде, штурвалның һәм идарә педальләренең торышын тикшерде. Очыш югарылыгын күрсәтә торган приборның укларын башлангыч сызыкка куйды, барометрның хәзерге вакытта һава басымына туры килүен, элемтәне барлады.

Азамат, самолётны очышка әзерләү бигрәк мәшәкатьле эш икән, дип уйлана-уйлана, элемтә наушникларын колагына беркетте. Анда җиңелчә генә гөжләү һәм радио аша хәбәрләшү тавышлары ишетелә. Менә Николай диспетчерлардан очышка рөхсәт сорады. Уңай җавап ишеткәч, самолётын акрын гына старт юлыннан борды да, алда берничә йөз метрга сузылган очыш юлыннан күзен алмыйча гына, идарәне очу режимына күчерде. Тигез бетон өслектән берникадәр баргач, очкыч сәгатькә 120-130 километр тизлек алды һәм җирдән күтәрелеп китте.

«Менә бит, шәхси һава транспортыннан файдалану бездә дә гадәти бер нәрсәгә әверелеп бара», – дип уйлап куйды Азамат. Чыннан да, очышка рөхсәт алганга ярты сәгатьләп уздымы-юкмы, алар инде күктә. Менә, самолёт 50 метрга,

аннан соң әкренләп 1000 метрга кадәр күтәрелде. Һава торышы шәп, күз күреме яхшы. Аста кечерәк шәһәрләр, авыллар кала. Тасма булып сузылган елгалар, яшел урманнар, болыннар, күлләр уч төбендәге кебек кенә. Күз алдындагы бу манзарага сокланып карап туймаслык та бит... Тик Азамат мондый хәлендә бу матурлыкка хозурлана алмый шул. Күптән түгел генә Сөмбелә дә шушыннан очып узган бит инде. Югарыдан җир өслеген күзәтергә бик ярата иде хатыны. Җилдән җитез очкычка утырып, кошлар белән узыша-узыша күктә очу турында хыялланды ул. Һичшиксез, мондагы матурлыкка сокланмыйча калмагандыр.

Азамат хатынының бәхетле елмаюын күз алдына китерде. Татлы хыяллар дөньясына кереп киткәнен үзе дә сизмичә калды. Бергә булган бәхетле көннәрен генә түгел, һәрбер мизгелне аерым-аерым барлап чыкты ул.

Вакыт тиз узды. Менә самолёт кирәкле аэродромга якынлаша. 15 километрлап калгач, Николай, диспетчерлар белән элемтәгә кереп, очыш полосасына төшү өчен рөхсәт сорады, төшү шартлары турында белеште.

Самолёт аэродромга якынлашкан саен, биредә һава хәрәкәте киеренкелеге ныграк сиздерә. Диспетчерлар якындагы самолётлар белән туктаусыз хәбәрләшеп торалар. Элемтәдә бер үк вакытта биш-алты самолёт булгалый. Кемдер очарга әзерләнә, кемдер төшә, кайберләре үз чиратын көтеп, аэропорт өстеннән әйләнә.

Әнә төшү полосасы да күренде. Диспетчер күрсәтмәләр бирүдән туктамый. Навигаторда тайпылышлар юк. Берничә минуттан очкычның шассилары җиргә кагылды. Полоса буенча берникадәр баргач, самолёт, борылып, янәшәдә шушындый ук кече классны өч самолёт һәм вертолёт торган урынга килеп туктады.

Аэродромның кече класслы самолётларга хезмәт күрсәтә торган бу өлеше шәхси эшмәкәр карамагында икән. Килгән самолёт хуҗаларына һәм пассажирларга хезмәт күрсәтү бизнесы да җәелә башлаган. Шушында ук кунакханә, ресторан, балалар бүлмәләре, мунча, бассейн һәм уеннар өчен тиешенчә уңайлыклар булдырылган. Азаматлар килеп төшеп, самолётны урнаштыруга, әлеге халык киң күңеллелек күрсәтеп, үзләренең хезмәтләрен тәкъдим итә башлады. Тик Азаматның, нәкъ менә хәзер, аларны тыңлап торырга вакыты бик тар иде. Ул тизрәк аэропорт җитәкчелеге һәм диспетчерлар белән сөйләшергә, әгәр кирәк икән, югалган очкычны эзләү эшләрен тизләтү өчен, бөтен мөмкинлекләрне дә эшкә җигәргә тели иде.

Аэропорт начальнигы Александр Петрович – беренче карашка ук киң күңелле адәм – аны дустанә каршылады. Азамат сөйли башлауга ук, эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлап алды.

– Әйе, мин хәбәрдар. Мондый гадәттән тыш хәлләрнең инде күптән булганы юк иде, – диде ул, хәлгә керергә тырышкандай.

Аннан соң Азаматның кем булуын ачыклауны кирәк санап:

– Сез очкычтагыларның берәрсенең туганымы? Белүемчә, самолётта икәү булганнар, – дип сорады.

– Әйе, минем хатыным белән авиаинструктор иде анда.

Авыр тынлык урнашты. Бераздан Азамат:

– Эзләү эшләре башландымы? Ничегрәк бара? – дип кызыксынды.

– Элемтә югалып, ярты сәгатьләп кабат бернинди хәбәр дә булмагач, эзләү-коткару төркеме оештырылды. Биш кешедән торган төркем, «Ми» вертолёт белән самолёт югалган квадратка очты.

– Аларның кирәкле җиһазлары бардыр инде?

– Әйе, вертолёт гадәттән тыш хәлләр министрлыгыннан. Коткару эшләре өчен махсус җиһазландырылган. Төркемдәгеләр барысы да тәҗрибәле...

Шулчак телефон чылтырады. Александр Петрович кем беләндер биш минутлап сөйләште. Трубканы куйгач, өзелгән әңгәмәне дәвам итте:

– Сезнең Казан да тикшерү өчен төркем оештырган икән. Менә, яңа гына, телефоннан шул төркемнең җитәкчесе Фоат Хәмитович Хәбиров дигән кеше белән сөйләштем. Мондагы хәлләр белән кызыксынды. Аның белән алга таба да элемтәдә торачакбыз. Тик әлегә кадәр берни дә ачыкланганы юк...

Александр Петрович, чарасызлыктан нишләргә белмәгәндәй, кулларын як-якка җәйде, иңбашларын сикерткәләде.

– Гаҗә-ә-әп, фән-техника алгарышы заманында яшибез, һәр җирдә компьютерлаштыру... Шул ук вакытта көпә-көндез самолёт кадәр самолёт югала һәм, инде менә ничә сәгать шуның эзен дә таба алмыйлар. Самолёт печән кибәнендәге энә түгел ләбаса...

Азамат бу сүзләрне бераз гына тавышын күтәребрәк әйтте. Ләкин Александр Петрович анысына игътибар итмәскә тырышты. Ни дисәң дә, аның каршысында бәхетсезлеккә тарыган кеше утыра. Кадерле кешесен югалту ачысын никадәр генә сиздермәскә тырышса да, беркемнең дә нервлары тимер түгел. Җитәкче бу очракта шуны яхшы аңлады. Монда инде үзара кычкырышып утырудан мәгънә юк. Ничек тә булса Азаматны юату иде уенда.

– Әлегә барысы да бетте, дип уйларга нигез юк. Самолётта нинди дә булса төзексезлек килеп чыгып, ул мәҗбүри рәвештә җиргә төшкән булырга мөмкин. Ни генә дисәк тә, яхшыга юрыйк...

– Самолёт төзек булмагандыр, дип уйларга нигез юк. Барлык сынаулар да, техник хезмәт күрсәтүләр дә төгәл үтәлгән. Экспертлар тарафыннан уңай бәяләнгән. Ышанычлы очкыч икәнлеге расланган. Мин аны шуңа да хатыныма сатып алдым инде.

Теле белән шулай сөйләнсә дә, Азамат үзе Александр Петрович әйткән фаразны хуп күрә иде – самолётта аз гына төзексезлек килеп чыккандыр да, ул җиргә төшәргә мәҗбүр булгандыр. Бу тирәләрдә авыл-бистәләр бик күп. Әгәр очкыч һавада шартлаган булса, берәр кеше күреп калып, әллә кайчан хәбәр итәрләр иде инде.

Гомумән, Азаматның шартлау турында башына да кертәсе килми. Аның өчен Сөмбеләсе исән. Тик, һич тынгылык бирмичә, күңелен борчып торган бер нәрсә бар: әгәр исән икән, ни өчен Сөмбелә кесә телефоныннан хәбәр бирми соң? Бәлки... Бәлки, аңсыз хәлдәдер?.. Юк, юк, моның булуы мөмкин түгел. Сөмбелә аңсыз хәлдә?..

Азамат, караңгы уйларын куарга теләгәндәй, башын чайкаштырды. Аның нәрсә уйлаганын сизгән диярсең, Алекандр Петрович:

– Бездә кесә телефоннары өчен антенналар челтәре тиешле дәрәҗәдә урнаштырылмаган. Күп урында элемтә юк, – дип, үз фикерен белдерергә ашыкты.

Менә монысын Азамат аңлый. Сүз дә юк, хәзер сөеклесе нәкъ менә шул сәбәпле телефон аша элемтәгә керә алмыйдыр. Бәлки, ул тиздән кесә телефоннары тота торган зонага килеп җитәр. Хәбәр бирер. Ул чакта барысы да җиңел сулар. Бөтен борчулар артта калыр һәм алар элеккедән дә бәхетле гомер итә башларлар.

Азамат, үзе дә сизмәстән, татлы уйларга бирелә баруын тойды. Ләкин мондый чакта йомшарырга ярамый.

– Гафу итегез, техника бик нык алга китте дип аталган хәзерге заманда самолётларның очышын локаторлар ярдәмендә күзәтеп булмыймыни?

Александр Петровичның маңгай җыерчыклары тагын да тирәнәйгән кебек булды.

Каршысында утырган бу кешене рәнҗетмәслек, шулай ук хәзерге авиатехниканы да бөтенләй юкка чыгарып ташламаслык итеп нинди җавап табарга соң?

– Беләсезме, хәзерге вакытта Россиядә коткару хезмәте тирән кризис кичерә. Кече авиация визуаль очыш кагыйдәләренә генә буйсынганлыктан, очыш барышында радиоэлемтә аша гына хәбәрләшеп була дигән сүз. Кече классларга керүче шәхси самолётлар хәрәкәте, гомумән, радиолокаторлар аша күзәтелми. Чөнки радиолокаторлар түбәннән очучы очкычларны күрерлек диапазонда эшләми. Сезнең хатыныгыз утырып очкан «Як» кебек самолётларны радар экраны аша күрү мөмкин түгел.

– Ә менә хәзерге самолётларда, һәлакәткә тарган очракларда, сигнал бирү өчен радиомаяк кебек нәрсә дә юкмыни? Мин бу өлкәдән бик ерак кеше, әлбәттә. Ләкин...

Сүз дә юк, сорау бик урынлы иде. Андый радиомаяк булса, һәлакәткә очраган самолёт бик җиңел генә табылыр иде дә бит... Ләкин бу мәсьәлә Александр Петровичның үзен дә борчый иде булса кирәк.

Диспетчерларның әйтүенә караганда, «Як» самолёты белән элемтә югалырга берничә секунд кала, штурвал артында утыручы очучы өзек-өзек сүзләр белән: «Шайтан алгыры... Берни дә аңламыйм... Юнәлешне билгеләү...» – дип, ашыгып нидер сөйләнгән. Шуннан соң алар бүтән элемтәгә кермәгәннәр.

Гадәттә, очкычлар һәлакәткә тарса, һава торышына сылтау дигән нәрсә бар: җил-давыл, явым-төшем, яшен, томан... Һәлакәтләрнең күпчелеге, чыннан да, нәкъ менә һава торышының начарлыгыннан килеп чыга. Бу очракта да шулай уйларга мөмкин. Өстәвенә пилотның «юнәлешне билгеләү...» дигән соңгы сүзе дә шуңа ишарә кебек. Ләкин «Як» самолёты хәбәрсез югалган көндә явым-төшем дә, болыт та күзәтелмәгән. Һава торышы хакында алынган мәгълүматлар да ул сәгатьләрдә күк йөзенең аяз булуы турында сөйли.

Азамат сораган радиомаяк, чыннан да, самолётларда булырга мөмкин. Фаҗигагә тарган очракта, эзләү эшләрен җиңеләйтү өчен, махсус сигналлар бирә торган радиостанция куела икән. Коткару вертолёты, шул сигналларны тотып, тиз генә эзләп таба ала. Тик әлеге җиһазларны ток белән тәэмин итү элементлары инде күптән тузган, аларның эшләвенә гарантия юк. Ә Җир орбитасындагы иярченнәр аша хәбәрләшә торган аппаратуралар Россиядә мондый җиңел очкычларда, гомумән, юк икән...

Аэропорт директоры сөйләгән һәр сүзен Азаматка аңлаешлы итеп җиткерергә тырышты. Аэрофлот эшчәнлегеннән бик ерак торган кеше өчен монысы да әһәмиятле, әлбәттә. Аның белән әңгәмә корганнан соң, Азамат берникадәр тынычлангандай булды һәм шул ук көне кабат Казанга очты.

* * *

Билгесезлек кешене бичара хәлендә калдыра. Азамат та шундый хәлдә иде. Кая барырга, кемгә мөрәҗәгать итәргә, бу авыр хәлдән ничек чыгарга?.. Аның баш миен әнә шундый сораулар туктаусыз бораулый. Теләсә нинди кыен хәлдән дә чыгу юллары бар, диләр. Шулай икән, Азамат очрагы өчен нинди юллар эзләргә соң?..

Бәлки, нәкъ шушы вакытта аның сөеклесенә ярдәм кирәктер? Шушы минутларда ул да кыен хәлдән чыгу юлларын таба алмыйча гаҗизләнәдер, бәгырькәй. Әйе, әйе, ул исән. Теләсә нинди шартларда да берничә атнага тәнендә җан сакларга көч таба алачак аның хатыны. Яраткан ире – Азаматы, туачак балалары – бәгырь җимешләре хакына ул андый көчкә ия. Азамат моңа чын күңеленнән ышана. Әнә шуңа да Сөмбеләне табып, аны бәладән йолып

кала алырына өмете зур. Шуның өчен ул бөтен мөмкинлекләрдән, хәтта беренче карашка өметсез булып тоелганнарыннан да файдаланырга тырышты. Әнә шуларны истә тотып, күрәзәчегә мөрәҗәгать итәргә ниятләде дә инде. Шушы яшенә җитеп, беркайчан да багучылар белән аралашканы, нәрсә дә булса юратырга теләп, аларга барганы булмады югыйсә. Теге яки бу мәсьәләдә күрәзәчеләргә мөрәҗәгать итеп, алардан уңай яки тискәре җаваплар ишеткән танышларының сөйләгәннәренә дә көлемсерәп кенә карады, шундыйларның күпчелеге кебек, багучыларны шарлатаннар, алдакчылар дип уйлый иде.

Табигатьтән өстен көчләргә ышану – Азамат өчен, гомумән, ят нәрсә. Ул – аяк терәп җирдә басып тора торган Җир кешесе. Чынга ашмас хыяллар, гайре табигый хәлләр белән кызыксынмый. Аның алга куйган максаты бер – матди яктан уңышка ирешү. Шуны тормышка ашыру өчен, як-якка карамыйча гына, армый-талмый алга атлый ул.

Нишләргә белмәгән үрдәк күлгә арты белән чума дигәндәй, Азамат та күрәзәче юравыннан юаныч табарга уйлады. Беркөнне, Динарны үз янына чакырып: «Миңа шәһәрдәге иң яхшы күрәзәчене тап», – диде ул. Ярдәмчесе бу сүзләргә бераз сәерсенеп караса да, хуҗасының теләгенә каршы килмәде, «баш өсте, әфәндем», дигәндәй, кушканны үтәү хәстәренә керешер өчен, тизрәк борылып чыгып китү ягын карады.

Нинди юллар, нинди элемтәләре аша тапкандыр, бер тәүлек дигәндә, Азаматның эш өстәлендә адреслары күрсәтелгән исемлек ята иде инде.

– Оһо, дистәдән артык болар монда. Безнең шәһәрдә шулкадәр багучы барлыгы башыма да килеп карамаган иде, – диде Азамат, исемлеккә күз төшерүгә.

– Саный китсәң, алар шәһәрдә тагын да күбрәк әле. Тик кайберләрен язып та тормадым. Күрәләтә кеше алдаучылар, акча өчен теләсә нинди ялганга баручылар. Бу хакта, аларга мөрәҗәгать итеп, авызлары пешкән кешеләр әйтте.

– Ә шушыларның иң көчлесе кайсысы соң, белешә алмадыңмы?

Динар икеләнеп калды. Ул, өстәлдә яткан исемлекне кулына алып, кабат игътибар белән карады.

– Кайсысы, дип... Менә, Госманова Зәрия яхшы юрый, диделәр. Әйткәннәре күп очракта туры килә, имеш. Тагын Луиза Әкбәрова дигәне дә көчле икән. Сөйләүләреннән аңлавымча, иң көчлесе дә шулдыр әле. Исемлектә мин аның фамилиясе астына сызып та куйдым. Тик ул хәзерге вакытта беркемне дә кабул итми ди бугай. Кемнәрдер шикаять язган да җирле хакимият белән аралары бозылган, дип ишеттем. Шул сәбәпле, хөкем, кеше хокуларын саклау органнарына да күп йөргән.

– Без нәкъ менә шул Луиза дигәненә мөрәҗәгать итәрбез, мөгаен... Түләрбез, акчасыннан тормабыз...

– Тик ул бушка да, акчага да беркемне дә кабул итми, диделәр. Тәмам ваз кичтергәннәр бичараны.

– Шулай инде, көндәшләр күп булганда, үзара көрәш шикаятькә бата. Һәм бу очракта, гадәттә, иң гадел кеше зыян күрә. Астыртын көндәшләренең Луизадан нәкъ шундый юл белән үч алган булулары бик ихтимал. Хәер... Безгә аларның үзара ничек аңлашулары мөһим түгел. Әүлиябыз шарлатан булмаса, дөресен әйтеп бирә ала икән, безгә кайсысы да ярый. Эчке сиземләвемчә, әгәр күрәзә дигән нәрсә чыннан да бар икән, Луиза нәкъ менә без эзләгән кеше булырга тиеш. Шуңа барыйк. Аннан соң тагын берәрсенә кереп чыгарбыз. Әйтик, Зәрия дигәненә...

– Бу эшне кайчан башлыйбыз?..

Азаматның уйлаган эшен шунда ук тормышка ашырырга яратканын белсә дә, Динар бу сорауны бирмичә кала алмады. Һәм, чыннан да, үзе фаразлаган җавапны ишетте. Азамат, озак уйлап тормастан:

– Ә нишләп кичектерергә, адреслары бар бит, хәзер үк кузгалыйк, – диде дә, бераз тынып торганнан соң: Вакыт югалту, акча югалту белән бер, – дип, үзе яратып әйтә торган сүзне дә өстәде.

– Хатыныгызның фотосурәте яки берәр шәхси әйбере кирәк булыр. Икесе дә булса, тагын да яхшы, – диде Динар.

Азамат ярдәмчесенә текәлеп карады:

– Ә алары нәрсәгә?

– Кешенең кайдалыгын, исәнме-түгелме икәнлеген күрәзәчеләр шуннан беләләр, имеш.

Азаматның да бу хакта ишеткәне бар иде, тик онытакан гына. Кайчандыр бер танышы, сугыш вакытында хәбәрсез югалган бабасының кайда күмелгәнлеген ачыклау өчен, фотосурәтен тотып, күрәзәчегә барган. Хикмәт димә, күрәзәче шуңа карап, бабасының кайсы шәһәрне азат иткәндә һәлак булуын да, хәтта кайсы туганнар каберлегенә җирләнүен дә дөп-дөрес әйтеп биргән. Соңыннан хәрби архивларда казынып табылган документлардан, чыннан да, бабасының шул шәһәрне алган чакта һәлак булуы, шундагы туганнар каберлегенә күмелүе ачыкланган.

Менә шул күрәзәчене тапсаң иде хәзер! Тик моның өчен башта әлеге танышын табарга кирәк, аннан соң теге күрәзәчене. Ә вакыт ашыктыра. Кем белә, ул күрәзәче нәкъ менә шушы Луиза үзедер әле...

Азамат, уйларыннан арынып, әле һаман да янәшәсендә сүзсез генә басып торган ярдәмчесенә endәште:

– Син машинага чыгып утыра тор, мин озак көттермәм, кирәкле әйберләрне генә алам.

Эш өстәлендә, асылташлар белән бизәлгән кечкенә генә рамда Сөмбеләнең фотосы тора. Азамат шуны алды. Әле туйларына кадәр төшкән фото. Сөеклесенең балкып елмаеп торган бу сурәтен бик ярата ул. Сызылып киткән кара каш, самимилеге бөркелгән зур күзләр, бераз гына иннек сөртелгән кызгылт алсу иреннәр, килешле генә түгәрәкләнеп килгән ияк – барысы да шулкадәр якын, газиз һәм кадерле.

«Бу минутларда кайда икән син, җанкисәк? Шушы матур йөзеңне нинди кайгылар сарды икән? Синең исән булуыңа чын күңелдән ышанам. Син дә минем хакта уйлыйсыңдыр», – дип үзалдына сөйләнде Азамат.

Күзеннән кайнар яшь тамчысы тәгәрәп, фотосурәткә тамды. Үзенең шушы йомшаклыгыннан оялгандай, Азамат рәсем өстендәге пыяланы учы белән ышкып сөртергә ашыкты. Сурәтне иреннәренә якын китереп үпте дә барсеткасына салды. Ә менә Сөмбеләнең шәхси әйберсен каян алырга? Һәрхәлдә, хатынының монда нәрсәдер булса алып килеп калдырганын хәтерләми ул.

Азамат өстәл тартмасын ачты. Менә берничә ручка, карандаш очлагыч, блокнот, кемдер кайчандыр бүләк итеп биргән аудиоплеер, кайчы, хәтта затлы гына зажигалка да бар. Тарау-торау яткан вак-төяк әйберләрне бармак очлары белән этеп күчергәләде. Әнә бер читтә дистәләп фоторәсем ята. Анда Сөмбеләнең сурәте дә бар. Тик алар шәхси әйберләр рәтенә керми шул.

Әле туйга кадәр үк сөеклесе белән бергәләшеп тә, аерым да фоторәсемгә төшкәннәр иде. Фотолар, ни өчендер, шушы көнгәчә өстәл тартмасында ята. Дөрес, Азамат, кайчак аларны кулына алып, сокланып карарга ярата. Әнә

Сөмбеләсе тирбәнгечтә утыра, бусында канәфер чәчәге өзә, ә менә монда... Тукта, бу сурәттә Сөмбелә түгел бит. Азамат рәсемне йөзенә якынрак китерде. Күзләреннән ирексез җылы нур бөркелгәндәй булды. Бу – Азаматның Сөмбеләгә туй бүләге итеп биргән кыйммәтле асылташ сурәте иде. «Ул безнең мәхәббәт талисманы булыр. Аннан беркайчан да аерылмам, һәрвакыт үзем белән йөртермен», – дип, Сөмбелә аны алтын чылбырга эләктереп, муенына асып йөри башлаган иде. Бу асылташны мәхәббәт символы итеп, йөрәк формасында эшләтте Азамат. Асылташның тагын бер үзенчәлеге бар – билгеле бер торышта аннан Азамат белән Сөмбелә исемнәренең баш хәрефләрен укырга була. Иң оста зәркән ясаучы яллап, зур акчага эшләтте бу асылташны. Хәер, яраткан кешесе, сөекле Сөмбеләсе өчен бернәрсә дә җәл түгел.

Асылташ сурәтенә Азамат озаклап һәм сокланып карап торды. Бу фото Сөмбеләнең шәхси әйбере түгел-түгелен. Ләкин хатынының тәнендә йөргән, аның тән җылысын һәрчак үзендә саклаучы асылташ рәсемен дә алырга булды Азамат. Кем белә, бәлки файдасы тиеп куяр, дип, аны да барсеткасына салып куйды да, соңга калмагаем дигәндәй, ашыгып ишеккә юнәлде.

***

Башка йортлар кебек үк гадәти бер йортның дүртенче катына менеп, пластик материал белән тышланган ишек янындагы кыңгырау төймәсенә шактый басып торганнан соң, эчке якта хәрәкәт сизелде һәм тонык кына: «Кем бар?» – дигән аваз ишетелде.

– Безгә Луиза Әкбәрова кирәк иде, – диде Азамат, сабырсызланып.

Үзе керергә теләгән ишекләрнең һәрчак ачык булуына һәм аларга бер каршылыксыз керә алуына чын күңелдән ышанган Азамат өчен бу ишек тә киртә булыр кебек түгел иде. Ул инде күңеле белән аннан әллә кайчан кергән һәм фатирның түрендә утыра. Тик эчтәгеләр тиз генә ачарга ашыкмадылар. Ишек артында бер генә кеше түгел, күрәсең, өзек-өзек сөйләшкәннәре колакка керә. Ниһаять, аннан:

– Нәрсәгә кирәк ул сезгә? – дигән тавыш ишетелде.

Монысы инде беренче сораган кеше түгел, тавышы өлкәнрәк кешенекенә охшаган.

– Сөйләшәсе бар, – диде Азамат.

Фатир эчендә тагын тынлык урнашты. Һәм ул шактыйга сузылды. Көтеп-көтеп тә бернинди хәрәкәт сизелмәгәч, Азамат тагын кыңгырау төймәсенә үрелде, шулчак эчтән, катгый итеп:

– Ул кабул итми! – диделәр.

Ишекне ачтырып, күзгә-күз карашып сөйләшүдән әле дә өметен өзмәгән Азамат:

– Аңлагыз, монда кеше язмышы турында сүз бара. Акчасыннан тормыйм, зинһар өчен, үтенечемне аяк астына салмагыз, – дип кычкырды.

Әлеге сүзләрнең тәэсире булдымы, бераздан ишекнең теге ягында «шалт-шолт» ачкыч борган тавыш ишетелде. Ишек ачылып, башта урта яшьләрдәге бер ханымның башы, аннан 13-14 яшьлек кыз баланың кызыксынучан йөзе күренде. Бу кыңгырау тавышына беренче эндәшкән кыз иде булса кирәк. Алар кунакларны баштанаяк күздән кичерделәр.

– Мин – Азамат Таһиров, бер якын кешемнең бүгенге язмышы турында кызыксынмакчы идем. Без аны өч көн элек югалттык. Зинһар, ярдәм итегез, – диде Азамат, ишекне япканчы әйтеп калыйм дигәндәй, ашыгып.

Кыз ишектән башын алды, ханым Азаматка сөзеп кенә карады да эчкә керергә ишарәләде.

Фатирның зал ягына үтешли, ханым үзалдына мыгырданды:

– Кабул итәргә исәбем булмаса да, яхшы ният белән йөргәнегез өчен генә керттем. Начар күңелле кеше түгел икәнлегегезне беләм, аңладым. Юкса, килүчеләрнең төрлесе була. Барысын да күрергә туры килде.

Ханым шулай сукрана-сукрана залга үтте. Юл уңаенда, Динар белән кызына күрше бүлмәгә чыгып торырга кушты. Чәйләп утырырга, кунакка чакырылган кеше түгел лә, эшне шунда ук башладылар. Азамат барсеткасыннан теге ике фоторәсемне алды. Башта ул күрәзәче алдына Сөмбеләнең портретын шудырды.

Луиза ханым, йә нәрсә сорыйсың, ни әйтергә телисең, дигән кебек Азаматка текәлде. Шунда гына Азамат әңгәмәне ничек башларга, сорауны ничек бирергә әзер түгеллеген аңлап алды. Ык-мык итте, ләкин башына, каршысында тишәрдәй булып карап утыручы шушы хатынга, тел әйләндереп сүз әйтерлек бер акыллы фикер дә килмәде. Хәер, мондый уңайсызлык өчен күңеленнән үзен битәрләргә дә ашыкмады. Күрәзәче булгач, барысын да үзе белергә тиеш, сорауны әңгәмәдәшенең баш миендә барлыкка килүгә үк аңларга тиеш, дигән уй күңеленә береккән иде аның. Чыннан да, иң катлаулы сорауларга да җавап алырмын, дип ышанып килгән күрәзәче, синең башыңны бораулап торган сорауны да белмәгәч, нинди күрәзәче була соң инде ул?! Азаматның фикер сөреше әнә шундыйрак иде.

Сүзсез генә карашып утыру вакыты көтелгәннән озаккарак сузыла башлагач, Азамат түзмәде: «Мине менә бу сурәттәге хатынның бүгенге язмышы кызыксындыра», – диде. Луиза ханым портретны кулына алды, җентекләп карый, өйрәнә башлады. Шактый шулай утыргач, ул: «Чибәр ханым!» – дип куйды. Менә сиңа ачыш! Аның чибәрлеген күрү өчен күрәзәче булу кирәк тә түгел, югыйсә. Азамат аннан мондый сүз көтмәгән иде. Шулай да ул, күңел хакы өчен дигәндәй, аның сүзен хуплап, баш селкегәндәй итте.

Ханым портретны өстәлгә куеп, анда бармакларын йөрткәләде. Бераздан соң, шактый көттереп кенә, аның авызыннан: «Ул сезнең хатыныгызмы?» – дигән сорау чыкты. Күрәзәченең шулай озак мыштырдавыннан Азаматның сабыры төкәнгән иде инде. Ул: «Әйе», – диде дә шунда ук хәлне төшендереп бирергә ашыкты:

– Әйе, ул минем хатыным, Сөмбелә. Моннан өч көн элек ул утырып очкан самолёт...

Азамат туктап калды. «Фаҗигагә очрады», – дип әйтәсе килмәде. Фаҗигагә очрау, димәк, үлем-китем дә булган, дигән сүз. Ә Азаматның күңеле Сөмбеләнең үлүенә ышанмый. Башкалар теләсә нәрсә уйласыннар, ләкин Азамат өчен ул исән, ул яши. Шуңа күрә, җөмләсен: «...радар экраннарыннан югалган. Элемтә дә юк. Мине аның кайда һәм нинди хәлдә булуы кызыксындыра», – дип тәгәлләде.

Күрәзәче аны, берәр сүзен колак читеннән уздырмагаем дигәндәй, дикъкать белән тыңлады. Һәр сүздән вакыйгаларга бәйләнеш табарга тырышканы әллә каян күренеп тора. «Күрәзәчеләрнең күбесе, күрәзәлек итүдән бигрәк, оста психолог. Алар кеше әйткән сүзләрдән чыгып, вакыйгалар агышына анализ ясарга сәләтле», дип ишеткәне бар иде Азаматның. Бу да шул үзенә кирәкле мәгълүматны көтә иде кебек. Ниһаять, ул телгә килде:

– Сабыр, сабыр... Мин хәзер хатыныгызның самолёт белән элемтә югалган чактагы халәтен күрергә тырышам...

Хатын бармакларын кабат фотосурәт өстендә шудыра башлады. Ә үзе аңа бөтенләй карамый да: башы күтәрелгән, күзләре йомык. Күз кабагының һәм

керфекләренең ара-тирә калтыранып куюы һәм кашлары арасында тирән җыерчыклар хасил булу, аның бик киеренке уйда икәнлеген күрсәтә.

Менә хатынның бераз ачылган иреннәре арасыннан: «Берни дә күренми... Томан... Ниндидер аңлашылмаучанлык... Юнәлешне югалту... Аңлашылмый торган тирәлек...» – дигән сүзләр кысылып чыкты.

Хатын кинәт кенә сөйләвеннән туктап, күзләрен ачты. Ике учы белән кат-кат битләрен сыпырды. Ул бу халәттә, яңа гына ниндидер киеренке эш башкарып, бик нык арган кешене хәтерләтә иде.

Луиза, аны яңа гына күргәндәй, Азаматка текәлеп карады. Һәм әлерәк транс хәлендә әйткән сүзләрен дәвам иткәндәй: «Мин томан күрәм. Бәлки ул чакта көн томанлы яисә болытлы булгандыр? Болыт эченә килеп кергәч, тирәлектәге урынны һәм юнәлешне билгеләү кыенлаша. Очкыч, нык түбәнәеп, биек агачка яисә тауга килеп бәрелгән булуы да ихтимал», – дип тезеп китте.

– Бөтен гаҗәпләндергәне дә шул: ул көнне күк йөзе чалт аяз булган. Томан да күзәтелмәгән. Ул өлкәнең метереология мәгълүматлары аяз һава торышы күрсәтә. Аэродром диспетчерлары да бертавыштан шуны раслый.

Күрәзәче хатын, «белмим инде» дигәндәй, иңбашларын сикертте. Хәлгә ачыклык кертердәй бүтән нәрсә әйтә алмады.

Инде китәргә дип, урыныннан кузгалырга җыенган Азаматның өстәлдә яткан икенче фоторәсемгә күзе төште. «Ә монысы турында нәрсә әйтерсез?» – дип, аны да ханым алдына этәрде. Луиза янә күзләрен йомып, бармакларын фото өстендә йөртә башлады.

– Бик кыйммәтле асылташ... Каяндыр тапканнар... җир астыннан, димме... Ниндидер пыяла калпак эчендә... Табылдыклар саклана торган урында...

Ханым күзләрен ачты. Башын селкеткәләде. Янә битләрен сыпырды.

– Сез нәрсә, бу асылташны берәр ювелир кибетеннән алынган, дип әйтмәкче буласызмы?

– Әйе, шундыйрак урында. Ювелир кибетендәме, музейдамы шунда...

Азамат урыныннан сикереп торды. Аның йөзендә мыскыллы зәһәр елмаю чагылып узды. Ханымның ялганын тотып, оялтырга теләү, шуның белән тантана итәргә җыену аның кыяфәтенә чыккан иде.

– Бу асылташ... бу асылташ, бик беләсегез килсә... минем хатында. Зәркәнчедән ясатып, аңа мин бүләк иттем. Ул аны уртак мәхәббәтебез хакына, талисман итеп үзендә йөртә... Музей, имеш...

Әһә, бүтән селкенер урының калмадымы, ялганың тотылдымы дигәндәй, Азамат хатынга тагын да мыскыллы караш ташлады. Ләкин Луиза бер дә читенсенмәде кебек. Һәрхәлдә, аның үз сүзләренә ышанычы зур иде. Һәм ул шуны сиздереп калырга ашыкты:

– Әйе, әйе! Музейда! Ул әле дә шунда саклана. Анда шундый әйберләр бик күп. Мин хәтта аның якынча кайсы тирәдә, кайсы шәһәрдә икәнлеген дә күрсәтә алам.

Ханым, урыныннан торып, стенага эленгән карта янына килде һәм бармак очы белән бер урынны әйләндереп күрсәтте. Бу Мәскәү тирәсе иде.

– Мәскәүдә, димәкче буласызмы?

– Бик мөмкин!..

Сүз дә юк, күрәзәче хатын әйткән җаваплар Азаматны канәгатьләндермәде. Шулай булса да, чыгып киткәндә, ул, илтифат саклап, ханымга бер яшел кәгазь акча сузды. Ханым аны алырга ашыкмады: «Кирәкмәс. Мин ул кадәр файдалы мәгълүмат бирмәдем кебек», – дип уңайсызлангандай итте. Тик Азамат акчаны

барыбер өстәлгә куйды да, кырт борылып, чыгу ягына атлады. Юл уңаеннан, күрше бүлмәдә күрәзәченең кызы белән бик күңелле әңгәмә корып җибәргән Динарны да үзе белән әйдәде...

Алар шактый вакыт сөйләшмичә бардылар. Азамат уйларына бирелгән иде. Ә Динар башлап сүз әйтергә кыенсынды. Офиска кайтып җитәрәк, Азамат үзе сүз башлады:

– Шарлатан! Томан, болытлы көн, имеш! Очкычларның күп очракта начар һава шартларында һәлакәткә очравына тәңгәл китерергә тырышып әйтүе инде бу хатынның. Аның өчен артык белем кирәк түгел. Асылташ турындагысы да охшатырга тырышып сөйләшү генә. Сүз дә юк, кыйммәтле асылташ. Аның затлы икәнлеген хәтта фотодан да чамаларга була. Асылташларның җир астыннан табылуы да гаҗәп түгел. Мин теләсә нинди асылташ турында үзем дә шундый фикерләр әйтә алам...

Динар хуҗаның зарларын сабырлык белән тыңлый бирде. Азаматның мондый кызып киткән чаклары сирәк була. Гадәттә, ул теләсә кайсы мәсьәләне салкын канлылык һәм үтә тынычлык белән хәл итә. Кем белә, бусында кызып китүе үзләрен күрәзәче дип атаучы ниндидер надан хатыннарга ышанып йөрүен аклау өчендер. Хәер, суга батучы соңгы чиктә саламга ябыша дигәндәй, Азаматның бүтән юлы да калмады. Бер караганда, бу хәл аның әлеге сантыйлыгын аклый кебек. Динар аның зарларын ахырынача тыңлап бетерде дә:

– Әле безнең тагын бер күрәзәчебез бар бит, – дип әйтеп куйды.

Азамат, аңышмыйчарак, ярдәмчесенә текәлде. Аның күз карашында, әле шушы хәлдән соң да син күрәзәчеләргә ышанасыңмы дигәндәй, гаҗәпләнү катыш аптырау галәмәте дә бар иде.

– Ник, Луизадан соң Зәрия Госмановага да кереп чыгарбыз, дип үзең әйттең түгелме? Бәлки, аннан берәр төпле сүз ишетербез. Җитмәсә, ул Зәрия дигәннәре менә шушы тирәдәрәк кенә яши икән.

Азаматны беләсез, ул – сүз кешесе. Әйткән сүзеннән чыкмый, вәгъдәләрен үтәргә ярата. Әйтеп тә аны үтәмәгән кешене көчсезләр рәтенә кертә иде. Шуңа да, инде башында, күрәзәчеләргә карата ышаныч юк, дигән фикер ояласа да, ул сүзен сүз итәр өчен булса да, Зәрия атлы күрәзәчегә дә керергә булды.

– Алай бик якында гына яши дигәч, әйдә соң, аңа да сугылып чыгыйк, – диде.

***

Зәрия алдагы күрәзәчегә караганда яшьрәк икән. Ул Луиза кебек карышып тормады. Эшне сораштырудан башлады. Бу аның өчен гадәти нәрсә, күрәсең. Күрәзәче янына күпләр киләдер һәм алар арасында якыннарының язмышы белән кызыксынучылары да шактыйдыр, әлбәттә.

Азамат барсеткасыннан фотоларны алып, Сөмбеләнең портретын өстәлдән аның ягына шудыруга ук, ханым: «Сезне бу ханымның язмышы, исәнме-түгелме икәнлеге кызыксындырамы?» – дип сорап куйды.

– Сорауны «исәнме-түгелме» дип куймыйк әле. Чөнки аның исән икәнлегенә иманым камил. Мине аның хәзер кайда икәнлеге һәм язмышы борчый, – диде Азамат.

– Сез аны югалткан идегезме?..

Азамат авыз чите белән генә елмаеп куйды. Әңгәмә башыннан ук сорау-җавап рәвешен алды. Тик сорауны Азамат түгел, ә күрәзәче бирә түгелме? Азамат башкачарак күз алдына китергән иде. Үзе сораулар биреп, аларга җавапны күрәзәчедән ишетермен, дип уйлаган иде, югыйсә. Ә монда –

киресенчә. Рольләр алмашынды түгелме?! Шулай да, әңгәмәнең болай башлануына ризасызлыгын күрсәтмәскә тырышып, көчәнеп диярлек:

– Әйе, югалды шул. Бу минем хатыным. Моннан өч көн элек ул утырып очкан самолёт... ни... хәбәрсез югалды, – диде ул.

– Аңлашылды...

Менә сиңа мә. Әле яңа гына аңлашылды аңа. Югыйсә, күрәзәче, Азамат әле ишектән кергәнче үк, барысын да белеп торырга тиеш иде бит. Ул – шуңа да күрәзәче. Зәрия, өстәлдәге фотога иелеп, үзенең «ырым-шырым»нарын башкарганда, Азамат әнә шулай уйланды. Күрәзәче, фотосурәт өстендә куллары белән йөртеп, аны озаклап «әфсенләде». Шактый вакыттан соң гына:

– Ул исән түгел, – дип куйды.

Бу хатынның үзе өчен нинди дә булса төпле сүз әйтәчәгенә бераз гына да ышанычы юк иде Азаматның. Ул җавапка битараф калды. Шуңа күрә: «Үлгән дип әйтмәкче буласызмы?» – дигән соравы да, ничектер, мәгънәсезрәк яңгырады. Кеше исән түгел икән, аның үлгәнлеге ап-ачык югыйсә. Ләкин күрәзәче аның бу соравын мәгънәсезлек дип кабул итмәде булса кирәк. Ул тагын да үҗәтлек белән кабат фотосурәткә иелде. Куллары белән пасслар ясый башлады. Бу нинди күрәзәче?! Кешенең инде исән түгеллеген белгәч, аның үле икәнлеген раслау кирәкме?

– Әмма... әмма ул үлеләр исәбендә дә юк.

Гаҗәпләнүдән Азаматның күзләре маңгаена менде. Ләкин, аннан да битәр, күрәзәче үз сүзләренә үзе гаҗәпләнде.

Әнә шулай авызларын ачып, бер-берсенә карашып торганнан соң, ниһаять, Азамат телгә килде:

– Сез әле генә киресен раслаган идегез түгелме? Моны ничек аңларга?..

Зәрия инде менә өченче мәртәбә куллары белән фоторәсемне «әфсенли».

– Мин аны исәннәр арасында да, үлгәннәр арасында да күрмим. Аңлашылмый... Берни дә әйтә алмыйм. Минем өчен монда каналлар ябык...

Әһә, бу «күрәзәче» башта үлгән дип, аннан исән дип, кыек атып туры тидермәкче иде. Кайсысы да булса туры килер, дип уйлагандыр. Хәйләсе барып чыкмады.

Азамат Зәриягә текәлде. Тик аның күз карашында ялганы тотылган кешенекенә охшаган нәрсә күрмәде.

Карап карыйк, монысына нәрсә ялганлар икән дигәндәй, Азамат асылташ сурәтен аның каршысынарак этәреп куйды.

Зәрия бусында берни дә сораштырмады. Фотоны игътибар белән карарга кереште.

– Асылташ, – диде ул, ниһаять. – Кыйммәтле, – дип тә өстәде.

Асылташның затлылыгын фоторәсемнән дә чамаларга була анысы. Моның өчен әллә нинди гайре табигый сәләткә ия булу мөһим түгелдер.

– Хәзер бу әйбер ниндидер пыяла тартма эчендә, күргәзмәдәме, музейдамы саклана.

Азамат бу сүзләрдән имәнеп киткәндәй булды. Карале, бу да Луиза Әкбәрова сүзләрен кабатлый түгелме?! Сүз берләшкәннәр диярсең. Бу очраклылыкмы, әллә?..

– Тагын нәрсәләр әйтә аласыз...

Зәрия фотоларны кабат әйләндергәләде. Ләкин бүтән бернәрсә дә әйтә алмады...

Азаматны машинада көтеп утырган Динар аңа сораулы карашын төбәде:

– Йә, монысы нәрсә әйтеп шатландырды?

– Артык искитәрлек яңалык ишетмәдем. Алай да, гаҗәпләнерлек бер сүз әйтте. Талисман рәсемен күрсәткәч, Луиза Әкбәрова кебек үк бу да, асылташ ниндидер музейда яки күргәзмәдә саклана, диде.

Динар бу сүзләрдән кычкырып көлде генә.

– Үзләренең шундый беркатлы алдау-йолдаулары белән кешеләрне ничек ышандыралар бу күрәзәчеләр...

***

Көн артыннан көн узып, югалган очкычны эзләүдә бернинди алга китеш тә булмады. Бер җылы сүз – күңел юаткыч, диләр. Азамат бу көннәрдә тирә-яктагыларның, якыннарының ярдәмен, кайгыртуын тоеп, күңелен шулар белән юатты. Иң авыр чакта да: «Ә бәлки табылыр... Бәлки менә бүген нинди дә булса шатлыклы хәбәр җиткерерләр», – дигән өмет белән яшәде ул.

Бу көннәрдә рәсми органнар гына түгел, ә җирле халык та самолётны эзләүдә үзләреннән күп көч кертте. Студентлар, яшьләр, инициатива күрсәтеп, үзләре эзтабарлар отряды төзеделәр. Волонтёрлар очкыч фаҗигагә очраган дип фаразланган урында, рәткә тезелеп, шундагы урман эчен «тарадылар», һәр карыш җирне тикшереп чыктылар. Шулай җентекләп эзләү дә уңай нәтиҗәләр бирмәде. Эзләү барышы озакка сузылган саен, өметләр өзелә барды. Табуга зур ышаныч белән керешеп тә, бернинди нәтиҗә күрмәгәч, волонтёрлар сафы сирәгәйгәннән-сирәгәйде. Инде рәсми комиссия дә, көймәнең комга терәлгәнен һәм барлык тырышлыкларның бушка икәнен аңлап, эзләүне сүлпәнәйтә башлады. Ахырдан бернинди нәтиҗәгә килмичә, «серле шартларда югалды» дигән мөһер белән, югалган самолётны эзләүне бөтенләй туктаттылар.

Чыннан да, эзләү озаккарак сузылган саен, һәлакәткә тарыган кешеләрнең исән-имин булуларына өмет тә югала бара иде. Никадәр генә алга киткән илдә яшәсәк тә, «олы дөнья»дан аерылган хәлдә кеше озак яши алмаячак. Хәзер инде көн генә түгел, сәгать узган саен, өметнең нечкә генә җепләре аяусыз өзелә бара иде. Өмет иң соңгы чиктә генә өзелә торган нәрсә. Бу көннәрдә Азаматны да бары тик өмет кенә яшәтте. Ул һаман нәрсәгәдер өметләнде, ышанычын югалтмады. Һәр телефон шалтыравын, менә яхшы хәбәр җиткерерләр, дигән өмет белән кабул итте ул.

Әнә шундый көннәрнең берсендә Азамат «Як» самолётын эзләү эшләре алып баручы төркем эшендә Татарстаннан вәкил буларак катнашкан Фоат Хәмитовичны өенә чакырды. Эзләү барышында җыйналган мәгълүматлар буенча экспертның фикерен белү иде исәбе. Гомумән, һөнәри белгеч буларак, Фоатның сүзе Азамат өчен бик әһәмиятле.

Очрашу рәсми түгел. Гадәти көнкүреш шартларында иркенләп сөйләшергә мөмкин. Рәсми даирәләрдә әйтелмичә калган фактлар да ачыла мондый вакытларда.

– Соңгы арада самолётларның техник хәле начарайды мәллә? – дип сүзне кырт башлады Азамат.

Фоат Хәмитович әлеге әңгәмәгә инде күптән әзерләнгән булса да, сүзне нәрсәдән башларга икән дип, аптырабрак калды. Чөнки самолётның сәер шартларда юкка чыгуы аның үзен дә гаҗәпләндерә. Үзең аңламаган нәрсәне башкаларга аңлатырга тырышудан да авыррак нәрсә бармы икән дөньяда?!

– Һич кенә дә алай дип әйтергә җыенмыйм, сәбәпләре бөтенләй башкададыр, мөгаен. Кече авиация шәхси кулларга сатыла башлагач, андый төрдәге самолётлар һавада куркыныч тудыра башлады. Хәзерге вакытта аларның күпчелеге бернинди

рөхсәтсез оча. Иң аянычы: «G» классына караган бу очкычлар, пассажир самолётлары оча торган юлга килеп кереп, аларның очышына куркыныч тудыра. «G» классында очучы самолётлар, нигездә, торак пунктлар булмаган урыннардан очарга тиеш. Шунысы өстенә һәвәскәр очучылар күбәйде. Дәүләт теркәве узмаган самолётлар да бихисап сан. Россиядә шәхси самолётларны теркәмәүнең тагын бер сәбәбе бар: «Як» кебек тотылган самолёт үзе йөзләрчә мең сум торса, аны рәсми теркәү өчен «Ространснадзор»га тагын шул кадәр акча чыгарып салырга кирәк. Еллык техник карау да 50 мең сумнан башлап 200 мең сумга кадәр төшә. Ә Америкада эшләнгән ыспай «Боинг» лайнерларының бәясе миллион долларлар белән исәпләнә. Әле бит аларны теркәү һәм техник карау өчен дә бермә-бер артык акча түләргә кирәк. Тик самолётны транспорт буларак түгел, ә җәмгыятьтә тоткан урынны күрсәтүче мөлкәт буларак бәяләүче миллионерлар, законнарны читләтеп булса да, шундый купшы очкычларга ия булырга омтылалар. Һәлакәтләр әнә шуңа күрә дә артты...

Азамат, сүзгә мавыгып, артык тирәнгә керә барган әңгәмәдәшен бүлдермичә булдыра алмады:

– Сабыр итегез әле! Безнең «Як» самолёты теркәлгән. Очышларга һәрчак алдан заявка бирелде. Самолёт югалган көнне дә очыш хакында тиешле органнарга алдан хәбәр ителде. Бу яктан бернинди дә шик булуы мөмкин түгел, – диде ул.

– Мин сезгә, самолётыгызны законсыз тоткансыз, дип әйтергә җыенмыйм. Бары тик шәхси самолётлар аркасында аварияләр еш була дип кенә искәртәм. Статистика буенча, Россиядә көн саен өч меңләп шәхси очкыч һавага күтәрелә. Шуларның нибары өчтән бере генә теркәлгән. Ә калганнары беркайда да исәптә түгел. Шуңа күрә дә Россиядә ел саен 250ләп шәхси очкыч мәтәлеп төшә икән.

– Ләкин аларны табалар бит. Ә безнең самолёт эзсез юкка чыкты. Менә шуны ничек аңларга?

Дөнья авиациясе тарихында самолётларның эзсез югалган очраклары байтак. Аларның югалулары да нindидер серлелек пәрдәсе артында. Мин шуңа күрә нәрсә дип аңлатырга да белмим.

– Мистиканың катнашы бар дип уйламыйсызмы?

– Бернинди дәлилләр булмагач, чынлап та, әллә нәрсәләр уйлый башладым инде...

– Мистика дигәннән, аптырагач, күрәзәчеләргә дә мөрәҗәгать итеп карадым бит әле мин.

– Нәрсә диделәр соң?

– Аларның әйткәннәреннән мине бернәрсә генә гаҗәпләндерде: талисманның фоторәсемен күргәч, алдан килешенгәндәй, икесе дә бер үк сүзне кабатладылар...

– Нинди талисман ул?

Азамат, өстәл тартмасыннан барсеткасын алып, аннан фоторәсемнәрне чыгарды.

– Менә шушы асылташның рәсемен күрсәткән идем. Алар икесе дә, хәзер бу асылташ күргәзмәдә яисә музейда саклана, диделәр.

– Нәрсәсе гаҗәп аның? Мин үзем дә, беренче карауда ук, бу затлы әйбернең урыны музейда яисә берәр ювелир кибетендәдер дип уйлап куйдым. Ә бу асылташның югалган самолётка нинди катнашы бар соң?

– Турыдан-туры... Бу кыйммәтле асылташны мин, иң оста зәркәнчедән ясатып, хатыныма бүләк иткән идем. Ул аны «мәхәббәт талисманы» итеп,

алтын чылбыр белән һәрчак муенына асып йөртте. Самолётка утырганда да... Шулай булгач, ул асылташ ювелир кибетендә дә, музейда да түгел, ә Сөмбелә кайда булса – шунда. Аның тәненә тиеп тора, – диде Азамат.

Шунда кинәт кенә Фоат Хәмитович рәсемне күзләренә әле якын китереп, әле ерагайтып карый башлады.

– Минем бу асылташны кайдадыр күргәнем бар... Нәкъ шушындыйны. Хәтерләмим генә бит...

***

Фоат чыгып киткәч, Азамат озак уйланды. Кара син аны, ул булып ул да, асылташны кайдадыр күргәнем бар, дип тора. Күргәне юк, әлбәттә. Ялгышадыр. Әллә соң зәркән ясау остасы нәкъ шундый ук асылташны тагын берне ясадымы икән? Затлы асылташ үзенчәлекле эшләнеше белән дә һәркемне үзенә җәлеп итәрлек. Килешле форманы табу өчен зәркәнче остага күп көч түгәргә туры килгән иде ул чакта. Азамат аңа эскизларны кат-кат эшләтте, кечкенә генә детальне дә күз уңыннан ычкындырмады. Куйган хезмәтләр юкка гына булмады, нәтиҗәдә, сокланып туя алмаслык сәнгать әсәре туды. Бәлки, талисманны Азаматка эшләп тапшыргач, ювелир остасы кемгәдер тагын шундыйны ясап биргәндер?..

Әлеге гаҗәеп талисманны эшләгән Зөбәер Гатин – Татарстанда гына түгел, тирә-як өлкәләрдә дә танылган ювелир остасы. Төрле шәһәрләрдә үз эшләреннән дистәләгән күргәзмә оештырган. Соңгы вакытта аралашырга туры килмәсә дә, аның телефон номеры Азаматның блокнотында саклана әле. Хәер, андый танылган кешеләрне эзләп табу алай ук кыен да түгел.

Кая, бер шалтыратып алыйм әле. Хәл белешү дә булыр, үземне борчыган сорауга җавап та алырмын дип, Зөбәернең телефон номерын җыйды.

– Әйе, тыңлыйм, – диде элемтәнең теге башындагы ир.

Аның бераз тыңкышрак ягымлы тавышын Азамат шунда ук таныды.

– Нихәлләрдә, Зөбәер әфәнде? Бу Азамат иде. Таһиров. Әгәр онытмаган булсагыз?..

Зөбәернең тавышы бермә-бер җанланып китте:

– О-о-о, Азамат Закирович! Шактыйдан тавышыгызны ишеткәнем юк иде. Эшләрегез ничек? – дип гөрелдәде ул трубкага.

– Эшләр бара...

– Тагын берәр ювелир әйбергә заказ бирергә уйлыйсызмы әллә? Теләсә кайсы вакытта үтәргә әзермен, Азамат Закирович. Теге вакытта без сезнең белән нинди асылташ ясадык бит, ә?! Уртак иҗат җимеше! Шедевр! Мәхәббәт талисманы дип атадыгызмы әле аны? Шә-ә-әп!..

– Әйе, шулай дип атаган идем. Минем бу шалтыратуым кабат заказ бирү өчен түгел. Хәл-әхвәлегезне белеп алыйм, дигән идем. Беррәттән әнә шул мәхәббәт талисманына кагылышлы соравым да бар иде.

– Тыңлыйм, Азамат Закирович, нинди сорау ул?

– Сез ул асылташ шикелле үк яисә аңа бик нык охшаган икенче талисман ясамаган идегезме? Бәлки, шәхси күргәзмәгезгә кую өчен, шуңа охшашрак берәр нәрсә эшләгәнсездер? Хәтерләп карагыз әле!

Трубкадан берара тавыш ишетелмичә торды. Зөбәер нәрсәдер уйлый иде кебек.

– Юк, андый нәрсә булмады, ышандырып әйтә алам. Ул бит бер минеке генә түгел, сезнең дә иҗат җимешегез. Аны шедевр хәленә китерү өчен, сез дә

киңәшләрегез белән күп көч куйдыгыз. Юк, уртак хезмәт җимешен үзләштерә торган кеше түгел мин. Мин анда ювелир буларак башкаручы гына идем...

Аннан соң, шикләнеп:

– Асылташка кагылышлы берәр күңелсезлек килеп чыкмагандыр бит? Кәефегез дә юк кебек тоела? Сөмбелә ханым ни хәлләрдә соң? – дип тә өстәде.

– Юк, аңа кагылышлы күңелсезлек килеп чыкмады. Ә кәефләргә килгәндә, безнең эштә төрле чаклар була. Гел елмаеп-көлеп кенә йөрмибез. Сөмбелә дә...

Азамат баштарак Сөмбелә белән килеп чыккан вакыйганы да әйтмәкче иде. Аннан кире уйлады. Туганы түгел, якын дусты түгел... Бу темага болай да башлар кайнаган. Тагын да сүз боткасы куертып торасы килмәде.

Шуңа күрә ул: «Барысы да тәртиптә. Калганын кабат очрашкач сөйләрмен», – диде дә телефонны куярга ашыкты.

«Карале, гел гаепсез кешедән шикләнә башладым. Нервлар беткән», – дип уйлады ул. Зөбәер сүзне бертөрле әйтеп, икенчене эшли торган кеше түгел.

Азамат суыткычтан башланган шешә алып, бәллүр бокалга коньяк салды да аз-аз гына йоткалап куйды. Шоколад кисәге сындырып, авызына капты. Чыннан да, соңгы көннәрдәге киеренке хәлләрдән соң, үзен бик алама хис итә ул.

Ни өчен Зөбәердән шикләнде соң әле? Ниндидер багучы хатыннар, талисманны кайдадыр, күргәзмәдәме, музейдамы күргәнебез бар дип ышандырырга маташкангамы? Алдау-йолдау юлы белән акча эшләп шомарып беткән ул адәм актыкларының ошатып кына сөйләүләре бик мөмкин. Азаматның үзенә дә шундый асылташ рәсемен күрсәтеп, бу кайдагы әйбер дип сорасалар, музейда яисә ювелир салонында, диячәк, әлбәттә. Кеше психологиясен бик яхшы аңлаган күрәзәче хатыннар, кыек атып туры тидерербез, бәлки, дип уйлап, музейда дигәннәр, билгеле.

Ә Фоат Хәмитович?.. Аны күрәзәче хатыннар белән чагыштырып булмый бит инде. Һәр сүзен төптән уйлап әйтә торган кеше. Картлык галәмәте, буталгандыр, дисәң... Фоатка картаерга иртәрәк әле. Ир уртасы кеше. Хәтере дә – күз тимәсен, тфү, тфү... Хаталанса гына инде. Аның һөнәре ювелир әйберләргә кагылышлы түгел бит. Үзе шул өлкәдә кайнамаган кеше өчен асылташ ни дә, чуерташ ни. Фоат, асылташ рәсемен күргәч, бөтен нечкәлекләренә төшенеп тә тормагандыр, бәлки. Кайчандыр шуңа охшаш берәр нәрсә күреп, шул исенә килеп төшкәндер.

Азамат әнә шулай итеп үз сорауларына үзе җавап эзләп маташты. Һәм үзен канәгатьләндерерлек җавапларны тапты да кебек. Һәрхәлдә, шикләреннән арынып, тынычлангандай булды.

***

Ләкин сорауларга җавап гел Азамат уйлаганча булмаган икән. Икенче көнне иртән Фоат кабат шалтыратты. Ул бераз дулкынланган иде. Хәл-әхвәлләр сорашкач:

– Азамат Закирович, дускай, кичә син миңа бер асылташ рәсеме күрсәткәч, мин, кайдадыр күргәнем бар, дигән идем. Син бу хакта оныткансың инде. Ә мин менә төне буе уйланып чыктым. Барыбер искә төшердем бит, әй, – диде.

Нишләп онытсын инде?! Азамат кичә үзе дә ничә сәгать буе шул хакта уйланып баш ватты лабаса. Күңеленнән шулай уйласа да, Азамат ул турыда артык сүз озайтмады. Аның Фоат авызыннан теге асылташны кайда күргәнен тизрәк ишетәсе килә иде.

– Әйт, кайда күргән идең? – дип кабаландырды ул Фоатны.

– Минем Нияз Хафизов исемле бер танышым бар. Галим-голәмәләр арасында кайнашучы, бераз сәеррәк адәм инде шунда. Бервакыт, ниндидер йомышым төшеп, аның өендә булырга туры килде. Аның китаплары бик күп. Шуларның берсен караштырып утырдым. Син күрсәткән асылташ рәсемен дә шунда күргән идем.

– Ялгышасыңдыр, дускай. Кичә син, күргәнем бар дигәч, үзем дә озак уйландым. Ялгыш күргәндер, икенче бер асылташ белән бутагандыр дигән нәтиҗәгә килдем.

Фоат, үзе дә шикләнгән шикелле, бераз эндәшмичә торды.

– Белмим инде, бәлки хаталанамдыр. Ул чакта шул асылташ рәсеменә сокланып, бик җентекләп караган идем. Ә мин бер мәртәбә күргән әйберне бик озакка истә тотам.

– Фоат Хәмитович, син ул танышыңда кайчанрак булган идең?

– Һм-м... Моннан өч-дүрт ел элек...

Аның әйтеп бетергәнен дә көтеп тормыйча, Азамат кычкырып көлеп җибәрде. Моңа үтә гаҗәпләнгән Фоат, әңгәмәдәшенең көлеп бетергәнен көтеп торды да:

– Гафу! Мин берәр ялгыш сүз ычкындырдыммы әллә? – диде.

– Юк, барысын да дөрес әйттең. Тик беләсеңме, монда бер каршылык бар: өч-дүрт ел элек ул «мәхәббәт талисманы»ның исе дә юк иде әле. Мин аны моннан ике ел элек зәркән остасы Гатин Зөбәергә заказ биреп ясаттым.

Элемтәнең теге ягындагы әңгәмәдәш тагын туктап калды. Сүз дә юк, Азамат китергән дәлил үз-үзенә нык ышанган, әле яңарак кына, мин күргән әйберемне озакка истә калдырырга сәләтле, дип торган кешенең мин-минлегенә тимичә калмагандыр. Азамат әңгәмәдәшен бу кыен хәлдән чыгару җаен карады:

– Фоат Хәмитович, андый гына ялгышулар була инде ул. Мин сине гаепләргә җыенмыйм. Әйдә, онытыйк бу турыда. Югыйсә, башка мөһим эшләр өчен күп вакытыбызны югалтабыз, – дип тынычландырырга тырышты.

Фоат, әле яңа гына йокысыннан уянган кеше кебек:

– Ә? Әйе, әйе!.. Бәлки ялгышканмындыр, – диде дә, бик дустанә генә саубуллашып, трубкасын куйды...

Азамат та, үз чиратында, шикләренең гел юкка гына булганлыгын уйлап һәм бу теманы ябылганга исәпләп, үзендә ниндидер бер җиңеллек тойды.

Тормышлар кабат үз эзенә төште. Ләкин аның бер эздән генә бернинди үзгәрешсез баруы Азаматны борчый иде. Чөнки Сөмбелә турында һаман бернинди хәбәр дә юк. Әнә шулай итеп, ай күрде кояш алды диярсең, кеше кадәр кеше югалды.

Ләкин ике-өч көн уздымы икән, Азамат тормышына яңа, тагын да гаҗәбрәк нәрсә килеп керде. Көннәрдән бер көнне Фоат Хәмитович аңа кабат шалтыратты:

– Нихәл, дускай? Әгәр вакытың булса, мин сиңа сугылып чыгармын дигән идем.

Азаматның эшендә дә, гомумән, тормышында да киеренке вакыт. Шуңа күрә әңгәмә куерту яисә хәл белешү өчен генә кем беләндер кара-каршы утыруны кирәк санамый. Ә монда Фоат шалтырата. Ул вакытны бушка уздыра торган кеше түгел. Әгәр килеп чыгарга уйлаган икән, ниндидер җитди сәбәпләре бар, күрәсең. Бәлки, Азамат өчен дә әһәмиятле нәрсәдер. Шуңа күрә, вакыты бик тар булса да, Азамат каршы килмәде, аны үзенә чакырды.

***

Фоат Хәмитович нәрсәдәндер бик дулкынланган. Ул Азаматның каршысына килеп утырды да, кулындагы «дипломат»тан бер китап алып, өстәлгә куйды. Нәрсә тапты икән инде моннан? Азамат китапны кулына алды. Тышлыгына күз төшерде. «Сәер табылдыклар», – дип кычкырып укыды ул.

– Азамат Закирович, кәгазь кыстыргыч куелган битен ач әле...

Азамат ашыкмыйча гына күрсәтелгән битне ачты... Аның кыяфәте күзгә күренеп үзгәрде. Авызы ачылган көе калды. Беравык хәтта сүзен әйтә алмыйча торды. Аннан ул ачык китапны өстәл өстенә тотып ыргытты да кәнәфиенең артына терәлеп, киерелебрәк утырды.

– Бернәрсә дә аңламыйм, – диде ул, учлары белән маңгаен тотып.

– Әйе, мин дә шул турыда баш ватам. Китапның тышлыгындагы исеме хәлгә бераз ачыклык кертә сыман...

Азамат кинәт урыныннан торды да өстәлдәге китапны кабат кулына алды һәм яңабаштан йотлыгып карарга кереште.

– Шайтан алгыры, ә бит, чыннан да, бу минем асылташ. Мәхәббәт талисманы. Монда бернинди шикләнерлек урын да юк. Мис-ти-ка! Башка сыймаслык хәл!..

Азамат китап тышлыгының беренче битен ачты. Аның датасына күз төшерде:

– Китап 2010 елда чыккан. Юк, юк, кара әле син, ювелир остасы әле асылташны ясарга керешмәгән, ә шуннан ике ел алдан чыккан китапта аның рәсеме бар. Моның булуы мөмкинме?

Фоат Хәмитович китапны үзенә сорап алды, актаргалап бер битен ачты:

– Тыңла, бу асылташ турында китапта менә нәрсәләр язылган. Әлеге асылташка 1974 елда Свердловск шәһәре тирәсендә казу эшләре алып барган археологлар тап була. Ул хәзерге заман технологияләренә нигезләнеп, бик хикмәтле формада эшләнгән. Иң гаҗәпләндергәне шул: асылташ табылган җир катламы моннан 250 миллион ел элекке перм чорына карый. Шуннан чыгып, галимнәр бу асылташка да шул яшьне бирәләр.

Фоат Хәмитович, инде монысына ни әйтерсең дигәндәй, әңгәмәдәшенә күз ташлады. Тик Азамат өчен бер миллион елы ни дә, 250 миллион елы ни – барыбер бер кебек. Карашыннан шуны аңларга була иде.

– Исеңә төшер әле, кеше кавеменә охшаш тереклек ияләре кайчан барлыкка килгән? – дип сүзен дәвам итте Фоат Хәмитович.

Азаматның кашлары җыерылды. Озак уйланганнан соң ул:

– Белмим. Дөресрәге, мәктәптә укып белгәннәр онытылган, – дип кенә әйтә алды.

Фоат Хәмитович, үзенең бу турыда күбрәк хәбәрдар икәнлеген күрсәтергә теләгәндәй, тантаналы рәвештә:

– Белүемчә, кешегә охшаган маймылсыманнар, ягъни приматлар моннан 55-60 миллион еллар элек яшәгән. Ә хәзерге кешегә охшаган акыллы затлар, ягъни Хомо Сапиенс моннан 40-50 мең еллар элек барлыкка килгән, – диде дә, китапны шапылдатып ябып, өстәлгә куйды.

– Сез... син... бу асылташ җирдә әле тереклек барлыкка килгәнче үк шул урында яткан димәкче буласыңмы?..

– Мин алай димәдем. Моннан 250 миллион еллар элек җир йөзендә кеше

кавеме булмаса да, тереклек булган. Ул чорларда җир йөзе динозаврлар белән мыжлап торган...

– Каян килеп чыккан икән соң бу асылташ ул чорга?

– Мондый сәер табылдыкларның бу беренче очрагы гына түгел икән. Дөнья буенча андый артифактлар бик күп. Күргәнеңчә, алар турында шактый гына калын китап чыгарылган. Бу китапта төрле гасырларда һәм елларда җир йөзенең төрле урыннарында табылган сәер табылдыклар турында мәгълүмат күп. Кайдадыр кечкенә самолёт моделе табылган, икенче бер урында сәгать механизмы, ике тәгәрмәчле велосипед, хәтта шул ук динозаврлар чорында заманча аяк киеме табаныннан калган, ташка әйләнгән эз дә тапканнар. Бу фактларның барысын да бер нәрсә берләштерә: аларны фәнни яктан аңлатып бирү мөмкин түгел.

– Шулай ук аңлатып булмаслык микәнни? Ә бит югыйсә, галим-голәмәләр, җир йөзендә фән аңлатып бирмәслек нәрсәләр юк, дип шапырынырга яраталар.

– Дөрес, әлеге табылдыкларны өйрәнүчеләр арасында кыю гына фикерлеләр дә бар. Андыйларның күпчелеге, әле кешеләр барлыкка килгәнче, хәтта динозаврлар яшәгән чорларга кадәр, җир йөзендә алга киткән икенче бер цивилизация булган, дип расламакчылар. Барлык табылдыклар шуларның акыл һәм кул хезмәте нәтиҗәсе, диләр.

– Ләкин асылташка аларның нинди катнашы бар соң? Ул заманнарда алга киткән цивилизация булган очракта да, алар нәкъ безнең заман зәркәнчесе ясаган талисманны ясый алганнармы? Инде безнең заманның зәркән остасы анда ясалган шушы таштан үрнәк алган дияр идек... Бу ташны ясаганда, остага караганда минем көчем күбрәк керде. Барлык эшләнмәләр һәм идеяләр минем аша узды. Ә мин бу китапны үз гомеремдә дә күргәнем дә, андый сәер табылдыклар турында ишеткәнем дә булмады.

– Әйе, сезнең асылташ очрагын элек яшәгән цивилизацияләр белән аңлатып булмый. Әгәр асылташ табылып, сез аны танымасагыз, аны да борынгы цивилизациядә яшәүчеләр эше дияр идек. Тик...

Фоат Хәмитович сүзен әйтеп бетермәде. Дөрес, ул алга таба ни әйтергә дә белми иде кебек. Шуңа күрә, ә үзең нәрсә уйлыйсың дигәндәй, әңгәмәдәшенә текәлде. Тик Азаматның нинди дә булса акыллы сүз әйтү түгел, барлык шушы мәгълүматны башына сыйдырырлык белеме дә юк. Ул бит гап-гади авыл малае. Тырышып-тырмашып тир түккән, үтә сизгерлеге һәм киеренке акыл хезмәте, сабырлыгы аркасында гына җәмгыятьтә үз урынын тапкан, югары дәрәҗәгә ирешкән кеше бит ул, фән әһелләренә генә таныш булган мондый сәер нәрсәләрне аңларга сәләтле түгел. Тагын бер атнадан дөнья базарында доллар курсының ничек үзгәрәчәген чамалап әйтеп бирергә мөмкин әле ул. Ә менә археологлар җир астыннан казып чыгарган әйбернең кайсы чорга караганын һәм ничек итеп анда килеп эләккәнен аның акылы белән генә фаразлап булмый...

Аның уйларын Фоат Хәмитович бүлде:

– Ә беләсеңме, тагын да үзгәрәк фикерле галимнәр дә бар. Әлеге очракны аларның фаразлары буенча аңлатып бирергә була.

– Алары нинди юрамалар тагын?

– Менә бу китапның авторы – Хафизов Нияз, нәкъ шундый теория өстендә эшли дә инде. Дөресрәге, ул физиканың җитдирәк тармагын өйрәнә. Ләкин бу табылдык асылташ язмышына кагылышлы кыю гына фикерләре дә бар. Сиңа аны күреп сөйләшү комачауламас дип уйлыйм.

***

Нияз Хафизов фатирына Азамат ялгызы гына бармады. Элекке танышы буларак, Фоат Хәмитович үзе дә иярде. Әңгәмәгә кереп китү тизрәк булыр, диде ул. Юлда барганда, Ниязның бераз гына сәеррәк кеше икәнлеген дә әйтергә онытмады.

Аның сәерлеген Азамат фатир ишеге ачылуга ук аңлады. Каршысында саргылт чәчләре бераз тузган, инде берничә көн кырынмаган, калын пыялалы күзлеген борын өстенә, ничектер, сәер итеп кыек утырткан, шакмаклы күлмәгенең түш төймәләре чишелгән, спорт чалбарының бер балагы кайтарылган, икенчесе идәнгә үк тиеп торган бер адәм чыгуга, аның Нияз икәнлеген чамалады.

Нияз, бик түбәнчелек белән кат-кат башын иеп: «Исәнмесез», – диде. Ул килүчеләрне тиз генә танымады. Күзе ияләнә төшкәч, Фоат Хәмитовичны танып, күрешергә кулын сузды. Аннан соң Азамат белән дә күреште. Кунакларны өйгә дәште.

Ике бүлмәле фатир бик тар һәм уңайсыз. Биредә теләсә кая чәчелеп, тарау-торау яткан өс киемнәреннән җыйнаксызлык күзгә ташлана. Фәкыйрь генә җиһаздан, кыршылып беткән обойларыннан фатирга инде күптән ремонт ясалмаганлыгын аңларга була.

Алгы бүлмәдә, Ниязның хатыны булса кирәк, бер ханым көзге каршында төзәтенеп маташа. Керүчеләрне күргәч, ул өстәлдә яткан сумкасын алды да чыгу ягына борылды. Кунаклар яныннан узганда, йөзендә нindидер мыскыллы елмаю чагылгандай булды. Авыз эченнән генә нәрсәдер мыгырданды. Аның ризасыз кыяфәтен күргәч, Азамат: «Җайсызрак вакытка туры килдек бугай», – дип уйлады. Алдан хәбәр итмичә килгәч, шулай инде, хуҗаларны уңайсыз хәлгә куюыңны көт тә тор.

Хатын артыннан ишек шапылдап ябылды. Ябу өчен кирәгеннән артыграк та көч куелды булса кирәк, алгы бүлмәдә торучы зур көзге дә зыңгылдады. Азамат уңайсыз атмосфераны тоеп, түргә үтәргәме-үтмәскәме дип, аптырабрак калды. Тик Нияз хатынының бу кыланмышына артык игътибар бирмәде. Бу хәл беренче мәртәбә генә түгел, аның мондый холкына инде күптән ияләнеп беткән, күрәсең.

Ул кунакларны бүлмәгә чакырды. Бу кечерәк кенә йокы бүлмәсен Нияз үзенә эш кабинеты итеп җайлаган икән. Уртада кечерәк өстәл. Стенаның бер ягын тулысынча диярлек китаплар шкафы алып тора. Өстәл өстендә иске фасондагы мониторлы компьютер. Янәшәдәге кечерәк журнал өстәлендә китаплар чәчелгән, ачылган көе идәндә ятучылары да бар. Күрәсең, өстәл өстенә сыймаганнарын үзе шунда куйган. Болай барысы да күз алдында бит.

– Сез хатынга игътибар итмәгез. Ул гел нәрсәдән булса да канәгать түгел, – дип кунакларны уңайсыз хәлдән чыгарырга тырышты хуҗа.

Кухня ягына үрелеп, аннан ике артсыз урындык алып керде дә утырырга тәкъдим итте.

– Фоатны беләм инде, ә сез, аңлавымча... – дип әйтә башлаган иде, аның сүзен Фоат Хәмитович дәвам итте:

– Бу теге көнне мин әйткән кеше инде. Таныш булыгыз: Азамат әфәнде. Сезгә аның авыр хәлдә калганын сөйләгән идем.

– Ә, әйе, әйе... Бик күңелсез хәл. Кайгыгызны... ни... авыр хәлегезне уртаклашам.

Нияз үзе дә ниндидер кайгы кичергән кыяфәт ясады. Бу аның шулай итеп Азаматка теләктәшлек күрсәтүе иде.

– Нияз әфәнде, сез күп еллар гыйльми эш белән шөгыльләнгән кеше буларак, бу вакыйгаларга нинди дә булса аңлатма бирә аласызмы? Сез тикшерә торган фәнни эшләр, берникадәр дәрәҗәдә, самолётлар югалуга кагыла бугай. Узган очрашу вакытындагы әңгәмәдән шулайрак аңладым. Фикерләрегезне Азамат Закирович белән дә уртаклаша алмассызмы?

Нияз, сүзне ничек башларга белмичә, бераз уйланып утырды. Киеренкелектән аның киң маңгаендагы җыерчыклары тагын да тирәнәйгәндәй булды. Ул уң кулы белән инде шактый чаларган чигә чәчләрен сыпыргалады. Ияк очындагы тырпаешкан төкләрен тикшергәндәй, чеметкәләп, йолкыгандай итте. Тамагын кырганнан соң, ниһаять, сүзләрен өзеп кенә сөйли башлады:

– Гыйльми эшләрем турыдан-туры самолётлар югалуга кагылмый, билгеле. Мин Фәннәр академиясенең вакыт үзенчәлекләрен өйрәнү институтында эшлим. Дөресрәге, эшли идем. Әле күптән түгел аннан китәргә туры килде. Кыскартуга эләктем. Безнең бүлекне гомумән яптылар. Фәнни коллегия тарафыннан мин эзләнүләр алып бара торган тармак кирәксез дип табылды. Үзен акламый торган эшчәнлек белән шөгыльләнә, дигән карар кабул ителеп, мине эштән кыскарттылар. Шулай булгач, кадерлеләрем, мин хәзерге көндә бөтенләй эшсез...

– А-а-лай икән, – дип сузды Азамат, галимнең хәленә кергәндәй.

– Дөрес, эштән китсәм дә, тик утырмыйм, – дип дәвам итте сүзен Нияз. – Вакытны физик процессларның агыш формасы буларак өйрәнүне дәвам итәм. Төгәлрәк әйткәндә, вакыт агышының акрынаюы һәм тизләнеше кызыксындыра мине. Вакытның турбулентлылыгы... Әйе, әйе, кадерлеләрем, вакыт өермә рәвешендә дә булырга мөмкин. Мин әнә шул юрама өстендә эшлим...

Нияз сөйләгән саен илһамлана гына барды. Аның күзләрендә ниндидер сәер очкын кабынды. Үзе фанатларча ышанган нәрсәне тыңлаучылар табылганга сөенеп, озаклап сөйләргә җыена иде кебек. Менә ул өстәл өстендә чәчелеп яткан кәгазьләр арасыннан нәрсәдер эзли башлады. Аларны актарган арада, алар ишелеп, идәнгә чәчелде. Галим аларны җыярга теләгән иде. Ләкин, киресенчә, бутап кына бетерде. Аннан соң кулын селтәде дә тарау-торау яткан кәгазьләрне читкәрәк сыпырды, өстәлдән үзенә кирәклесен эзләвен дәвам итте. Ниһаять, тапты булса кирәк.

– О-о, менә, – диде ул, кош тоткандай сөенеп, ике-өч кәгазьне өскә күтәрде. Аларны, тантаналы рәвештә, Азаматның кулына тоттырды. – Игътибар белән карагыз, хөрмәтлем, безнең тикшерүләр ахырына якынлашып килә иде инде... Тагын аз гына тырышсак... Менә монда барысы да ачык...

Нияз нәрсәнедер расларга теләгәндәй, үзенең сөякчел имән бармагын кәгазь битенә төртте. Тик формулалар белән чуарланып беткән биттә Азамат аңларлык бернәрсә дә юк иде. Ул, уңайсыз хәлдән чыгарга теләгәндәй, күзләрен челт-мелт йомгалады. Бәлки, аңлашыла торган язмасы шундадыр дип, кәгазьнең артын әйләндерде. Ләкин анда да шул ук формулалар һәм ара-тирә, «без дә бар бит әле монда» дигәндәй, саран гына язылган сүзләр очраштыргалый.

– Гафу, Нияз әфәнде, тик мин...

– Бернәрсә дә аңлашылмый, шулаймы?

– Мин мәктәптә укыганда да физиканы бик яратып бетерми идем... Ә монда, әнә, формулалар гына...

Фоат Хәмитович әңгәмәгә кушылуны кирәк тапты:

– Нияз әфәнде, әйдәгез әле, безне кызыксындырган мәсьәләгә якынрак килик.

– Ә-ә-ә, самолёт югалу турындамы?..

Тик ул җавап бирергә ашыкмады, киресенчә, үзе сораштыра башлады:

– Бәлки ул көн болытлы булгандыр? Яки томан?.. Идарәне югалткан самолёт берәр җиргә мәтәлеп төшкәндер дә...

– Юк, юк, ул көнне һава чалт аяз иде. Хәтта мәтәлеп төшкән очракта да аннан нәрсәдер калган булырга тиештер бит? Ә монда бөтенләй бернәрсә табылмады.

Нияз ниндидер авыр мәсьәләне хәл итәргә җыенгандай, эшлекле генә ишекле-түрле йөренде, тамагын кыргалады, ябык кулының учы белән, тырпаешкан тыңлаусыз чәчләрен артка сыпыргалады.

– Мин төп эшемнән тыш, аномаль күренешләрне өйрәнү белән дә шөгыльләнәм. Гайре табигый хәлләрне. Бу – минем хобби. Сер түгел, мондый күренешләрне, нигездә, энтузиастлар өйрәнә дә инде. Ә фән үзе аңлатып бирә алмаган теләсә нәрсәне инкарь итә. Ә аны аңлатырга тырышкан кешеләрне шарлатаннар дип атый...

Нияз озаклап сөйләргә җыена иде булса кирәк. Хәер, моны ул үзе дә яшермәде:

– Бу темага мин сезгә, хөрмәтлеләрем, сәгатьләр буе лекция укый алыр идем. Бик кызык ул...

– Әгәр самолёт югалуга нинди дә булса ачыклык кертердәй булса, без тыңларга әзер, – диде Азамат.

– Менә, тыңлагыз алайса... Мин әле студент елларымда ук аномаль күренешләр, гомумән, гайре табигый хәлләр белән кызыксына башладым. Курсташларым, мәхәббәт романнары укып, ләззәтле уйлар белән исереп йөргәндә, эзотерик китаплар укып җенләнә идем. Мин хәтта оча торган тәлинкәләргә, чит дөньялардан очып килгән гуманоидларга, полтергейстка, өрәкләргә һәм башка шундый гаҗәп хәлләргә кагылышлы язмаларны газеталардан кисеп алып, бер альбомга терки башладым. Алар миндә шактый җыелды. Әле һаман саклыйм...

Нияз, китап шкафының иң югары бүлемен ачып, аннан калын гына альбом алды да Азаматка тоттырды. Альбомның һәр битенә газета кисәкләре ябыштырылган. Вакыт һәм керләй саргайткан кәгазь кисәкләренә кайсы елда һәм нинди газетадан алынганлыгы пөхтәләп язып куелган.

– Мин аларны, нинди тематикага кагылышлы булуларына карап, аерып җыйдым, – дип дәвам итте Нияз «лекция»сен. – Шунысын да әйтим: анда сезне кызыксындырган сәер археологик табылдыклар турында язылганнары да байтак. «Сәер табылдыклар» дигән китабым нәкъ менә шуларга нигезләнеп язылды да инде. Төрле елларда җирнең төрле почмакларында табылган сәер әйберләр турында ул. Анда язылган әйберләрнең һәрберсенә «серлелек» мөһере сугылган. Әйтик, кайчандыр, әле динозаврлар яшәгән заманнарга ниндидер тешле тәгәрмәчләр яисә сәер механизм калдыклары каян килгән? Моны галимнәр ничек аңлатырга белми. Фән әһелләренең күпчелеге аларны күрмәмешкә салышудан артыгын булдыра алмый. Кыюраклары үз фикерләрен белдерергә тырыша, төрле юрамалар тәкъдим итә. Кешелек барлыкка килгәнче, җир йөзендә югары үсешкә ия икенче бер цивилизация яшәгән һәм әлеге сәер табылдыклар шуларның эшчәнлеге нәтиҗәсе дигән фикердә күпчелек. Чыннан да, бу иң ышанычлы юрама кебек. Ләкин монда бер каршылык бар, хөрмәтлеләрем.

Табылдыкларның кайберләре нәкъ менә безнең заман технологиясе белән эшләнгән. Мисаллар китерәм. Санкт-Петербург археологлары, Камчаткада эзләнү эшләре алып барганда, ниндидер механизмның ташка әйләнгән детальләрен табалар. Механизм яткан җир катламын тикшергәч, аның моннан 400 миллион ел элекке чорга караганлыгы мәгълүм булган. Кытайда бер борынгы каберлекне тикшергәндә, галимнәр кечкенә генә Швейцария сәгате табалар. Сәгатьнең эчке ягына «Swiss» дип гравёрлап язган сүзне дә укырга мөмкин була хәтта. Ягъни «Швейцария» дигәнне аңлата. Ә бу каберлекне 400 ел дәвамында беркем дә казымаган. Каян килгән анда заманча Швейцария сәгате? Тагын бик күп мисаллар китерә алам. Шулай булгач, хәзерге заман технологияләренә нигезләнеп төзелгән әйберләрнең табылуы элекке цивилизацияләр калдырган дигән юраманы юкка чыгара түгелме соң? Бу хәлне аңлатып бирү өчен башка юллар эзләргә кирәк. Мин тәкъдим иткән гипотеза буенча, әлеге әйберләр борынгы заманнарга вакыт аралыгы аша күчкән...

Әлегә кадәр галимне игътибар белән тыңлап утырган Азамат сабырсызлана башлады:

– Ягез, шуннан, ә самолёт югалуга боларның нинди катнашы бар соң?

«Лекция»сен бирелеп тыңлауларына куанган Нияз, үз бәясен белеп кенә һәм шул ук вакытта тыңлап утыручыларга аңлаешлы итәргә тырышып дәвам итте.

– Турыдан-туры катнашы бар. Альберт Эйнштейн турында ишеткәнегез бардыр дип уйлыйм. О-о, аны белмәслекме соң?! Егерменче гасырның иң даһи акыл иясе. Аның мәшһүр чагыштырмалылык теориясе генә дә ни тора бит! Чын мәгънәсендә фәнни шедевр! Бу картлач вакыт турында бик кыю фикерләр әйтеп калдырган. Алай гынамы, бөек галим аларны теоретик яктан исбатлап та биргән. Без вакытны нәрсә дип беләбез әле?

Нияз Хафизов мәктәп укучысыннан сорау алган укытучыга охшап калды. Ул, башын ия төшебрәк, күзлек өстеннән, үзен тыңлап утыручыларга текәлде. Сорауны ишеткәч, ничектер бөрешебрәк утырган Азаматка мыскыллы караш ташлады.

– Аңлашыла, сез мәктәптә укыганда, икеле капчыклары булгансыз. Укытучы биремнәрне тикшергәндә, алда утыручы иптәшегезнең киң җилкәсе артына посkансыз, өй эшләрен партадашыгыздан күчергәнсез, имтиханнарга кергәндә, учыгызга шпаргалка язгансыз... Фоат Хәмитович, бәлки, сез мәктәптә физиканы яхшы белгәнсездер? Исегезгә төшерегез әле.

– Вакыт – материянең үзлеге, – дип, дәресен бишлегә белгән укучыдай чатнатып җавап бирде Фоат!

– Нәкъ шулай, хөрмәтлем. Ләкин без, кешеләр, вакытны үткәннән киләчәккә таба юнәлгән, даими тизлектә агучы бер нәрсә итеп күз алдына китерәбез. Елгада су аккан кебек. Юкка гына, «гомер үтә аккан су кебек», дип җырланмыйдыр...

Фән корифее, мәзәк хәл турында сөйләгән кешедәй, елмаеп куйды. Ләкин ул халәте озакка бармады. Йөзе бик тиз җитдиләнде. Бу алга таба әңгәмәнең җитди булачагына ишарә иде.

– Гомуми чагыштырмалылык теориясе буенча, вакыт хәрәкәт итми. Пространствода бирелгән тизлек буенча үзебез хәрәкәтләнәбез. Без акылыбызга сыйдыра ала торган вакыт хәрәкәте, ягъни аның үзгәрүе, объектлар арасындагы ераклыкны үзгәртү яки бер объекттан икенче объектка таба хәрәкәтләнгәндә тизлекне үзгәртү ул. Эйнштейн бу теориясе белән физика өлкәсендә чын мәгънәсендә революция ясый. Җир йөзендә яшәүче без – гөнаһлы бәндәләрнең

акылы җитмәслек гаҗәп хәлләрне дә менә шул теория нигезендә аңлатып булыр иде...

Нияз маңгаена бөрчек-бөрчек бәреп чыккан тирне кульяулыгы белән сөртеп алды. Өстәлдәге стаканнан су эчте. «Аудиториядә студентлар каршында лекция укыгандагы кебек хис итә бу үзен», – дип уйлады Азамат. Ә лектор, бераз тын алгач, «лекция»сен тагын да кызыбрак дәвам итте:

– Вакыт могҗизалары турында сөйләгәнче, мин сезгә пространство хикмәтләре турында да әйтеп китмәкче булам. Пространствоның кәкрәйгән яки бөгелгән урыннары булуын берегез дә күз алдына да китерә алмас, мөгаен. Ә бит андый урыннар бар һәм теория буенча да күптән исбатланган. Менә бу мисал сезгә кызыклы булыр дип уйлыйм. Җирдән галәмгә ракета очты, ди. Ул галәм тирәнлегенә ераграк китә икән, кире әйләнеп кайтканда, бу ракетадагы космонавтның җирдә калган замандашларыннан берсе дә исән булмаячак. Чөнки галәмдә озак вакыт сәяхәт ясаганда, ракетадагы космонавт, әйтик, ун елга гына картайса, җир өстендә калганнар утыз, кырык елга картайган булалар. Бу мәсьәләгә кагылышлы тагын бер кызык нәрсәне әйтим. Галәмгә очкан космик корабльнең тизлеген арттырган очракта, вакыт агышы җирдә дә, космик ракетада да бердәй булырга мөмкин. Ә инде космик ракета тагын да зуррак тизләнеш белән очса, кире әйләнеп кайтканда, космик ракетага әле старт бирелгән чакка да туры килеп булыр иде хәтта. Яисә космонавт үзенең бала вакытына да кайта алыр иде. Әйтик, ул кайтканда, җирдә аны ун яшьлек малай чагы каршылый. Болар – теория, әлбәттә. Чынбарлыкта андый нәрсәгә ирешү өчен, космик ракета яктылык тизлегенә ирешергә, ягъни секундка 300 мең километр тизлектә очарга тиеш. Әлегә бу мөмкин түгел...

Үзенең ялкынлы чыгышыннан рухланып, һаман кыза гына барган Ниязны туктату һич мөмкин булмас кебек. Ул үзен тыңлап утыручыларны да күрми, аларны оныткан, бөтен барлыгы белән үзе генә аңлаган һәм белгән фән дөньясына кереп чумган иде.

«Бу хыялый үзенең фәне белән бөтенләй саташкан», – дип уйлады Азамат, аның акылдан шашкан кешенекедәй күзләренә карап. Ниязның фән дөньясына һаман тирәнрәк керә баруы һәм төп темадан читләшүе Фоатны да борчый иде булса кирәк. Ул да, сабырлыгын югалтып, инде менә икенче мәртәбә аңа:

– Нияз әфәнде, сез тагын мавыгып киттегез бугай, – дип, төп мәсьәләгә якынрак килүен үтенде.

Кинәт әйтелгән бу сүздән Нияз шып туктап калды, аптырау һәм гаҗәпләнү галәмәте чагылган күзләрен Фоатка текәде. Аның бу карашы иң кызык чакта уеныннан бүленергә мәҗбүр ителгән сабый баланыкын хәтерләтә иде. Шулай да ул тиз генә үз-үзен кулга алды. Инде тынычлана төшеп:

– Нәрсә турында сөйләшә башлаган идек әле? – дип кайтарып сорады.

Аның бу кыяфәтен күргәч, Азамат чак кына көлеп җибәрмәде. Сабый балалар самимилеге. Нәрсә белән булса да бик мавыгып китү, таркаулык. Таркаулык – даһилыкның бер сыйфаты, диләр. Әйе, әйе, бу хакта кайдадыр укыганы бар иде.

– Сүз башыбыз «Як» самолётының көпә-көндез бернинди эзсез юкка чыгуы турында иде, – диде Азамат, үртәлеп.

– Ә мин сезгә нәкъ шул хакта сөйләргә җыенам да инде. Вакыт дигән нәрсәнең без уйлаганга караганда күпкә гаҗәп икәнлеген аңлатмакчы булган идем. Вакыт аралыгы аша бер заманнан икенчесенә күчү, хәзергә әле исбатланмаса да, дөньяда була торган хәл. Күп кенә сәер вакыйгаларны,

шул исәптән, сезнең самолёт югалу очрагын да бары тик шуның белән генә аңлатырга мөмкин. Свердловск өлкәсеннән табылган менә бу асылташ, «мәхәббәт талисманы» дидегезме әле, нәкъ менә шуңа дәлил булып тора. Сезнең хатыныгыз утырган «Як» самолёты да Свердловск шәһәренә җитәрәк юкка чыккан түгелме?..

Азамат, әйтелгәннәрне аңлап бетердемме дигәндәй, сөйләнгән сүзләргә ачыклык кертүне кирәк санады:

– Самолёт, вакыт аралыгы аша узып, башка заманга күчкән, димәкче буласызмы?

– Дөрес аңлагансыз. Нәкъ шулай дип уйлыйм. Менә инде сез дә эшнең нәрсәдә икәнлегенә төшенә башладыгыз.

Нияз Хафизов, әле генә сөйләгәннәренең юкка булмаганына, әңгәмәдәшен үз сүзләренә ышандыра алуына куангандай, горур гына башын чөйде.

– Галәмдәге «кара упкыннар» турында ишеткәнегез бармы? – дип дәвам итте ул сүзен. – Андый вакыт-пространство чоңгыллары белән галәм мыжлап тора. Теоретикларның әйтүләренчә, вакытның гаҗәп могҗизалары шундый урыннарда була да инде. Нәкъ менә пространство бик нык кысылган һәм кәкрәйгән ул урыннарда вакыт өермәсе турында сүз алып барырга мөмкин. Дөрес, бу «кара упкыннар» читтән күренми. Чөнки очраган һәр нәрсәне үзенә йотучы әлеге комсыз чоңгыллар үзләреннән бернинди яктылыкны да, башка төрле нурланышларны да кире кайтармый. Шуңа күрә без аларны күрмибез. Вакытның турбулентлылыгын китереп чыгаручы андый чоңгыллар безнең Җир тирәсендә дә очраштыргалый. Кинәт кенә юкка чыккан кешеләр, әнә шул вакыт аралыгына эләгеп, элекке заманнарга күчүчеләр инде. Мин җыйган гайре табигый мәгълүматлар арасында аларга кагылышлылары да шактый.

Нияз Хафизов шкафта озаклап актарына торгач, ниндидер китап алды. Аның эчтәлеген игътибар белән карады да, бер битен ачып, кычкырып укый башлады:

– Бу хәл 1980 елда була. Ике альпинист тауга күтәрелә. Алдан баручысы арткарак калган иптәшенә борылып карый да гаҗәпләнүдән тораташ ката. Аның иптәше ниндидер синусоид формасына килеп бөгелә һәм өскә таба озынаеп сузыла башлый. Сузылган саен, нечкәрә бара һәм кинәт кенә юкка чыга. Җирдә аның боз чапкычы гына кала. Шунысы гаҗәп: ул тип-тигез урында җир йоткандай юкка чыккан. Һәм иптәшенең тирә-якны тикшереп чыгып эзләнүе бернинди дә нәтиҗә бирмәгән...

Нияз, китабын ябып, кире үз урынына куйгач, укыганына нәтиҗә ясагандай:

– Мондый мисалларны күпләп китерергә була. Шулардан чыгып, чыннан да, пространствоның теләсә кайсы өлешенә, теләсә нинди ерак араларга да, хәтта үткән яисә киләчәк заманнарга да мизгел эчендә күчү мөмкин дип уйларга нигез бар. Әлегә фәндә өйрәнелмәгән мондый күренеш телепортация дип атала. Ә инде һич көтелмәгән урыннарда кешеләрнең юкка чыгуына «кара упкыннар» сәбәпче булырга бик мөмкин. Димәк, шундый урыннарга очраклы гына туры килгән кешеләр мизгел эчендә башка урыннарга күчәргә мөмкин.

Теләсә кемне гаҗәпкә калдырырлык әлеге мисаллар Азаматның да күңелен кузгатты.

– Шулай күп мәгълүмат була торып та, аларның берсе дә фәнни яктан тикшерелмәгәнме? Монда инде очраклылык турында гына сүз бармый шикелле. Фактлар хәттин ашкан. Ничә еллар дәвамында җыелган күз алдындагы хәлләргә аңлатма бирә алмагач... – дип, үз фикерен әйтеп калырга ашыкты ул.

– Бу өлкәдә өйрәнүләр гел алып барылмаган дияргә җыенмыйм. 1943 елның октябрендә Америка Кушма Штатларының Хәрби диңгез көчләре тарафыннан «Филадельфия эксперименты» дигән киң масштаблы тәҗрибә үткәрелүе турында ишетеп беләсездер. Дөрес, моның турында бернинди рәсми мәгълүмат булмаган. Ләкин кайбер чыганакларга һәм, имештер, шунда катнашкан кешеләрнең матбугатка барып ирешкән азмы-күпме сүзләренә караганда, андый эксперимент булган дип исәпләнелә. Хәтта аларга Альберт Эйнштейн үзе җитәкчелек иткән дигән фаразлар да бар.

Тагын Эйнштейнга кереп китте. Болай булса, фәнни лекция озакка сузылмагае, дип исәпләгән иде Азамат. Тик бу юлы Нияз артык җәелмәде:

– Анда эксперимент объекты булган «Элдридж» эсминецы пространствода күз ачып йомганчы берничә дистә миль ераклыкка күчкән. Эсминец кадәр зур корабль пространствода күчеш ясый ала икән, вакыт-пространство өермәсе өчен бер моторлы кечкенә «Як» самолёты чүп кенә инде. Мин үземнең тикшерүләрдән чыгып, сезнең «Як» самолёты, вакыт барьеры аша узып, икенче заманга күчкән дигән фикердә. Шуңа күрә аның бернинди эзе дә табылмаган...

Нияз моны бер шәһәрдән икенче шәһәргә бару шикелле гадәти нәрсә кебек әйтсә дә, Азамат өчен бу башка сыймаслык хәл иде. Кеше, һич уйламаганда, хәзерге заманнан гаип булып, икенче заманга күчсен әле! Димәк, вакыт аша үткән заманнарга гына түгел, киләчәккә дә күчәргә мөмкин дигән сүз бит бу. Ләкин аны бер нәрсә борчый: вакыт аша күчкәндә, Сөмбелә исән була микән, әллә соң анда самолёты гына күчкәнме? Ул күңелен тынычсызлап торган бу сорауны Ниязга да бирде.

– Әйе, иң беренче чиратта хатыныгызның сәламәтлеге кызыксындырганы аңлашыла. Һм-м... 250 миллион еллар элек... Тик ул заманнар... җир йөзендә динозаврлар хакимлек иткән чор...

Нияз Хафизовның, һәр сүзен үлчәп, өзеп-өзеп әйтүеннән, үткән заманнарга күчүнең шактый ук куркыныч икәнен искәртергә теләве сизелеп тора. Уйлаганының бөтенесен дә әйтеп, әңгәмәдәшен куркытасы да килми иде аның. Җирдә аждаһага охшаган гигант тереклек ияләре яшәгән чорда; зур гәүдәле динозаврлар, үзләрен туендырып тору өчен, җир йөзен чын мәгънәсендә канлы көрәш мәйданына әверелдергәннәр, дисенме? Бер-берсен азык чыганагы итеп кенә күргән бу борынгы җанварларда, тереклек нигезен тәшкил итүче аксымның һәрчак табигый әйләнештә булганлыгы хакында әйтсенме?! Әллә соң, синең гүзәл хатының берәр динозаврга азык булгандыр, ә син бүләк итеп биргән кадерле асылташ – «мәхәббәт талисманы» шул куркыныч җанварның иткә туймас ашкайнату ситемасы аша узып һәм, әлбәттә, андагы ферментлар тәэсиреннән аз гына да зыян күрмичә, табигый юл белән тирәлеккә чыгарылгандыр да, археологлар казып алганчы, шунда 250 миллион ел буена бернинди үзгәрешсез ятачак дип, Азаматның йөрәген җәрәхәтләсенме?

Әнә шуңа күрә галим, сүзләрен уйлап әйтергә тырышып, әңгәмәсен дәвам итте:

– Хатыныгыз ул заманнарга исән-сау күчкәнме икәнлеген хәзер фаразларга гына кала, билгеле. Ләкин шул ук аңлатып булмаслык сәер хәлләр антологиясенә күз салсак, вакыт аша күчкәндә, кешеләрнең сәламәтлегенә зыян килми, дип уйларга да нигез бар. Әйтик, гел көтмәгәндә, Җир шарының теге яки бу өлешендәге шәһәрләрдә һәм авылларда элекке заманнардагыча киенгән кешеләр пәйда булган очраклар бар. Алар, гадәттә, үзләренең бу урынга каян һәм ничек эләккәннәрен аңлатып бирә алмыйлар. Үзләрен узган вакытларда яшәүчеләр итеп расларга тырышучыларның сүзләреннән чыгып, архивларда

тикшеренгәннән соң, чыннан да, алар әйткән елларда шундый исемдәге кеше яшәгәнлеге ачыклана...

Нияз Хафизов никадәр генә ышандырырлык итеп, тормыштан мисаллар китереп һәм фәнни яктан нигезләп сөйләмәсен, Азаматның аларга бик үк ышанып җитмәгәнлеге әллә каян күренеп тора. Хыял канатына чикләр юк шул, хыял белән кайчак чынга ашмастайга да ирешергә була. Ә аек акыл башкачарак хәл итә. Ул, тукта әле, булмастайга ышанма дип, хыялый уйларны тезгенләп тора. Азамат та әнә шундый халәттә...

– Хөрмәтле Азамат дускай, сезгә асылташны үз күзегез белән барып күрергәдер бәлки? – дип әйтеп куйды Нияз.

– Ә каян табарга соң аны?

– Хәзерге вакытта ул асылташның кайда саклануы минем «Сәер табылдыклар» дигән китабымда күрсәтелгән иде кебек. Хәтерем ялгышмаса, Мәскәүдәге бер археологик музейда ул...

Нияз Хафизов өстәлдә яткан китапны актарып, кирәкле битен ачты:

– Менә, рәхим итегез...

***

Мәскәү – зур шәһәр. Азамат белән Динарга музейны табу алай җиңел булмады. Ярый әле навигаторлары бар иде. Инде үзләре эзләгән урамны тапкач та, әле шактый әйләнгәләп йөрергә туры килде. Музей дигәннәре аулак кына бер почмакта, подвал шикеллерәк урында икән. Монда кешеләр дә аз йөри, керүче кеше бармы икән, дип уйланды Азамат.

Имәннән ясалган борынгы авыр ишек ачылуга, аңа тоташтырылган шалтырамалар үзара бәрелеп, чылтыраган тавыш чыгардылар. Артык зур булмаган бүлмәне алып торган музейның алгы ягындагы йомшак кәнәфидә йокымсырап утыручы бик үк яшь булмаган хатын, тавышка сискәнеп, «дерт» итеп китте, күзләрен ачты. Икенче бүлмәгә керә торган ишек янындагы утыргычта сканворд чишеп утыручы сак хезмәткәре дә, «эш»еннән бүленеп, керүчеләргә күтәрелеп карады.

Бу – төрле елларда һәм Россиянең төрле төбәкләрендә казып табылган археологик экспонатлар музее икән. Стена буена тезелеп киткән витриналарның пыяла капкачлары астында сөяк калдыклары, борынгы кешеләрнең эш һәм сугыш кораллары, бизәнү әйберләре, металл акчалар һәм тагын әллә нинди көнкүреш кирәк-яраклары бар. Алар барысы да билгеле бер кагыйдәләр буенча, хронологик тәртипә урнаштырылган. Һәрбер экспонатка аңлатма язуы куелган. Анда әйбернең кайчан, кайда һәм кем тарафыннан табылуы язылган.

Биредәге бердәнбер фәнни хезмәткәр – экскурсияче-гид хезмәтен дә башкаручы ханым: «Кызыксындырган сорауларыгыз булса, әйтегез, җавап бирәм», – диде. Сораулар бар иде, билгеле.

– Музеегыз кеше күзеннән еракта урнашкан. Махсус яшереп куелган, диярсең. Халык йөриме соң ичмасам? – диде Азамат.

Ханым үзләренең эшсез утырмауларын белдерергә ашыкты:

– Биредә кеше өзелми. Төрле уку йортларыннан, мәктәпләрдән еш киләләр безгә. Алар белән даими элемтәдә торабыз. Әле хәзер мәктәпләрдә каникуллар булгач кына килүчеләр сирәгәйде, – дип аклангандай сөйләнде.

Хәер, Азамат өчен болары әһәмиятле түгел. Сүз бәйләнеше өчен генә сорады. Аны хәзер бер генә нәрсә – «мәхәббәт талисманы» гына кызыксындыра. Ул шушы тирәдә генә түгелме икән дип, берничә өстәлне караштырды да, һәр бүлмәдәге экспонатны аерым-аерым карап чыгу шактый вакытны алачагын

аңлап, гидка үзен кызыксындырган төп сорауны бирде. Дөресрәге, ул аңа баштан асылташның үзләре белән алып килгән сурәтен күрсәтте дә:

– Менә бу рәсемдәге асылташка охшаган экспонат сакланмыймы сездә? – дип сорады.

Рәсемгә карагач, ханымның йөзе яктырып китте:

– Әйе, бу бездәге экспонат рәсеме, – диде ул, елмаеп. – Әйдәгез, мин сезгә аны күрсәтә дә алам.

Ханым аларны үзе артыннан ияртте. Тар гына аралык аша үтеп, тагын бер бүлмәгә килеп керделәр. Түрдә артык зур булмаган пыяла шкаф тора. Аның өске өлешенә «Необъяснимые находки» дигән язу эленгән. Янәшәдә генә Альберт Эйнштейнның телен чыгарып төшкән рәсеме. Азаматның бу рәсемне кайчандыр күргәне бар иде. Тик даһи акыл иясенең, әнә шулай балаларча шуклык белән төшкән рәсемен һич кенә дә аңлый да, башына да сыйдыра алмый ул. Гомумән, бу кешегә җитдилек хас дип уйлый иде.

Экскурсияче хатын аларны пыяла япкыч белән капланган бер экспонат янына алып килде. «Менә!» – диде ул, эзләгән әйберне табышуда зур ярдәм күрсәткән кешедәй, йөзенә тантаналы төс чыгарып...

Азаматка нәрсәдер булды. Ул кинәт кенә башы әйләнгәнен тойды. Әйтерсең, аяк астындагы идән чайкала башлады. Ул каядыр упкынга оча кебек. Ярый әле янәшәсендә Динар бар. Ул хуҗасының хәлен аңлап, җиңелчә генә аны терсәгеннән тотты. Хәер, бу вакытта Динар үзе дә Азаматтан ким гаҗәпләнмәгәндер. Алар каршында әле кайчан гына Сөмбеләә түшенә асып йөргән асылташ, «мәхәббәт талисманы» ята бит! Дөрес, ул бераз гына тоныкланган кебек. Ләкин ул, һичшиксез, шул асылташ – «мәхәббәт талисманы».

Әле кайчан гына ул Азаматның да, Сөмбеләнең дә шәхси әйбере иде. Аңа алар гына хуҗа иде. Ә бүген талисман бикле йозак астында. Ул дәүләт байлыгы булып исәпләнә. Азаматның аңа бернинди хокукы да юк.

Азамат акылы белән шуларны уйласа да, моны күңеле белән кабул итә алмады. Ул асылташны үзенең хәләл акчасына алды, зәркәнчедән зур акча түләп ясатты, иң затлы әйбер дип, сөеклесенә бүләк итеп бирде. Бу бит аның шәхси милке. Үз милкеңә үзең хуҗа булмагач, нәрсә инде бу?..

Әнә шуларны уйлаган Азаматның ачуы, ярсу булып, тышка бәреп чыкты. Ул бөтен тәне белән калтыранып куйды.

Аның сәер халәтен экскурсияче дә күреп алды.

– Сез үзегезне начар хис итәсезме әллә? – диде ул, хафаланып.

Ләкин Азамат аны ишетмәде дә. Ул, гомумән, бу минутларда беркемне дә ишетми, фани дөньяда бөтенләй гаме булмаган кеше кыяфәтендә тораташтай катып калган иде. Шулай булмый хәле дә юк...

Тик бераздан соң гына аның авызыннан:

– Бу асылташ минеке, – дигән сүзләр сытылып чыкты.

Гид, күзләрен түгәрәкләндереп, бер Азаматка, бер Динарга карады.

– Гафу итегез, нәрсә дисез?

– Бу асылташ минеке, – дип, катгый итеп, баягы сүзләрен кабатлады Азамат.

Экскурсовод, бер адым артка чигенде, чыгу ягына каерылып карады.

– Сез нәрсә, акылыгыздамы?

– Әйе, әйе, бу минеке. Мин аны әле моннан ике ел элек кенә сөекле хатыным Сөмбеләмә бүләк итеп биргән идем. Ул – безнең мәхәббәт талисманы...

Ярсыр дәрәҗәгә җиткән Азаматны Динар чак-чак кына тотып тора. Аны никадәр генә тынычландырырга тырышмасын, юкка гына...

– Акылдан шаштыгызмы әллә? Ике ел элек бүләк иткән идем, дисез. Экспонат астындагы язуга карагыз. Ул 1974 елда археологик казынулар вакытында табылган. Ә аның күпме вакыт җир куенында ятканлыгын беләсезме? 250 миллион ел! Әгәр тагын бер сүз әйтәсез икән, мин сак хезмәткәрен чакырачакмын...

Ләкин аның чакыруы кирәк булмады. Биредәге шау-шуны ишетеп булса кирәк, сак хезмәткәре үзе килеп керде дә билендәге каешка беркетелгән пистолет кобурасына ябышты. Ул Азаматны экспонатны урларга җыена дип уйлады булса кирәк. Эшне зурга җибәргәнче, моннан чыгып таярга кирәклеген чамалаган Динар, алгарак чыгып, хәлне аңлата башлады:

– Гафу, гафу, минем дустымның шулай өянәге килә торган гадәте бар. Курыкмагыз, сезнең экспонатларга беркем дә тимәячәк. Без хәзер чыгып китәбез, – диде дә, җиңеннән тотып, Азаматны үз артыннан сөйрәде.

Бусында Азамат карышмады. Ул кыска гына вакытка булып алган йомшаклыгыннан үзе дә оялгандай, Динарга буйсынып, чыгу ягына атлады. Ишек янына җиткәч, Азамат кабат экспонатлар саклана торган пыяла шкаф ягына борылып карады. Эйнштейн портреты... Әле бая гына, бирегә кергәндә, аның шук малайларча елмаеп, телен чыгарып торуын Азамат килештермәгән иде. Ә менә хәзер аның болай төшкән рәсеме бик урынлы кебек тоелды аңа. Бала чакта үзләренең дә бер-берсен шулай тел чыгарып үртәүләрен искә төшерде. «Бә-бә-бә», – дип үчекләп, кемнең дә булса булдыксызлыгыннан көләләр иде. Бу портретны тикмәгә генә куймаганнар монда. Ул экспонатлар карарга кергән һәр кешене: «Ә-ә, гаҗәпме? Дөньяда андый табышмаклар күп инде ул. Кешелек әле тиз генә аларның серенә төшенә дә алмас. Бә-бә-бә», – дип үртәп озата кебек.

***

Мәскәүгә барып, талисманның үзен күреп кайткач, Азамат нык үзгәрде, бөтенләй үз эченә бикләнде. Хәтта бизнеска кагылышлы төп вазифаларының кайберләрен тугрылыклы ярдәмчесе Динарга ышанып тапшырды.

Соңгы вакытта фәлсәфи уйлар тынгылык бирми аңа. Элегрәк ул фәннең бик көчле булуына чын күңеленнән ышана иде. Хәзер ышанычы югалды. Бу дөньяда фән аңлатып бирә алмаган әйберләр бик күп икән ләбаса! Әле кайчан гына, күрәзәчеләргә ышанмыйча, аларны шарлатаннар дип, көлеп йөргән иде. Ул сөйләшкән күрәзәчеләрнең асылташ турында әйткәннәре хак булган икән бит...

Тик Азаматның язмыш зилзиләләре алай тиз генә тынарга җыенмаган икән әле. Соңгы вакытта көннәр, атналар мәңгелекнең үзе кебек озак узды. Инде кичергәннәре дә аз түгел югыйсә. Ә язмыш аңа яңадан-яңа сынауларын чәпәп кенә тора. Әллә бу дөнья тоташ могҗизалардан гына торамы икән, дип уйлый башлады Азамат. Чөнки сынауның чираттагысы аны гаҗәпләндереп кенә калмады, һушын җибәрә язды...

...Гадәти иртә иде ул. Йокысыз үткән төннән соң, таң алдыннан азрак кына черем итеп алды Азамат. Хәер, аны черем итү дип тә булмый. Йокылы-уяулы төш күреп, саташып ятты шунда. Уянып, ике кешелек караватының читенә торып утыргач та, авызын ачып иснәнгәләп, күргән төшен искә төшерергә азапланды. Тик юкка гына... Күпме тырышып та, берни дә барып чыкмагач, урыныннан кузгалды. Шулчак аңа йокы бүлмәсендә тагын кемдер бар кебек тоелды. Артына борылып караган иде, имәнеп китте. Карават башына тотынып

торуы гына егылудан саклап калгандыр – анда ниндидер хатын-кыз ята лабаса. Йөзе белән тәрәзә ягына борылган, ә менә мендәргә чәчелгән чәчләре Азаматка бик таныш кебек күренде. Әйе, әйе, Сөмбеләсенекенә охшаган бит! Азамат, иртән уянгач, мендәр өстендә дулкынсыман таралып яткан әнә шул чәчләреннән сыйпап иркәләргә, назларга ярата иде сөеклесен. Нәрсә бу? Соңгы вакытта башыннан узган аяныч вакыйгалар психикасына зыян китермәгәндер бит? Галлюцинация башланмагандыр югыйсә. Әллә соң ул һаман төш күрәме, саташамы? Азамат ирексездән беләген чеметеп карады. Юк, ул уяу.

Шунда, әллә үзенә текәлгән караштан, әллә йокысы туйган – караватта ятучы хатын-кыз кулларын сузып киерелеп куйды, башын Азаматка борды. Йә, Хода!.. Бу – Сөмбелә үзе иде. Азамат тораташтай катып калды. Әле кайчан гына сөйгән хатынын исән-имин күрү өчен җанын бирергә әзер иде. Берничә көн элек кенә, Сөмбеләмнең нурлы йөзен бер генә күрсәм иде дип, Ходайга ялварды. Нинди генә могҗиза белән булса да хатынын үзенә кайтаруын сорады. Менә Сөмбеләсе каршысында ята. Теп-тере, исән-сау. Бу үзе үк могҗиза түгелмени?..

Әллә соң?.. Кайдадыр озаклап югалып торып, таң алдыннан сиздермичә генә ире янына кайтып яткан хатын турында нәрсә уйларга була?.. Ләкин Азамат мондый караңгы уйларын тиз онытты. Ул сөеклесен теләсә нинди шартларда кабул итәргә әзер иде. Тик үзендә аңа каршы атларлык көч юк. Аяклары тартмый. Сүз әйтергә теле әйләнми. Кулын сузып, кочагына алыр иде, кыршау белән уралгандай, бөтен тәне тораташ катып калган.

– Ә беләсеңме, сөеклем, мин нинди төш күрдем?..

Менә сиңа мә! Әйтерсең лә алар кичә генә икәүләшеп шушы ятакка башларын төрткәннәр. Төне буе сөю-сәгадәт бакчасының татлы җимешләреннән ләззәтләнгәннәр дә арып-талып йокыга талганнар. Әйтерсең, бу ятакны Азамат айлар буе ялгызы гына җылытмаган...

Берни әйтмичә, үзенә текәлеп торуы озаккарак сузылды ахры, Сөмбелә кабат телгә килде:

– Нишләп эндәшмисең, бәгърем?

Азамат, уянып киткәндәй, дерт итеп куйды. Бик авырлык белән генә телен әйләндереп:

– Синең нинди төш күргәнеңне беләм, кадерлем. Самолёт... бик борынгы заманнар... динозаврлар, – диде ул.

– Юк, юк, алары турында мин сиңа соңрак сөйләрмен. Ә менә хәзер генә, уяныр алдыннан гына күргән төшемне сөйләмәкче идем. Әгәр сине ул кызыксындырмый икән, динозаврлар турында сөйлим...

Сөмбеләнең соңгы сүзләре шундый гади килеп чыкты, әйтерсең лә динозаврлар безнең көндәлек тормышыбызда еш очрый торган гадәти тереклек ияләре һәм ул гомере буе шулар арасында яшәгән.

– Самолётыбыз Свердловск аэропортына җитәрәк кенә әллә нәрсә булды, – дип башлады сүзен Сөмбелә. – Очкычыбызның приборлары чыгымчыларга тотынды, ориентир югалды. Фәнис, никадәр генә «ас» очучы булмасын, ул да каушап калды. Штурвалны әле тегеләй, әле болай боргаласа да, самолёт аны тыңламады. «Шайтан алгыры... Берни дә аңламыйм... Юнәлешне билгели алмыйм», – дип сөйләнгәнен хәтерлим. Аннан соң самолётыбызның тәрәзәләрен куе ак томан сара башлагандай булды. Ул, һаман саен куера барып, сөт төсенә керде, бөтен дөнья ап-ак иде. Шуннан соң тәнемнең һәр күзәнәгендә көчле калтырау тойдым. Һуштан язганмын... Аңыма килеп, күзләремне ачканда, ниндидер таныш булмаган, үзем өчен бөтенләй ят җирдә ята идем.

Торып утыргач, ерак та түгел, кулына олы таш кисәге тоткан Фәнисне күреп алдым. Ул минем якка борылып та карамый. Каядыр алга текәлгән. Мин дә шул тарафка күз ташладым, 100-150 метрлап арырак, албасты шикелле тереклек иясен күрдем. Ул Фәнискә таба килә иде. Фәнис таш белән шуны каршыларга җыенган, күрәсең. Менә теге албасты якын ук килеп җитте. Миңа андый җанварлар кинолар, китаплар аша таныш. Динозавр, дип аталалар. Аждаһага охшаган бу ерткыч Фәнискә җитәрәк туктады. Аның янында Фәнис бөтенләй кечкенә булып күренде. Динозавр башын әле тегеләй, әле болай боргалап күзәткәннән соң, очлы тешле авызын зур ачып үкерә башлады һәм корбанына ташланды. Шул мизгелдә Фәнис кулындагы ташны динозаврга томырды. Ләкин ул ерткычка бернинди зыян да салмады. Аның гәүдәсенә килеп бәрелгән таш, стенага сибелгән борчак шикелле, читкә тәгәрәде. Ә җанвар... ә җанвар...

Сөмбелә сулкылдап еларга тотынды. Азамат хатынын кочагына алды. Шактый вакыт узгач кына, Сөмбелә, тынычланып, сөйләвен дәвам итте.

– Динозавр Фәнисне мизгел эчендә ботарлап-өзгәләп ташлады. Берничә минут узуга, кан исен сизеп булса кирәк, аның тирәсенә үзе шикелле үк албастылар җыйналды. Ә тегенең корбанын беркем белән дә бүлешәсе килми. Берәрсе якыная башлауга, ырылдап, өстенә ташлана. Санаулы минутлар эчендә Фәнис торган урында кызыл тап кына калды. Ялманып, тирә-якны иснәнгәләп йөрүче бер динозаврның күзе миңа төште. Миндәй җан иясен аның үз гомерендә дә күргәне булмагандыр, мөгаен. Шуңа күрә ул кабер салкынлыгы бөркеп торучы күзләре белән озак текәлеп торды. Бу нәмәрсә ашарга яраклымы-юкмы? дип тикшергәндер инде. Мин урынымнан кузгалырга теләп талпынып куйдым. Хәрәкәт итүче һәр нәрсәне ашарга ярый дигән хайвани инстинкт буенчамы, җанвар, авызын зур ачып, яман үкереп, миңа ташланды. Сакланырга бер коралым да юк. Тирә-якта ник бер агач, йә таш кисәге күренсен?! Динозавр миңа җитәргә дүрт-биш метр калгач, башка чарам юк, муенымдагы талисманны йолкып алып, аңа томырдым. Ләкин тидерә алмадым. Менә җанвар бөтенләй якында гына. Аның иләмсез зур ачылган авызын гына түгел, андагы һәрбер тешен ап-ачык күрәм. Әле алай гынамы, тешләре арасына кысылган ит калдыкларыннан чыккан яман сасы ис тә борыныма килеп бәрелде кебек. Тагын берничә мизгел һәм...

Сөмбелә, җаннарны өшетерлек дәрәҗәдә куркыныч мизгелләрне исенә төшереп, бөтен тәне белән калтыранып куйды...

– Ләкин шулчак могҗиза булды, – дип дәвам итте ул сүзен, бераз тынычлангач. – Ниндидер нечкә генә кызгылт нур, минем баш очымнан узып, динозаврның башына барып кадалды. Шул мизгелдә, җанварның коточкыч олы гәүдәсе, ком тутырылган капчык кебек, шапылдап җиргә ауды. Әлеге кызгылт нурның чыганагы, һичшиксез, минем артымда булуы аңлашыла иде. Алдарак җыелып торган ерткычлар төркеме турында да онытып, артыма борылып карадым. Миннән нибары йөз-йөз илле адым арырак һавада ниндидер түгәрәк очкыч асылынып тора. Аның көмеш сыман өслеге кояшта ялтырый, тирәли урнашкан түгәрәк яктырткычлары төрле төсләр белән җемелди. Динозаврга төбәп җибәрелгән әлеге нур менә шул очкычтан килә икән. Минем андый очкычларны рәсемнәрдә күргәнем бар иде...

– Оча торган тәлинкә?.. НЛО? – дип аның сүзләрен бүлде Азамат.

– Әйе, моңа кадәр күргән кешеләр тасвирлаган, оча торган тәлинкәләргә охшаган. Озак та үтмәде, «тәлинкә» җиргә төшеп утырды. Астагы люгы ачылып, аннан көмеш төсле киемнән ике кеше төшеп, миңа таба йөгерә

башладылар. Килеп җиткәч, кулларымнан тотып, сөйрәп диярлек, «тәлинкә»гә алып киттеләр. Күз кырые белән артыбыздан дәррәү ташланган динозаврлар көтүен күреп калдым...

Сөмбелә, шул чактагы куркыныч вакыйгаларны кабат кичергәндәй, сөйләвеннән туктап, озак кына бер ноктага текәлеп утырды. Киеренке тынлыкны бетерү өчен, Азамат үзе сорау бирде:

– Һәм син, оча торган тәлинкәгә утырып, күз күрмәгән, колак ишетмәгән ерак планеталарга сәяхәт кылдың инде, э-эме? Сириус йолдызының берәр планетасында кунак иткәннәрдер әле үзеңне? Безнең кояшка иң якын йолдыз Сириус дип беләм. Хәер, ераклыкның монда әһәмияте дә юк. «НЛО»лар теләсә нинди ераклыкны мизгелләр эчендә үтә ала, дип ишеткәнем бар иде. Планетасын гына түгел, Йолдызын да иң заманча телескоплар белән күреп булмаган, бездән миллионнарча яктылык елы ераклыгында урнашкан берәр планетага барып чыккансыздыр әле?..

Сөмбеләнең йөзе кабат кояштай балкыды:

– Юк, белмәдең. Мин күргәннәрне син күз алдына да китерә алмаячаксың. Без бернинди чит планетага да очмадык. Җирдә калдык. Мин ерак планеталарга түгел, ә киләчәк заманнарга сәяхәт кылдым. Киләчәк заманнарда булып кайттым бит, бәгърем, аңлыйсыңмы?..

Азамат кылт итеп Нияз Хафизовны исенә төшерде. Ул да чорларның бер заманнан икенчесенә күчә алуы турында сөйләгән иде. Аның фаразлары дөрескә чыга түгелме?

– Әгәр сер булмаса, кайсы заманнарга барып җиттең соң?

– Аңлавымча, егерме икенче гасырның урталары иде...

– Нинди телдә аңлаштыгыз?

– Үземне коткарган ике кешедән башка беркемне дә күрмәдем. Чөнки мине карантинда тоттылар. Ул заманнарда йогышлы чирләрдән тулысынча арынганнар икән инде. Шуңа күрә борынгы заманнардан килгән кешеләрнең йогышлы авырулар таратуыннан саклану йөзеннән, алар белән аралашмыйлар, ара саклыйлар. Аларда бер заманнан икенчесенә күчү – гадәти бер нәрсә. Безнең татар теленә бик якын телдә аралаштык. Һәрхәлдә бик җиңел аңлаштык. Вакыт аралыгы аша күчешнең фәнни теориясенә нигез салучының да татар кешесе булганлыгын әйттеләр миңа. Аның голографик портретын да күрсәттеләр хәтта. Исеме... исеме Нияз Хафиз кебек. Хәтерлим, аның сурәте астына «Максатлы эшнең ахыры хәерле була» дигән канатлы сүзләр дә язылган иде әле...

– Нияз... Хафиз? – дип көчкә телен әйләндереп сорады Азамат.

– Әйе, әйе, Нияз Хафиз! Ә нигә гаҗәпләндең аңа?..

Соңгы вакытларда булып узган вакыйгалар Азаматның башын тәмам әйләндергән иде. Гайре табигый хәлләргә кагылышлы мәгълүмат ташкыны, әллә соң саташаммы, дигән уйларга этәрә. Ә андый мәгълүматны аз-азлап кына сеңдерү өчен вакыт кирәк. Вакыйгалар агышын ашыктырырга һич кенә дә ярамый. Шуңа күрә Нияз Хафизов турында сүзне озынга сузарга теләмәде ул.

– Андый исемне каядыр ишеткәнем бар иде, – дию белән чикләнде...

Нияз Хафизовның тузгыган тыңлаусыз чәчләрен, төк баскан какча яңакларын күз алдына китерде Азамат. Эшләү өчен аз гына мөмкинлек, шартлар тудырылмаган көе дә ул нинди зур эшкә тотынган бит әнә! Кыскартуга эләктем, ди. Бүгенге көндә эшсез. Хезмәт хакы юк дигән сүз. Кеше ничек яшәргә, гаиләсен ничек туйдырырга тиеш? Ә ул шулай да яшәргә тырыша. Димәк,

исеме киләчәккә барып ирешкәч, ул кеше фәнни эшләрен ташламаган, дәвам иткән һәм ахырына кадәр җиткергән булып чыга инде. Нәкъ кирәкле вакытта, кирәкле урында Сөмбеләне динозаврлардан коткарып калу да шул Нияз башлаган эшкә бәйле түгелме икән? Талисманны тикшергәч, ул заманнардагы фәнни теорияләр буенча, пространство һәм вакыт координаталарын билгеләү авыр булмагандыр. Вакыт аша күчеш мөмкинлеге килеп тууга, иң беренче эш итеп, Сөмбелә күчкән заманга «очкан» булулары ихтимал...

– Киләчәк матурмы? – дип сорап куйды Азамат, уйларыннан бүленеп.

– Искиткеч! Дөрес, мин шәһәр урамнарында йөри алмадым, кешеләр белән дә аралашмадым. Алдан әйткәнемчә, карантинда тора идем. Төрле заманнарда яшәүчеләр белән аралашу гадәти хәл, күрәсең, карантинда утыручылар бер мин генә түгел идем. Ә мин барлык уңайлыклары тудырылган һәм безнең шушы заманга туры килерлек зәвык белән җиһазландырылган бүлмәдә яшәдем. Миңа голографик картиналар күрсәттеләр. Шулар аша киләчәк кешеләренең көнкүрешләре, яшәешләре белән таныштым. Аларның тормышын сүзләр белән генә аңлатып бетерерлек түгел. Ул заманнар бөтенләй икенче дөнья кебек. Мин сиңа берәр вакыт бу хакта озаклап сөйләрмен әле, бәгърем.

– Ә ничек минем ятакта пәйда булдың соң син? Ни өчен мин бернәрсә дә сизмәдем?

– Мине шул ук оча торган тәлинкәдә безнең заманга китереп куйдылар. Син, төнлә уянып, тәрәзәдән күк йөзен күзәтә идең. Тәлинкәне күрдең. Тик очкычтагылар сиңа үзләренең нур чәчкеч приборларын төбәгәч, һушыңны югалттың. Ә күргәннәреңне хәтереңнән «сөрттеләр». Шуңа күрә син ул вакыйгаларның берсен дә хәтерләмисең. Бәлки, төш күргәндәй булгансыңдыр...

Азамат, нәрсәнедер хәтерләргә тырышкандай, кашларын җыерды. Ләкин күпме генә уйламасын, төнге вакыйгаларны исенә төшерә алмады. Аннары барысына да кул селтәде дә:

– Динозаврларга азык булган Фәнис кызганыч, – дип әйтеп куйды.

– Ә ул исән, – диде Сөмбелә, берни булмаган кыяфәттә.

Менә сиңа кирәк булса, иске авыздан яңа сүз! Азаматның күзләре маңгаена менде.

– Карале, кадерлем, әле менә яңарак кына, Фәнисне динозавр ялмап, ашап бетерде, дигән идең түгелме? Инде исән, дисең. Мин саташа башладыммы әллә?

Сөмбелә энҗедәй ак тешләрен күрсәтеп, матур итеп елмайды. Иңнәреннән кочып, Азаматны тынычландырырга ашыкты.

– Юк, саташмыйсың. Борчылма, Фәнис исән. Киләчәк заманнарга кайтып, Фәнисне кызганып, балавыз сыгып утырганымны күргәч, мине динозавр авызыннан йолып алган кешеләр ни өчен кайгыруымны сораштылар. Мин аларга Фәнис турында әйткән идем, шуларның берсе, аны коткару мөмкин эш, диде. Мин дә башта, синең шикелле гаҗәпләнеп, авызымныачып калдым. Аны борынгы җанвар ашап бетерде бит инде, үлгән кешене ничек коткарырга була соң, дим. Алар елмаешып куйды. Вакытның катлы-катлы булуы һәм өермәлелеге турында нидер аңлатып маташтылар. Ләкин мин аларның берсен дә башыма сыйдыра алмадым. Безнең заман кешесе өчен акыл ирешмәслек нәрсәләр! Кыскасы, шул ук вакыт могҗизасы! Фәнисне динозавр ашаганчы булган мизгелләргә вакыт аралыгы аша күченеп, аны динозаврлардан йолып калырга була икән. Һәм шулай эшләгәннәр дә. Үзебезнең заманнарга күченер алдыннан, мине азга гына Фәнис белән очраштырдылар. Ул исән-сау.

Кәефләрем яхшы, диде. Соңыннан, карантин вакыты узгач, аны да нәкъ минем шикелле, безнең заманга кире кайтарачаклар...

Юк, болары Азаматның башына барып җитә алмады. Аның акылы өчен кирәгеннән артык катлаулы нәрсәләр...

***

...Сөмбелә табылды. Аның шулай кинәт кайтып керүе Азамат өчен бер яктан сөенеч булса, икенче яктан кыенлыклар да китереп чыгарды. Моны кешеләргә ничек аңлатырга? Ай дәвамында бөтен җәмгатьчелекне аяк өстенә бастырдылар бит. Югалган самолётны эзләүгә кемнәр генә җәлеп ителмәде!.. Иң оста эзтабарлар, иң заманча эзләү чаралары эшкә җигелде. Ә самолёт җир йоткан шикелле юкка чыкты. Аның белән бергә Сөмбелә дә югалды. Инде менә һич көтмәгәндә кайтты да керде. Аның шул рәвешле кайтуы бер гаҗәп булса, сөйләгәннәре тагын да искитмәле. Кешеләр шуңа ышанырлармы? Кемгә дә булса ул хәлләрне расларга маташу үзеңнән көлдерү булмасмы? Хатыным мине кызык итәргә теләп, ай буе кайдадыр качып яшәгән яисә сөяркәсе куенында булган, дигән сүзләргә ышаначаклар. Ә менә, хатыным киләчәк заманнарга күчеп, вакыт аша сәяхәт итеп йөргән, дисәң, кычкырып көләчәкләр. Чигәләренә бармакларын куеп бөтерәчәкләр, әмма бу сүзләргә һич ышанмаячаклар. Ә Азамат үзе ышаныр идеме? Юк, әлбәттә. Моннан берничә ай элек кемдер аңа бу хакта сөйләсә, ул аны җитди кабул итмәс иде. Әкият сөйләп йөрмә дип, кул гына селтәр иде.

Ә менә фән әһелләре, галим-голәмәләр бу хәбәрне ничегрәк кабул итәрләр иде икән? Берничек тә! Тыңлап та тормаячаклар. Юкса, гасырлар дәвамында кешеләр аңында ныклап формалашкан фәнни теорияләрне, теоремаларны, пастулатларны яңадан карап чыгарга туры киләчәк. Гыйлем ияләре фәндә революция ясардай яңалыкларны кабул итәргә әзер түгел. Алар яңага тотынганчы, искегә ябышып ятуны кулайрак күрәчәк. Гомумән, кешелек дөньясы яңалыкларны авыр кабул итүчән. Урта гасырларда яңалык кертергә маташучы галимнәрне инквизиция кырса, әле кайчан гына бастырсалар, әле якын үткән заманнарда, башкалардан үзгәрәк уйлаучыларны «сары йорт»ларга тыгып котылганнар. Хәзер исә андыйлар, Нияз Хафиз кебек, җәмгыятьтән кысрыклана. Фән тармагында гына түгел, әдәбият-сәнгатьтә дә, эстрадада да «новаторлар»ны бик өнәп бетермиләр. Бу очракта да шулай булачак. Матбугат бер кат шаулап алыр, билгеле. Ләкин Сөмбелә ирен кызык итәргә теләп, ай буе шәһәр кунакханәләренең берсендә качып яткан да инде менә сагындырып кына аның янына кайтып кергән, дигән сүзләр кешеләр өчен чын дөреслектән якынрак булачак. Чөнки аларга шулай кызыграк...

Азамат – соңгы елларда бер китап та укып карамаган кеше – Нияз Хафизовның «Сәер табылдыклар» дигән китабын бу көннәрдә кулыннан төшермәде. Вакыт аша күчешкә кагылышлы бүлекләрен укыганда, аны гаҗәпләнү катыш хафалану биләде. Фәндә аңлашылмаган урыннар әнә бит ничек күп икән! Бөтен көч белән шуларны өйрәнәсе бит югыйсә. Ә фән, киресенчә, үзе аңлатып бирә алмаганнарны инкарь итәргә генә белә. Профессорлар, докторлар кебек гыйлем ияләре белән дөнья тулган. Аларның күпчелеге мондый эшләрдә бармакка бармак та тидерми кебек. Нияз Хафиз әйткәнчә, бүгенге көндә гайре табигый хәлләрне аңлатып бирү тулысынча энтузиастлар өстендә. Хөкүмәттән бернинди ярдәм дә күрмичә, алар бу өлкәдә нәрсәдер эзләнәләр әле. Эш өчен заманча лабораторияләр турында әйтеп тә торасы юк, хәтта хезмәтләре өчен бернинди гонорарларга да өметләнә алмыйлар. Аларның фәнни юрамаларын фән

аксакаллары чигә тирәсендә бармакларын бөтереп кенә бәяли. Бу энтузиастлар әнә шундый гомуми кинаяле көлү астында гыйльми эшләр белән шөгыльләнеп яшәп яталар. Яшәпме, әллә көн күрергә тырышыпмы?..

Уйлый торгач, Нияз Хафизга финанс ягыннан ярдәм итәргә, дигән катгый карарга килде Азамат. Ул аңа эшләү өчен бина бирә ала, кирәк булса, кыйммәтле җиһазлар алырга да ярдәм итәчәк, эшенә карата лаеклы хезмәт хакы да бирәчәк. Миллионнар, миллиардлар белән эш йөртүче кеше өчен мөмкин эш бу. Әгәр Нияз гыйльми эзләнүләрен ташлый икән, фән өчен зур югалту булачак. Галимнәр фәннең әлеге тармагына бүгеннән ныклап тотынсалар, йөзләрчә еллар узгач, чыннан да, вакыт аша очраклы «кара упкыннар»дан түгел, ә ясалма күчеш каналлары аша да киләчәккә ашыгу һәм үткәнгә җиңел генә кайту мөмкин булыр. Кайчан да булса кемдер бу эшне башларга тиештер бит инде?! Иң соңгы чиктә, үткәннәргә кайтып, Сөмбеләнең динозаврлар авызыннан котылып калуы хакына бу эш башланырга тиеш...

***

Азамат, ярдәм итәргә дигән ният белән, Ниязның өенә китте.

Ишекне хуҗа үзе ачты. Тик Азаматны танымады булса кирәк, бернинди соравын да көтмичә, аклангандай:

– Ни... Мин акча тапмаган идем шул... Минем әле түләрлек акчам да юк... Әгәр тагын бераз сабыр итсәгез... Фәнни эшләрем өчен гонорар бирәчәкләр... Бирерләр, дип уйлыйм...

– Нинди акча?.. Нәрсәгә? – дип кайтарып сорады Азамат, аңламыйча.

Нияз ишектән керүчегә калын пыялалы күзлеге аша игътибар белән карады:

– Ник, сез суд приставы түгелмени? Беркөнне, коммуналь хезмәтләр өчен бурычыгыз күп җыелган, түләмәсәгез, фатирыгызны бушатырсыз, дип килеп әйткәннәр иде. Ул сез түгел идегезмени?

Аннан соң Азаматны кайда күргәнлеген исенә төшерде бугай:

– Ә-ә, сез теге... ни... хатыныгыз самолёт белән югалган... Әйе, әйе, шул кеше икәнсез. Гафу итегез, мин бит пристав акча даулап килгәндер, дип уйлаган идем.

Өй эчендә теге көнге шикелле үк тәртипсезлек: әле тегендә, әле монда китаплар, кәгазьләр аунап ята. Һәм шулар чолганышында, бүлмә уртасында мескен хәлдә Нияз басып тора. Ул тирә-якка чәчелгән кәгазьләренә караган да туктаусыз үзалдына сөйләнә:

– Хәлләр мөшкел бит әле, хөрмәтлем. Акча бетте. Хатын ташлап чыгып китте. Түли алмагач, фатирдан да куып чыгарсалар... Вакытлыча гына булса да берәр эшкә урнашыргамы инде?.. Тәмамлыйсы гыйльми эшләрем бар... Беләсезме, алар бик әһәмиятле... Минем теория буенча...

Ул менә хәзер үзенең теориясен сөйли башларга җыенгандай талпынып куйды. Тик башлаганын әйтеп бетермәде. Чарасызлыктан нишләргә белмичә, кулларын як-якка җәйде.

– Сез ул фәнни эзләнүләрегезне дәвам итәчәксез, әлбәттә. Күзегезгә карап вәгъдә бирәм, – диде Азамат тыныч кына.

– Ничек? Аңламадым... Сез миңа эш тапмакчы буласызмы?

– Эш булыр анысы. Мин сезгә фәнни эшләр белән шөгыльләнергә мөмкинлек таптым кебек. Ә хәзерге вакытта сезгә нинди ярдәм кирәк? Тартынмыйча әйтегез.

Нияз, бу кеше чынлап сөйлиме, әллә үрти генәме, дигән кебек, шикле карашы белән әңгәмәдәшенә текәлде. Азамат аңа хәзер акча кирәклеген үзе

дә чамалый. Фатир өчен бурычлар бар, диде бит. Юкса, чыннан да, куып чыгарырга да күп сорап тормаслар.

Азамат «дипломат»ына тыгылып, аннан ике төргәк акча алды да өстәлгә куйды. Аларны күргәч, Нияз ачкан авызын ябарга да онытты. Бары тик бераздан соң гына һушына килеп:

– Юк, бу кадәр акча кирәк түгел. Мин ул кадәр акчаны кире кайтарып бирә алмаячакмын. Әле гонорар бирерләрме, – дип сөйләнде. – Әгәр эш тапсагыз, мин эшләргә алыныр идем. Мин беразга гына йөк төяүче-бушатучы булып эшләргә дә риза...

Ләкин Азаматның тавышы кискен яңгырады:

– Алыгыз! Боларны фәнни эшләрегезгә гонорар дип уйлагыз...

Шулчак кинәт кенә өстәлдә эшләп торучы компьютер чылтырый башлады. Бу интернет элемтәсе – «скайп» иде. Нияз, кабаланып, «мышка»га барып ябышты. Аның төймәсенә басты. Бераздан экранда бер хатын-кызның кыйшайган йөзе пәйда булды. Азамат Ниязның хатынын шунда ук танып алды. Теге көнне килгәндә күреп калган иде бит...

– Нәрсә, ялгыз яшәү рәхәтме? – дип кычкырды ханым.

Бу сүзләрнең, иренең хәленә керүдән бигрәк, ачуын басарга җыенудан әйтелгәнлеге аның кыяфәтеннән үк күренеп тора. Кереш сүзе, үзенчә... Әгәр шуларга каршы берәр җавап ишетсә, бөтен ачуын чыгарырга әзер ул.

– Рәхилә!.. Син бигрәк инде... Әлбәттә, читен синсез, – дип аклангандай сөйләнә башлады Нияз һәм хатынының кармагына килеп тә капты. Эх, син, мәми авыз! Эндәшми калсаң, нәрсә була иде?! Хатынның кабынып китүенә шул сүзләр җитә калды:

– Хәчтерүш, әлегә кадәр яшәвең белән миңа бурычлы син. Мин булмасам, бетәсең бит. – Рәхилә, сүзләрен үтемлерәк итү өчен булса кирәк, үкереп елый башлады. – Син бәдбәхеткә кияүгә чыгып, чәчкәдәй яшь гомеремне әрәм иттем. Укыганда, талантлы кеше чыгар дип, бик күтәргәннәр иде шул үзеңне. Мин дә, галим чыгар, дәрәҗәсе дә югары, акчасы күп булыр, дип уйлаган идем. Өметләрем акланмады. Синең белән бергә укыган Вил Тимурович, әнә, югары даирәләр арасында кайнаша. Докторлыкны яклады. Эше бар. Акчаны көрәп ала, диләр. Син, мәхлук, кандидатлык диссертациясен дә рәтле-юньле яклый алмадың бит. Фәннең төплерәк тармагында да эшләргә мөмкинлек биргәннәр иде югыйсә. Ә син, хыялый, тормышка ашмас нәрсәләр белән баш ватып, вакыт әрәм итәсең...

Хатын һаман саен ярсый гына барды. Сөйләгән саен йөзендәге кызыл тимгелләр артты гына. Нияз, аны тынычландырырга тырышып:

– Рәхилә, дим. Зинһар өчен, чәпчемә әле. Күрәсең, өйдә үзем генә түгел. Кунак бар...

Арттарак торган Азаматны Рәхилә шунда гына күреп алды. Аның кыяфәтендә мыскыллы елмаю чагылып узды. Ул тагын да ныграк чәпчергә тотынды:

– Кунак, имеш. Беләм мин синең кунакларыңны. Аралаша торган кешеләрең арасында бер җүнле кеше бар дип беләсеңме?.. Барысы да үзең шикелле саташканнар, житәр-житмәс, тиле-милеләр.

– Рәхилә, нишләп шулай дисең инде?..

Нияз әле компьютер экранына, әле Азаматка карап алды. Шулкадәр мыскыл итүгә түзә алмыйча, биргән акчаларын кире алмасын, дип шикләнә иде булса кирәк. Ә хатыны аның шикләнүләренә исе китми, һаман кыза гына бара.

Менә ул тозлап-борычлап зәһәр сүзләр кычкырды да, ахырдан, ачуына чыдаша алмыйча, кулындагы «мышка»ны компьютер экранына атып бәрде.

Элемтәнең теге ягында нәрсәдер шакылдады. Өстәлендәге веб-камерага эләгеп, ул килеп төште булса кирәк, экранда Рәхиләнең йөзе юкка чыкты. Нәрсәдер дөбердәде, шакылдады һәм элемтә өзелде.

Инде сабырлыгы калмаган Нияз, хатынының тагын шалтыратуыннан курыккандай, компьютерны бөтенләй сүндереп куйды.

– Әй, минем хатын бер чәпчи башласа, туктатып булмый, – диде ул, аклангандай.

Әлеге тамашаны берни эндәшмичә карап торган Азамат:

– Ала-а-ай икән, – дип суздым.

Аннан соң, конкрет бер фикергә килеп:

– Менә нәрсә, Нияз әфәнде. Сез иртәгә үк үзегезне тәртипкә китерегез. Мунчага барып, яхшылап юынып кайтыгыз. Кырыныгыз. Чәчтарашка кереп чыгыгыз. Аннан соң өстегезгә берәр рәтлерәк кием алыгыз. Кыскасы, кеше янында кешечә күренерлек булсын. Галстугы-мазары дигәндәй. Яхшылап ял итегез. Берсекөнгә менә шушы адреста көтәм. Эшләргә әзерләнеп килегез, – дип, Ниязга үзенең визиткасын тоттырды.

– Ә нинди эш? Әгәр әйтергә мөмкин булса?..

Азамат, аңа сынаулы караш ташлап:

– Һәрхәлдә, йөк бушатучы түгел инде, – диде.

Ул чыгып китәргә җыенган иде инде. Ләкин соңгы чиктә, кире уйлап, өстәл янәшәсендә торган урындыкны үзенәрәк тартты да шуңа утырды. Аның әле сүзе бетмәгәне, нәрсәдер әйтергә теләгәне күренеп тора. Нияз, дикъкать белән тыңларга җыенгандай, аңа текәлде.

Азамат:

– Минем тагын бер соравым бар, – диде дә тукталып калды.

Тик менә Азаматның уйлары чуалды булса кирәк, ул фикерен тиз генә туплый алмыйча азапланды. Шактый утыргач кына:

– Нияз әфәнде, ә менә вакытны үзгәртеп, киләчәктән хәзерге заманга күчү очраклары бармы? Безнең заман кешесе ерак үткәннәргә күчә алгач...

Үзе кызыксынган темага кагылгач, Нияз Хафиз бермә-бер җанланды. Әле ярты сәгать элек кенә мескен күренгән кыяфәте, ничектер, тантаналы төс алды. Хәер, бүген аның кәефен күтәрердәй вакыйгалар да булды бит: ниһаять, акча мәсьәләсе хәл ителде. Фатирына булган бурычларын тиененә кадәр түләп бетерәчәк. Суд приставы килсә дә, борчыласы түгел, хәзер ул аның белән аяк терәп сөйләшәчәк. Кем белә, Рәхиләсе дә кайтыр әле, бәлки. Тотрыклы хезмәт хакы алып эшли генә башласын! Әнә бит, каршында утыручы шушы гаярь ир заты аңа эш табам диде. Шуңа күрә Нияз бүген аның теләсә кайсы соравына җавап бирергә әзер иде.

– Азамат Закирович, хөрмәтлем, киләчәк заманнардан хәзерге вакытка күчү очракларына дистәләп мисал китерә алам. Сезгә мәгълүм «Сәер табылдыклар» дигән китабымда алар хакында язган идем инде. Кирәк булса, аннан укый аласыз. Бу уңайдан минем тагын да кызыклырак юрамаларым бар...

Ниязның күзләре очкынланып киткәндәй булды: ул башын чөеп җибәрде; бармакларын тырпайтып, тыңлаусыз чәчләрен артка таба сыпыргалады; кинәт кенә ишекле-түрле йөренеп алды. Аның нәкъ шундый халәтен Азамат хәтерли әле. Фоат Хәмитович белән беренче мәртәбә бирегә килгән көнне дә, галәмдәге «кара упкын»нар, вакыт-пространство могҗизалары турында «лекция» укыганда да аның күзләре нәкъ шулай ук әсәрләнгән иде.

Менә ул йөренүеннән кинәт кенә туктады да Азаматның каршысына ук килеп басты һәм, ярымпышылдап:

– Сезнең НЛОлар турында ишеткәнегез бармы? – дип сорады.

Әллә соң моңа Сөмбеләнең сәер генә «кайтып төшүе» турында сөйләргәме икән, дип уйлаган иде Азамат, тик тәвәккәлләмәде. Әгәр бу хакта әйтсә, барыбер коткарганнар дип, гыйльми эшләрен дәвам итмәскә дә мөмкин бит ул.

Азамат та, Ниязга ияреп, тавышын түбәнәйтте:

– Мин үзем ул НЛОларга бик үк ышанып бетмим. Ә менә ишетергә туры килгәләде... Оча торган тәлинкәләр... гуманоидлар... чит планета кешеләре...

– Менә, менә, чит планета кешеләре. Оча торган билгесез объектлар турында сөйләшкәндә, без чит планеталарны, чит галактикаларны күз алдында тотабыз. Шулай бит?

– Шулай, күрәсең...

– Ләкин, минем уйлавымча, тәлинкәләр барысы да чит планеталардан килүчеләр түгел. Аларның кайберләре Җирдән.

Азамат елмаеп куйды:

– Җир кешеләре Җиргә очып килә, димәкче буласызмы?

– Юк, очып килүчеләр түгел. Киләчәктән безнең заманнарга күчкән җир кешеләре алар. Кем белгән, йөз ел да узмас, кешелек «кара упкын»нарны үзенә буйсындыра башлар. Хәтта бер заманнан икенчесенә күчү өчен «вакыт тоннельләре» төзү дә мөмкин булыр. Һәм иң кызыклысы нәрсә дип уйлыйсыз, хөрмәтлем? Сез моны, хәзерге замандагы кебек, очраклы гына вакыт аралыгына туры килеп, үткәннәргә күчеп, вакыт корбаны булу белән бутамагыз. Ул заманнарда вакыт аша сәяхәт итү – хәзер чит илгә сәфәр кылып кайту белән бер булачак.

– Теләгән кеше, тукта әле, фәлән гасырның фәләненче елына барып кайтыйм, дип җыенып чыгып китә алачак, димәк.

– Әлбәттә! Самолётларга да, поездларга да, автобусларга да билет алган кебек, «юл хакы» түләү дә булыр, билгеле...

Бу минутларда Нияз хыялларының чиге-чамасы юк иде. Аның фантазиясе теләсә нинди чынбарлык киртәләрен үтеп чыгарга сәләтле кебек.

– Әле алай гынамы, – дип дәвам итте ул сүзен. – Бер заманнан икенче заманга кунакларга йөрешү, өйләнешү, әйтик, урта гасырлардан кырыгынчы гасырга килен төшерү...

Нияз, хыялына бирелеп, җиңелчә генә Азаматның касыгына да төртеп алды хәтта:

– Урта гасырның затлы дворян нәселеннән тәрбияле, нәзакәтле, гүзәл кәләш алу начар түгел бит, ә-ә?! Алар инде минем Рәхилә шикелле тәртәгә типмәячәкләр. Тәрбия икенче...

– Болар барысы да мөмкин хәлләрме соң?

– Әле ничек кенә мөмкин! Ә менә тагын тыңлагыз: борынгы экологик чиста көтүлекләрдә тукланган малларны ризык урынына файдалану.

– Динозавр итенме?

– Ә нигә динозавр? Борынгы җанварларның үлән белән туклана торганнары да булган. Әйтик, киләчәк кибетләрендә стегозавр итеннән ысланган колбаса, ресторannarда трицератопсның парда пешерелгән ите, казылык, кентрозавр эчәкләреннән тутырма торадыр, бәлки. Янәшәсенә берәр борынгы үсемлекнең итләч яфракларыннан салат та булса... Де-ли-ка-тес!

Нияз ирексездән иренен ялап куйды. Муенындагы төере уйнаклап алды...

Ул көнне алар озак сөйләштеләр. Азамат урамга чыкканда, әлерәк кенә яңгыр явып узган иде. Күктәге ала-тилә болытлар арасыннан вакыт-вакыт

ялтырап кояш күренеп китә. Асфальт иңкүлекләрендәге күлдәвекләр өстендә хасил булган нәни генә шадраларда кояш нурлары чагылып җемелди.

Шуларга карый-карый, Азаматның уйлары кабат Сөмбеләгә әйләнеп кайтты. Менә бит язмыш аларга нинди сынаулар әзерләгән! Ни өчен кеше ышанмастай бу хәлләр алар башына гына төште соң әле? Аңламассың.

Тик ул күпме генә тырышса да, уйларының очына чыга алмады. Аннан соң, кулын селтәп, күлдәвекләрне әйләнеп уза-уза, ашыгып машинасына атлады.

***

Иртәнге планёрка тәмамланып, кабинетыннан ярдәмчеләре һәм бүлек җитәкчеләре чыгып беткәч, Азамат компьютерда шәхси электрон почтадан хат-хәбәрләрне карарга җыенган иде, ишектән тартынып кына бер адәм килеп керде. Кем ул? Нишләп йөри? Монда керергә кем рөхсәт иткән аңа?

Азамат, гаҗәпләнеп, керүчегә төбәлде. Ак кәчтүм-чалбардан, өр-яңа матур галстук, чәчләрен килешле генә артка тарап куйган. Ә үзе кыенсынып кына елмая. Кайда күргәне бар иде бу кешене? Исенә генә төшерә алмый бит!

Кинәт Азаматның хәтере яктырып киткәндәй булды. Карале, онытып тора икән бит. Ул Ниязны чакырган иде бит. Әле кабул итү бүлмәсендә утыручы референтына, әгәр килсә, бернинди тоткарлыксыз туп-туры миңа керт, дип әйткән иде. Менә килеп тә җиткән...

Азамат, колачын җәеп, керүче каршысына килеп басты. Аның иңнәреннән тотты да, бераз читкәрәк каерылып, кабат баштанаяк күздән кичерде.

– Танырлык та түгел сезне – менә монысы шәп! Югыйсә, эткә салган сөяк шикелле, кадерсезләнеп йөрисез.

Аннан соң, шушы минутта гына кабинетка килеп кергән Динарга да мөрәҗәгать итеп:

– Ә хәзер эшкә тотыныйк. Нияз әфәнде, мин сезгә өченче каттан олы бер бүлмәне бирәм. Ул сезнең эш урыныгыз булыр.

– Ә мин нәрсә белән шөгыльләнермен соң анда? – дип сорады Нияз, мәсьәләгә ачыклык кертергә тырышып.

– Үзегезнең гыйльми эшләрегезне дәвам итәчәксез, әлбәттә. Нинди җиһазлар кирәк, исемлеген төзеп китерегез. Кайтартырбыз. Бүгеннән башлап эшкә керешегез. Динар сезгә бүлмәне күрсәтер. Әйдәгез, хәерле сәгатьтә! – диде.

Аннан соң, гафу үтенгәндәй:

– Вакытым юк. Кичекмәстән хәл итәсе мәсьәләләр бар, – дип, ашыгып, чыгу ягына борылды.

Инде китәм дигәндә, тагын нидер исенә төшерде:

– Әгәр фәнни эшегезне ахырына җиткереп, вакыт аша башка заманнарга күчү мөмкинлеге табасыз икән, беренче чиратта минем хатынымны – Сөмбеләне ахыргача коткарырга ашыгыгыз. Аңа хәзер кичекмәстән психологик ярдәм кирәклеген мин аңлыйм...

Азаматның үзенә теләктәшлек итүенә Нияз чын күңеленнән куанды:

– Әлбәттә, хөрмәтлем. Алга шундый максат та куйгач, һичшиксез, ерып чыгарбыз. Максатлы эшнең ахыры хәерле була, – диде ул, авызын колагына кадәр җәеп...



Рифкать
Имаев

# МИНЕМ ҖАНДА – ҮЗГӘ КОЯШ

## Канәгатьмен

Куганым юк мал артыннан,
Байлыкка күзем сукыр.
Ач та түгел, ялангач та,
Яшим, Аллага шөкер.

Баш очымда кояш көлә,
Йөргән юк янып-көеп.
Яшәп яткан көнем җирдә,
Тормышның ямен тоеп.

Минем җанда – үзгә кояш,
Шигырьләрем – байлыгым.
Кемдер алтын-көмеш җыя,
Ә мин шигырь сайлыймын.

Саулык булсын, шунсы мөһим,
Байлыкка китмәс исем.
Башкалардан ким-хур түгел,
Тормыш, Аллага шөкер.

## Үзебез гаепле

Бүген бар да начар, дибез,
Өйрәндек зарланырга.
Соры булып төшкә керә
Яуган ак карлары да.

Рифкать ИМАЕВ (1948) – *шагыйрь; «Гомер агышлары», «Алма балланган вакыт», «Уйламыйм, дим, уйлата» һ.б. китаплар авторы. Түбән Камада яши.*

Хозурланып яшәр чакта
Кышның ал таңнарына,
Корт төшкәндер, ахрысы,
Күпләрнең җаннарына.

Теләмәсәк тә алдарга,
Өйрәндек алданырга.
Әллә картаябыз инде,
Остардык зарланырга.

Бөтен гаеп үзебездә,
Катнашмый монда заман.
Сүз сөйләргә остардык та
Эшне оныттык тәмам.

Күпме генә болгатсак та,
Май төшмәстер буш сүздән.
Башларга кирәктер безгә
Иң башта үзебездән.

## Җитми туган якларга

Узды явып җылы яңгыр –
Аңлады, көттермәде.
Артыннан ук килә чыгып
Салават күперләре.

Аңлашканнар – җир белән күк
Гамәлләре изгедән.
Ялтырый су, әз генә дә
Ким түгелдер көзгедән.

Тау битендә җиләк пешкән,
Болыннары – шау чәчәк.
Минем кебек хыялыйлар,
Исереп йөриячәк.

Тирәкләрдә – сандугачлар,
Чәчәкләрдә – бал корты.
Ял итәргә телим дисәң,
Бу бит әзер ял йорты.

Караплар торам таң калып,
Таңнар ата алланып.
Уза рәхәт җәйге көннәр,
Бер-берсенә ялганып.

Бу илаһи гүзәллекне
Ничек бозмый сакларга?
Тотасыз да чит ил, дисез,
Җитми туган якларга!

## Серле чишмә

Ага чишмә өстән-аска,
Су сикерә таштан-ташка.
Бүген монда мин берүзем
Бер кеше юк миннән башка.

Кем килсә дә ихтыяры,
Хозурлансын монда туктап.
Алны-ялны белми чишмә,
Төн керсә дә ятмый йоклап.

Чишмәләр дә төрле-төрле,
Көмеш сулар юа керне.
Гади генә булмас чишмә,
Саклыйдыр ул берәр серне.

Битем юдым, суын эчтем,
Сихәт алдым җаннарыма.
Бу якларга юлым төшсә,
Тагын киләм яннарыңа.

Чишмәләрдә яшькелт үлән,
Юлларында ап-ак комы.
Кереп китте шигыремә
Сиздермичә чишмә моңы.

## Уйлы чагым

Гомер төйнәлгән төен,
Сүтелгәненә сөен.
Шунсы мөһим: яшәмәдем
Көйләп гел кеше көен.

Гомер – сүтелгән йомгак,
Яшәлгән бик тә тыйнак.
Менмәдем кеше теленә,
Гаепсезләрне кыйнап.

Юк, гаепләмим көзне,
Юа, дип минем эзне.
Кирәк җирдә әйтә килдем
Әйтәсе килгән сүзне.

Һәр гомер – ул бер инеш
Теләгәненә ireш.
Күренә инеш тамагы,
Димәк, йомгаклап килеш.

Ни әйтим сезгә тагын:
Салмакланган шул агым.
Гомерне бизмәнгә салып
Нәтиҗә ясар чагым.

## Көзге халәт

Урман юлы, сары яфрак –
Атлыйбыз сүзсез генә.
Алтын яфрак төшеп ята
Тын гына эзебезгә.

Кайлардадыр җилләр исә,
Таң ата безсез генә.
Урман юлы, сары яфрак –
Атлыйбыз сүзсез генә.

Чал урман күк сабыр гына
Керәбез көзебезгә.
Без – көзләрдә, көзләр – бездә –
Аңлыйбыз үзебез дә.

Әйтеләсе әйтелгәндер,
Калмаган сүзебез дә.
Кояш байый, көзге кояш
Сагышы күзебездә.

Игътибарлырак булыгыз,
Күрерсез үзегез дә.
Алтын яфрак явып калды
Тын гына эзебезгә.



Ралия
Кәримова

# ТАШЛЫ ТУФРАК

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

*Якыннарымның якты истәлегенә багышлыйм...*

Поезд килеп туктауга, халыкны аралап, алар вагонга таба ашыктылар. Иң алдан Әгъзам абзый, аның артыннан зур фанер чемоданнар тоткан уллары – унбиш яшьлек Әгъләм атлый. Әйбер авырлыгыннан бер якка янтайган йөкле Тәлига апа кече кызын – Фәһимәсен җитәкләгән, олырагын – Әдибәсен янәшәсеннән иярткән. Һәркемнең кулында, аркасында әйберләр, төенчекләр, юл капчыклары.

Ленинградка алып китмәкче иде Әгъзам үз гаиләсен. Ләкин ул дигәнчә барып чыкмады. Уйлаштылар да Чиләбегә барып, шуннан Ташкентка китәргә булдылар. Менә бүген китәрләр, Аллаһы боерса! Авылда үзенә көн бетәчәген, рәтләп яшәргә ирек бирмәячәкләрен күптән аңлады Әгъзам.

Яңавылда поездга утыруга, ир белән хатын тамбурга чыктылар, туган яклары белән саубуллашып, тәрәзәгә текәлеп озак кына карап тордылар. Паровоз пар болытлары пошкыра-пошкыра әкрен генә кузгалып киткәндә, күңелләр тулды.

Күзләренә килеп төелгән яшьләрен күрсәтмәс өчен, ире башын иде, Тәлига исә түзмәде, елап ук җибәрде. Исән-сау әйләнеп кайтулар насыйп булыр микән газиз туган якка? Ниләр күрер бу башкайлар чит җирләрдә? Хуш, Яңавыл – Туган җир! Китәсе килеп китмибез, туган илдән кем туйган дип җырлаулары бигрәк дөрес икән лә... Дөньялар болганды шул. Тырыш хезмәт белән төн йокламый тапкан малларын пыран-заран китерсеннәр дә, ничек үзәгең өзелмәсен? Җыен хөрәсән әллә кем булды, бөтен ялкау хуҗа хәзер дөньясына! Күпме кеше «халык дошманы», «кулак» дигән исем тагылып юкка чыкты кырмыска оясыдай кайнаган илдә...

Ирнең аксыл йөзе сулып киткәндәй. Уртаклашмаган кайгы, эчкә бикләнгән хәсрәт бигрәк тә авыр, аеруча газаплы була икән. Ул хатынын биленнән тотып

Ралия КӘРИМОВА – *шагыйрә, прозаик; «Мин – табигать баласы», «Бәхет бүләк итеп», «Яшәү яме» исемле китаплар авторы. Түбән Камада яши.*

вагон эченә әйдәде. Алар бер-берсен тынычландырып, балалары янына барып утырдылар. Ә балаларга иң кызыгы – поездга утыру, каядыр китү иде. Бу серле яңалык алар тормышына ниндидер шатлык өсти. Таныш түгел юллар буйлап алга ыргылучы поезд тәрәзәсеннән дә аларга әле өр-яңа дөнья ачыласы бар!

Ир белән хатын вагондагы күңелле шау-шуны ишетмәделәр, шомлы тынлыкка чумдылар. Поезд тәгәрмәчләре бер көйгә текелдәп, аерылышу көен суzды.

Чиләбегә килеп төшүгә, аларны Әгъзамның дусты Нури каршы алды. Ул авылдан күптән чыгып киткән, монда төпләнеп яши, сату-алу эше белән мәшгуль иде. Туган якка кайткан саен очрашалар алар. Әгъзам китә алмады, туган авылы Салихта өйләнеп торып калды. Якташлар вокзал буендагы буш эскәмиядә бераз сөйләшеп утырдылар, киңәшләштеләр дә каядыр барып килергә ниятләделәр.

– Әйберләргә, апаеңнарга күз-колак бул, яме! – диде Әгъзам улына, хатынына да нидер пышылдады һәм алар биек йортларга таба киттеләр.

Биш яшьлек Фәһимә әткәсенең тротуар буйлап каядыр китеп баруын абайлап алды. Шул арада, ай күрде – кояш алды дигәндәй, кызчыкның аларны куып җитмәкче булып артларыннан йөгерүен һичкем күрми калды.

Тротуар тулы халык каядыр ашыга, кеше арасыннан әткәсе белән теге абыйның аркалары гына күренгәләп ала. Юл буендагы зур кибетләрнең ялтырап торган тәрәзәләренә карый-карый, абына-сөртенә йөгерә торгач, кечкенә кыз әткәсен күздән югалтты. Ул адымнарын кызулатты, бөтен көчен җыеп алга йөгерде. Арыгач, ниндидер зур йорт янына җитеп, туктап калды ул. Тирә-ягында кешеләр күп, ләкин әткәсе беркайда да күренми! Кире борылырга, әнкәсе янына кайтырга кирәк! Кызчык борылып, берничә адым атлауга, аптырап туктап калды... Юл чаты дүртәү, кайсына борылырга соң? Кая барырга белмичә, ул елап ук җибәрде. Янына тукталып, үзенә нидер әйткән кешеләрне дә аңламады Фәһимә.

Як-ягына карап, елап торган бала янына килеп баскан озын итәкле, кара чәчле хатын, аның саргылт бөдрә чәчләреннән сыйпап, ягымлы тавыш белән:

– Не плачь, девочка, а где твои родители, где твои мама, папа? – дип аңа текәлде. Бала русча берни аңламаса да, бераз тынычлангандай булды. Ул кулы белән алга күрсәтеп сөйләнде:

– Әнкәйләр пуез буенда, шунда барасым килә!

– Красивая девочка, хорошая!

Кызны җитәкләп, хатын аны каядыр алып китте. Кызыл тасмасын салдырып, кулына тоттырды, итәк кесәсеннән катып беткән түгәрәк кәнфит алып бирде. Фәһимә елавыннан туктады. Озак кына ашыгып атладылар алар, чегән хатыны юл уңаенда кешеләрдән акча сорады, кемнәрнеңдер кулларын тотып нидер карады. Тирә-якта ыгы-зыгы артты, кайберәүләр кызга карап нидер әйтте, тик Фәһимә русча аңламады. Ниндидер татар хатыннары туктады:

– Кара әле, чегәннәр бу баланы урлаганнар ахры, аларга охшамаган бу кыз!

– Милиция чакырырга кирәк!

Шау-шу көчәйде. Халык күбәйгәннән-күбәя иде, алар атлы арбалар тезелгән базар янына килеп җиттеләр. Бер кырыйда аллы-гөлле озын итәкләрдән, матур төймәләр, алкалар таккан чегән кызлары бии. Кызчык аптырап тирә-якка карады. Шулвакыт, йә Хода! – кинәт кенә Фәһимәнең каршысына әтисе килеп чыкты. Кызчык хатыннан кулын тартып алды да, каты итеп:

– Ә-әткәй! – дип кычкырып җибәрде һәм аңа ташланды.

Әткәсе, аптырап, син монда каян килеп чыктың, дип, баланы кулына алуга, теге чегән хатыны кеше арасына кереп югалды.

– Йә Ходай, кызымны чегәннәр урлап китә язган бит! Рәхмәт, Раббым, баламны каршыма чыгардың! – Әгъзам баланы кысып-кысып кочаклый, үбә иде.

Еракган ук күрде Фәһимә: әнкәсе, абыйсы һәм апасы елашып беткәннәр, бик борчулы кыяфәттә як-якка караналар, һаман аны эзлиләр иде.

– Кая китеп югалдың, балакаем, нигә киттең? – дип, әнкәсе кызарган күзләрен тутырып карады да аны кочагына алды. Ташкент поезды китәргә сәгатьтән артыграк кына вакыт калган иде.

* * *

Поезд тәгәрмәчләре текелди дә текелди. Тәрәзәдән күренгән куе урманнар, яшел болыннар, текә таулар, түгәрәк күлләр инде артта калды, аларны саргайган үләнле көйгән җирләр, комлы сәхрәләр, шәрә зәнгәрсу таулар алыштырды. Яшеллек аз, үсемлек юк диярлек җирләр дә бар икән... Кәкре-бөкре булып үсә алмый утырган вак кәрлә каен, саксаул агачлары, сәмәннән эшләнгән тәбәнәк өйле кышлаклар, икешәр өркәчле дөяләрне күргән балаларның күзләре гел тәрәзәдә.

– Әткәй, монда елгалар юк микән әллә? – дип, Әгъләм әткәсенә текәлде. Әткәсе җир йөзендәге уникe зур елганың җидесе Азиядә булуын әйткәч, ул шатланып куйды. Үзләренең Урал авылы янындагы төлке фермасында булышуларын, тегермән буасында ничек балык тотканнарын сөйләп баручы улының йөзенә сокланып карап торды Тәлига. Кече кызы сыман, шулкадәр дә әткәсенә охшар икән бу бала! Хатын тагын уйлар йомгагын тәгәрәтә башлады...

Ул Башкортстанның гүзәл почмагында урнашкан авылын, үзләренең иркен йортын, биек ат абзарларын, мал-туарын күз алдына китерде. Нык иде шул тормышлары, шуңа көнләшүчеләр дә күп булды. Ире тырыш, эшчән, булдыклы, укымышлы иде, яңача гәҗитләрне дә авылда беренче булып ул алдырды. Барын да укып, алдан белеп торды.

Абруйлы иде ул авылда. «Кулак» диеп кулга алгач та, төрмәгә утыртмадылар аны, ул үз-үзен аклап кире кайтты. Чөнки бар малын – ике сыерын, өч атын яңа төзелгән колхозга илтеп тапшырган иде инде. Тырма-сукалар, ат эшлияләре, хуҗалык кирәк-яраклары, олавы белән ташылып, күмәк хуҗалык милкенә әйләнде. Хуҗалык рәисе булып алган яшьлек дусты Габделхәй белән дә кистереп, каты сөйләште Әгъзам. Тагын кулга алып, төрмәгә тыгулары да бар иде. Ә өйләрен колхозга алырга, избач итәргә дип карар чыгаргач, ул бик хурланды, Тәлиганың да җаны өзгәләнде. Алар тиз генә җыенып, авылдан китәргә булдылар.

– Илдә чыпчык үлми, баш исән булсын, эшләрбез дә яңадан корырбыз дөньяны, – диде ире. Тик хатынының йөкле булуы, сигез баладан өчесе генә исән калуы бераз шөбһәләндерә иде аны.

Китәр алдыннан Ленинградтагы туганнарын, Ташкенттагы танышларын, Сәмәркандтагы якташларын искә төшерделәр. Кайларга гына таралмаган инде бу татар халкы?.. Хәзер илдәге давылда таралышкан, төрмәләрдә юкка чыкканнар күпме тагын! Әгъзамның Иж-Бубый мәдрәсәсен бетергән укымышлы абыйсын – авыл мулласын бер ай элек төнлә килеп ГПУга алып киттеләр, һаман бер хәбәре дә юк бит! Исән-сау гына булсын инде, Алла сакласын үзен! Төрмәләрдә иза чигә микән, ни хәлләрдә икән Имаммөхәммәт абзыйлары, күпме йөреп, сорашып та берни белә алмадылар.

Күрше вагонда Төркестан фронтына баручы ГПУ кешеләрен күрү дә төрле уйларга этәрә. Ә Әгъләм тукталышларда гел шулар тирәсендә бөтерелә, сугышчыларның киемнәренә сокланып карый малай. Лангар, Бассаган якларына, басмачларның соңгы зур төркемнәрен тар-мар итәргә баралар икән ди алар.

* * *

Инде өч-дүрт тәүлек буена көне-төне тыкылдаган тәгәрмәчләр тавышы гына түгел, ашау җитмәү дә, билгесезлек тә хәлсезләндерә. Керүче-чыгучылар – капчык, төен, сумка күтәргән кешеләр күренмәсенгә, шүрлек башларына чыпта сыман пәрдә элеп куйдылар. Балалар бертөрлелектән арып, үзләренә уен таптылар. Әгъләм сеңелләренә кызык-кызык сораулар бирә:

– Күзеңне йомгач, нәмә күрәсең? – ди ул Әдибәгә.

– Үзебезнең ишегалдын күрәм, – ди кызкай.

– Мин бернәмә дә күрмәем, – ди Фәһимә.

Абыйлары тагын:

– Эт ния өрә? – дип сорый. Кызлар уйланып торганда, үзе үк:

– Сүләшә белмәгәнгә! – ди. Алар өчәүләп көлешәләр. Әдибәнең чая кара тут йөзе, авыл кызларына гына хас тыйнак елмаюы мут шаянлык сирпеп торса да, бармагыңны авызына куйма, тешләп өзәр!

– Уты юк – яна, канаты юк – оча, аягы юк – йөгерә, ул нәрсә? – дип табышмак әйтә абыйлары. Кызлар уйга калалар. Үзе Фәһимәгә карап, тәрәзәгә, кояшка күрсәтә.

– Кояш, – ди бәләкәче.

– Болыт, – дип өсти икенчесе.

– Су, – дип тәмамлый егет үзе.

– Ягез, балалар, тамак ялгап алыйк! – дип әнкәләре бүлдермәсә, уйныйлар иде әле. Улына титаннан кайнар су алып килергә кушып, әчмуха чәен ача башлады.

Тышта, комлы чүл өстендә җил чәнечкеле дөя үләнен тәгәрәтә... Ә ир белән хатын кайгы касәсеннән авыз итә-итә, балаларын билгесезлеккә таба алып баралар.

Менә поезд тизлеген әкренәйтә башлады да ниндидер станциягә килеп туктады. Су, ризык алырга, хәл җыярга чыгучылар ком бураны туздырып чабып килүче җайдаклар төркемен күрделәр. Иң алдагы җайдак кулындагы кара байракны күрүгә, кемнәрдер:

– Чума! Чума! Кара үлем! – дип кычкырыша башладылар. Халык тиз генә кире тынчу, эссе вагоннарга кереп тулды. Коточкыч авыру һәркем өчен куркыныч иде. Озак та тормады, паровоз пошкыра-пошкыра кузгалып та китте. Әгъләмгә монда бар да кызык, ят, яңа. Ул өстәге шүрлектә, тәрәзәдән күзен алмыйча, каршысында яткан сеңлесен дә ишетмичә, тирә-юньне карый, күз күрмәгән җирләр белән таныша иде.

Поезд Чимкент дигән зур гына шәһәргә килеп җитте. Юлаучылар вагоннан төште. Монда да гаҗәп хәлләр күп икән...

Менә өсләренә иске чапан кигән, чалма ураган, кулларына таяклар тоткан бертөркем сәләмә генә киемле кешеләр, беравыздан: «Йә, Алла! Йә Алла!» – дип кабатлап, учак тирәли әйләнәләр. Арадан берсе:

– Бүгүн ислам галәме үлкән мүсибәтга, огур жудоликкә учради... Шәйх Содик Мүхәммәт Йосуф хәзрәтләри уафат! – дигәч, берничәсе бергә:

– Аллох өз рәхмәтига олсин! – дип кабатлый иде.

Тар гына урамнан ишәккә атланган каратут йөзле, сакал-мыеклы ир килә,

аның артыннан ук кара кием белән капланган, баш түбәсенә юка гына ипигә охшаган көлчәләр өеп торган хатын-кыз атлый.

Шундагы бер апа кычкырып сорап куйды:

– Минга нимә алыб килдиңез?

– Сут, катик, коймок келди...

Әгъләм, Әдибә һәм Фәһимә, исләре китеп, шуларга карап тордылар. Яннарыннан ялтырап, керләнеп беткән малахай бүрекле, ишәк җитәкләгән карт, чигелгән түбәтәйле, буйлы матур халатын чуклы билбау белән ураган егет, яулыгын чөеп бәйләгән, киң йөзле, кысык күзле хатын, аллы-гөлле күлмәк, шундый ук чалбар кигән, озын кара чәчләрен әллә ничә чатка үреп салган чибәр кызлар үтеп китте.

– Әнә дүрт аяклы печән чүмәләләре килә! – дип кычкырып җибәрде Әгъләм, алга таба күрсәтеп. Кечкенә ишәкләргә бик биек итеп зур йөк – печән төягән ирләр узды. Әгъзам тагын балаларын кисәтте:

– Карагыз аны, монда балаларны урлап китәләр, бер-берегезнең кулын җибәрмәгез, җитәкләшеп кенә барыгыз, – дип, аларны базар мәйданына алып китте.

Чинар агачының җәенке ботаклары астында утыручы, башына бәрән бүрек кигән карт аларга:

– Әссәламегаләйкем вә рәхмәтуллаһ! – дип эндәшкәч, әткәләре дә сәлам бирде. Мөселман кешесе бит!

Тирә-яктагы чүп-чар арасыннан китеп, уң якка борылуга, бик матур, чынаяктан ясалган төсле ялтырап торган зур, бизәкле таш мәчет, аның каршында шундый ук зәңгәрсу киң һәм биек капка күренде. Әдибә, әнкәсенекедәй елтыр кара күзләрен зур ачып:

– Хөррият капкасыдыр инде бу, әйеме, әткәй! – дигәч, Әгъзам көлеп җибәрде.

Хөррият дигәннәре кайда, кайсы җирләргә китеп югалды икән соң? Кайчан да булса күреп булыр микән аны? Гаепсез килеш иленнән качып диярлек китеп бар инде... Әле ярый, эзләп табып яңадан берәр гаеп такмасалар. Менә ничек болгана ил... Шулай уйланды ир. Алар базардан ят ризыклар – кавын, карбыз, ләвәшләр алдылар да вагонда әйберләрен саклап калган әнкәләре янына ашыктылар.

Тәгәрмәчләр текелдәвенә тәмам ияләшеп беткән балаларга Ташкент шәһәренә якынлашып килүләрен ишетү зур сөенеч иде. Әйберләр барланды, төенчекләр төйнәлде, догалар укылды... Алда юлчыларны шомлы билгесезлек көтә иде.

* * *

Ташкент янындагы кышлакка килеп урнашуларына бүген ике ай булды. Торыр почмак алырга җыелган акча сизелеп кими иде. Гаиләсенә торыр куыш, үзенә эш эзләп йөреп, Әгъзам вакытның үткәнен сизмәде дә. Бер таҗик картының иске генә өен сөйләштеләр. Җиденче сыйныфны тәмамлаган улына да эш эзли әткәләре. Ерак түгел җирдә, горноспасательная станция дигән урында яшь егетләрне эшкә җыялар икән, дип ишеттеләр алар. Бүген шунда бардылар, шөкер, юллары уңды! Өйрәнчек итеп алырга булдылар Әгъләмне. Әдибәне үзбәк мәктәбенә укырга бирделәр, төпчекләре әнкәсе янында, өйдә. Өй дигәне кечкенә алачык. Тәлига өйнең түшәмнәрен юды, стеналарын агартты, чистартты, үзенчә матурлады. Юкны бар итте, гаилә учагын тергезер

өчен көченнән килгәнне эшләде ул. Эшнең рәтен белеп, тырышып дөнья көтте. Алачык янындагы кечкенә бакчаны бик яраттылар, кичләрен, һава җиләсләнә төшкәч, бергәләп шунда чыктылар, ташлы туфрагында казындылар, чистарттылар. Тик туган авыл истән чыкмады, сагындырды, андагы зур йортлары, бакчалары күз алдыннан китмәде. Тәлига моңланып әкрен генә җыр сузды:

Һаваларда ике аккош,
Агыйделдә кышлавы.
Бигрәкләр дә авыр икән
Туган илне ташлавы...

Тирә-юньдә йөзем куаклары, тут агачлары үсә, гөлчәчәкләр хуш ис бөрки. Бу комлы-ташлы туфракта ничек үсә икән алар? Әгәр җире безнең авылдагы кебек булсамы? Һәр якның үз туфрагы, үз үсемлекләре, читтән китереп утыртсаң, тернәкләнеп китәр идеме икән алар? Кешеләр дә шулай: яңа җиргә күченеп утыруны авыр кичерәләр, тик нишлисең, тәкъдирдә шулай язылгандыр... Шулай фикер йөртте хатын.

Әйе, яңа җирдә тормыш корып җибәрү җиңел түгел икән. Кышлакта күбрәк гади дихканнар яши. Төрле милләт кешеләре – үзбәкләр, таҗиклар гына түгел, татарлар, руслар да бар. Җир эшкәртеп, мамык үстерүчеләрдән тыш, шахтёрлар да, терлекчеләр дә очрый. Ярый әле халык тыныч, күршеләр әйбәт булып чыкты. Әле бер әйбер кирәк, әле икенчесе юк – күршеләр белән тиз танышып, аралашып киттеләр. Бары – бергә, югы – уртак, дигәндәй, әкренләп мондагы тормышка ияләшә башладылар.

Үзбәкстанның эссе һавасына күнегү генә Тәлига өчен аеруча кыен булды: көндез өйдән чыгарлык түгел, эссе һава тыннарны куыра, карынындагы баласы тынычсыз булыр, ахры. Кичке якта бакчадагы агачлардан җиргә коелып калган җимешләрне – алыча, өрек, чикләвекләр җыеп йөргән кызларына карап, зур өметләр баглый, күңелен тынычландыра, алар өчен шатлана ул. Биредә ачтан үлмәсләр, ризык табарга була икән! Ире танышларын эзләп тапты, район кулланучылар җәмгыятендә яхшы гына эшләп китте.

1934 елның көзге аяз бер көнендә Тәлига бәбәйгә чирләде. Якын-тирәдә бүлнис юк, кендек әбисен чакырыйк, диделәр дә бер үзбәк карчыгын алып килделәр. Төнгә кадәр тулгаклап җәфаланды ул, хәлдән тайды. Тик бала туарга ашыкмады. Әгъзам бер кереп, бер чыгып йөрде, хатынының кулларын тотты, маңгай тирләрен сөртте. Ниһаять, иртәнге якта муенына кендеге уралган, зәңгәрләнеп беткән бала дөньяга аваз салды. Кичергән борчылулары эзсез калмаган, күрәсең, малай бик хәлсез, зәгыйфь иде. Бераздан кечкенә Мәгъдәнне әнкәсенең күкрәгенә куйдылар.

– Әй сабыем, мә, имәргә тырыш, улым!

Икенче көнне генә авызына ими алды бала. «Балык тәнле» булып туды сабый, тән тиресе кытыршы иде.

– Тернәкләнеп китәр микән балакаем! – дип өзгәләнде ана.

Авыру баланы ничек кенә дәваламадылар, ниләр генә сөртмәделәр, нинди генә үлән суларында юмадылар, тик файдасы булмады. Табиблар климат ярамавын сәбәп итте. Йокысыз төннәр борчулы көннәрне алыштыра торды.

Язмыш сынаулары бетмәгән икән әле, дүрт кенә ай яшәде сабый якты дөньяда, Үзбәкстанның ташлы туфрагына салып куйдылар бу оҗмах кошын...

Җиргә ямьле яз кояшы карауга, Тәлига мамык үстерү бригадасына

эшкә чыкты. Беркөнне улы эштән кайтып, өйрәнү өчен бер айга базага җибәрәчәкләрен әйтте. База дигәннәре еракта, Тянь-Шань таулары буенда, Чимган дигән җирдә икән. Унбиш яшьлек баланы ничек шул тикле ерак җиргә җибәрмәк кирәк инде. Борчуга калды ана. Тик ире аңа:

– Кайгырма, карчык, мин үзем озата барырмын, мин эш белән Наманганга барам, шул якка, – дигәч, тынычлана төште.

Әгъләм ярыйсы гына үзбәкчә өйрәнде, яңа җиргә, эшенә тиз ияләште. Озын буйлы какча гәүдәсе тазарып, матурланып китте. Шәһәрдә кайнап торган тормыш, яңа дуслар кызыксынучан егетне моңарчы күрелмәгән башка дөньяга алып кереп китте.

Шәһәрдә әледән-әле яңа завод-фабрикалар, уку йортлары ачыла торды, үзбәкчә, русча гәҗит-журналлар чыга, төрле концертлар куела иде. Абдулла Кадыйри исемле дусты аны мәдәният яңалыклары белән таныштырып кына тора. Искелекнең җиңелүе, илнең үсеше, индустрияләштерү, хатын-кыз иреге, җирле халык тормышы турында сәгатьләр буе сөйләргә әзер ул. Хикәяләр яза үзе, язучы. Сәмәркандта «Кызыл каләм» исемле әдәби берләшмә ачуларын, анда катнашкан яшь язучылар Хәмзә, Фитрат, драматург Зәфәри, шагыйрь Гафур Голәм, тагын әллә кемнәр турында сөйли. (Тик бу егетләрнең утыз җиденче елда репрессия корбаннары булып юкка чыгачагын әле берсе дә белми иде шул.) Әгъләм дә рабфакта укыр, аннары, бәлки, Төркестан дәүләт университетына да керер, Алла боерса! Ташкентта утызлап югары уку йорты, йөзләп техникум бар, анда кырык дүрт мең студент укый, ди бит дусты. Шундук өстәп тә куя: «Һәр мөселманның бурычы – белемгә омтылу! Беләсеңме, моны Мөхәммәд пәйгамбәр әйткән!» – ди ул.

Үзбәкстанның Россия составына кушылуына ун ел тулуны бәйрәм иткән көннәрдә егетләр Язучылар союзы ачылу тантанасына бардылар. Рәссамнар берлегендә булып, күргәзмә карадылар, Әгъләмгә Урал Таксынбаев дигән яшь рәссамның яңа гына язылган «Хатыннарны азат итү» картинасы бик ошады. Бәлки әле ул үзе нәрсә дә булса иҗат итеп карар, кызык бит! Рәсем төшерү өчен дә укырга кирәк икән шул.

Шундый уйлар белән канатланып йөргәндә, Чимганга китәр көн дә килеп җитте. Кирәк-яракларны җыеп, юл биштәрен әзерләп, алар юлга чыкты.

Йөз чакрымлап юл үткәч, өч юлчы, поезддан төшеп, көнчыгышка борылды. Барасы юл кыскара, алда, тау буендагы зур таш янында учак яна, тирәсендә кешеләр кайнаша иде. Өчаякка эленгән казаннан тирә-юньгә хуш ис бөркеп шулпа исе, яңа суелган куй ите исе тарала. Тау буена тирмәләр корылган. Күптән түгел агып төшкән ерганаклар эзе тау битен чуарлаган. Юлчылар якынаюга, тирмә тирәсендә кешеләр күренде.

– Әссәламегаләйкем! – дип эндәшүгә, хуҗалар аларны учак янына чакырды. Хәл-әхвәлләр сорашып, танышып, кая баруларын белештеләр, сөйләшеп киттеләр. Кунакчыл халык яши икән бу якларда, туганын күргәндәй ягымлы, әдәплеләр. Якындагы тирмәдән чыккан Әлимхан белән Гыйлемхан исемле ике чабан ипле генә әңгәмә корып җибәрүгә, Корбан исемлесе коштабакка салып майлы калҗалар китереп куйды да:

– Утырыгыз, Әгъзам әкә! – дип, аларны дастархан янына чакырды. Сүз иярә сүз китте, Әгъзам аларга үзенең туган ягы, ничек бу якларга килеп чыгулары турында бәян итте. Дөнья хәлләрен сөйләшеп алдылар. Егетләр тау ягына күрсәтеп, андагы яшерен сукмаклардан атлы төркем килеп чыгу мөмкинлеген әйтеп кисәттеләр. Куркыныч хәлләр дә күп була икән монда.

Туплау пунктына сәгать дүрткә барып җитәргә тиешлекләрен уйлап утырган Әгъләм егеттән:

– Ә син татарча кайда өйрәндең, яхшы сөйләшәсең? – дип сорады. Әлимханның әтисе Оренбург ягында, Каргалы мәдрәсәсендә укыган икән. Тамак ялгап, әйрән эчелде, бераз хәл җыйгач, Әгъзам:

– Менә бит, Хода бәндәләре, якташларны күргән кебек булдык, – дип рәхмәт әйтте, алар саубуллашып барыр юлларына кузгалдылар.

Тирә-якның матурлыгына сокланмый мөмкин түгел иде: алда горур чал түбәләре белән болытларны терәп утырган Зур Чимган таулары күренде. Йөзәр мең еллык серләрне, байлыкларны саклаучы бу тауларда нинди могҗизалар саклана икән? Ерак түгел хәрби киемле кешеләр кайнаша.

Йөргән таш шомара, ятканы мүкләнә, дип юкка әйтмәгәннәр шул. Әгъләм белән иптәше үз хезмәтләре турында бер ай эчендә бик күп яңалыклар белделәр. Тауларда коткаручы югары хәзерлекле, белемле, физик яктан көчле булырга, элемтә чараларыннан дөрес файдаланырга, техниканы, альпинизм кагыйдәләрен яхшы үзләштерергә тиеш икән. Егетләр көндезләрен бик эссе, төннәрен салкын булуга карамастан, иртәдән кичкә кадәр укыдылар, тауларда йөрделәр, сикерделәр, әзерләнделәр. Ашау ягы яхшы иде, биргәнне сыпыртып кына куйдылар. Бер атна эчендә кара-кучкыл төскә кереп, кояшта каралдылар. Тик тау инженерлары укыган лекцияләрдә русча терминнарны аңлап бетерү мөмкин түгел иде: «горные выработки, эксплуатация подземных сооружений, спасение и эвакуация людей, пожарная безопасность и работа по тушению пожара, особые условия несения службы» кебек катлаулы сүзтезмәләрнең мәгънәләре татар аңына тиз генә барып җитә алмый икән шул... Застава начальнигы, чик сакчыларының отряд башлыгы да татар кешеләре булып чыкты – аңлашылмаганны сорарга да мөмкин иде.

Кыска вакытлы ялда аларны таулар арасында диңгездәй җәелеп яткан Чарвак сусаклагычына алып бардылар. Андагы матурлык, бәллүрдәй чиста һава, иртәнге сихри таңнарны каршылау барлык авырлыкны юып алгандай итә.Тауларның шифалы һавасы җанга рәхәтлек өсти, күңелләрне җилкендерә. Ә Чимган тауларының биеклеге өч мең өч йөз метрдан да артуын, көнбатышка өч йөз егерме чакрымга сузылганын белгәч, Әгъләм соклануын яшерә алмады. Искиткеч бит бу! Безнең якларда мондый карлы, биек таулар юк… Их, авылда калган дус малайларга күрсәтәсе иде бу тауларны!

Ташкентка кайткач та, егет бу манзараларны озак оныта алмады. Сеңелләре, бигрәк тә Әдибә зур кызыксыну белән таулар турында, абыйсының ниләр күрүе турында җентекләп сораштыра, географияне яратуын, үскәч укытучы булырга теләвен сәбәп итеп куя. Гаиләдә кичке сөйләшүләр гадәткә әйләнде. Шулай итеп тагын бер ел үтеп китте.

Тик кара сакалың кая барсаң да үзеңнән калмый, дип юкка гына әйтмәгәннәр икән. Инде тынычландык дигәндә, көтелмәгән хәл – Әгъзамны тикшерергә тотындылар. Милициядән килеп документларын сорадылар, бүлекчәгә чакырдылар. Тәлига да пошаманга төште. Нишләргә, кая барырга, кемгә сыенырга? Тагын тынычлап яшәргә ирек бирмәсләр микәнни? Нинди гаепләр тагарлар? Син кулак, төрмәдә синең урын, димәсләрме? Ирен кулга алсалар, нишләргә мөмкин соң? Урысчасы начар, яңача укый-яза белми. Хатын аптырашта калды. Балаларны, улын хәвефләрдән ничек сакларга? Әлегә бу сорауларга җавап юк иде.

***

Халык мыжлап торган шәһәр урамы буйлап көпә-көндез елый-елый кайту беркемгә дә килешә торган эш түгел түгелен, тик шулай да күз яшьләрен тыя алмый Әдибә. Менә китү көне, иптәшләрдән, дус кызлардан, сыйныфташлардан аерылу көне дә билгеле инде: эткәсе иртәгәсе көнгә билетлар алган. Ул иелеп салкын арык суында битен чылатты, тынычлангач, карт ябалдашларын җәеп үскән карагач төбенә басып, тирә-юньгә күз салды.

Еракта, томан эчендәге кебек Тянь-Шань тауларының чал түбәләре шәйләнә. Таулардан искән йөгерек җил шәһәргә җиләс һава китерә. Таулар да, ерганаклардан агып төшкән, кушылып көчле ташкынга әверелгән салкын сулы арыклар да, иртә яздан шау чәчәктә утырган хуш исле җимеш бакчалары, җәен ак алтындай җәйрәп яткан мамык басулары – бары да торып калачак! Сыйныфташларын, бигрәк тә Әдибәне читтән генә гел күзәтеп йөрүче кара күзле, озын буйлы чибәр малай Бабоджанны бүтән күрә алмас инде ул.

Иске шәһәр базары янына бертуктамый чылтырап кызыллы-сарылы трамвай килеп туктады. Сирәк кенә булса да Өске Жува ягына баручы автобуслар узгалады. Менә инде ул Ташкент – таш кала! Иске шәһәрнең кәкре-бөкре, тар һәм серле урам-тыкрыклары, ташлы балчыктан сыланып эшләнгән коймалары, йортлары яшеллеккә чумган! Кая карасаң да мәчет манаралары, тарихи биналар, алар бихисап монда! Кызкай абыйсын көтә торгач, тагын үз уйларына чумды.

Кичә генә укытучы абыйлары тарихи урыннар турында сөйләп, тиздән балаларны экскурсиягә алып барачагын әйткән иде. Якында гына борынгы акыл иясе, бөек суфи Зәнки-ата һәм аның хәләл җефете Канбәр-бибинең зираты, мавзолей хәрабәләре бар икән.

– Зәнки атаның чын исеме – Шәех Айхуҗа ибн Ташхуҗа Мансур, ә аларга мавзолейны 1390-1409 елларда Аксак Тимер үзе төзеткән, – диде мөгаллим. – Инде искереп җимерелә башласа да, халык онытмый, ул урынны карап, җыештырып тәртиптә тота. Изгеләр зираты бит ул!

Әнкәсенең дога укыганда әйтә торган Зәнки бабай сакчы булсын, дигәне әллә шул шәхес турында микән?!

Әдибә кызыксынып тирә-якка карады, ашыгып килүче абыйсын күреп каршысына чыкты.

– Абыем, эшең беттеме? – диде кыз. – Әйдә тизрәк мәктәпкә, әнкәй дә көтәдер инде.

Мәктәптән белешмәләр, кирәкле кәгазьләрне алып, мәктәп белән соңгы кат хушлашып, алар өйләренә ашыктылар.

Ишек төбеннән түргәчә тезелгән төенчекләр, кием-салым салынган капчыклар, чемоданнар, сумкалар тагын үз хуҗаларын көтә иде. Китәргә булгач китәргә инде! Яңа гына беренче сыйныфны тәмамлаган Фәһимә кадерләп кенә дәреслекләрен актарып утыра: алып та китә алмый аларны, калдырырга да җәл!

Тәлига улы белән сөйләшкәннән соң бакчага чыкты, тандырда пешкән юка икмәкләрне юл кәрзиненә тутырды, әйберләрен җыйды. Әгъзамы кайтканда, ул барысын да хәстәрләп бетергән иде инде.

– Әйдә, Әгъзам, зиратка барып, улыбыз кабере белән дә саубуллашып кайтаек! Чит җирләрдә ялгызы кала бит!..

Туган якларга якынрак булу теләге көчле идеме, Свердловск тирәсенә кайтып урнашырга риза иде хатын. Авыр вакытта сыендырган, ризык-нан биргән бу үзбәк якларын калдырып китүе дә җәл иде.

Икенче көн дә китү мәшәкатьләре белән бик тиз үтте. Озатырга күршеләр җыелды, изге теләкләр әйтелде, догалар укылды.

Өч ел элек Ташкент вокзалына килеп төшкән көннәрне уйлап, монда аларга яшәргә мөмкинлек биргән, сыендырган, туендырган, сыйлы-икмәкле якка рәхмәтләрен әйтеп, кичке якта бу гаилә тагын поездга утырды. Ике катлы тонык тәрәзәдән вокзал бинасы күздән югалганчы карап бардылар. Поезд тизлеген арттыра башлады, ә тышта инде караңгылык куерганнан-куера иде. Юллар, юллар, тагын билгесезлек... Урал таулары ничек каршылар икән аларны?

1937 елның июнь уртасында юлчылар Ревда бистәсеннән Дегтярка ягына юл алдылар. Урта Урал Русиянең авыр промышленность үзәге буларак күптән билгеле як, табигый байлыклары белән дан тоткан як икән! Әгъләм монда чуен кою, бакыр эретү заводлары булуын белде, эш табуы авыр булмас кебек тоелды аңа. Әтисе ничектер уйга чумган. Әнкәсе, сеңелләре тирә-юнь белән танышкандай, якындагы катнаш урманнарга карап баралар. Бар табигать йокыдан уянып, урман-кырлар яшеллеккә чумган, болын чәчәкләре күренә, аллы-гөлле күбәләкләр оча. Гел туган яклардагы кебек инде.

Тәлига күңеле белән авылында, яшьлегендә йөри. Әгъзамы белән чишмә тавында очраша иде алар. Чишмә тавышын тыңлыйлар иде.Чишмәгә суга барган җирдән урлап алып китте дә инде аны Әгъзамы. Чөнки абыйлары каршы булды.Ябышып чыгу оят иде ул заманда. Шуңа да ике ай буена килмәделәр дә, өйгә дә кертмәделәр. Чишмә тавындагы карт тирәкләр генә аның борчуларына да, бәхетенә дә шаһит иде. И-и, ул салкын чишмә, эчәсе иде суларын, тәме һаман онтылмый! Авылына, Салихка кайтасы иде! Күңеле нечкәрде аның, күзләре яшьләнде. Онытылмый, юк шул, онытылмый икән туган як! Барыбер бер кайтырлар әле...

Дегтярка бистәсе тигез урында урнашса да, аның тау асты дип йөртелгән өлеше дә бар икән. Шунда килеп җиттеләр дә Аксәет авылы кешеләрен – Зәки исемле кодаларын эзләргә керештеләр. Сораша торгач, тиз таптылар. Зәки белән Мөкәррәмә ачык күңелле, бик мөлаемнар, кешелекле икәннәре күренеп тора. Кызлары Хәния белән Сәкинә дә кунак кызларын тиз үз итте. Балаларга йокларга урын табылды. Кунаклар юл тузаннарын кагып, мунчада юынып та чыккач, өстәл әзерләнде, төн буена сөйләшеп сүзләр бетмәде. Туган-тумачаның хәлләрен, авылга кайтып килүләрен сөйләделәр.

– Нишләргә икәнен ачык кына уйлап та бетермәдем, – диде Әгъзам, – эшкә урнашканда энәсеннән җебенәчә тикшерерләр инде.

– Хәзер закун бик каты, Әгъзам туган. Көчленеке замана. Менә сине, Әгъләм, урнаштыру авыр булмас кебек. Синдәй камсамуллар, спортсменнар кайда да кирәк.

Икенче көнне үк егетне ияртеп алып китте ул. Барганчы кызык вакыйгалар турында сөйләде.

– Эшчеләр бистәсе Свердловскига якын, турыдан кырык чакрым да юк. Монда ике йөз еллар элек үк атаклы Демидовлар бакыр эретү, тимер, чуен кою эшләрен башлап җибәргән, – ди Зәки абыйсы. – Хәзер бу эшләр киң күләмдә башланды, илгә тимер, чуен күп кирәк.

– Урман, су, руда булгач, эш барадыр инде. Елгалар да зур гына күренә.

– Су юллары буйлап, Чусовой елгасы белән безнең якка, ә Исет елгасы буйлап Азия ягына китәргә мөмкин, безнең Дегтярка Азия белән Ауропа чикләренең уртасында утыра, – ди Зәки абыйсы.

– Ә син, Зәки абый, үзең нинди эштә соң?

– Әй, энем, әллә ни зур түрә түгел, бригадир гына. Каен агачыннан күмер яндырабыз, ә тузыннан дегет агызабыз. Ревда тимер юлына шуларны җибәреп торучы инде мин. Ә сине «Дегтярский рудник» начальнигы иптәш Гарновский янына алып барам хәзер, – диде ул.

Икенче көнне үк эшкә урнашты егет. Горноспасатель булып эшләгәнен исәпкә алып, аңа ике урын тәкъдим иттеләр. Бер атнадан остазы Галимулла абзый Әгъләмне җыелышка алып китте. Җыелышта бик кызык хәбәрләр ишетте ул. «Дегтярский рудник» бакыр җитештерү планын арттырырга тиеш икән. Совет власте урнашканда, 1917 елда элекке хуҗалары шахталарга су тутырып яраксыз хәлгә китергән булалар. 1925-1930 елларда монда вакытлыча килешү нигезендә «Лена-Голдфилдс» дигән америка фирмасы торгызу эшләре алып барган. «Москва», «Петербург» шахталары кебек үк хәзер «Нью-Йорк» һәм «Лондон» шахталары да ачылырга тиеш ди.

– Принята Государственная программа интенсивной разработки Дегтяровского месторождения, – дип сүз башлады Гарновский. Озак сөйләде ул. Партия һәм иптәш Сталин күрсәтмәләре буенчаниләр эшләнергә тиеш, барысы да җентекләп тикшерелде. Җыелыш ике сәгатькә сузылды.

Көн артыннан көннәр узды. Егет кичләрен укыды. Соцгород дигән районнан бер баракның ике бүлмәсен бирделәр Әгъләмнәргә. Тәлига Зәки янына, урман кисүчеләр бригадасына урнашты. Әгъзамның хезмәте бистәдән читтә, мал азыгы, атларга печән хәзерләү белән мәшгуль, кеше күзенә бик күренеп йөрмәскә тырыша, кунарга да кайтмый. Төрле мәшәкатьләр белән вакыт тиз үтте.

Яңа ел бәйрәменә әзерләнеп йөргән көннәр иде. Кызыл почмакта бертөркем кызлар шау-гөр килә. Араларында ак челтәр кофта, кара борчаклы итәк киеп, нечкә билен каеш белән буган, бик сөйкемле кызны күреп Әгъләм туктап калды. Мәрмәрдәй нәфис муенына төшкән саргылт чәчләрен, йомры күкрәкләрен, тулы иренен күздән кичерде.

– Что, парень, уставился на нашу Майю?

Кызлар чыркылдашып көлешә башладылар. Егет кызарынды, иптәше артыннан китапханәгә кереп китте. Кичен өйгә кайтканда, Әгъләм белән Дима өч кызны куып җитте. Аларның уртадагысы – Мәйсәрә исемлесе нәкъ шул кыз иде.

– Аня, – дип таныштырды үзен бик чаясы һәм ике иптәшенең дә исемнәрен атады.

Саҗидә белән Мәйсәрә үзләрен басынкы һәм тыйнак тоталар, Аня кебек күп сөйләшмиләр. «Үзебезнең тәрбияле татар кызлары!» – шулай уйлады егет. Яшьләр клубында кичке уеннарда, бию кичәләрендә алар еш очраша башладылар. Кызлар бу чибәр, басынкы егеткә тиз ияләште. Киноларга бергә йөриләр. Мәйсәрәне бик тә ошатты егет. Кыз озатып кайту кыюлык өстәде аңа. Якыннанрак танышып, сөйләшеп йөри торгач, ул аны ныклап яратуын аңлады.

Чәчәкле, җылы май җитте. Эшкә барганда, кайтканда, Мәйсәрә очрамасмы, дип як-ягына карый Әгъләм, юк сәбәпне бар итеп почтага, аның эшләгән урынына да кергәли үзе. Аны күрсә, йөзендә елмаю уйный, күзләре балкып китә егетнең; ул баштанаяк шатлык нурына күмелде, чөнки бәхетле иде. Сөйгәненең зәңгәр күзләреннән, якты карашыннан мәхәббәт уты, яшәү дәрте ала!

– Син бит минем язгы кояш нурларында коенган зәңгәр чәчәгем, – ди Әгъләм, уенда булса да кызны иңбашларыннан кочып.

Бүген дә чалбарын юып, матрац астына кибәр-кипмәс тигезләп салган абыйсына карап, Фәһимә:

– Абый, син аны үтүкләнсен өчен шунда куйдыңмы? Син тагын клубка барасыңдыр инде, анда күңеллемени? – дип абыйсы янында бөтерелде.

– Әйе, хезмәт хакы алгач, бер үтүк юнәтергә кирәк инде. Әйдә, сеңлем, сине дә алып барам, дәресләреңне хәзерләп бетер!

Кызчык шатлыгыннан аны кочаклап алды. Бик әйбәт шул аның абыйсы. Укып та йөри, эшендә дә яраталар үзен. Абыйсы белән горурлануын яшерми Фәһимә. Әдибә апасын алмый, ә аны ияртә! Апасының үз иптәшләре, дуслары. Хәния белән көн дә очрашалар, серләшәләр. Мөкаррәмә апа яңа күлмәк тегеп биргән әле үзенә.

Бу елда комсомол яшьләр җыелышып «Бәллүр тау» карьерына бардылар. Кварц, гранит катламнары белән дан тоткан бу тау ерактан ук төрле төсләргә кереп ялтырап тора. Кызгылт, зәңгәр, аксыл, сары төсләр чиратлашып чагыла. Урал тау байлыклары турында күпме легендалар, әкиятләр чыгарганнар, чынбарлыкка туры килгәннәре дә күп икән. – Комсомол секретаре шулай сөйли: элек малахитны император сараена җибәргәннәр, эрмитажда да малахит зал бар икән. Күпме байлыкны, асылташларны чит илләргә озатканнар, алар белән француз корольләренең резиденциясен, Версаль сарайларын бизәгәннәр. Ә хәзер алар халыкныкы, үзебезнең эшче-крестьяннар байлыгы, ди секретарь. Элек бакыр рудасын мичләрдә яндырып эреткәннәр, акча сугу өчен 480 тонна бакыр җитештергәннәр. Алтын рудасы да башта Уралда табылган! Корыч коюны әйтәсе дә юк.

Әгъләм бу сөйләшүдән соң зур горурлык хисләре кичерде. Үз эшенең мөһимлеген аңлап, дәүләт өчен файдалы кеше булуына шатлана ул. Борчыла да үзе, теге вакытта әткәсенә тагыла язган кара мөһер – кулак исемен һичкемгә белдерми, искә аласы да килми. Илдә репрессия көчәйде, кешегә ышаныч бетте. Халык дошманнары да йоклап ятмый, күрәсең. Ачылып китеп сөйләшергә куркыныч. Һәркөн шундый яңалык: кемнедер алып киткәннәр. Партиянең күренекле вәкилләрен дә, түрәләрне дә аямыйлар, төнлә дә кулга алалар, гаеп табалар. «Халык дошманы» дигән ярлык тагып, үзләрен генә түгел, гаиләләрен, балаларын төрмәгә утырталар. Шушындый шомлы заманда кулга алынган Иван Петрович урынына Әгъләмне смена начальнигы итеп куйдылар. Башы белән эшкә чумды егет.

Политинформациядә бөек юлбашчыбыз Сталинның яңа карарларын, илнең хәрби көч-куәтен ныгыту максатында эшләнергә тиеш эшләр турында сөйлиләр. Златоуст заводларында туп снарядлары кою өчен чимал кирәклеге, СССРда яңа төр техника үзләштерү, ашыгып корал җитештерү – болар барысы да сугыш чыгу куркынычын искәртә, күңелгә шомлы уйлар килә башлый .

Дусты Дима белән «Ворошиловча төз ату» значогын алганнан соң, Әгъләм спорт нормативларын тапшырырга ялгызы йөрде. Дима тиздән өйләнергә җыенуын сәбәп итеп, спортзалга килә алмады. «Аня белән безнең мәшәкатьле чагыбыз, дустым», диде ул.

Уйга калды Әгъләм. Ул да кайчан да булса өйләнер, тик кая алып кайтыр ул сөйгәнен? Бик бәхетле яшәрләр иде алар. Дима белән Аня да бәхетле булсын...

– Абый, Германия белән дуслык килешүе төзелгән, – диде сеңлесе Әдибә, абыйсы кайтып керүгә. – Бүген радиодан сөйләделәр.

Эштә дә, өйдә дә гел шул турыда сөйләштеләр.

– Герман белән дуслашкач, сугыш чыгар дип куркасы юк инде, улым, сине әрмиягә алсалар да, әйбәт кенә хезмәт итеп кайтырсың, Алла бирсә, – ди әнкәсе. Әткәләре генә бу хәбәргә бик ышанып бетми.

– Борчылма, әткәй, безнең Кызыл Армия көчле ул, сугыш башласалар, любой дошманны юк итәргә әзер!

– Менә бит хәзер солдатка да унсигездән ала башларга дигән карар чыккан, юкка түгел ул, улым. Сине дә озак тотмаслар, ичмасам бәләкәй генә булса да бер йорт төзеп керергә кирәк ие. Илләр тыныч торса.

– Үзебезнең өй белән мунча булсамы, картым!

Тәлига бу хәбәргә ышаныргамы-юкмы дигәндәй, әле иренә, әле улына карады.

– Безнең бригатта сүләп тордылар, бура сатучылар бар икән монда, әткәсе! Өчебез дә эшләп торганда, дим.

– Беләм, мин карап йөрдем, хакын да сөйләштем инде. Акчасын гына ничек җиткерәсе...Түбә тактасын белешәсе калды.

Уйлаштылар, сөйләштеләр дә яңгырлар башланганчы землянка казырга, бура алып, күтәреп куярга дигән фикергә килделәр. Көнне төнгә ялгап эшкә тотындылар: урын алып, барын әзерләделәр. Бурычка бата-бата, дус-ишләр, танышлар белән өмә ясап, бураны өеп куйдылар. Кызлар җил-яңгырга карамый йомычка җыйды, йорт тирәсен чистартты. Эштән туктаган арада апасына карап:

– Кайда бакча, кайда түтәлләр булыр икән, апа? – диде Фәһимә. Аның күз алдында шаулап торган җимеш бакчалы үз өйләре пәйда булгандай тоелды.

Ноябрь аенда җир идәнле җыйнак кына өй калкып чыкты. Тәрәзәләргә такта кактылар. Шатлыгы эченә сыймады Тәлиганың. Авылларындагы зур, биек йортлары түгел дә соң, тик үзләренеке бит! Язга бетереп тә куярлар әле. Идән-түшәмен, морҗасын җиткерсәләр, җәйгә күчәрләр дә, Алла бирсә!

Бүген Әгъләм эштән борчылып кайтты.

– Нәрсә булды, улым? Эшеңдә ул-бу булмагандыр бит?

– Юк, әнкәй, фин сугышы башланган, – диде Әгъләм. – Миннән яшьрәк егетләрне дә военкоматка чакыралар. Ә миңа повестка һаман юк!

– Син эшеңдә кирәгрәктер, улым! Синдәйләргә бронь бирәләр бит. – Әткәсе малаена карап торды да өстәп куйды: – Иртәгә мин Яңа соцгородка барам, вербовщик итеп эшкә чакырдылар.

– Ярый ла ахыры хәерле булса, – диде Тәлига, кызлары янына барып басты да өстәл әзерли башлады. Өстәлгә кабыклы бәрәңге янына катык, аннары арыш ипие куйды.

Өстәл тирәсенә, җиделе лампа яктысына җыелдылар. Сугыш турындагы хәбәр барысын да борчуга салса да, табын артына утырдылар...

Бисмилла әйтеп ашый гына башлаганнар иде, урамда кемнәрнеңдер шаулашып кычкырышканы ишетелде. Бар да сикерешеп торды. Кинәт шунда барак тәрәзәсенә каты итеп суктылар.

– Пожа-ар! Йортыгыз яна!

Котлары алынып, бөтенесе урамга йөгерде. Бар халык чиләкләр, багорлар күтәреп ярдәмгә ашыга. Түбәндә, тау астында биек ут көлтәләрен салкын җил уйната, гүелдәп аларның яңа йорты яна иде! Ут яктысында кешеләр кайнаша, якындагы йортларны очкыннан, ялкыннан саклыйлар, күрәсең. Ах, нишләргә, өйләре инде янып бетеп килә!

Тәлига, нишләргә белмичә, әле чиләккә, әле багорга ябышты, аннары хәле китеп җиргә утырды да кычкырып елый башлады. Күрше марҗасы килеп юаткандай итте:

– Вставай, Тайя, мокро и холодно, заболеешь! – Ул җирдән торырга булышты. Шул арада корымга буялган Әдибә белән куркынган Фәһимә килеп әнкәләрен кочакладылар, алар да кушылып еларга тотынды. Күршеләре җитәкләп диярлек кайтыр юлга борды:

– Монда инде берни эшләп булмый! Әйдәгез, янып бетте бит, җиле дә нинди көчле!

Кар катыш яңгыр ява башлады. Ике сәгатьләп вакыт үтүгә, киемнәре юешләнгән, корымга баткан Әгъзам белән Әгъләм кайтып керде. Мөкәррәмә белән Зәки күренде.

– Ут төрткәннәр булса кирәк, кем этлеге булыр бу?

– Бер явыз бәндә бар монда, шул булмагае, тик тотылмаган бур түгел...

Якты хыяллар белән шатланып төзегән бу өйләре дә үзләренә язмаган икән бит!

– Ярый әле үзегез, балалар исән-сау, ул тиклем елама, Тәлига! – дип тынычландырды Мөкәррәмә.

Кышкы салкыннар башланды. Кияргә җылы кием, ягарга утын алырга акча юк иде. Тормыш ничектер тагын да авырлаша барды. Ипи алырга барганда Әдибәнең кулыннан талон кенәгәсен талап ала яздылар. Ярый җитезлеге коткарды кызны.

– Азык-төлекне норма белән генә бирүләре СССР белән Финляндия арасындагы сугыш аркасындадыр инде. – Шулай дип гөманлады Әгъзам. – Ай-һай, тормышлар аруланыр микән соң?

Язгы кояш җиргә турырак карауга, Әгъләмгә хәрби комиссариаттан повестка китерделәр. Эшләгән эшен тапшырып, медкомиссиядә каралып, әти-әни, туганнар, дуслар белән саубуллашып, вакыт тиз узды. Мәйсәрәсе белән кулга кул тотынышып кич буе урамда йөрделәр алар, сөйләшеп сүзләре бетмәде.

– Көтәрсеңме мине, зәңгәр чәчәгем, – диде егет, кызны кочагына алып, – өч ел бит, аз гомер түгел!

– Биш түгел лә, тик кайткач карт кыз димәссеңме соң? – дигән булды кыз, иркәләнеп.

– Әйтәмме соң, мин бит сине би-и-ик нык яратам!

– Мин дә. Менә сиңа бүләккә кулъяулык чиктем. Мине онытма, хатларыңны ешрак яз, җаным! – Мәйсәрә Әгъләмнең күкрәгенә капланды, аның күзләре яшьләнгән иде.

Иртән вокзалга җиткәндә, Тәлигага нидер булды: әйтерсең лә аның йөрәген суырып, җанын өзеп алдылар. Бердәнбер улы – ныклы терәге китә бит, исән-сау әйләнеп кайтыр микән?

– Борчылма, әнкәй, СССР зур һәм көчле ил, ак финнарны җиңдек, мин тынычта хезмәт итеп кайтырмын. Исән-сау гына яшәгез! Мин кайткач, зур итеп өй бетерербез! Әткәй, синең белән дә бар да яхшы булыр дип уйлыйм. Кызлар, әткәй-әнкәйне борчымагыз, тырышып укыгыз! – Башта Фәһимәне күтәреп алып үпте дә: – Кара аны, тагын чегәннәр урлап китмәсен! – дип шаяртты. Аннары әнкәсенең күз яшьләрен сөртте, озак кына кочагыннан чыгармый торды. Зур сеңлесе һәм әткәсе белән хушлашуга, «По вагонам!» дигән фәрман ишетелде. Башкалар белән бергә Әгъләм дә вагонга таба атлады, борылып, «сау булыгыз», дип кычкырды да вагон ишегеннән кереп юк булды.

...Әгъләмнән хатлар килүен түземсезләнеп көтәләр: Әдибә белән Фәһимә, почтальон килмәсә, почтага ук баралар. Мәйсәрә кызларны күрүгә, вакыт табып, яннарына чыгып урый. Соңгы хатында абыйлары үзен Түбән Новгород дигән шәһәргә танкистлыкка укырга җибәрәчәкләрен әйтеп язган иде. Озак кына хаты булмый торды. Менә бүген зур шатлык – көтелгән хат килде! Тәлига кулларын алъяпкычына сөртеп, ашыгып сәке читенә утырды.

– Әйдә, укы тизрәк, кызым!

## ЯНГЫН ЧЫККАЧ СОҢ БУЛЫР

**Узган гасырның 60нчы еллары уртасында, миңа алты-җиде яшь булгандыр, бездән өч чакрымдагы Келәтле авылы тарафыннан төнге якта ялкын күтәрелгәнне күреп котсыз калган идек. Янгын чыккан һәм Келәтле яна дип кайгыга баттык.**

**Соңрак белдек: Келәтле тавы артында яңа төзелеп килгән «Нефтехим» берләшмәсенең беренче торбасыннан чыккан ялкын булган икән ул.**

**Хәзер инде биек-биек торбаларны санап бетерерлек кенә түгел һәм аннан чыккан төтеннәргә, якты ялкыннарга беребезнең дә исе китми. Туган җир тиз арада үзгәрде, Түбән Кама каласы белән бергә «Нижнекамскнефтехим», «Нижнекамскшина», Техник углеродлар заводы һәм башкалары калкып чыкты, янәшә генә КамАЗ гиганты колачын җәйде. Авылдашларымның күбесе шул заводларда эшли, яшәү рәвеше шул комплекска яраклашты һәм безнең төбәк инде илле елдан артык шул цивилизация кануннарына буйсынып яшәп ята.**

**Әйе, Келәтле ягыннан күтәрелгән ялкын алты-җиде яшемдә котсыз калдырган иде, хәзер исә туган ягымны шул ялкынлы торбалардан башка күзаллау мөмкин дә түгел, кеше бар нәрсәгә күнегә, ияләшә. Әмма соңгы вакытта мин Кама Аланы тарафыннан афәт ялкыны күтәрелмәгәе дип куркып яшим. Анда атом станциясен төзи башларга җыеналар дигән хәбәр котны ала.**

**«КамАЗ», «Нижнекамскнефтехим», «Нижнекамскшина» кебек ил масштабындагы объектлар уңышлы, табышлы эшләп килгән төбәктә, Идел буена тоташкан Кама буенда атом станциясе төзү бөтен Кама-Идел регионын котылгысыз куркыныч астына куя түгелме? Чернобыль катастрофасыннан соң ничә ел үтте, ә Припять елгасының суын һаман да әле эчәргә ярамый, алай гына да түгел, гомумән, ул тирәдә яшәргә ярамый. Японнарның Фукусима фаҗигасе бөтен кешелеккә дә янамыймы?**

**Прогресс яхшы нәрсә, әмма аның бер куркыныч җитешсезлеге бар – ул торымнан-торымга шартлап кую сыйфатына ия. Денем өчен түгел, көнем өчен дип яшәүче кешеләр хәл итмәсен иде төзелеш планнарын.**

**Егерме беренче гасыр безнең өчен Америкада небоскрёбларны җимерү белән башланды. Терроризмның үзенең дә радиациягә тиң сыйфатлары бар. Планета күләмендә иң көчле, иң тотрыклы, иң бай булып саналган Америкада да шундый катастрофаларны кисәтә алмадылар бит. Россия уртасындагы Кама-Идел регионында атом станциясенең киләчәктә өстебезгә килерлек коточкыч афәтләр ихтималы икәнен кисәтү – бүген бөтенебезнең дә киләчәк буыннар алдындагы әхлакый бурычы ул.**

**Зөлфәт ХӘКИМ**

Барчасына да аерым-аерым күп сәлам юллаганнан соң, үзе турында шундый юллар язган иде улы:

«Минем хәлләрем яхшы. Безне кыска сроклы танкистлар курсында укыталар. Вакыт тыгыз, занятиеләр күп. Тиз генә язалмам».

Җавап хатын бергәләп яздылар. Үзебезнең тормышыбыз бер көе, үзгәрешләр юк, диделәр. Әгъзамны тагын тикшерүчегә чакыртуларын әйтмәскә булдылар.

Менә җәйнең иң матур чагы – чәчәкле июнь җитте. Тәлига белән Әгъзам озак кына уйлаштылар да ике-өч көнгә генә туган якларына кайтып килергә булдылар. Кызлар янына иптәшкә Сәкинә килмәкче булды.

Вокзалда билетлар алуга, яннарына ике кызылармеец килеп басты.

– Фахров Әгъзам син буласыңмы?

– Әйе, сезгә нәрсә, иптәшләр?

– Нинди иптәш булыйк без сиңа. Әйдә, атла!

– Кая?

– Баргач күрерсең!

Әгъзам Тәлиганың борчулы йөзенә карап елмайгандай итте.

– Борчылма, хатын, бар, өйгә, балалар янына! Мин кайткач китәрбез. Мин тиз кайтырмын, – дип ышанычлы адымнар белән ишеккә таба борылды. Аннары хатынын кочаклады, күз кысты, аны шулай алып киттеләр.

Тәлига вокзал уртасында ялгызы калды.

Озак көтте Тәлига ирен. Шомланып, борчылып көтте ул. Эшендә дә аңа юньле киңәш бирә алмадылар. Шул китүдән Әгъзам кире әйләнеп кайтмады.

Кайгы ялгызы гына йөрми, диюләре хак бит ул. Әгълэмнән кыска гына хат килде, аларның танк бригадасын чик буена җибәрәләр икән. Шул көнне радио илебездә Бөек Ватан сугышы башлануын, безгә фашист илбасарлары һөҗүм итүен җиткерде...

***

Дегтярка мәктәбендә дә яралы солдатлар өчен госпиталь ачылды. Өлкән сыйныф укучыларын госпитальгә дежурга билгеләделәр. Ундүртенче яшь белән баручы кызга эш кайда да күп иде, Әдибә дәресләр бетүгә әнкәсенә ярдәм итәргә йөрде.

Тәлига төнге сменадан арып кайтса да, бераз хәл алуга, Ревдага, төрмәгә ашыкты. Бүген кабул итү көне икән. Иренең хәбәрен белә алмый озак йөрде ул. Бер атна элек кенә урау юллар аша хәбәр килеп иреште: 58 нче статья белән гаепләнгән, бик ябыккан, кыйналган Әгъзамны Бәдрәш авылы мулласы дизентерия белән авыручылар барагында күргән! Хәле бик начар иде, ашарга бирмиләр ди, исән микән, исән булса, тиздән аларны Чиләбегә күчерергә мөмкиннәр, дип әйтергә кушкан.

Үзбәкстанда чакта ире алган зур чуклы шәлен сатып, бераз ризык юнәтте дә, ашарга әзерләп, төрмә капкасы янына китте Тәлига. Озын, биек таш койма буендагы чират акрын бара, кайберәүләрнең әйберен кире боралар, алганнарыныкын бик озак тикшерәләр. Инде чират җитә дигәндә генә, кабул итү пунктын шап итеп ябып куйдылар. Ашыйсы килүдән, арудан күңеле болганса да, ул тагын көтәргә булды. Бер сәгатьләп вакыт үтүгә, такта тәрәзә күтәрелде, ачулы йөз пәйда булды.

– Фамилия? Статья?

– 58 нче, Фахров Әгъзам, – диде хатын, куркуын җиңеп.

– Такой не числится! Следующий…

– Нәрсә дигән сүз инде бу, нишләп не числитсә?

Хатын чираттагы халыкка, артындагы озынча ябык иргә сораулы караш ташлады.

– Юк , диделәр сиңа, бар, өеңә кайт! – диде ир, йомшак кына итеп.

Хатын тагын берәр хәбәр булмасмы дигәндәй, бераз көтте.

Ярсып, үкси-үкси елады ул баракка кайтканда. Гаепсез кешене дә юкка чыгара торган нинди залим дөнья бу? Иблисләр бастымыни аны? Кайда икән, ач, авыру килеш нинди җәфалар чигә икән аның газиз ире? Исән микән, юк микән? Сораулар җавапсыз иде.

Кызлары да, үзе дә бик сагындылар әткәләрен, кичләрен үзәкне өзеп, гел аны сөйлиләр, искә төшерәләр дә елашып алалар. Аннан башка ничек яшәргә? Кадере юк кешенең бу илдә!

Атна саен барды Тәлига төрмә капкасы янына. Нишләргә? Ни өчен кулга алдылар ирен? Гаебе нидә? Кайчан суд булган? Тик мондый сорауларга җавап бирергә теләүче дә юк иде. Нишләргә соң?

Илдә канкойгыч сугыш бара, безнең гаскәрләр һаман чигенә, диләр. Ниләр күрербез, билгесез... Улы ут эчендә, хатлары бик сирәк килә, шулай да борчыла, киңәшләр бирә үзе: «Авылга, Башкортстанга кайтып китсәгез, яхшы булыр иде, әнкәй, – дип язган ул. – Илдә чыпчык үлми! Котылып чыккач, сезне әткәй дә авылдан эзләр. Фашистларны җиңгәч, сугыш беткәч, мин дә авылга кайтырмын! Ышаныгыз, Җиңү безнең якта булыр!»

Ачлык дигән бик яман нәрсә үзен еш искә төшерә башлады. Мәктәптән кайткач, кызларга ашарга берни юк! Кечесенә иртән бер кашык балык мае эчертә Тәлига. Эштә бирелгән паёк бик тиз бетә. Сугыштагы улы да, төрмәдәге ире дә сыйланып ятмыйлар бит, алар да ач йөридер, дип юата хатын үзләрен. Түзәргә кирәк, бөтен ил өстенә килгән хәсрәт бит бу!

– Помнишь, апа, Ташкентта базардан сухофрукты алып кайта идек, – ди Фәһимә.

– Анда булсакмы... – Әдибә уйга калды. – Әллә, әнкәй, чынлап та авылга кайтабызмы?

– Кайда яшәрбез соң, балакаем? – Аннары уйланып торды да: – Без узарга тиеш юллар бетмәгәндер шул әле, – дип куйды...

Иртән эшкә килгәч, яңа гына смена начальнигы итеп билгеләнгән Настя исемле хатын Тәлигага таба карап сөйләнде:

– Безнең арада халык дошманы хатынына урын булмаска тиеш!

– Нәрсә сөйлисең син, Настя, нинди халык дошманы ди ул?

– Аның улы сугышта танкист, командир, – диештеләр хатыннар.

Тәлига аптыраушта калды. Кичкә инде ул катгый бер фикергә килгән иде. Ашыгып өенә кайтты, аннары Мөкәррәмә янына китте.

– Зәкидән хат һаман юкмы?

– Юк, Тәлигакаем, исән булса, бер язар иде, берәр нәрсә булгандыр, әллә ранин булып ята микән...

– Сугыш бит ул, төрле хәл булырга мөмкин, Әгъләмемнән дә бик сирәк килә хәзер. Нимес Мәскәүгә уктала ди бит!

– Әй, ул каһәр суккырының муенын кайчан борырлар инде! Бик авыр бит тормышлар! Үзегез ничек кенә яшәп ятасыз соң?

Хәлләрен сөйләп биргәч, дусты:

– Ни әйтсәң дә, туганнарың – апаң, җиңгәләрең янында җиңелрәк булыр. Кызларың үсеп килә, кайт иленә! – диде ул. – Иреңнән хәбәр булса, йә улыңнан хат килсә, авылыгызга җибәрербез, анысы өчен борчылма!

Саубуллашканда, Мөкәррәмә кызларының кечерәйгән киемнәрен төреп Тәлигага бирде.

Мәктәпкә баргач, кызларга төрле яктан сораулар яуды:

– Файка, вы ещё приедете?

– Ада, ты дальше учиться будешь или работать?

– А дежурить в госпитале ты уже не будешь?

Фәһимә почтага барып, Мәйсәрә апасы белән дә хушлашырга өлгерде.

– Абыеңнан хат киләме, нәрсәләр яза?

– А я сама ему писала, – диде кызкай, горурланып. – Сестра только адрес написала.

Үзләренең авылларына кайтып китәселәрен әйткәч, Мәйсәрә күңелсезләнде, кызны кочаклап алды да хат язып торырга кушты.

Дус-ишләр белән хушлашып, әйберләрен күтәреп, алар тагын вокзалга киттеләр. Репродуктордан Левитанның көчле тавышы яңгырады:

– Передаём сводку Совинформбюро!

Хәбәрләрдән ниндидер кырыс, күңелсез чынбарлык тарала, шул җанга үтеп керә иде.

Тәлига тирә-якка карады. Вокзалда хәрбиләр күп. Ул үзенең улын, аның хушлашып хезмәткә китүен, үзләренең бергәләп аны озатып калуларын, аннары шушында иренең кулга алынуын исенә төшерде.

Вокзал янында ыгы-зыгы. Диварларда сугыш турындагы плакатлар, фашистларны дөмбәсләүне төшергән карикатура рәсемнәре.

Танклар, сугышчылар төялгән эшелоннар туктап та тормый, Көнбатышка таба китә тора. Каршы якта килеп туктаган составтан станоклар бушаталар. Икенче вагоннан сәләмә киемле немец әсирләрен төшерә башладылар. Әдибә белән Фәһимә, шаккатып, шуларны күзәтте. Менә ул фашистлар, кешелекнең дошманнары! Күпме шәһәр-авылларны җимергән, яндырган, күпме кешеләрне, солдатларны үтергән алар! Мәктәптә укытучылар сөйләгән, киножурналларда күрсәтелгән вәхшилекләрен искә төшерде Әдибә. Ул йодрыкларын кысып, нәфрәт белән тегеләр ягына карады:

– Абыкаем, күбрәк кырыгыз сез бу хәшәрәтләрне! – диде кыз, пышылдап.

...Таш-таулар арасыннан поезд алга омтыла. Вагоннар иске, салкын. Красноуфимск станциясенә дә җиттеләр. Алда – Яңавыл – Туган җир! Ничек каршы алыр аларны туган авыл? Кемнәргә кайтырга икән ике бала белән? Авылдашлар, туганнар ничек икән – ничә еллар үтте бит инде. Бөгелмәде, сыгылмады, сындырырга тырыштылар – сынмады. Тик барыбер бик авыр икән лә кайтып керүе. Шундый уйлар тынгылык бирми, эчке дерелдәү йөрәккә кадәр үрмәли иде.

Эленке-салынкы болытларны куып, көзге җил исә. Поезддан төшеп, вокзал алдына чыгуга, аларны салкын һава бөтереп алды. Килешле генә башлык астыннан бүселеп чыккан саргылт бөдрәләрен эчкәрәк яшереп, кара-көрән юка пәлтәсен тарткалады Фәһимә. Көчәйткечтән тигез тавыш яңгырады:

– Санитарный состав прибыл на первый путь!

Сугыштан кайтучы яралы ирләрен каршыларга поезд янына хатын-кызлар ашыга. Кайсылары кул арбасы тартып килгән. Киемнәр тузган, йөзләр сагышлы...

Кемнәрнеңдер газиз баласы йә кадерле ире кан эчендәдер, үлем белән тартышадыр... Кайсысы кулсыз, аяксыздыр... Йә Ходаем, үзең ярдәмеңнән ташлама шуларны! Минем улым ничек икән, исән микән балакаем?..

Вокзал янында бер гарип солдат, агач аягын агач арбасына сузып утырган

да күшеккән куллары белән өздереп гармун уйный. Баш очындагы чаганның сирәк сары яфракларын сары сагыш итеп җил туздыра.

– Өши башладыңмы, кызым? – дип, Тәлига юл капчыгыннан калын шакмаклы шәлен алды. Унбер яшендә генә булса да, буйга тартылып, озынаеп киткән кызын шәл белән төреп, чукларын артка тартып бәйләп куйды. Кызчык бераз җылынып киткәндәй булды. Олысы бирешми, ныклырак анысы... Хатын авылга кайту өчен ат белешергә китте.

Җиде еллап гомер үтеп китсә дә, Яңавыл әллә ни үзгәрмәгән икән. Вокзал янында шул ук бер-ике катлы агач йортлар, алар искерә төшкән дә җимерек ихаталар гына күбәйгән. Монда юлаучылар аз, атлар янында берничә кеше кайнаша. Тәлига белешә торгач, бер бабай белән сөйләшеп килеште. Арык атның иске генә арбасына булган әйберләрен төяделәр дә кайтыр юлга чыктылар.

Көн болытлы, агачларның шәрә ботаклары салкын җилдә селкенә, арба тәгәрмәче туң җирдә шыгырдап бара. Кызлар үзара русча нидер сөйләшәләр, тик уйга баткан хатын берни дә ишетми. Ул һаман фронттагы улы, бәлагә тарган ире, авылдагы туганнары турында уйлый. Аның бетмәс уйларын бүлеп бабай сорап куйды:

– Йә кызым, читтән кайтасызмы, ирең сугыштамы?

– Әйе, Сверлау ягыннан, – диде ул теләр-теләмәс кенә, чит кеше алдында ачылып китә алмыйча .

Көн кичкә авышып, җиргә караңгылык иңә башлагач, алда авыл шәйләнде. Авыл башындагы зиратны уздылар, арырак кура җиләге бакчасы утырта башлаганнар икән. Йортлар искергән, читән-коймалар да сирәкләнгән. Утын әзерләргә ирләр юк шул хәзер. Чишмә тавы гына элеккечә һаман биек, аста үсеп утырган тал-тирәкләр юанаеп үсеп киткән. Бер чакрым да юктыр, янәшәдә генә Мәликә түтәсе яшәгән Урал авылы шәйләнә.

Менә ничек кайтып керергә язган икән туган авылга!.. Хәтерендә Тәлиганың... Китәр алдыннан председатель, халыкны җыеп:

– Бу кулаклар белән сөйләшмәгез, ярдәм итмәгез, йөрешмәгез! – дип үгетләп маташканда, Мәликә түтәсе:

– Үз туганым! Синнән куркып тормам! Ишектән кертмәсәң, морҗаларыннан төшәрмен! – дип чәчрәп чыккан. Менә шул куркусыз түтәсенең кечкенә өенә ике бала белән кайтып төште Тәлига. Елашып, кочаклашып күрештеләр, сөйләштеләр. Әгъзамның фаҗигале язмышы өчен бик борчылды түтәсе. Үзләренең дә ир туганнарының берсе теге елларда ук атып үтерелгән иде, ә энеләре сугышта. Төпчек энеләреннән хәбәр юк икән. Бар җирдә дә җитмәүчелек, юклык күренеп тора, авылларны нужа баскан!

Урал дигән кечкенә авылда Тәлига җиң сызганып эшкә тотынды. Таҗетдин җизнәсенә ияреп урман кисте, карлы-бозлы эскертне каерып, малга салам ташыды. Әдибә дә колхоз эшенә чыкты. Көннәр кыскарды, төннәр озынрак була башлады.

Октябрь бәйрәменнән соң Фәһимә дүртенче сыйныфка үзләренең Салих авылы мәктәбенә барды. Мәктәп салкын, укучылар күп түгел. Укытучы Мәрзия апа балаларны яңа кыз белән таныштырды. Арифметика дәресе иде, парта өстендә укучыларның саргылт кәгазь кисәкләре, каләмнәре ята. Фәһимә өр-яңа дәфтәрләрен алды (сугышка кадәр абыйсы Горькийдан посылка итеп җибәргән иде аларны), барысына да уртасыннан берәр табак алып өләшеп чыкты. Дәрестә кызның сорауларга рус телендә җавап бирүе генә малайларга кызык: алар тып-тын калып тыңлыйлар. Апалары дәрес материалын бу кыз

аңласын өчен русчалап та кабатлый. Өч-дүрт ай эчендә укытучы апасы кызны ярыйсы гына татарчага өйрәтте, иптәшләре дә ярдәм итте, үзләре русча аңлый башлады. Февраль бураннарында бер чакрымдагы Уралдан мәктәпкә бару, аннары Мәликә әбиләренә кайтып йөрү бик арыта. Аннары ачлык та тинтерәтә! Үзе бала күрмәгән Мәликә түти кызларны өнәп тә бетерми ахры, әнкәләрен чәй эчәргә чакырганда, кызлар читтән карап торалар. Тәлигага бу газап, әлбәттә.

Елга аша чыгып чыршы, элмә кисәргә барганда, кайчак Фәһимәне дә ияртә әнкәләре, фермага утын, сарыкларга элмә кайрысы алып кайталар.

Сугышның иң авыр чорлары иде бу. Авылда әле бер йортка, әле икенчесенә кара хәбәр килә. Дегтяркадан хат алдылар: «Зәки Сталинград өчен барган сугышларда авыр яраланган, аяксыз икән, госпитальдә ята икән. Исән калуына бик сөендек! Язгы ташулар үткәч, бәлки кайтарырлар. Ә Әгъзам турында берни белә алмадык!..» Мөкаррәмә шулай язган иде.

Ай артыннан айлар үтте. Чәчү башланыр алдыннан һәр хуҗалык басуга тирес чыгарырга тиеш. Мал-туар урынына абзар-кураларда җилләр генә килеп сала... Абзар артларында электән калган тиресне, тиресле җирне кырып-себереп кырга ташыдылар. Югары уңыш алу өчен ниләр генә эшләмәделәр. Җиргә коелып калган башакны берәмләп чүпләделәр. Тылда калган халык ач булса да, фронтка кирәк икмәк! Бөтенесе дә фронт өчен, җиңү өчен тырышып эшләде.

Беркөнне Тәлиганы җиңгәсе чакырып җибәргәч, кызларын ияртеп аларга барды ул. Җиңгәсе авыл хәлләрен сөйләде:

– Бер-ике уч бодай алып кайтканда тотылган Әсманы төрмәгә алып киткәч, ике баласы өйдә япа-ялгыз калды бит! Ачтан үлмәгәйләре... Шунда күчеп яшәсәгез, сабыйларга зур таяныч, ярдәм булыр ие, – диде җиңгәсе. Шулай итеп, алар Салихта яшәп калдылар.

Дүрт балага ашарга юнәтү бик авыр инде, тик нишләмәк кирәк! Илгә килгән хәсрәт бит!

Тәлига үҗәтләнеп эшкә ябышты. Яшәү өчен көрәш дәвам итте.

Ашлыклар өлгереп җиткәч, уракка төштеләр. Иртә таңнан кара төнгәчә кырда, басуда хатыннар. Председатель очраган саен ашардай булып карый, Тәлигага бәйләнә. Бүген дә:

– Менә миннән йөз чөереп, Әгъзамны сайлаган идең дә, ул кайда да мин кайда! Ул кем дә мин кем! – диде ул, масаеп. – Бүген кич минем янга амбарга килерсең!

Үзеннән әче бал исе килә. Тәлига читкә тайпылды:

– Дөньяда ир заты беткән дисәләр дә, сиңа карыйсым юк, бәйләнмә миңа, Габделхәй! Әнә авылда күпме ялгыз хатыннар...

– Ачка катарсыз әле... – Тегесе сүгенеп китеп барды.

Тәлига йөрәге ярсуга түзә алмыйча тагын ире турында уйлады. Намусын сатып ләззәт ала торган хатын түгел лә ул! Сизә, исән түгел инде аның Әгъзамы! Сугыш чыккач, ашарга бирмичә ачтан интектергәннәр, газаплап үтергәннәр аны! Төшенә дә гел шулай керә. Яратышып яшәделәр алар, тик бәхетләре генә гомерсез булды! Чын хуҗа иде, балалары өчен дә үлеп тора иде әткәләре.

Кич Әдибә эштән елап кайтып керде. Кызлар фермадан кайтканда, хуҗа очрап аны арбадан куып төшергән:

– Нәрсә дип син, кулак калдыгы, колхоз атына утырып йөрисең, бар, җәяү кайт!

Бәрәңге утыртырга җир бирмәве дә үчлектән инде, аны кызлар да аңлый. Урта Азиядә алынган матур киемнәр бәрәңгегә алыштырылып бетте.

Тагын яңгырлы, пыскак көз җитте. Басу читләренә агачлардан тәңкә-

тәңкә алтын коела! Җилләр яфрак туздырып йөргәндә, укырга күрше Күрдем авылына киткән Фәһимәләр атнага бер-ике тапкыр гына кайта башладылар. Бер ялда, абыйларыннан инде өч ай хат килмәвенә аптырап, Ленинградтан эвакуацияләнгән рус хатыны Полина янына керде кызлар, бергәләп командование исеменә хат яздылар. Җавап көттереп килде: Курск юнәлешендә барган, миллионлаган корбаннарны йоткан коточкыч авыр бәрелештә – танк сугышы дип аталган мәхшәрдә булган абыйлары хәбәрсез югалган икән! Ачы хәсрәттән Тәлига йоклый да, ашый да алмады. Берничә айдан бу гаиләнең бөтен өметен өзеп, һәммәсен зур кайгыга салып, кара мөһерле хат килеп төште: «Сезнең улыгыз танкист Фахров Әгъләм Орлов өлкәсенең Чегатаево авылы янында батырларча һәлак булды», – диелгән иде бу хатта. Баһадирдай улы танкта янып үлгән бит! Аның фаҗигале төстә һәлак булуы – соңгы ышанычның, өметнең өзелүе иде...

– Улым, багалмам! Җиңеп кайтырбыз дигән идең! Шулчаклы инсафлы, акыллы булып үсүләрең кемнәр өчен булды соң? Бөтен өметем синдә генә ие бит!

Елап туйгач, ул үз-үзенә:

– Хуатит! Тукта, Тәлига! Күпме еласаң да, кире кайтмаслар бит инде! – диде. Тәне буйлап, чеметтереп әллә нәрсәләр йөгерешкән сыман булды. Тәлиганың кечкенә нәфис гәүдәсе тагын да бәләкәйләнде. Аның тормышы тоташ югалтулардан гына тора микәнни соң? Кызлар да, абыйларын уйлап, кара кайгыга батты, әнкәләре өчен борчылды.

– Әнкәй, син чирләп егылсаң, без нишләрбез, бигрәк бетерендең! Ашарга юньле ризык та юк бит ичмасам!

– Каенсар төбендә кар булмас, кайгылы йөрәктә май булмас! – дип куйды ул.

Данлы җиңүләрне, сугыштагы уңышларны хәбәр итеп, озак көтелгән яз житте. Кардан арчылган урыннарда яшел үлән баш калкытты. Үлән кабарып, яшел хәтфә өстендә беренче чәчәкләр – умырзаялар күренде. Һавадагы яз исе, сыерчыклар килүе күңелгә рәхәтлек өстәде. Урман инде яшелләнә башлады, агачлардагы нәни яфраклар рәхәтләнеп кояш нурында коена! Менә тиздән кузгалак, юа, какы үсеп чыгар! Фәһимә җентекләп үләннәрне карый. Черек бәрәңге боламыгы ашап эчләр авырта инде! Оны булган кеше берәр учлап кына арыш онын боламыкка салып болгата, аш ясый. Үзләренә карата булган мөнәсәбәткә, ачлыкка түзалмыйча, Әдибә апасы Кемеровога эшкә китеп барды.

Мәктәптә укулар әйбәт кенә бара, җиденче сыйныф бит, сынатмаска инде. Ярый әле укытучылар әйбәт: хәлгә керәләр, ярдәм итәргә тырышалар, киләчәккә зур өмет уяталар. Фәһимә дусты Наилә белән һәрчак бергә, серләре дә уртак, киләчәккә төрле план коралар, туйганчы икмәк ашау турында да бергә хыялланалар. Менә бүген дә пионервожатый Әнгам (булачак халык шагыйре Атнабаев) политинформация үткәрде. Укучыларыннан бер-ике яшькә генә өлкәнрәк булса да, озынча гәүдәле, шинелен кысып буып куйган бу егет Фәһимәгә аерым игътибар итә. Тик кыз аңа күтәрелеп карарга да ояла.

– Сиңа ничек карады... сизденме? – ди Наилә.

– Кит инде, сүләмә юкны! – Фәһимә кызарып читкә карый. – Мәктәпне тәмамларга вакыт җитеп килә, имтиханнар турында уйла.

Тугызынчы май көнне мәктәптә укучыларны быргы-барабаннар тавышы астында «линейкага» тезеп бастырдылар. Завуч тантаналы итеп:

– Балалар! Бүген илдә зур шатлыклы хәбәр! Фашистларга каршы дүрт ел буе барган канкойгыч сугыш тәмамланган! Ишетәсезме, сугыш беткән, балакайлар! Җиңү безнең якта! Совет армиясенә, бөек Сталинга дан!

Рус теле укытучысы Гайшә апалары да, Мәрзия апалары да елый иде!

Бар да дәррәү «ура» кычкырды! Бала чагын сугыш афәте урлаган яшь буын шатлыгыннан нишләргә белмәде! Дәресләр булмады, укытучылар да, укучылар да өенә, авылларына сөенеч хәбәр алып кайтырга ашыкты. Нәдим, Җәмилә, Наилә, Марс, Фәһимәләр – алты-җиде бала авылларына елый-елый йөгереп кайттылар:

– Җиңү, Җиңү! Сугыш беткә-ә-ән!!!

Авыл халкы урамга чыкты, шатлыктан кочаклашып елашулар башланды. Кемнәрдер мәтәлчек атты, ура кычкырды. Яулыклар, ирләреннән калган иске бүрекләр һавага очты. Яраланып кайтканнар да шатлыктан күз яшьләрен сөртте. Чит җирләрдә ятып калган якыннарын юксынып та, әрнеп тә, исәннәренең кайтуына өметләнеп, шатланып елаучылар да – һәммәсе бер- берсен Җиңү бәйрәме белән котлады! Бу шатлык аһәңе әйтерсең лә дулкын булып Җир шары буйлап тарала, киләчәктә тормышларның яхшырачагына ышаныч, өмет тудыра иде.

Сугышта һәлак булган улын, гаепсезгә төрмәгә әләгеп юкка чыккан ирен уйлап, Тәлига үксеп-үксеп елады. Бәхетлеләрнең ирләре кайтыр...

Күз яшьләре, кайнар эз ясап, бите буйлап сузылды да сузылды. Ә аңа тагын да нужа арбасына җигелеп, дөнья йөген тартырга, җан сакларга гына түгел – кызларын тормыш юлына чыгарырга кирәк иде.

Элек үзләренеке булган зур, алты почмаклы матур йорт колхоз карамагында, өстә колхоз идарәсе, астын китапханә иткәннәр. Килендәшенә баргач, озаклап, күз яшьләрен йотып карап тора Тәлига өйләренә, ихатасына:

– Исәнме, газиз йортым!

Әнә түрбакча, бу якка караган өч тәрәзә, аларның күптән буявы уңган! Бакча да ташландыкка әйләнеп беткән. Себерелгән чиста ишегалды буйлап, салмак елмаю белән, әкрен генә атлап, каршысына ире килә сыман... Йөрәге, бөтен җаны әрнү-сызлаулардан сыкрый, газапка чума ул, күзләреннән яшь тәгәрәп төшә. Кереп урап чыгасы килсә дә түзә. Күптән үзенеке түгел шул инде! Их, дүрт почмаклы түгел, хәтта өч кенә почмаклы булса да, үзләренең йорты булсамы!..

Сугыш беткәч, орден-медальләр тагып, авылга ирләр кайта башлады. Әсманың ире дә кайтып җитәргә тиеш, кая барырга? Тагын кемгә йортка керергә? Авылдашлары, ахирәтләре булдыралганча ярдәм итәргә тырыштылар, киңәш бирделәр. Тик һәркемнең гаиләсендә ярлылык, ачлык, җимереклек һәм юклык! Мәликә апасы тагын үзләренә чакырды.

– Олы кызым безне үз янына Күмертауга алдырмакчы, бер дә чыгып китәсем килмәй шул, – диде Тәлига апасына.

Әдибә Кемерово ягында эшли башлаган, почтага телефонистка булып урнашкан иде.

– Фәһимәңне кияүгә бир! Сугыштан кайткан, өе булган берәр кешегә!

– Ни сүләйсең, аңа әле уналты да тулмады бит!

– Тулыр нибуч! Авылда кызлар буа буарлык, алучы булса, димен инде.

Юраганы юш килгәнме, уналты яшь ярымнан кияүгә бирде ул кече кызын. Тулып пешкән җиләк кебек, чибәр, килешле, эшчән кызга күз атучылар булды. Фәһимә Гатаны сайлады, кияү тугыз яшькә зуррак иде. Ата-анасыннан калган кечкенә генә иске өен яңартып башка чыктылар, шунда яши башладылар. Чистартып, ташларын җыеп, бәрәңге бакчасы ясадылар, аны коймалап алдылар. Бу ана хыялының иң югары, тантаналы ноктасы иде бит! Үзенчә бәхетле иде ул, кызын урнаштырып кала алуына, аның юньле кешегә тап булуына бик шатланды. Чөнки Гата – дөньяның ачысын-төчесен татыган, акыллы, төпле егет иде.

***

Гата әткәләре 1921 елгы ачлыкта үлгәннән соң туды, әтисен бөтенләй күрмәде. Михнәтне күп кичергәнгәдер, Гатага җиде яшь тулганда, балаларын ятим калдырып, әнкәсе дә якты дөньядан китеп барды. Үлгәндә хәлсез тавышы белән уртанчы улы Фатыйхка пышылдады: «Бәләкәй энеңне ташлама, улым!» Ташламады аны абыйсы. Гата, мәктәпкә йөреп, дүрт сыйныфны тәмамлады. Аннары көтү көтте, бөтен эштә дә абыйсының ярдәмчесе булды.

Зур абыйлары үз гаиләләре белән яши, Фатыйх абыйсы да өйләнде. Ә апасы еракка кияүгә китте, хәбәре юк. Инде тормыш көйләнеп бара сыман. Кәҗүннәй урманыннан агач кисеп, искесе янәшәсенә яңа йорт җиткереп чыктылар, сыерлары бар. Их, әткәсе-әнкәсе дә булса иде!.. Инде буй җиткереп килгәндә, абыйсы белән җиңгәсе җилкәсендә ятарга теләмәгән үсмер бәхет эзләп авылдан чыгып китте.

Җәй уртасы җитеп килгән, юкәләр шау чәчәктә утырган чак иде. Шәһәр вокзалы янына кеше күп җыелган. Гата килеп җитте дә, үзе чамасындагы бер егеткә карап:

– Монда нәрсә бирәләр? – дип сорады, ә тегесе:

– Атаң башы! – диде дорфа гына. Гата китә башлагач, ул:

– Эшкә язалар, вербовщиклар килгән, яңа шәһәр төзергә кешеләрне чакыралар, – дип аңлата башлады.

– Кайда икән соң ул шәһәр?

– Җир читендә! Комсомольск на Амуре дип атала ди!

– Миңа да эш бик кирәк тә соң, ундүртем генә тулды шул әле!

– Ә син уналтыдамын дип әйт, гәүдәң озын күренә, бергә китәрбез! Миңа да уналты, ә исемем Вәсил минем, Васька дип йөртәләр.

– Гата!

– Гришка булырсың! Әйдә, бас минем янга!

Көтмәгәндә шулай үзгәрде дә куйды аның тормышы. Кичтән Вәсилләргә кайтып чоланда йокладылар, кечкенә йортта алар унбер бала икән. Юлга бераз ризык – иске бәрәңге юнәттеләр.

Икенче көнне көндез, исемлек буенча тикшереп, аларны поездга утырта башладылар. Менә поезд шуышкан еландай әкрен генә кузгалып китте, малайларны куркытып, каты итеп паровоз кычкыртты. Озатучылар вагондагыларга кул болгый, саубуллаша, якыннарының исән-сау эшләп кайтуларын тели иде.

– Китү шушы инде, озак барачакбыз, – диде Вәсил, тәрәзәгә карап, энеләренә кул болгагач.

Поезд тәгәрмәчләре бер көйгә текелди дә текелди. «Коры паёк» дип бераз икмәк бирделәр, кайнар су титанда, күпме телисең, шулай алырга ярый. Кызык! Вагондагылар яңа шәһәр турында гәп корды:

– Шәһәр карурманда, тайга уртасында булачак ди.

– Кытай чигенә якын икән.

– Әй, ул гынамы, бездә әле иртә, ә анда инде кич, кояш бата ди!

– Менә хикмә-әт!

Шултикле ерак микәнни, нindирәк икән соң ул шәһәр?

– Бөек юлбашчыбыз Сталин чакыруы буенча яңа төзелешкә барабыз, иптәшләр! Сез – комсомоллар, илебезнең ышанычлы яшьләре, сынатмассыз дип уйлыйм, – диде вербовщик. – Ә хәзер кем нәрсә эшли белә, нинди һөнәргә

өйрәнергә тели, шул турыда сөйләшик. Җир казучылар кирәк булачак, урман кисүчеләр, балта осталары, ә ташчылар бармы арагызда? Урынга барып җиткәч, теләсәгез, яңа һөнәргә өйрәнерсез!

Бу вагондагы халыкның күбесе җир сөргән, икмәк үстергән гади җир кешеләре, тик авыз тутырып ипи ашамаган, матур тормыш күрмәгән крестьяннар иде.

– Балта-пычкы тоткан бар инде, җирен дә казырбыз анысы, яшәр куыш, ашарга икмәк, хезмәт хакы булсын!

– Булыр! Сезнең өчен озын-озын бараклар төзелгән инде анда!

1935 елның август башында «төзүчеләр бригадасы» Хабаровск дигән шәһәргә килеп төште. Аларны шунда ук елга вокзалына алып килделәр дә, «Коминтерн» пароходына төяп, Амур елгасы буйлап төньякка таба алып киттеләр. Киң, зур елга буйлап пароходлар, йөк төягән баржалар уза. Амурдан хәтта Тын океанга да барып җитәргә мөмкин икән! Күз күрмәгән, колак ишетмәгән җирләрне кызыксынып күзәттеләр Гата белән Вәсил. Яннарында урыс, татар, бурят, башкорт егетләре бар иде, тагын чукча, коряк, хант кебек әллә кемнәр җыелды, гаиләле, балалы кешеләр – һәркем үз телендә сөйләшә, шаулашалар! Нинди генә милләтләр юк икән монда!

Көндез һава эссе иде, кичкә таба бераз салкынайтты. Бу тирәдә сазлыклы җирләр күп, диләр, шуңадыр һавага черки, вак чебен таралды. Безелдәп муенга, биткә ябышалар, алардан качып котылыр хәл юк, тән кычыта. Урынга барып җитеп, тизрәк юынасы, вәгъдә ителгән баракларга урнашасы килә.

Пароход иртән Пермское дигән авыл янына килеп туктады. Килүчеләрне ике ир каршы алды. Тирә-юньдә баткаклык, юл юк, йортлар аз күренә, бараклар төзелеп бетмәгән икән, икенче ярда үтә алмаслык куе урман – күз күреме җиталмаслык булып җәелгән яшел тайга... Халык яр буенда ук шаулаша башлады:

– Ә шәһәр кайда?

– Где обещанное жильё?

– Безне монда һич кенә дә көтеп тормаганнар бит!

– Ничек шалашта яшәмәк кирәк?

– Обманули нас!..

Халыкны бригадаларга бүлделәр. Гаталар бригадасын якындагы Дземги дигән авылга алып килделәр. Мондагы җирле халык нанаецлар икән. Телләре аңлашылмаса да, үзләре юаш, игелекле күренә, ярдәм итәргә тырышалар. Кайберәүләрне, җәлләп, шунда ук үз торакларына алып киттеләр.

Яңа җирдә яңа тормыш шулай башланды: ачлы-туклы халык землянкалар казыды, шалашлар ясады, брезент палаткалар корды, торыр куыш әтмәлләде.

Сазлыклар белән уратып алынган тайгада йөзәр еллык мәгъруր наратлар, кедр агачлары ябалдашлары белән күк йөзен терәп торалар сыман. Яшькелт хәтфә келәмдәй үлән арасыннан табып нарат җиләге ашады егетләр, тик бригадирлар аларга озак юанырга ирек бирәме соң?! Кул пычкылары белән юан-юан агачларны бүрәнәләргә кисү башланды, тайга эче шау-шуга күмелде.

– Ерак түгел Хабаровскига тимер юл салучы ГУЛАГ тоткыннары урман кисә, анда барып чыга күрмәгез! – дип кисәтте бригадир.

Бер бригада ауган агачларны кисеп, бруслар ясар өчен лесозаводка ташыды, икенчеләре бруслар ясады, чөнки йортлар һәм баракларны кышкы салкыннарга кадәр төзеп куярга кирәк иде.

Ерак Көнчыгышның табигате кырыс, бик үзенчәлекле, быел октябрь ахырында ук чатнап торган салкыннары белән кыш килде.

Бөтен илдән җыелып килгән «төзүчеләр» дә, армия хезмәтендәгеләр дә, тоткыннар да түзә алмаслык авыр шартларда егермешәр сәгать эшли башлады.

Җыелышларда – купшы сүзләр, ә тайгада пычкы, балта тавышлары тынып тормады. Бик зур авырлыклар белән булса да, йортлар, кибет, телеграф-почта, хастаханә төзелде. Һәр елны яңадан-яңа кешеләр килә торды, шәһәр халкы күзгә күренеп артты. Хезмәт энтузиазмы югары булса да, салкында авырып яки туңып үлүчеләр дә күп иде.

Гатаның иптәше Вәсил телгә оста, хәйләкәрлеге дә бар, эш дип артык бетеренми. Яңа килгәннәрдән Жиган кушаматлы һәм ерак Днепр буеннан килгән Микола Жук исемле егет белән дуслашты ул. Акчага кәрт уйнатып, Гатаны да әздән генә төп башына утыртмады. Ярый әле Гата кемнең кем икәнен тиз төшенде. Ипи карточкасын уенда оттыргач, шунда бүтән кәрт тотмаска ант итеп сүз бирде һәм сүзендә торды, ай буе ачлы-туклы йөреп, гомерлек сабак алды бит!

Бер кичне киногa баргач, егетне «Ударник» клубына, хор түгәрәгенә чакырдылар. Түгәрәктә татар яшьләре дә байтак булып чыкты. Монда халык җырларын, төрле маршлар, русча романслар өйрәнделәр. Тик татар җырлары гына бөтенләй ишетелмәде. Бер кичне Гата түзмәде, күкрәген тутырып сулыш алды да татар халык җыры «Рәйхан»ны сузып җибәрде:

Аклы ситсы күлмәгеңнең
Якаларын кем уйган?
Их Рәйхан,
Исемең матур, кемнәр куйган,
Сине лә күреп кем туйган!..

Бөтенесе – музыкантлар да, җырчылар да тын калып татар җырын тыңлый! Чал дулкынлы Амур өстенә татар моңы тарала! Дөньяга сибелгән татар халкының ачы язмышын бәян итмәсә дә, үзәкләрне өзеп елыйсыны китерә иде бу җыр! Милли җанлы гади бер егетнең үз телен, илаһи моңын, гореф-гадәтен сакларга омтылуы чагыла иде аның җырында! Барысы да кул чаба башлады.

– Ещё, ещё спой, Гриша!

– Вот, татарчонок, дай-ёт, артист настоящий!

Тавышы көчле, сулышы киң иде егетнең. Ул татар халык җыры «Карурман»ны сузып җибәрде:

Кара да гына урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә...

Татарча аңлаганнарның күзләрендә яшь ялтырады. Хорга йөрүчеләр арасындагы өлкәннәр дә, чибәр кызлар да бу зәңгәр күзле озын буйлы егеткә сокланып карап торды, бар да аны мактады, котлады. Сашка исемле егет белән бергә кайтырга чыктылар.

– Син кайсы якныкы?

– Башкортстаннан, Яңавыл стансасыннан. Ә үзең?

– Мин Саратовтан, Сарытаудан, чын исемем Сәхип минем.

– Бәй, анда да татарлар бармыни?

– Һе, татар булмаган җир юк ул! Элекке татар җирләре бит ул Сарытау. Минем мәрхүм әнием дә татар кызы, мин аны бик ярата идем, әле дә сагынам. Синең әниең бармы? Җиде яшьтән ятим дисеңме? Син кайсы бригададан әле? Безгә яңа бaрактан бүлмә бирәчәкләр, әйдә бергә керәбез!

– Ярар, бик шәп булыр!

Бер айдан яңа баракка күчтеләр алар. Сашка бик акыллы егет булып чыкты.

Вакыт сизелми дә үтте. Егетләр бөтен көч-дәртләрен биреп эшләделәр. Шәһәр күзгә күренеп үсте, матурланды. Озын булып төп урам – Комсомоллар проспекты шәйләнә башлады. Ул бер яктан – шәһәрне, икенче баштан Дзёмги бистәсен бергә тоташтырды. Амур буенда шәһәрнең яңа районнары булып «Пожарный» һәм «Аварийный» бистәләре калыкты. Вакытлыча төзелгән электростанцияләр эшчеләрнең гомум торагындагы бүлмәләрне яктыртты, күңелләрне җылытты.

...Бөтен дөньяны аклыкка күмеп, тагын кыш килде, яңа ел башланды. Беркөнне Сәхип:

– Синең якташың Васька кеше үтергән! – дигән хәбәр алып кайтты, – кичә кич урамда бер егетне талаганнар, акчасын алып, пычак белән чәнечкәннәр ди. Бүген Миколаны, Васьканы кулга алганнар, ә Жиган юкка чыккан!

Коточкыч хәл! Гата Вәсилнең гаиләсен, әнисен күз алдына китерде... Яхшы күңелле, әйбәт кенә егет иде бит, нишләгән ул, кемнәргә ияргән?.. Нинди аяныч язмыш! Тик һәр кеше үз язмышын үзе сайлый, бәхете дә, тынычлыгы да үз кулында!

Якташының киләчәге турындагы уйлар аңа һич тынгы бирмәде.

Армиягә алыныр вакыты җиткәч, ул туган авылына кайтып килергә уйлады. Башкортстанга – Яңавылга кайтып җитеп, поездан төшкәч тә, урам буйлап Вәсилләр йортына таба китте ул. Вәсилнең әнисе йорт алдында йөри иде, капкадан кереп аңа эндәште:

– Исәнмесез, апа! Мин Вәсил яныннан кайттым, хәтерегездәдер, без бергә киткән иек! Менә ул сезгә күчтәнәчләр җибәрде!

Озын кара плащ кигән ыспай егет сәләмә киемле, чабаталы малайга һич тә охшамаган иде.

– Шулаймыни, нишләп үзе кайтмай, хат та язмай башлады хәзер.

– Анда эш бик тыгыз, апа. Яңа шәһәр төзибез бит, вакыт юк. Язар әле, борчылмагыз!

Дөресен әйтергә кыймады егет. Ашыгып хәрби комиссариатка китте.

Авылына кайтып, туганнары белән күрешү шатлыгы бераз басылгач, әти-әнисенең каберенә барды, аннары урман-кырларны карап кайтты.

Хәрби хезмәткә чакырып көтелгән повестка килде. Ни гаҗәп, армия сафларына алынгач, Гатаны берничә егет белән Ерак Көнчыгышка билгеләделәр. Кайткан юл белән キрегә, аннан да арырак – Сахалин утравына таба алып киттеләр аларны. Хезмәт итә башлаганда, аның урыс телен белүе дә, җырга осталыгы да бик ярап куйды. Бер кәлимә сүз әйтә белмәгән якташлары алдында да, башка солдатлар каршында да дәрәҗәсе югары иде. Җитмәсә, ротада Гатаны башлап җырлаучы – запевало итеп билгеләделәр. Хезмәт итүнең авырлыгы әллә ни сизелмәде. Ату коралларын да тиз үзләштерде егет. Тик җиде ел буе шушында булырмын дип юри дә уйламаган иде. Хезмәт срогы бетеп өлгермәде, 1941нең июнендә немец фашистлары башлаган канлы сугыш аны шулай озынайтты да куйды. Көньяк Сахалинны Германиянең союзнигы булган японнардан сакладылар алар.

Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен бирелгән медальләрен чыңлатып, бары тик 1946 елда гына туган авылына кайтты Гата! Авылда туган-тумача белән күрешеп, хәл белеп, бераз ял итәрмен дә, тагын Амур буйларына китәрмен, дип уйлаган иде ул. Тик абыйсы аны калырга күндерде:

– Китмә син, кал, апаем, без бит ир туганнар икәү генә калдык, икебез ике җирдә булаекмени? Туган бик кирәк ул, кадерле ул туган! Өйләнеп җибәрерсең, өй бар, авылда күпме чибәр кызлар, татар кызлары! Тегендә китсәң, берәр марҗага кабарсың. Читтә дә читән башына элеп куймаганнардыр... Ә эш кайда да җитәрлек ул хәзер. Чит җирдә олтан булганчы, үз илеңдә солтан булу яхшырак түгелмени?

– Ярар, беләм, монда кирәгрәктер шул мин, зур абыйларның балаларына да ярдәм итәргә кирәк, әтисез үсәләр бит!

Кичке уенга чыккан беркөнне ул бар дөньясын оныттырган Фәһимә исемле матур кыз белән танышты. Кыз да бик ошатты үзен.

Сөйләшергә уртак темалар да күп: бер үк юллардан йөргәннәр икән бит! Озакка сузмадылар, өйләнешеп тә куйдылар. Гатаның иске йортын сипләп күтәрделәр дә яңа урамга башка чыктылар. Морҗа чыгару белән, Фәһимә идәннәрне юды, өйне чистартты. Әнкәсе белән тәрәзәләргә челтәр, пәрдә кордылар, мич буена кашага элделәр. Урын-җирне кабартып, сәкегә megендәрләрне өйделәр, каплап куйдылар. Эштән кайтып кергән Гата ишек төбендә тукталып калды, соклануын яшермәде:

– Ай-һай, бигрәк матур булган бит үз өебез! Хур кызлары төшкәндер монда!

– Әйдә, кияү, ашыбыз җитеште, тары оныннан тәбикмәк тә пешердем!

– Әй безнең әби! Алтынга тиң бит ул! Бабай яшь чагында ук белгән. «Җирдәге алтынны алмам, Тәлиганы алырмын!» дип өйләнгән бит аңа!

Әбисе канәгать, үзе кеткелдәп көлә. Ана назы күрми үскән егет әбисен яратты, хатыны да тырыш, эшчән, булдыклы иде.

Фәһимә белән Гата икәүләп киңәштеләр дә туй сыман мәҗлес үткәреп алырга булдылар, азрак ит юнәттеләр. Абыйсы умартадан бераз бал бирде. Кунаклар чакырылды, өстәлгә булган ризыклар куелды. Әнкәләре чөгендердән дә әллә нинди ризыклар әзерләде. Абый-җиңгәләренә мәҗлес тә, аларның матур куышы да ошады. Балавызлы балдан куелган әче бал шәп иде, кунаклар хушланып утырдылар, аннары Гатаның көр тавышына кушылып җырлап җибәрделәр:

Ай югары, ай югары,
Айга менәсем килә.
Айга менеп, түбән карап,
Сезне күрәсем килә!

Апалары алып килгән ал чәчәкле матур кытай ашъяулыгы бигрәк ошады Фәһимәгә. Әдибә апасы да кияүдә инде. Ул Кемеровода эшләгәндә үк үз якларыннан килгән татар егете Габдулла белән танышты. Өстенә кара драп пәлтә, башына тәбәнәк каракүл бүрек кигән чандыр гына бу егет, Әдибәне эштән көтеп ала, фатирына озатып куя. Сүзгә дә оста үзе.

– Яңавылда безнең үз өебез бик зур, биек. Минем әткәй күрше авылда колхоз рәисе булып эшли, – ди ул, сер бирмәгән кызга карап.

Тора-бара Әдибә дә бу шома егеткә ияләшә, үз язмышын бәян итә: ничек авылдан китүләрен, чит җирләрдә яшәүләрен, әткәсе, абыйсы турында, авылдагы кимсетелүләр турында сөйли. Бер-берсен яратып йөреп, берничә айдан алар өйләнешәләр дә туган җирләренә кайтырга булалар.

Яңавыл кырындагы авылга кайтып төшкәч, Әдибә артына авып китә яза: аларны җимерек йортта күп балалы ярлы гаилә каршы ала. Иренең шундый

оста ялганчы булып чыгуына исе китә Әдибәнең. Авылга кунакка килгәч, әнкәсенә, сеңлесенә елый-елый сөйли ул бу хәлләрне.

– Кызым, балага да узгансың, баланы ятим итеп яшәрсеңмени, аерылышу бездә булмаган хәл, кеше көлдермә! – ди әнкәсе.

Әнкәсенең сүзен аяк астына салмый Әдибә, иренең ялганнарына өйрәнсә дә, тик аңа бер ышанычы да калмый. Бераздан аларның кызлары туа. Фәһимә кырык чакрым дип тормый, бәби котларга апаларына җәяүләп барып җитә: он, бәрәңге күтәрә, сөтен-каймагын ала, кызчыкка матур итеп күлмәк тә тегә. Бераздан әнкәсе дә бала карарга дип анда китә. Әдибә сатучы булып эшкә урнаша, ә кияү ит комбинатында тракторчы булып эшли. Әкренләп Яңавыл кырыена йорт сала алар, тормыш дәвам итә. Тик Әдибә өчен аның бер кызыгы да булмый. Ә Фәһимәләрнең гаиләсендә бер-бер артлы дүрт кыз дөньяга килә.

***

Шулай сизелми дә еллар үтә, оныклар үсә...

...Сабырлыгы, акыллы киңәшләре белән кешеләр күңелен яулаган Тәлиганы хәзер инде авыл халкы үзара Акъәби дип йөртә. Күзләренең төсе җуелып, битен-маңгаен җыерчыклар сарса да, зиһен үткенлеген җуймаган Тәлига янына күрше-күлән һаман да киңәшкә керә әле. Үз гомерендә беркемгә дә бернинди начарлык кылмаган Тәлигага ни өчен соң язмыш шундый авыр сынаулар бирде – утларына салып яндырды да бозларына салып туңдырды?.. Соңгы вакытта ул бер ноктага текәлә дә уйга бата. Ирен, улын уйлый, аларның сөякләре, кадерсезләнеп, кай җирләрдә ята икән? Әгәр алар исән булса, үз нигезендә картаймас идеме әллә Тәлига?! Юк, хәзерге тормышыннан зарланмый, кызы да, кияве дә кадер-хөрмәттә генә яшәтәләр үзен. Әмма үз нигезеңдә адымнарың да бүтән, үз йортыңда һавасы да җанга шифа шул...

Ястык почмагын учы белән чытырдатып кысып, Тәлига үз җанын биләгән сагыш-сагыну аша тулган айга текәлде. Аның сагышы айга да күчә һәм ай да аның белән бергә өзгәләнә, гүя ай да «үз нигезем» дип пышылдый сыман тоелды. Әй, җүләр, айның үз нигезе була димени инде?! Ә бәлки иксез-чиксез галәмдер аның нигезе? Кем белә... Тәлиганың җыерчыклы йөзеннән әкрен генә күз яшьләре ага да ага. Юк, күз яшьләре түгел, аның үз нигезеннән читтә үткән еллары, язмыш сынаулары да ташка әйләндерә алмаган күңел хисләредер ул. Үз нигезең...

Ә нигезенә кайтты, барыбер кайтты Тәлига. Ташлы туфракларны күргән Тәлига... Ул чор кешеләре язмышыдай кырыс, җаннарны өтеп алырдай салкын февраль аенда кайтты ул. Кызлары-кияүләре, бакыйлыкка күчкән әниләре җәсәден, ике-өч минутка гына булса да үз ихатасына алып кереп, җиргә куеп тордылар. Шул мизгелдә, февраль күгендә кинәт кыска гына вакытка ялтырап кояш күренде. Җем-җем килгән ниндидер яктылык бормаланып очып, күккә күтәрелде. Шуны гына көткәндәй, кояш болытлар артына яшеренде, җиңелчә генә җил исеп куйды һәм бу яктылык зәңгәрсу караңгылыкта эреп югалды...



Марс
Хафизов

# ШАТЛАНЫП ТУЙМЫЙ КҮҢЕЛ

## Туган тел – йөзек кашы

Туган тел һәрбер татарга
Озын юлның юлдашы.
Маяк булып юл күрсәтә
Туган тел – йөзек кашы.

Туган тел аркасын куймый
Иссә дә җилләр каршы.
Авыр чакта ярдәм итә,
Туган тел – йөзек кашы.

Туган тел, сиңа бәйләнгән,
Бар татарның язмышы.
Әй дә моңлы, үзең назлы
Туган тел – йөзек кашы!

Туган тел күккә күтәрә
Моңлы азан тавышы.
Туган җирем Татарстан,
Туган тел – йөзек кашы.

«Әни», – диеп тел ачылган –
Безнең тормышның башы.
Без татарлар – алтын йөзек,
Туган тел – йөзек кашы.

Марс ХАФИЗОВ (1949) – *шагыйрь; «Яраларны юа мәхәббәт», «Бергә чакның кадерләрен белик», «Бер елмаюың җитә» һ.б. китаплар авторы. Түбән Камада яши.*

## Килә сөясе

Кайвакытта яңгыр булып
Килә явасы.
Мәңге сиңа гашыйк булып
Килә каласы.
Йә булмаса кояш булып
Нурлар сибәсе.
Нурлар булып назлап кына
Килә сөясе.

Кайвакытта җилләр булып
Килә исәсе.
Чәчләреңне сыйпап кына
Килә кочасы.
Йә булмаса чишмә булып
Килә агасы.
Сулар булып иренеңә
Килә тамасы.

Кайвакытта гөлләр булып
Килә үсәсе.
Алсу гөлле чәчәкләрне
Бүләк итәсе.
Аермасын берүк Ходай
Гомер-гомергә.
Мәңге сөяр ярым булып
Керден күңелгә.

## Хәерле кич

Кояш белән ай очрашкан
Якты көн үтеп бара.
Аккан болыт арасыннан
Нур сибеп ай елмая.
Яшь чакларның гомере аз
Бигрәкләр дә тиз үтә.
Һәр минутның кадерен белеп
Яшәүләргә ни җитә.

Хәерле кич туган җиргә,
Милләттәш, туганнарга!
Хәерле кич барыгызга –
Әби-бабай, өлкәннәргә,
Әти-әни, яшьләргә.
Күңелегез картаймасын,
Яшәргә дә яшәргә.

Юлчыларга юл күрсәтеп,
Ай нурын сибеп торсын.
Һәрбер эшләгән эшегез
Мактауга лаек булсын.
Сөйгән ярлар кавышсыннар,
Бәхетле булсын тормыш.
Гаилә авырлыкларын
Читләтеп үтсен язмыш.

Бала-чага дисәләр дә,
Чакмасын бала угы.
Өегездә ямьле булсын,
Күңелләр моңга тулы.
Сөйләшегез, җыр җырлагыз
Туган татар телендә.
Күңел тынычлыгы телим
Гаиләгезнең күгендә.



Алмаз
Хәмзин

# БАРМАГЫҢНАН ҮБӘР ИДЕМ...

БӘЯН

...Әгәр берәрсе минем баштан кичкән бу хәлләрне үзенеке итеп сөйләсә, һич ышанмас идем. Ничек инде шулай башыңны югалтып гашыйк булырга мөмкин? Тәҗрибәсез, тормыш күрмәгән яшүсмер дә түгел бит үзем. Инде буй җиткән, яшәүнең байтак ачы-төчесен татыган, кырыкмаса-кырык мәртәбә ялгышкан, кыйналган, алданган егетнең дөньясын онытып, каяндыр репетиция бүлмәсенә килеп кергән кызга, бер күз төшерү белән, акылы томалансын!.. Әй, егет, уян! Акылыңа кил! Ләйсирәләрең, Рәзинәләрең нишләр? Алар да бит сиңа гашыйклар. Күзләренә ничек туры карарсың?

Хәер, минем аларга «яратам!» дип әйткәнем юк әле. Ләкин бит алар – «җан кисәкләрем», «күз нурларым», «бәгырькәйләрем» миңа өмет баглап, гомерлек тормыш юлдашым булырга өметләнеп йөриләр. Ләйсирәне генә алыйк: ансамбльгә килгән һәр кичендә миннән күзен алмый, гел текәлеп карап тора иде бит, җаныкаем. Репетицияләр, концертлар тәмамлангач, өенә хәтле озаттырып кую аңа бәхет мизгелләренең иң кадерлесе булгандыр. Үзем дә, кышларын, аның татлы иреннәреннән аерыла алмыйча, подъезд эчендә, ә җәйләрен клуб каршындагы эскәмиядә төн үткәрә идем. Әй, шаян да, шук та инде, чибәркәй. Үзе: «Бар кит!» – дия дә, китә башласаң, очып килеп куна, аякларын билемә атландырып. Китәрсең, бар... Муенымнан кочып алган кулларыннан ычкынырмын димә. Үзе көлә дә көлә, «кит!» дигәннән башка бүтән бер сүз дә эндәшми. Яратасыңмы, дип тә сорамый. Мин дә тыныч кына гыйшык шаукымында эрегән. Рәхәт бит... Инде шулай икенче ел озатышып йөрибез. Әллә нәрсәсе бар шуның үзенә тарта торган! Ирен читендәге чак беленеп торган сөйкемле чокырымы, күзенең нурлы зәңгәрлегеме? Хәтта кыска итеп кистерелгән аксылрак чәче дә Ләйсирәгә килешеп тора. Аяклары төп-төз, буе калку, тик менә биле генә нечкә түгел. Әй, анысына игътибар иткән юк ла... Тәмле итеп үбә белү осталыгы барында андый гына җитешсезлеге пүчтәк нәрсә. Биле юан дигән нәрсә уйга да керми.

---

Алмаз ХӘМЗИН (1947) – *прозаик, шагыйрь; «Озак яшисегез килсә» китабы һәм күпсанлы җырлар, юморескалар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Шул, үбешүдән башка мәхәббәт тирәнгә китми безнең. Ярамый. Өйләндереп куярлар да, институт тәмамламыйча ук, бала карап ятарсың аннан соң...

Институттагы курсташ Рәзинә искиткеч, үземә тиң кыз да бит менә, ләкин... Ләкин ул: «Мин, укып бетергәч, авылга кайтачакмын, син барыбер шәһәрдә калырга хыялланасың», – ди. Анысы шулай инде. Авыл хуҗалыгы институтын ташлап, Төзелеш институтына, архитекторлыкка шылырга уйлап йөрим. Җырчылыкны камилләштерергә дә исәп юк түгел. Матурын да матур Рәзинә, тыйнак та, акыллы да, нишлисең, күрәсең, безгә бергә булырга язмаган – язмышым каядыр сөйри, алда нәрсә буласын чамалый алмыйм. Күңелемә яткан сәнгать дөньясы мине үзенә тарта, бәлки шунда юнәлермен...

...Шулчак янәшәмдә утырган дустым Мәхмүт, касыкка төртеп, уйларымнан бүлде.

– Ачык авызыңны яп! Селәгәеңне сөрт! – дип кискен тавышы белән әйтеп куйды. Мин, әлеге кыз бүлмәгә кергәннән бирле, һаман шуңа карап утырам икән. Айнып киттем. Кулъяулыгым кайда соң? Таптым. Кесәмнән чыгаруым булды, Мәхмүт тагын:

– Елыйсыңдамы әллә? – димәсенме.

– Көлмәле! – мәйтәм. – Күрәсеңме нинди шәп кыз.

– Күрәм, күрәм... Сукыр түгелмен... Синдә генә шундый күз бар дип уйлыйсың мәллә?

– Нинди күз?

– Рәссам күзе. Ай-яй, малай, күрдеңме атлавын – йөзә, юк, йөзми, бизәк чигә...

Минем шаккатудан һаман авызым ачык икән әле. Инде мондый хәлемне күптән сизеп алган Ләйсирә килеп эндәшкәч, яңадан айнып киттем.

– Күзең итәгенә ияреп китә инде!

Китә шул. Менә шунда карап утырам бит. Итәге тибрәлә, тез буыннарын сыйпап, күңелне кытыклап тора. Ә өстәрәк... ә өстәрәк, билгә хәтле җире дерелди, шул дерелдәвек итәгенә дулкын ясата түгелме?

Ансамбль җырлый...

Елга порты яннарында
Чайкала диңгез.
Су буйлап безгә кунакка,
Дуслар, килегез,
Дуслар, килегез!

Әйе... Биле күлмәгендә дулкын куптара. Их, шул дулкыннарда чайкаласы иде. Менә-менә акылымны җуям бугай дигән хәлдә күзләремә томан кунды. Зиһен дә, күзләр дә томанда – ачык изүдә нindидер «хикмәтләр» бар – анысын инде мин сезгә аңлата алмыйм.

Ләйсирә:

– Зәбир, әллә авырыйсыңмы? – дип, борчулы күзләрен миңа төбәп карап тора икән.

– Башым әйләнә... Әллә нәрсә булды, – дидем бугай мин шунда Ләйсирәгә.

Мәхмүт, көлеп:

– Аның шундый өянәге бар, – дигән булды.

– Әйдә, чыгып керик.

– Юк, юк, Ләйсирә, хәзер үтә бу шаукым.

Үтми икән шул. Мин әлеге кызның томан эчендә генә булса да чия төсле уймак хәтле иреннәрен төсмерләдем, озын керфекләре астындагы шомырт-кара күзләреннән исәрләнеп калдым... Чәчләре кара, ләкин кыска иде бугай...

Шул көннән соң «чирләдем». Диагнозым – мәхәббәт.

Ул кызның исеме Сәбилә икән. Кустанайдан Казанга Мәдәният институтына укырга килгән. Монда популяр «Сөмбел» ансамбле бар икәнен ишеткән. Менә шуның клубта репетиция үткәрелгән чагында бүлмәгә килеп керүен күзәтеп, бер күрүдә гашыйк булуымны сөйләвем бу.

Дөресен әйтим: шул көннән соң әллә нәрсә булды миңа. Боектым. Репетициягә барам да, дөньямны онытып, һаман аңа карап утырам. Ләйсирәнең дә миңа карашы үзгәрде. Без озатышмый башладык. Ләкин ачуланышу булмады. Ләйсирә бу хәлне үтәр дип уйлады, күрәсең. Шулай уйлавына сәбәп тә бар иде. Чөнки Сәбиләгә якын килә алмыйча озак йөрдем. Телгә-сүзгә хәйран оста һәм батыр кеше булып саналсам да, Сәбиләгә сүз катарга кыймадым. Аңа карыйм да янам-көям, вакыты-вакыты белән күкрәгемне яшен ярып үткән сыман тоела.

Тора-бара бу халәтемне ансамбль җитәкчесе Виртуоз Актанышев та сизде. Мәхмүт әйткәндер инде. Ул, гашыйк егет хәлен аңлаганга күрәдерме, минем белән сөйләшүне төпле итеп, ягъни «по душам» алып барды. «Бер дә аптырама, бер синең генә баштан үтмәгән андый хәлләр, без дә кыенлыклар кичтек, әле хәзер дә башлар буталгалап, җүләрләнеп куям. Әллә ни исең китмәсен, кирәк булса, үзе килеп муеныңа асылыныр!» – дип тынычландыргандай әйтте.

– Тик үзең асылына күрмә! – дигән җөмләсен Мәхмүт арага тыкмаган булса, сөйләшүебез ирләрчә булачак иде дә, әйтеп, әңгәмәбезне пүчтәккә әйләндерде. Көлешкән булып таралыштык инде.

Әйттең дә бетте, әйттең дә сөйләшкәнчә була дигән сүз түгел бит әле ул. Йөрәк һаман көя. Сәбиләне күрүем була, баш салкын кан белән эшләвеннән туктап, кайнарга керешә. Виртуоз: «Муеныңа килеп асылыныр», – дип әйтсә дә, әле монда ул асылынганчы түзәргә кирәк ич – акылдан шашарсың...

Интегеп йөрүдән туйгач, беркөнне кич, репетициядән соң бөтен кыюлыгымны җыеп, Сәбиләгә:

– Сәбилә, сине озата барыйм әле? – дидем.

Ул кисәк борылып, нигәдер русчалатып:

– Бесполезно! – диде. Колагым дөрес ишетәме?

Аптырап калдым:

– Нәрсә?

– Бесполезно! – диде ул, кабатлап.

Үземне чәйнәп ташланылган сагыз итеп тойдым. Моңа хәтле күпме кызның кумиры булып йөргән Зәбирме мин?! Никадәр тамашачы каршында һәрвакыт «бис»ка җырлаган җырчы Зәбир шушы буламы инде? Гарьләнерлек, җәберләнерлек сүз әйттеме ул? Юк, минем күңелемдә ачу кайнамый, юк, юк... Аны бит үзем үлеп гашыйк булган кыз – Сәбилә генә әйтте. Болай гына, уйламыйча, үртәп, үчекләр өчен генә... Мин аның бу сүзен йоттым. Бетте ул сүз – әйтелмәгән...

Бу вакыйгадан соң мин репетициядә ике атна буе күренмәдем. Виртуоз шуңа күрә тулай торакка мине эзләп килгән икән.

– Авырдыңмы әллә? – генә диде дә, иртәгә Җитен комбинаты клубында концерт буласын әйтеп, чыгышымның бик кирәклегенә аеруча басым ясап китеп барды. Әлбәттә, бу араларда ни сәбәпле югалып йөргәнемне ул аңлый

иде инде. Мәхмүт белән Ләйсирә әйтмиләрме соң аңа. Бәлки Виртуоз һәм Сәбилә арасында бу мәсьәләдә сөйләшү дә булгандыр – анысы миңа ачык түгел.

Мин, әлбәттә, Сәбиләгә бернинди дә дәгъва белдерә алмыйм. Егерме алты яшькә якынлашып, пеләшләнә башлаган егеткә ник карарга тиеш соң ул. Чибәрлегем дә ташка үлчим генә. Әле күкрәгемдә югары уку йортын тәмамлагач тага торган ромбигым да юк. Юанычым шул: җырлыйм инде. Җырлаганымны яраталар бугай...

Менә Җитен комбинаты клубында концертыбыз бара. Залда халык шыгрым тулы. Ансамбльнең һәр җыры көчле алкышларга күмелә. Күңелем тулы һаман сагыш булса да, бар көчемне җыеп, сынатмаска тырышам. Элеккеге кебек, күтәренке рух белән, кызлар арасында йөрим. Күренүгә Ләйсирә яныма килеп басты.

– Авырдыңмы әллә, Зәбир?

– Юк, – мәйтәм. – Сагынсыннар әле дип яттым, югыйсә минем барлыгымны да белмисез. Инде кияүгә чыгып беткәнсездер дип уйлаган идем, һаман ялгыз йөрисез икән әле...

– Син килмәгәч белмисең дә инде, кияүгә чыкмасак та, әнә кайберләребез парлаша башладылар бугай, – дип Сәбилә белән Мәхмүткә төртеп күрсәтте.

Килүгә үк, күзгә чалынган дустым Мәхмүтнең Сәбилә янында чуалганын абайлаган идем инде.

– Матур пар! – дип кенә әйтә алдым. Сүземне тәмамлауга, күкрәгем буйлап тагын яшен уты чатнап үтте. Көчкә хәлгә килдем. Ләйсирә сиздеме-юкмы – әйтә алмыйм. Сизгәндер... Бәлки, аңа минем шулай әйтүем кирәк булгандыр?.. Ә бәлки юктыр...

Матур пар... Минем сәхнәгә чыгып җырлыйсым бар – тиз генә хәлгә килергә кирәк. Кирәк, кирәк!.. Мәхмүткә караганда шәбрәк җырларга! Әйе, шәп итеп җырларга! Нindине? «Гел елмайны!» Илһам Шакировча – боргалап, үзәкне өзәрлек итеп!

Сәхнәгә мине дәштеләр. Виртуоз: «Шул сөйләшкән җырмы?» – дип сорады да, сәхнә уртасына чыгып, аякларын киереп басып, уйнап җибәрде. Ул да сизә бит инде бүген ничек уйнарга кирәклеген. Әйдә, Зәбир, сынатма, бир кирәген, багышла тегеңә җырыңны, янәмәсе. Каян чыккандыр ул көнне гайрәт-көч, шәп бәрдем мин ул җырны:

> Бер генә елмаеп карадың,
> Гомергә калдырдың газабын.
> Гел елмай, гел кара күзләремә,
> Ялкын сал, ут када йөрәгемә,
> Җил генә үтмәсен үзәгемә,
> Тик өметемне өзмә генә!..

Белсәгез, күрсәгез иде ул кичтәге миңа булган алкышларны! Кабат-кабат чакырып җырлаттылар. Ахыргы мәртәбә җырлаганда, микрофон эшләмәде. Шнурыннан тотып, идәнгә төшердем дә юри таптагандай итеп, шунда ташладым. Виртуоз уйнавын дәвам итте, ә мин, микрофонсыз гына, җырның соңгы сүзләренә хәтле дәвам иттем. Бер ялгансыз – халык торып басып кул чапты. Ә Сәбиләнең исе дә китми, нүжәли шулхәтле битараф инде ул миңа? Тирә-юньдәгеләр шатлыгымны уртаклаша, кулымны кысалар, кызлар битемнән үпкән булалар... Мәхмүт каядыр олаккан, күренми...

Җитен комбинатындагы уңышлы чыгышымнан соң, ансамбль кызлары

үземә ягымлырак карый башладылар. Хәер, элек тә мөнәсәбәтләре начар түгел иде, ләкин күңелләре миндә түгел иде аларның. Кычкырып әйтмәсәләр дә беләм, һәммәсенең яратышкан егетләре бар. Яратмаслык та түгел ич үзләрен – чибәрләр, тәртиплеләр, тыйнаклар. Кайберләрен каршы алырга егетләре клубка хәтле килә, репетициядә җырлаганнарын көтеп утыралар, ансамбльнең бәйрәмнәрендә, кичәләрендә катнашалар.

Үзегез беләсез, мөнәсәбәтләр гел үзгәреп тора бит. Бүген-иртәгә ирең булырдай кеше, берсекөнгә кисәк кенә, ниндидер аңлашылмаучанлыктан, чит кешегә әверелә дә куя. Кешенеке бик җайлы хәл теләә кебек тә: алар борчылмыйлар да сыман, исләре дә китми шикелле; бүген шулай, иртәгә икенче төрле, шуннан нәрсә булган – алдыңнан артың яхшы, диләрме әле? Менә миңа алай кирәкми шул. Мәхмүт, ачу китереп, Сәбилә янында бөтерелә. Ә минем сару кайный. Үҗәтлегем юк түгел дә бит, нишлим соң, нахалланып ябышып булмый. «Бесполезно!» – дип әйтте бит инде... Бәлки, кызулык белән генә ычкынгандыр ул сүзе? Бәлки, инде менә хәзер, кемлегемне – нинди шәп җырчы булуымны үз күзләре белән күреп, үз колаклары белән ишеткәч, фикере үзгәргәндер. Инде андый сүзне ник әйткәненә үкенәдер?

Виртуоз да әнә беркөнне:

– Тегенең белән эшләр ничек соң? – дип сорап торды.

– Ничек булсын инде, – мәйтәм, – шул килеш, якын китерми...

– Алай икән. Ә син кыюрак бул! Син бит, Зәбир, бик әйбәт егет, тора-бара, менә күрерсең, әйтте, диярсең, ул сине ярлатачак!

– Тора-бара... Ә хәзергә Мәхмүт белән торып торсынмы?

– Әй, Мәхмүт – шалапай бит ул... Мин сиңа шуны гына әйтә алам: ычкындырма кызны, тагын бер кат сүз башлап кара!

Виртуоз шулай дигәч, Сәбиләгә сүзне ничек дип башларга кирәген бик озак уйлап йөрдем дә, бер кичне клуб коридорыннан үтеп барышлый каршыга очрагач, җайлап әйтелергә тиешле сүзләрне әйтеп тә тормыйча, тегене стенага китереп кыстым.

– Син нәрсә, үзеңне патша кызы дип белдеңме әллә, чибәркәй?! – дидем.

– Көч белән алам дисең инде? Всё равно бесполезно! – ди бу, һаман үзенекен тукып, киребеткән нәрсә. Инде бу юлы болай килеп чыгасын көтмәгән идем. Татарчасын да җүнләп белми бит әле, себер марҗасы. Шуңа гашыйк булып йөрим бит, үзем дә уҗым бозавы инде.

– Бар, гуляй! – дидем дә ычкындырдым кочактан. Ник чукынып китми шул Мәхмүте белән!..

Ярар, килешмәсә килешмәс әлеге гамәлем, ягез, җәмәгать, мин моның белән нәрсә эшли алам инде?.. Тагын бүтән кагылсаммы?..

Күңелгә уелган яра төзәлми икән шул. Янда йөри бит – ташлый алмыйм мин җырны, җырлыйсым килә, җырлыйсым.

Менә тагын сабантуйлар җитте. Безнең ансамбльне һәр елны Аккош күле янында уздырыла торган Киров районы сабан туена чакыралар. Зур мәйданда шау-гөр килеп җырлыйбыз да, бәйрәм уңаеннан җыелышып, күркәм генә урында, күбрәк тирәкле күл кырыенда, өстәл корып бәйрәм табыны оештырабыз. Ансамбльнең кызлары, әйткәнемчә, барысы да чибәрләр. Тавышларыннан сандугачлар көнләшерлек. Халык арасында тикмәгә түгелдер инде аларның популярлыгы. Үзләренә генә түгел, тавышларына таң калган, гашыйк булган егетләр менә шушы сабантуйларда аларны хөрмәт итеп, җыр сәнгатендә югары үрләр яулауларын теләп, табын артында тост күтәрәләр.

Мактау сүзләре җыр белән үрелеп бара. Уен-көлке тамашага әйләнә. Мин генә ни әйтергә белмичә тик утырам. Әллә инде берәр чәркә шәраб җиффәреп алыргамы? Бәйрәм бит. Виртуоз да, әнә, табын түреннән чокырын күтәреп миңа ымлый. Ярый, андый талантлы җитәкче белән, бергә ирешкән уңышларны искә төшереп, эчмәсәң гөнаһ булыр. Рәхмәт, Виртуоз! Ансамбльнең уңышлары өчен, әйдә!

Карале, хәйран әйбәт булып китте бу. Ул арада яныма Мәхмүт килеп җитте.

– Әйдә, дустым, синең уңышлар өчен, – дип, чәркәмә акны салды да, минем эчкәнне көтеп тормыйча, үзенекен чүмәлтеп куйды.

Нәрсә? Сынатып утырыйммы? Колхоз председателе малае әле абзагыз, бик беләсегез килсә!.. Үзем Сәбиләне күзәтәм, сизәм, ул да күз кырые белән генә миңа төбәлеп ала. Бер сулыш белән, мөлдерәмә чәркәмне каплап куйдым.

Шулвакыт Сәбиләнең бер карашын тотып алдым да:

– Һаман бесполезномы, Сәбилә? – дидем.

Ул миңа акаеп кына:

– Дурак! – диде.

Мин күтәрелеп аңа ыргылдым. Бирәм хәзер кирәген... Җимерәм чибәрлеген... Күлмәген умырам... Чурту матр – китәм Себергә! Ул, бу мәсьәләнең юньлегә бетмәсен аңлап, куаклыкка йөгерде. Шулчак аяк астыма каяндыр корыч аркан кисәге килеп төште, абынып егылдым. Кемдер ыргытты түгелме? Сәбилә кая югалды? Электәге кебек, бу юлы корсакка якынрак, ләкин йөрәктән түбәнрәк җирдән сызылып әрнү йөгерде. Мин «уф!» дип кенә әйтә алдым, әмма сер бирмәскә тырышып, яңадан торып утырдым. Корсагымда әрнү катыш җылылык сизәм – рәхәт кенә. Аракыны чама белән генә эчсәң файдалы, диләр, шулай икән шул.

Сабантуй матур гына үтеп китте. Җәйге озын көннең караңгысы төшкәч кенә, тулай торакка кайтып, егылдым. Күлмәк өстеннән кигән җиңелчә курткамны салдым. Күлмәгем дә салынырга карышып маташмады. Нигәдер майкамны тәнемнән куптарып булмый, корсак өлеше коңгырт төскә баткан. Бүлмәдәш дусларым аптырап карап торалар, әйтерсең лә мин аларны хәзер Сабантуйдагы кызык хәлләрне сөйләп көлдерергә тиеш!.. Нәрсә булган майкага? Тәннән купмый гына бит. Җитмәсә авырта хәзер. Тәки әкрен генә куптардым моны – бүксәмнең биш сантиметрлап җире киселгән бит... Менә сиңа мә!.. Яңадан әкренләп кан саркый башлады. Яра төбендә элпә генә. Аның теге ягында эчәкләрдер инде? Шаккатып карап торган дусларымның берсе – Рудамир дигәне, аңын югалтып, караватка ауды. Мин майкамны ертып, корсак әйләнә ярамны бәйләдем. Үземнең дә хәлем китте. Ниһаять, Рудамир аңына килде: ул, Әлфәт исемле бүлмәдәшем белән мине җитәкләп, Губкин урамындагы әллә ни ерак булмаган травмпунктка алып киттеләр. Килү белән, табиблар өстәлгә сузып салдылар да, бер-ике укол кадап, милициягә хәбәр итәргә кирәк дип, ярамны тегәргә тотындылар. Мәйтәм, милициягә әйтергә кирәк түгел, Сабантуйда троска абынып егылып шулай булды ул. Ярый әле ышандылар, милиция чакырмадылар. Юкса, бу җәй көне шабашкага китеп булмый иде. Ныгытып бәйләгез, иртәгә үк төзелеш отряды белән Арчадагы бер авылга сыерлар абзары төзергә китәсем бар, дим. Көләләр. Кая монда андый эшкә бару, бер-ике атна урын өстендә ятарга тиешсең, диләр. Ике көннең берендә повязканы алыштырырга кирәк булачак икән. Аларны тыңлау юк инде, киттем дә бардым, җәй буе бүлнистә ятыйммыни, акча эшләргә кирәк. Андый җирләргә без Рудамир белән йөрибез.

***

Безне каршылаган төзелеш начальнигы Рудамирга:

– Нинди инвалид алып килдең син монда? – ди икән. Ничава, шул тишек корсак белән дә сынатмадым әле башкаларга. Ни бит, Сәбилә янына акчалы булып, яхшы кәчтүм киеп, пеләшемне парик белән каплап кайтып керсәм, «бесполезно» булмас, бәлки.

Колхоз бәрәңгеләре алып, ферма түбәләре ябып, байтак акча эшләп, сентябрьнең унбишләрендә институтка кайтып кердек. Шулай, эшләгән кешегә сүз әйтүче юк институтларда – соңга калып кайтсак та. Укулар күптән башланса да, эленке-салынкы йөрисең башта. Әле менә үземә яхшы кәчтүм эзләдем. Шәһәр кибетләрен аркылы-торкылы йөри торгач, таптым тагы үзен – шәп, караңгы коңгырт төстә, минсиңайтим. Министрлар гына кия торган. Күзе маңгаена менсен әле Сәбиләнең.

Киеп барып кердем репетициягә, исе дә китмәде, мәнсезнең. Ә үзе, ә үзе – тагын да ныграк чибәрләнгән. Ул чәчләрен эре дулкын ясатып бөдрәләтүен әйтимме, өстендә теге беренче күргән вакыттагы кебек күлмәк кенә түгел, бик бай кеше кызына охшап, купшы туташларда гына була торган куе зәңгәр кәчтүм. Минекенә, әйтәм ич, борылып та карамады. Фу, дигән сыман карашын гына күреп калдым. Үземнең әллә исем киттеме? Тач мәктәп завучы булган да куйган инде, менә шул. Беләм, күрәм, сизәм – тагын янына килсәм, «бесполезно» диячәк. Җитмәсә, ачу китереп, Мәхмүт белән сөйләшеп тора бит әле. Мәхмүтен дә әйтер идем инде, «дус, дус» дигән булып йөри, ә үзе һаман шул Сәбилә кырыенда бөтерелә. Янәмәсе Сәбиләнең хисләрен бик хәйләкәр генә белешеп, миңа җиткереп торачак. Нигәдер һаман җиткерә алмый әле. Дус түгел син, Мәхмүт – төлке, ә тегесе – елан.

Мин үзем бу хәлгә күнегеп тә, күнеп тә барам төсле инде. Тик менә баш белән йөрәк кенә тарткалаша. Баш, мескенлеккә калып йөрмә шуның белән, ди, ә йөрәк... ә йөрәк, нигәдер, киреләнә.

Башыма караганда, йөрәгем Сәбиләне ныграк ярата шикелле. Йөрәкнең бәгыре бар шул аның. Гадәттә, приборлар янып чыкмасын өчен, предохранитель куялар. Минем йөрәгемнең предохранителе йомшак бугай, менә-менә янып чыгарга тора. Эчемдәге бәгырь, предохранитель ролен үтәрлек түгел, түзмәс, озакламый янып чыгар, эшләр болай барса. Электр тогы арткан чакта приборлар эштән чыкмасын дип, көчәнешне киметәләр, миңа да мәхәббәт утын сүндеребрәк «нуль»гә төшерергә кирәк булыр. Һәм шулай иттем дә.

Сәбиләгә гупчым игътибар итмәгәндәй булып йөрим. Бер репетицияне калдырмый ансамбльгә киләм. Кыска гына вакытка концертлар белән якын-тирә авылларга чыгып керәбез. Укуыннан бушаган чакларында Сәбилә дә баргалый. Ул ансамбльдә икенче сопрано партиясен алып бара. Тавышы матур. Андый үзгә тавышлы кызлар ансамбльдә өчәү генә: Рания, Рушания һәм ул. Сәбиләне пианинода бик яхшы уйный, диләр, ләкин аның уйнаганын беркайчан күргәнем дә тыңлаганым да булмады. Шулай да кечкенә чагында Кустанайда музыка мәктәбендә укыганлыгы миңа мәгълүм иде. Сәбиләнең ансамбль кызлары рәтендә үтә матур итеп басып җырлавы күз алдымда: алар ярым түгәрәк ясап тезеләләр дә, ул, үзәккә бераз яны беләнрәк борылып, сул кулын артка яшерер, башкалар да аның төслерәк, талгын гына тибрәлеп, җыр сузалар. Сокланып туя алмаслык күренеш һәм халәт.

Җырла, комачауламыйм, тимим теңкәңә, язмышыма шулай язгандыр,

бәхетле бул, күңел кошым! Мин синең янәшәңнән үз юлым белән барам, ялгызым, җаныма сагыш тулган килеш, җырларым белән...

Мәхәббәт утында өтәләнеп инде менә өченче ел үтеп бара. Сәбиләнең миңа карата карашы чак кына да үзгәрмәде. Бу халәткә инде, берәрсе булса, күптән кул селтәгән булыр иде, Их, Сәбилә, Сәбилә... Ник очрадың соң син минем гомер юлымда?.. Әллә берәр җиргә китеп югалыйм микән? Еракка-еракка... Ичмасам онытылыр идең... Себергә?.. Анда да җырчылар кирәктер? Танылып, данлыклы җырчы булып, яңадан Татарстанга кайтып керсәм, син нәрсә дияр идең?.. Уйларга гына җайлы, анда суык шул. Катып-туңып йөргәнче, Ташкентка китсәм дә була. Йә, бардым ди, шуннан нәрсә? Сәбиләгә ачу итепме? Аның ни гаебе бар? Җүләр дә инде мин. Әнә, берәү, кем әле – Кәрим Питрәчев дигән егет, Магаданга барган ди бит. Өзелеп сөйгән яры: «Дөнья читенә алып китсәң дә риза!» – дигәч, ул, башта үзем барып урнашыйм, аннан сине чакыртырмын, дип шул җәһәннәм тишегенә китеп барган. Менә бит мәхәббәт нишләтә? Алтын приискасына эшкә кергән егет, сөйгәненә килсен дип акча җибәргән, ә тегесе монда кияүгә чыгып йөри икән. Менә син ышан кызларга. Ә Сәбилә бит миңа ым да какканы юк. Җүләрләнеп Себергә китәмме соң?! Нәрсәгә миңа Сәбилә? Йөрсен Мәхмүте белән, бәхетле булсыннар! «Бесполезно»дан башка сүз дә белми бит ул. Бетте-китте, бу турыда бүтән уйлау юк.

Ромео белән Джульеттаныкы кебек мәхәббәткә әверелгәнче туктатырга кирәк безнең арадагы мөнәсәбәтне. Аларның болай булган бит: Джульетта ярату хәсрәтеннән дару каба да озаграк йоклый, ә Ромео аны үлгән дип белеп, үзен-үзе үтерә. Йокысыннан уянгач, Джульетта, аны үлгән хәлдә күреп, янәшәдәге кинжал белән үзен кадап үтерә. Мондый чарасызлыкка барып җитмәгән бит әле мин.

Ләйлә белән Мәҗнүн мәхәббәтен искә алыйк. Алар бер-берсе белән гаиләләренең дошманлыгы аркасында кавыша алмыйлар. Ләйләне башкага кияүгә бирәләр, ә Мәҗнүн чүлгә китеп ялгыз яши башлый. Ләйләгә багышлап җырлар яза, күп газаплар кичерә. Соңыннан икесе дә сагыштан саргаешып үләләр.

Юк инде, Сәбиләкәй, мондый ук хәлгә төшәргә Мәҗнүн түгел әле Зәбир – өмет итмә!

Таһир белән Зөһрәнең язмышлары кызганыч. Таһирны сандыкка салып суга агызалар. Ул, исән калып, читтә өйләнә, аннан, кире әйләнеп, туган ягына кайта. Ә монда аны тотып алып, гәүдәсен тураклыйлар. Зөһрә сөеклесен кырык көн буе елап озата. Бигрәк кызганыч. Мине кызганып еларлык сөйгән яр да юк бит. Сәбиләнең күзеннән кырык көнлек түгел, бер секундлык яшь тә чыкмас, мөгаен.

Отелло белән Дездемонаны кара инде син. Көнчелектән сөйгәнен буып үтерүгә барып җитә бит Мавр. Ну, Мәхмүт, болай йөрсәң, Дездемона ясыйм мин синнән!..

Үземне дә «Сүнгән йолдызлар»дагы Мәхдүмгә тиңлим түгелме соң? Ул бөкре, ә мин – пеләш. Юк, туктале, Зәбир, бирешмә, башыңны югары тот! Җырлавыңны бел! Менә быел бишенче мәртәбә «Кышкы эстрада» җыр фестивале була, шунда син лауреат булырга көрәш!

«Химиклар» мәдәният сараенда уздырыла торган бу фестивальгә ансамбль быел аеруча нык әзерләнде. Безгә – Мәхмүт белән икебезгә аерым җырлау номинациясендә чыгыш ясау хокукы бирелде. Мин Рим Хәсәновның «Син – гомер агышларым» дигән җырын җырларга булдым. Мәхмүт үзенә шул ук

композиторның «Сиңа тагын мин бер киләм әле» җырын сайлады. Исәбе – бу юлы лауреат исемен алу иде. Миңа нәрсә, күнегелгән, инде өч елда өч мәртәбә лауреат булдым, ә Мәхмүт көнләшә. Инде өч елның берсендә дә дипломант исеме эләктерә алганы юк бит. Кызганып та куям үзен. Быел бирсеннәр иде инде аңа да.

Залдагы халыкның күплеге – сөендергеч хәл. Буш урындыкларга карап җырлавы бик авыр. Дәртләнә алмыйсың, дулкынлану да булмый. Җырны җиренә җиткереп башкару өчен тамашачының сулышын тою мөһим. Кемгә ничектер, миңа шулай. Бераз дулкынлану җаваплылыкны арттыра.

Бүген һәр җырчыга бер җыр башкарырга кушылган – шул бәяләнә. Алдан җырлау чираты Мәхмүткә эләкте. Ул бу очракны бәхеткә санады, күрәмсең, шатлыгы йөзенә чыккан иде. Чөнки миннән соң җырлау аңа кыен булыр, жюри аны-мине чагыштырып карагач, өстенлек кемгә биреләчәге көн кебек ачык. Дөресен әйтим, шәп җырлады ул көнне Мәхмүт, аның өчен сәхнә артында чын күңелемнән җан атып утырдым. Алдан әйтеп куям, аның исеме «Кышкы эстрада» фестивале дипломантлары арасына кертелгән иде.

Ниһаять, Мәхмүттән соң ике номенант җырлагач, миңа чират җитте. Җайлап кына, уйланып, җырның эчтәлегенә чумып, көйгә кушылдым. Рәхмәт Виртуозга, ул уйнаса уйный инде!..

Акты ташып, акты ярсып кар сулары,
Шулдыр инде язның...

Кинәт микрофонда тавыш бетте. Әллә сүндерделәрме?.. Ләкин җырлавымны дәвам иттем. Уйнавыннан туктап, аптырап калган баянчым Виртуоз Актанышев миңа яңадан кушылды. Тавышымны көчлерәк чыгарырга тырышып, көчәнебрәк җырларга керештем. Тамакка әллә нәрсә булды – әче төер утырды, тавыш кырылып чыга башлады. Микрофонга җырлагандагы кебек хисләнеп җырлауның эзе дә калмады. Карлыккан тавышым бөтенләй бетәр дип, сәхнәдән чыгып киттем. Залдагы тамашачы бу хәлгә ризасызлык белдереп, тавыш куптарды. Кайберләре: «Звукорежиссёр, на мыло!» – дип кычкыра ук башлады. Сызгыру, дөбердәүләр...

Әмма бераздан микрофон терелде. Фестиваль үз эшен дәвам итте. Ләкин мин инде кабат сәхнәгә чыгып җырларлык хәлдә түгел идем. Ул елны мин «лауреат»сыз калдым.

Нигәдер соңгы еллар миңа гел кирелеген генә күрсәтеп тора әле. Мәхәббәт мәсьәләсендә дә эшләр уңай якка бармый, инде менә җыр өлкәсендә дә бәхетсезлекләр өстәлеп тора. Андый минутларда, һәрвакыт, элегрәк печән чапкан чакта, урманда, бер кара еланны аракыдан бушаган шешәгә кертеп калдырганым искә төшә. Шунда, һәркөнне барган саен, шешә эченнән тилмереп карап тора иде, җаныкаем. Нигә аны шулкадәр җәфа чиктердем икән? Ни гаебе бар ул җан иясенең минем каршыда? Бер начарлык та кылмады бит югыйсә ул. Йөрсен иде рәхәтләнеп үзенең аланында. Ә мин аның башына җәпле таяк белән бастым да, шешәгә тыгып куйдым. Җиңдем, янәмәсе... Агулы нәрсәне үтерергә кирәк, диләр бит инде. Тиктомалдан вәхшилек кылдым түгелме соң? Хәзер менә шул еланны искә төшерәм авыр чакларымда. Әллә шуның җәбере тия микән, дим? Еланнарның каргышы төшә, диләр бит. Шулайдыр. Шулай булмаса, мондый михнәтләр үземне читләп узар иде. Ярый, Аллага тапшырган инде. Үлде инде ул елан шунда, хәерлегә булсын алдагы язмышым.

Ансамбльдәге көннәр гадәттәгечә үтә торды. Мин, Авыл хуҗалыгы институтын ташлап, Төзелеш институтының кичке бүлегенә укырга кердем һәм төзелешкә эшкә урнаштым. Архитекторлар әзерли торган бүлеккә эләгеп булмады, Промышленность һәм гражданлык объектлары төзү бүлегенә алдылар. Бу болайрак булды.

Әйе, архитектор буласым килә, керү имтиханнары тапшырып йөрим. Рәсем ясауга махирлыгым бар. Мәктәптә укыганда да андыйрак эшләрне миңа тапшыралар иде. Математикадан әллә ни мактанырлык чамам юк югын, әмма укытучыбыз Вера Павловнаның безне интектерүе белемгә гаять файдалы нигез салгандыр, шулай дияргә нигез бар.

Менә математикадан имтихан бирәм. Мәсьәлә, мисалларны тиз генә чишеп, иң беренчеләрдән булып, имтихан алучы ябь-яшь кыз алдына килеп утырдым. Чибәр дә инде, нәгаләт! Миннән яшьрәк тә бугай. Кай арада югары белем алып, бездәй «ломоносовларны» сыный бит, әй. Институтлар ташлап йөрсәң, шулай була ул, Зәбир. Менә яшь кызлар үзеңнән сынау алалар хәзер. Яңаклар уттай яна, колаклар кызыша. Тирли-пешә чибәркәйнең мәсьәлә-мисалларымны тикшерүен күзәтәм. Алай сызгаламый, ялгышлар юк, күрәсең. Менә тотынды бу өстәмә сораулар яудырырга: логорифмнар, ди, интеграллар... Соңгы терминны гомумән ишеткән юк. Үтмәдек без аларны мәктәптә, минәйтәм. Шундый чибәр кыз сораулар биргәндә, җавабын да тиз генә табып булмый бит әле аның. Тәмам батырды бу мине. Тотлыга ук башладым. Күз алларым томаланып китте. Томан артындагы әлеге кыз җә убырлы карчыкка әверелә, сихерче рәвешләренә керә, аждаһа төсле дә булып китә. Агулы сорауларын чәчеп бетергәч, «дүртле», диде. «Дүртле?» Нишлим ул «дүртле» белән? Конкурстан үтмим бит. Димәк, армиягә! Шагом марш! Нишлисең, юри батырды инде бу мине, юри. Конкурс зур, кемнедер сызарга кирәк, димәк, мине.

Хезмәт итеп кайтсам кайтам, әмма «бишле» куегыз инде, дип ялынмаячакмын. Соңыннан гарьлеген кая куярсың. Председатель малае бит мин!

***

Еллар үтте. Армия хезмәте дә артта калды. Ансамбль кызларының кайберләре кияүгә чыкканнар, шул исәптән Ләйсирә дә. Мине көтсенмени – бестолковыйны. Сәбилә никтер ялгыз икән әле. Үземнең дә башыма өйләнү фикере керми. Өйләнсәң дә, ни торыр җир юк, ни институт бетерелмәгән. Әллә инде акылга да утырып бетелмәгән?.. Дуслар да бер-бер артлы башлы-күзле булып, гаилә корып яшиләр. Инде соңгысын өйләндереп йөрим – шаһит егет булып. Күпмесендә бу вазифаны башкарганмындыр, санаган юк. Дустым Азат өйләнә. Булачак хатыны Хәдичә – искиткеч сөйкемле, уңган-булган кеше. Каян табалар шундыйларны, миңа бер дә очрамыйлар. Шул кичне Хәдичә, колагыма кирт киртләп, туйга үзенең менә дигән сердәше шаһит кыз булып киләчәген әйтеп куйды. Кара аны, ычкындырасы булма, ялгышырсың, дип тә өстәде. Ярый, килсен, китәр әле! Инде миңа өйдәгеләр дә күп кандидатуралар күрсәттеләр, күнегелгән.

Менә туйга җыеналар. Кунаклар арасында кемнәр генә юк. Барысы да бәхетлеләр, парлылар, мин генә дуадак ата каз кебек басып торам. Әле кызмаганмын. Бераз шәраб чеметеп алсам, туктатып булмас үземне – баянны алып уйный да, җырлый да, бии дә башлыйм. Дөресен генә әйткәндә, шуның өчен чакыралар да инде үземне туйларга. Ни күрим – Хәдичә Азатыннан

вакытлыча аерылып, минем янга бер кызны җитәкләп килә. Еректан ук сүзен безне таныштырудан башлый:

– Менә бу – Зәбир, шаһит егет, безнең дустыбыз. Ә бу – минем сердәшем, Төзүчеләр институтының яшь доценты Галия.

Мин күзләремә күренәме, бу өнемме-төшемме дигәндәй, авызымны ачып, әлеге Галиягә карап каттым. Шул бит бу, әйе... теге вакытта имтиханда мине батырган кыз.

Хәдичә сүзен дәвам итте.

– Нәрсә өнсез калдың, башка вакытта бик кыю бит үзең, – дип, миңа күзен кысып, кызның сыйфатын баш бармагы белән бәяләп, Азаты янына йөгерде.

Хәдичә бу кыз белән теге вакытта очрашканымны белми ич. Каян белсен?.. Монысы да хәтерләми. Аллага шөкер!

Минем уңайсыз хәлдә калуымны аңлап булса кирәк, Галия сүз башлады.

– Хәдичә сезнең турыда бик күп сөйләде. Төзүчеләр институтын тәмамламыйча армиягә алынуыгыз турында да. Карагыз әле, нигә шунда үземә мөрәҗәгать итмәдегез. Мин бит еш кына керү имтиханнарын кабул итәм. Хәзер яңадан бездә укырга теләгегез юкмы? Терәк барында сезгә уку бик җиңел булыр иде. Сезнең талантлы икәнлегегез йөзегезгә чыккан. Сезнең кыяфәтегез зыялы, сез – музыкант, шагыйрь, композитор – бу күркәм сыйфатларыгыз арасында архитекторлык юнәлеше аеруча калку күренер. Әйдәгез, бергә булыйк!

– Рәхмәт сезгә. Менә бит мине тормышта нинди бәхетле борылыш көтә икән! Сез иреклеме?

– Әйе. Гафу итегез, мин сезгә һич яшерми әйтә алам. Инде, ялгышлык белән кияүдә булдым. Яшьлек хатасы. Бер студентым тәкъдим ясап, яшәп карадык. Хәзер, укып бетергәч качты. Ә сез акыллы, һичшиксез, акыллы.

– Анысын дөрес әйтәсез. Әйдәгез, ул турыда сүз кузгатмыйк әле. Бүген бәйрәм – дусларыбызның тантанасы! Җырлыйк, биик!

Ага сулар, ага сулар,
Ага сулар ник болай?
Аккан сулар кире кайтмый,
Яшь гомерләр дә шулай.

Без аның белән бүтән беркайчан да очрашмадык.

***

Армиядән кайткач, мин Төзелеш институтында укуымны дәвам итеп тормадым, документларымны алып, Пединститутның музыка укытучылары әзерли торган факультетына имтихан бирдем. Комиссиядәгеләр пеләш башыма карап тордылар да, тавышыма сокланып, укырга алырга булдылар. Яңадан җырлы тормыш башланып китте. Югыйсә бит Сәбиләгә минем Авыл хуҗалыгы институтында укып йөрүем ошамыйдыр, ярый алайса, Төзүчеләр институтын бетереп, йортлар төзү комбинатының директоры булырмын дип хыялланып йөрүләрдән чыккан иде бу җүләрлекләр. Менә шулай һаман укып, җырлап, Сәбиләгә карап янып-көеп яшим. Бәйрәмнәре дә булгалый яшәешебезнең. Ансамбль кызларының туган көннәрен үткәрәбез җыелышып. Әнә Гөлиянең егерме биш яше тулган – шуның юбилей кичәсендә өйләрендә утырабыз.

Дөресен әйтим, соңгы араларда кызларыбызның миңа карата мөнәсәбәте аеруча җылы юнәлеш алды. Сизелә. Әллә картаябыз дип уйлыйлар микән?

Ансамбльдә өйләнмәгән шундый егет бар, понимаешь, ә алар күктәге бөркетне эзләсеннәрме? Картаеп кияүгә чыкмыйча калсалар, яннарындагы чыпчыктан да мәхрүм калалар ич. Кара инде, кара, каршымда күзләрен уйнатып утыручы Сәрияне! Янәшәсендә Сәбилә, миңа карата игътибары – «нуль». Әй, җаныкаем, синең дә яшең бара!.. Сәрия өстәл астыннан аягы белән миңа төртә, нәрсә әйтмәкче буладыр... Һаман саен онытылып Сәбиләгә карап утыргангамы икән? Карамаска тырышам бит инде. Ул бертуктаусыз аякка төртә, башы белән ымлап, мине каядыр чакыра. Нәрсә булган моңа, чыгып керик әле, ди ахрысы. Ярый, чыктым да ди, шуннан нәрсә? Әллә инде күбрәк киткәнме – әйткән тостларның берсен дә калдырмый эчеп утыргач? Ярый, чыгыйм инде, тилмертмим кызны? Берәүгә дә сиздерми, чыгып керүемә сәбәп тапкан булып, Сәрия артыннан юыну бүлмәсенә юнәлдем. Керүем булды, шарт итеп эчке яктан ишекнең келәсен элде дә куйды Сәрия. Стенага мине китереп терәде дә, күкрәкләрен оясыннан чыгарып, битемне уа башлады.

– Нәрсә кирәк сиңа, ник аның артыннан тилмереп йөрисең, кара монда, аның мондыйлары юк та әле, – дип «кавыннарын» кулыма тоттырды. Әле күзгә, әле биткә каплавыннан сулыш ала алмый тончыгып үлә яздым.

– Бүген түгел, Сәрия, – мәйтәм, – бүген түгел!..

– Кайчан, кайчан?..

Ул бу сүзләрнең кайчан үтәләчәген гомере буе көтеп йөрде бугай...

Ә минем күзләр һаман башкада булды, беләсез...

Юыну бүлмәсеннән Сәрия белән бергә чыктык. Шул минутта Гөлиянең этисе ике шешә аракыны форточкадан урамга атты, ә энисе... Әле генә миңа «кияү» дип ычкындыргалаган энисенең йөзенә кара болыт кунган иде. Әлбәттә, кунакка чакырылу күңелле булып бетмәде, хуҗаларның ниятенә туры килеп җыелмаганбыз икән шул. Әти-энисенә «кияү»нең чәчле яки чәчсез булуы да мөһим түгел икән – акыллы гына булсын. Күрәләр бит, ишетәләр, сыныйлар – Зәбир төпле кеше: эчми, тартмый, әлегә өйләнмәгән, ялгыз – кызларына менә дигән пар түгелме соң? Кызларын кавыштыру, дөресрәге чын-чынлап ярәштерү өчен, туган көне дигән булып җыйган мәҗлестә Сәрия эләктереп маташа түгелме аны? Ачуы чыккан эти кешегә мәҗлесне тарату өчен бер литр аракыны тышка томыру – урынлы гамәл, минемчә. Хуҗаларга рәхмәт әйтеп таралыштык...

Аңладым, пеләш булу мәхәббәткә комачауламый икән бит. Ләкин барыбер эч поша, чәч булса, мишәйт итмәс иде әле. Гаеп миндә түгел лә – нәселдә – безнең, ир-затларның берсендә дә юк ул чәч дигән нәрсә. Шулай да өйләнмичә калмаганнар. Бик акыллы булу галәмәтедер инде бу – чәч коелу, шулай диләр ич. Хәерчегә җил каршы, дигәндәй, җитмәсә, артист булып киттем бит әле. Өстәвенә атаклы кызлар ансамбле «Сөмбел»дә җырлап йөрим. Кызлар, пеләшлек килешми, диләр. Парик киеп җырларга кушалар. Язмыштан узмыш юк, бу кирәклекне инкарь итеп булмый, «ялтыравыкны» каплап, парик киеп җырлап йөри башладым. Югыйсә, башым болай да матур – йомры. Виртуознык кебек түгел. Үзе әйтмешли: «Безләр нишләр, чәчсез калсак – чүмәлә башлар!»

Аллам сакласын, чыннан да, ул пеләш калса – эше харап: утыз-кырык җөйле, ямау өстенә ямау баш, ярый әле чәченең куелыгы каплап тора ул кичергән язмыш сырларын. Җә, ярый, монысы аерым тема.

Авылым сабан туена бер кайтуымда да киеп куйдым бит мин бу парикны. Гадәтләнгән. Шуны кимичә җырлап булмый башлады. Мәйдан кырыенда

рәхәтләнеп моңланып, дуслар белән туйганчы сөйләшеп, күңел өчен генә, туган якның матурлыгы, халкының гүзәллеге, яшәүнең чамасыз ямьлелеге өчен бераз «тамак чылатып» алгач, мөлдерәп миңа карап торган кызга күзем төште. Сөйләшеп, читкәрәк, зиреклеккә кереп киттек. Яныбыздан челтерәп инеш ага. Көмеш суында елтыр-елтыр килеп балыклар уйный, янәшәдә генә ишетелеп торган Сабантуй музыкасына бииләр. Кыз минем җырлавыма, тавышыма соклануын дулкынлану катыш белдерде. Йөзе моңлы, керфекләре, иреннәре, каушаудан микән, дерелдиләр. Иягендәге сөйкемле чокыры, муенындагы бәләкәй генә миңе муенса төймәләренең дәвамы ителеп, әле кояшка да үрелеп карарга насыйп булмаган түшендә миңа карап тора сыман. Их, егетләр! Шунда кереп югалыр идем!

Мин, ирексездән, үз-үземне белештерми, кызны кочып, янәшәдә үсеп торган зирек агачына кыстым. Ул: «Нишлисез сез, җибәрегез, кеше күрер», – дип чәчемә ябышты. Башымда парик икәнлеге шунда гына искә төште. Кыз: «Гафу итегез!» – диде дә, зиреклектән чыгып, халык арасында югалды. Мин ул салдырып биргән паригымны тотып, нишләргә белми калдым.

Бу хәлне күрмәделәр микән, дигәндәй тирә-юньгә карыйм. Шаһитлар юк: күктә болытлар җыела башлаган, агачлар шаулый, инеш ага, балыклар качкан. Ниндидер яшел бака гына, «мин күрмәдем» дигәндәй, үлән арасына сикерде. Ачудан кулымдагы парикны бака сикергән якка томырдым да яңадан Сабантуйга, дуслар янына юнәлдем. Тормыш дәвам итә.

Бер еллап вакыт үтте. Авылда яңадан Сабан туйлары гөрләп узды. Теге кыз күренмәде, ләкин күңелдә аның якты образы һәрвакыт яши бирде. Көннәрдән бер көнне почтальон миңа таныш түгел кешедән хат тапшырып китте, шаккатырсың – теге кыздан. Мин аның исемен дә белми идем. Ләйлә икән. Хатында: «Теге вакыттагы хәл өчен тагын бер тапкыр гафу итегез! Сез һаман күңелемнән чыкмыйсыз. Быелгы Сабантуйга кайтырга батырчылык итмәдем, чөнки мин кунак кызы гына шул. Инде сезне бөтенләйгә югалттым, ахрысы», – диелгән иде. Үзе адресын язмаган. Оныткандыр. Бәлки, әле тагын язар...

Менә ул бер күрүдә мине оныта алмый икән. Бер күрүдә бит әле – минем шикелле, Сәбиләгә гашыйк булган кебек. Сәбилә хәзер кайда йөри, Кустанаена кайтып киткәнме, Казандамы? Җәйге еллар үтеп китсен инде – көзгә таба күрешергә насып булыр.

Авылдагы тормыш үз җае белән дәвам итте. Халык печәндә, бакчада. Инде җәйге ялымның соңгы көннәре бетеп бара. Шул арада, урман бете кадалып, авылның бер малае авырып китте. Менә бәла – ул хәтерсезләнеп калды. Беркөн моны бөтенләй югалттылар. Авыл халкы бер гаилә кебек бит – бөтен дөньяны бетереп эзләү башланды. Үлде микән әллә дигән фикерләр дә булмады түгел. Эзли-эзли җәфаланып беткәннән соң, көн азагына таба, Сабантуй үтә торган җирдән бер йомгак чәч табып кайттылар. Әлеге малайныкына охшаган – бакырсыман. Бөтен халык аптыраушта. Ничек болай булырга тиеш соң бу? Нүжәли?..

Күрше колхозның кукуруз басуын турарга киткән агайлар югалган малайны ияртеп кайтып керделәр. Ничек ул анда барып чыккан?.. Сөенечнең чиге юк. Шунда, кукуруз басуыннан чыга алмыйча, адашып йөргән. Арган. Йоклаган. Теге чәч йомгагын бер читкә атып бәрделәр дә, җиңел сулап, барысы да өйләренә таралыштылар. Мин китмәдем. Ныклап карыйм, әлеге дә баягы минем парик икән. Кызганып куйдым үзен. Инешкә төшеп, юып, селкеп, элекке хәленә кайтарып киптердем – кирәге булыр...

Паригым миңа ияреп яңадан Казанга кайтты. Гастрольләр, концертлар

яланбаш, йә түбәтәй, йә эшләпә киеп үтә. Парик – пенсиядә, кирәге юк. Ята шунда – шүрлектә.

Беркөн яныма дустым, атаклы баянчы Лимар Ашмарук килде. Аның белән, гомумән, еш күрешәбез. Килгән саен әлеге парикны киеп көзгегә карый. Ул – пеләшнең пеләше. Карый да:

– Күрәле, кордаш, унсигез яшь бит, ә! Нишләп безне Ходай каргаган икән? – дип уфтана.

– Ал үзеңә! – мәйтәм. – Киеп чык сәхнәгә!

– Нигәдер оялта...

– Күнекмәгәнгә ул, – мәйтәм, – бер күнексәң, салмассың да әле! Бүген Оперныйда концертың, на всякий случай ал үзең белән, кисәң киярсең, кимәсәң – юк.

– Әлфия Авзалова ни дип әйтер бит әле?

– Ә син аннан сорап торма!

Шундый фикергә килдек тә концертка киттек. Утырам карап, әнә Әлфия апа сәхнәгә чыга, әле баянчылары күренми, җырлый башлый:

Нихәл итим, гармунчыбыз,
Гашыйк булды үземә...
.....................................

Күрәсең, шулай уйланылган. Шул сүзләрне әйткәч кенә, баянчылар ике яктан уйнап чыгарга тиешләр икән. Чыктылар. Карыйм, Лимар кигән бит тегене. Әлфия апа яңадан баянчылар уйнаганга кушылып: «Нихәл итим...» – дип җырлап, Лимарга каравы булды... шып итеп туктады. Микрофонда актанышча «бәтәч» дигән сүз әйтелде. Бу матур гаҗәпләнү, ревер аша кабатлана-кабатлана, Опера театрының бөтен бизәкләренә сыланды. Халык беркавым өнсез торды... Һәм зал көчле алкышларга күмелде. Белмим, кайчан да булса Опера театрыбызда мондый кул чабуларның ишетелгәне булды микән?..

Шулай итеп, минем парик Лимар башында дөньяның күркәм сәхнәләренә гастрольләргә йөри башлады.

Соңрак Лимардан: «Аны урладылар...» – дигән хәбәр килде.

Кем башларында матурлык символы булып халкыбызга хезмәт итә икән ул хәзер?

***

«Сөмбел» ансамбленең концертлары өзелеп тормый. Менә тагын «КамАЗ»га чакырганнар. Сәбилә дә бара. Ни әйтсәгез дә, егетләр, әле һаман яратам мин аны. Армиядә ике көннең берендә төшемә керә иде. Кияүгә чыккан. Тормыш иптәше итеп компьютерлар белгечен сайлаган. Әллә шуңа тагын да ныграк борынын чөеп йөри дисәм ялгышамдыр, бәлки, миңа гына шулай тоеладыр. Мәхмүт барыбер аның күләгәсе... Ни җитми инде аңа – мин армиядә чакта үзе дә өйләнгән бит. Хатыны бик чибәр, Киноплёнка заводында эшли, уңган-булган дигәндәй...

Сәбиләнең ире гаять кырыс икән. Кызлар шулай сөйли. Машинасы белән ансамбльгә китереп куя, каршы ала. Тыгыз гәүдәле, озын буйлы, тик татарчасын юньләп белми торган чи татар, диделәр. Менә нинди ир кирәк булган икән аңа?!

«КамАЗ»да меңәрләгән тамашачы каршында чыгыш ясаганнан соң, Казанга кайтып төштек. Ноябрь ае. Киткәндә шактый җылы көннәр торса да, кайтып кергәндә, башкалабызда кар ява башлаган иде. Суык. Мин салкын тия күрмәсен тагы дип, башыма «КамАЗ»га барыр алдыннан алган яңа паригымны киеп куйдым. Ныграк җылыну өчен «Чулпан» ресторанына кердек. Кызларыбыз бу тәкъдимгә каршы килмәде, Сәбилә дә... Безне күргәч, рестрорандагы халык җанланып алды. Чүтеки данлыклы «Сөмбел» ансамблен күрәләр түгелме соң алар? Табыныбыз әллә ни мул булмаса да, бераз «тамызып» алгач, күңелләр йомшарып китте, эчкә җылы керде, Виртуоз Актанышев баянын тартып җибәрде, җыр таралды, биючеләр дә табылды. Безнең кызларның билләрен чит-ятлар коча башлады.

Урыслар да әрсезләнде. Берсе килеп, биергә теләмәгән Сәбиләне чакырып җилтерәтергә кереште. Сәбилә чыкмый. Теге һаман үҗәтләнә. Мин очып барып урыска күкрәк терәдем.

– Бесполезно! – мәйтәм, Сәбиләнең үзеннән отып калган коточкыч сүзен моңа акырып. – Она не хочет танцевать!

Урыс сугышырга маташа. Мин нәрсә, карап торырга тиешме? Үлсәм үләм, валлаһи манчыйм мин бу бәндәне!

Эш катлаулыга китәргә торганда, безне дуслар аерды. Тегенең дә яклаучылары бар икән. Төртешә торгач килештек – урамга чыгып бәрешергә! Шулай дип уйлавыбыз булды – без инде «Кольцо» мәйданында. Сугышырга тотындык. Кем кем белән туры килә – бүленешеп бәргәләшәбез. Бу тамашаны карарга дип безне халык сырып алды. Мин теге урыска портфель белән сылыйм, ә ул, миңа караганда остарак икән, күренеп тора – бокс белән шөгыльләнгән. Төя дә төя башны. Селки торгач, кулымда кәчтүмнәр тутырган портфельнең сабы гына калды. Чүтеки урыс шәп сугыша, үзем дә сабантуйларда батыр калган егет тә бит, ләкин теге биленнән алырга ирек бирми, тибенә дә әле. Урысның йодрыгы дөп-дөп башка тия, ләкин мин егылмыйм. Тагын дөп-дөп... Тагын, тагын... Нигәдер күз алларым караңгыланып китте – кич җиткән дип уйладым. Көндәшем шулчак, нигәдер, каршымда маймыл кебек читкәрәк сикерә башлады. Үзе миңа куркып карый. Шулай маймылланды-маймылланды да мәйданны читләтеп алган тимер читән аша сикереп чыгып, зур тизлектә үтеп баручы машиналар арасыннан әллә кая китеп югалды. Сугыш шып туктады, «дошманнар» каядыр качты. Минекеләр: «Нәрсә булды да нәрсә булды?» – дип сорыйлар.

Мәйтәм:

– Бернәрсә дә булмады, ул нигәдер качты?

Юньләп бернәрсә дә күренми. Әллә күзем чыкканмы дип пошаманга төштем. Юк, башымны теге дөмбәсли торгач, паригымның арты алга күчкән икән. Баш кабыгын куптардым бугай дип уйлагандыр ахрысы теге. Куркуыннан шылган. Искә төште, мин бит парикны салырга онытканмын. Әй көлештеләр дә инде шунда дусларым.

Байтак вакыт күгәргән күз төпләре белән йөрелде, әмма Сәбиләгә кагылдыртмадым...

Еллар үтә торды. Инде, соң булса да, укырга кергән институтымны тәмамладым. Укытучы булдым. Исемем халык арасына таралды. Урамга чыксам да таныйлар. Яраталар да бугай. Инде өйләндем дә. Ансамбль үз эшен һаман дәвам итә. Виртуоз булганда, әле ул бик озак халыкка хезмәт итәр. Кызларның да күбесе «башлы-күзле» булып бетте. Тик берсе, үтә

горур, борынын чөеберәк йөрүчесе – Әлфинур гына ялгыз калды. Ул Киров өлкәсендәге кайсыдыр район башкарма комитеты рәисенең гаҗәеп күркәм, чибәр кызы иде. Искиткеч көчле һәм матур тавышлы, беренче сопранодагы кыз. Аларның гаиләсе Казанга күчеп килгәч, әтиләре үлеп китте. Еш кунак була идек без аларда. Соңгы елларда, әнисе мине күргән саен:

– Әй, Зәбир, бик ярата идем үзеңне, киявем була алмадың, – дия торган иде.

– Якын килеп булмаслык иде бит, Гайшә апа, кызыңа! Кыргый, дип әйтимме?

– Зәбир җаный, өйләнгәнче әйтәсем калган үзеңә, буып сал син аны караватка, диеп. Инде ничә мәртәбә, кунакка чакыргач, икегезне дә эчертеп бергә яткырырга дип уйлап караган идем... Эчмисең бит...

– Рәхмәт, Гайшә апа, рәхмәт, шулай мине яратып сөйләвеңә! – дип кенә юата алдым аны. – Әлфинур чыннан да алтын кеше, язмышына шулай язгандыр, бәлки берәрсе туры килер әле – бар бит яхшы кешеләр.

– Балаларыгызны үзем карап, юанып яшәрмен дигән идем, – дип китеп барды шул соңгы очрашуыбызда Гайшә апа. Шуннан соң озак яши алмады инде.

Ансамбль туктаусыз юлда. Илебезнең без булмаган почмагы калмагандыр. Ул Себерләргә бару дисеңме, Урта Азия, чит илләргә чыгып керүләрне әйтәсеңме?..

Бервакыт Мәскәүдән поездда кайтып киләбез. Ансамбльнең иң көчле чагы. Кызлар барысы да элеккеләр, тәҗрибәлеләр, теләсә-нинди конкурста җиңеп чыгардай чаклары. «Космос» залында концерт биргән идек. Поезддагы урыннар плацкарттан алынган. Арылгангамы, һәркем үз эше белән мәшгуль: кемдер китап укый, кайбер кызлар үзләренә бәйләм эше алганнар, кайсы-берсе чәй эчә, йоклар өчен урын-җир көйләүчеләр дә бар. Минем урын Сәбилә белән янәшә туры килде. Ара-тирә аңа күз төшереп алам. Бала тапканнан соң бераз сулыккан кызый. Әллә гаилә тормышы җайлы гына бармый микән? Ишетәсе килмәсә дә, кызларның «чыш-пышы» кайвакытта ишеттергәли шул. Иренең чит-ятлар куенында кунып йөрүләре хак микәнни соң? Ышанасы килми, бу кадәр чибәр хатынны да санламагач, нинди кеше икән соң ул? Бар шул, бар Сәбиләнең йөзендә хәсрәт чаткылары. Әнә кызларның күбесе ирләренә минут саен телефоннан шалтыратып, хәл белешеп торалар. Ә аңа шалтыратмыйлар да, үзе дә телефонына үрелми. Кызганыч хәл. Мин түзмәдем, аның кулларына үрелдем. Каршы килмәде. Аннан соң, кыюлыгымны җыеп, күзләренә карадым, анда менә-менә тамам дип торган тамчылар җыела башлаган иде.

– Нигә мин сине шулхәтле нык яраттым икән, Сәбилә? Бармакларыңнан үптер, ичмасам? – дигәч, сул кулының никтер тумыштан үсмичә калган чәнти бармагына күзем төште. Ул кисәк сикереп торды да, үкси-үкси елап, тамбурга йөгерде, мин аның артыннан.

– Елама, Сәбилә!..

Ул елаудан туктар хәлдә түгел иде. Тамбурга кызлар йөгереп чыкты.

– Нәрсә булды да нәрсә булды? Нишләттең аны?

– Бернәрсә дә эшләтмәдем...

Үксүеннән чак туктап:

– Аның гаебе юк, – дип кенә әйтә алды Сәбилә.

Төнгә ул башка урынга күченде.

Ул кичне поездда Мәхмүтне югалттык. Сәгать төнге унбер – ул һаман юк. Виртуоз эзләтергә кирәк булыр дигән карарга килде. Монда Сәбиләнең хәле – хәл, җитмәсә монысы әллә кая китеп олаккан... Инде проводницага кереп, бу турыда хәбәр итмәкче идек – Мәхмүт пәйда булды. Күрше вагонда булган икән. Йөзендә ниндидер канәгатьсезлек, психлана, әллә бераз «тамагын да чылаткан» инде? Исе килә. Ярый, кайтты, шунысына рәхмәт.

Йокларга яттык. Минем күзгә йокы керми. Сәбилә дә боргалана бугай, стена аша шуны тоям. Нәрсәгә ул шулхәтле үксеп елады? Гаиләсендә бер-бер хәл булганмы? Мин әйткән сүзләр күңелендәге берәр ярасын кузгаттымы? Ярый, иртәгесе кичтәгедән зирәгрәк диләрме әле? Бик озак борчылып ятсам да, йокыга киткәнмен икән...

– Әй, торыгыз, Казанга җитәбез! – дигән тавышка уянып киттем. Кызлар күптән аяк өсте, юыналар. Виртуозның да тавышы ишетелә. Мәхмүт әле һаман башыннан бөркәнгән килеш ята. Аны төрткәләп торгыздык. Күзем белән Сәбиләне эзлим. Юк, ул минем якка карамый, урын-җирен җыя. Карале, мин аның йөзенә туры карарга куркам ич. Гафу үтенергә кирәк бит, ләкин бу гамәлем артыграк булыр сыман тоелды. Җә, ярый, берәр уңай вакыт табылыр әле...

Безгә юынырга чират җитмәячәген аңлап, юынмаган килеш кенә чемоданнарны күтәреп, вагоннан төшәргә әзерләндек. Менә поездның тәгәрмәчләре шыгырдап туктады. Состав соңгы юлга куелган икән. Кызлар вокзалга таба атлады. Ә безне КамАЗ машинасы артыннан өерелеп чыккан унлап егет төркеме чолгап алды.

– В чём дело, егетләр?

– Хәзер белерсез.

Күрше вагон тәрәзәсеннән проводница карап тора. Әлеге егетләрнең берсе шуннан сорый:

– Кайсысы?

Мәхмүт кызның җавабын көтеп бетермәде, КамАЗның подножкасына сикереп менде дә, кабинасына кереп бикләнде.

Кыз:

– Әнә, машина кабинасына кереп киткәне.

Виртуоз:

– Егетләр, без бернәрсә дә аңламыйбыз, в чём дело?

– Хәзер белерсез! – диде дә берсе минем корсакка пычагын батырды. Мин аңымны югалтып җиргә аудым. Калганын хәтерләмим.

Хастаханәдә аңыма килдем. Пычак тагын шул трос белән яра ясалган эзгә туры килгән икән. Йөрәктән түбән. Ярый әле ул урындагы кесәдә Сәбиләгә бирелергә тиешле унбишләп фотография булып, бирелмичә калган. Пычак шуларны тишеп, эчәкләргә әлләни зыян ясый алмаган.

Калганын болай аңлаттылар. Мәхмүт ул кичне, Сәбиләгә үч итеп, күрше вагондагы проводницага «мәхәббәт куертып» маташкан. Эчкәннәр. Проводница ярыйсы гына чибәр кыз – сүзгә килгәннәр. Мәхмүт кызны җәберләрлек сүзләр әйткән, һәм кызый, иртән поезд Казанга килеп төшүгә, үзенең бандитларын чакырган. Нәтиҗәсе менә шул, мин җиргә егылгач, тегеләр качып беткәннәр. Әлбәттә, аларны проводница аркылы таптылар. Ләкин Мәхмүтнең этлеген миңа татырга туры килде.

Килде ул яныма, хастаханәгә, гафу үтенде. Барысы өчен дә: ике мәртәбә микрофонны сүндерүче дә ул булган икән – аны да әйтте.

Бу вакыйгадан соң озак яши алмады Мәхмүт якты дөньяда. Көнчелеге эчтән ашады аны. Ә башка яклары белән әйбәт кеше иде бит, югыйсә.

Еллар арты еллар үтә торды. Инде «Сөмбел» ансамбле дә юк. Атаклы баянчыбыз Виртуоз Актанышев та вафат. Ә мин әле эстраданы ташларга исәпләмим. Кайбер төркемнәр, җырчы кирәк булгач, үзләренә чакырып торалар. Гастрольләр җитәрлек. Тамашачым да әле онытмый.

Күптән түгел генә филармония залында иҗат кичәм узды. Анда Сәбилә дә килгән иде.

– Менә, Зәбир, бу минем әтием, – дип әтисе белән таныштырды.

Әтисе дә:

– Беләбез, беләбез, телевизордан без аны бик яратып карыйбыз, – диде.

Аннан соң минем 50 яшьлек юбилеемда да Сәбиләне күрергә туры килде. Монысында инде әнисе белән дә таныштырды. Әнисе:

– Шушымыни инде ул, Зәбир? – дигән булды шаяртып.

– Әйе, – мәйтәм, – «Сөмбел» ансамблендә Сәбиләгез белән җырлап йөрдек.

– Беләбез, беләбез, Зәбир, бик яхшы яктан беләбез сине. Сәбилә сөйләде.

– Рәхмәт, апа! Яхшы кыз үстергәнсез!

– Яхшысын яхшы, тик менә...

Сәбилә әнисенең касыгына төртте. Ана кешенең сүзе ярты ачылган иреннәрендә эленеп калды. Сәбилә үзе дәвам итте:

– Ярый, Зәбир, без китәбез, тагын кайчан була концертың?

– Бу араларда юк әле.

– Без килербез.

– Килегез, кил!..

Бу вакыйгалардан соң тагын байтак вакыт үтте.

Беркөн тукталышта кузгалып баручы автобуска сикереп мендем. Күрәм, сул яктагы утыргычта ул:

– Ай, Сәбилә, синме бу?

Шулчак Сәбилә кулларын тиз генә сумкасы астына яшерде.

– Зәбир!

– Танып буламы әле?

– Бер дә үзгәрмәгәнсең, Зәбир, һаман шул килеш!

– Рәхмәт. Ничек кенә мактасаң да, узган гомере кеше йөзендә һәм йөрәгендә сырлар калдыра инде ул, Сәбилә.

– Шулай. Син хәзер төшәсеңме?

– Төшәм шул... – дидем мин, уфтанып.

– Телефоныңны әйт әле. Йомышым бар иде...

– Рәхим ит: 89172961505.

Мин кузгалып киткән автобусның артыннан карап калдым. Әкрен генә сибәләп ява башлаган яңгыр тамчылары, аның күз яшьләре белән кушылып, пыяла битеннән агалар иде... «Эх, Сәбилә, Сәбилә, бармакларыңнан үбәр идем!..»



*Классик әдип Гомәр Бәширов «Җидегән чишмә»нең
күтәп алынган кунагы иде.*




*Шагыйрь
Хәниф Хөснуллин
(1935-1994).*



*«Җидегән чишмә»нең чираттагы кичәсеннән соң. Уңнан сулга: Рахмай Хисмәтуллин,
Николай Кузнецов, Равил Фәйзуллин, Мәсгут Сибгатов, Әхмәт Гадел, Наил Нуретдинов. 1978 ел.*



*Түбән Камада Казан шагыйрьләре белән очрашу мизгеле. Сәхнәдә шагыйрь Рахмай Хисмәтуллин (уңда) һәм Әхсән Фәтхетдинов. 1978 ел.*




*Фәнзаман Баттал һәм Зөлфәт Хәким уртак тел тапканнар. 1991 ел.*



*«Кама таңнары» әдәби берләшмәсенең иң актив әгъзалары.*

# БУ ХЫЯЛЛАР НИГӘ ЯКТЫ ДИСӘҢ...

ОЧЕРК



Түбән Кама шәһәренә беренче тапкыр аяк баскан кеше яшеллеккә күмелгән урамнарга, матурлыгы белән күзне камаштырган дүрт манаралы Җәмигъ мәчетенә, Тукайның әкият геройлары белән каршы алган гаҗәеп ял паркына игътибар итми калмый. Сөембикә, Бакый Урманче, Чишмәле, Ямьле, Чулман урамы дигән исемнәр дә колакны иркәли кебек. Кечкенә генә, җыйнак кына булып утырган бу каланың үз йөзе бар. Ул йөзне кем матурлый, кемнең якты уй-хыяллары соклангыч чынбарлык булып чагыла – күпләр үзенә бу сорауны биреп тә тормыйдыр.

«Архитектор – иң-иң шәп профессия ул». Юк, бу минем сүзләр түгел. Гомере буе шул өлкәдә эшләп, Татарстан Республикасының, Россиянең атказанган архитекторы исемнәренә ия булган **Фирдәвис Гайнетҗан улы Ханов** шулай ди. Менә кырык елга якын ул Түбән Камада, шушы бер генә урында хезмәт куя. Шәһәрнең һәр сукмагы, һәр тыкрыгы, кул изәп калган һәр агачы, һәр йорты аныкы, үзенеке, үз, җанына якын.

***

Нинди генә язмага тотынсам да, үз героемның нәсел-нәсәбе белән кызыксынмый калмыйм мин. Алдан ук сиземләвем беркайчан да алдамый: булдыклы, уңган затларның нәсел тамыры иманлы әби-бабайларга барып тоташа.

Фирдәвис абыйның әнисе Һидая апа ягыннан бөтен токым – муллалар нәселе, Әбелхарис бабай – Уфада укып, Риза Фәхретдиннең үз кулыннан таныкнамә алган, аның хәер-фатихасы белән Актанышка хәзрәт итеп җибәрелгән кеше. Шул ук вакытта андый зыялы, укымышлы затларны кирәксенмәгән дәүләтнең чираттагы корбаны да... Ул замандагы бик күпләрнең ачы язмышын кабатлап, чор тегермәнендә иләнгән, тузанга әйләндерелгән, юкка чыгарылган, әмма барыбер затлы тамырын калдырырга өлгергән татар ире. Әнә бит, кызы Һидаяга гына кара – гарәп графикасында да рәхәтләнеп укыган-язган, латинга күчкәч, шул рәвешчә дә, аннан инде, татарны асыл мирасыннан, тарихыннан аерган кириллица дигәннәре килеп кергәч, ул язуны да үзләштергән, алай гына да түгел, башкаларга да өйрәткән гап-гади авыл баласы. Зур-зур университетларда уку бәхете тәтесәме?!. Әтисе Әбелхарисны кулга алгач, тентүгә керүчеләр өйдәге бар китапны урам уртасына чыгарып өяләр. Юл аркылы гына яшәүче, җир идәнле өйдә көн күрүче гаилә рәхәтләнә генә – әлеге китапларны үзләренә ташып, такта урынына идәнгә түшиләр. Һидая исә, кырыкмаса кырык сәбәп табып, аларга кереп йөри. Кергән саен, әтисенең җан ярасы, йөрәк җылысы булып яткан

китапларның берсен булса да эләктереп чыгарга тырыша. Кызның күңелендә: «Әткәй кайтуга, бөртекләп булса да җыела торсын әле», – дигән самими уй бөтерелде микән? Тик ул чакта бер киткәннәрнең кире кайтуы гына ай-һай... Нурдидә абыстай, төпчек улы Нәсихне җитәкләп, Актаныштан Минзәлә төрмәсенә кадәр җәяү бара – күчтәнәчне алып калсалар да, ире белән күрешергә рөхсәт бирмиләр. Әй шул чакта Нәсихнең елаулары... Икенче тапкыр килгәч, «передача»ны да алып тормыйлар – Әбелхарисны Казан төрмәсенә күчерелде, диләр. Бу аерылышуның гомерлеккә икәнен Нурдидә абыстай сизенми калмагандыр, башын иеп Актанышка кире җәяү юл totканда, «ни өчен» дигән бер соравына мең җавап эзләгәндер, таба гына алмагандыр. Кайда, кайчан, ни рәвешле юк иткәннәр аның газиз ирен, балаларының газиз атасын – бу сорауның җавабы да хәзергәчә җиде кат сер астында кала бирә...

Еллар үтеп, билгесезлек пәрдәсе күтәрелә төшкәч, талап алынган байлык өчен дәүләт беркадәр компенсация түли түләвен. Әнкәсе Һидаяның ул тиеннәрне күз яшьләрен сөртә-сөртә, «бабагыздан, сезнең өлеш», дия-дия, балаларына, оныкларына таратканын Фирдәвис абый яхшы хәтерли. Гаиләнең малы да, гаилә башлыгының гомере дә әнә шул тиеннәр белән бәяләнә...

Инде үзе әни кеше булып, пар канаты – Гайнетҗаны белән өй тутырып бала үстергәндә, Һидая апаның гыйлем хәзинәсе, тел йозагы астында сакланган сагышы, күңел моңы, күңел матурлыгы нарасыйларына күчә: Хәмдиясе, Мөдәррисе, Фирдәвисе, Дифинәсе, Гөлсинәсе, Фәрүсәсе һәммәсе эшкә уңган, төскә булган... Фирдәвисе бигрәкләр дә укуга һәвәс, рәсем төшерергә дә кулы килешеп тора.

– Авыл йортында эш тавык чүпләп бетермәслек бит инде ул, шулай да, мин укуга сәләтле булгач, артык эш кушмыйлар, ә менә Мөдәррис абыйга эләгә иде... Әнкәй миңа рәсем ясарга бирә иде. Акбур белән дә, күмер, карандаш белән дә ясыйм. Бервакыт чегәннәр авыл буйлап келәм сатып йөрделәр, әнкәй берне сатып алды да миңа да шундыйны ясарга кушты. Чүпрәкне таякка тарттырдым да, әнкәй теләгәнчә, үзебезнең күлләрне, аккошларны, казларны төшереп, буяу белән картина ясап куйдым. Стенаның бер ягында – чегән «картинасы», икенче ягында минеке эленеп торды, – дип балачак хатирәсен яңарта Фирдәвис абый. – Туган авылым Актанышбашта башлангыч мәктәп кенә иде, аны тәмамлагач, Актанышка йөреп укыдык. Авыл башында Изгеләр зираты дип йөртелгән иске зират бар, шуның янында бер-беребезне көтеп торабыз да, җыелышып беткәч, кыр казлары кебек тезелешеп, Актанышка китәбез. Юлда туктап, ял да итеп алабыз. Мине «Художник» дип йөртәләр иде, чөнки мәктәптә биш-алты ватман кәгазе ябыштырып ясалган су буе стена газетасын бизим. Рәсем дәресендә укытучыбыз, сыңар куллы Энгель абый да мине кыстый-кыстый рәсем ясата: портрет төшерәм, открыткалардан чәчәкләр күчерәм, укытучым кушканча, торналар, куяннар ясыйм... «Художник» кына түгел, «Бөрлегән малае» дигән кушаматым да бар иде әле...

Монысының – үз тарихы. Әнкәсе, инде бала табар вакытым җиткән дип тормый – елдагыча, сентябрь аенда бөрлегәннән кайтып керми. Беркөнне, хатын-кызлар белән җыйнаулап бөрлегәнгә киткәч, кинәт кенә тулгагы башлана. Ахирәтләре аны күтәреп, көч-хәл белән Әҗәкүл авылына кайтарып җиткерәләр, бер әбинең йортында Фирдәвис дөньяга килә. Аннан соң ул Кендек әби Гайнетҗан абыйлар йортында һәрчак кадерле кунакка әверелә. Ә менә малайга «Бөрлегән малае», «Бөрлегәндә туган» дигән кушамат берегеп кала.

Таш стена арасында түгел, табигатьнең үзендә аваз салырга ашыккан малай күңеленә ак болытлар аклыгы, болыннар киңлеге, урманнар сере, йолдызлар хыялыйлыгы күчте микән әллә? Җырлап торган күңел бу кадәр гел матурлыкка тартылмас иде... Җанда бөреләнгән хыял да бүтәннәрнекенә охшамаган: рәссам булырга! Бары тик рәссам!

– Мәктәпне тәмамлап, рәхәтләнеп ял итеп алгач, пароходка утырып, Казанга чыгып киттем. Ният – бары тик сәнгать училищесына керү, бары тик художник булу бит инде. Вестибюльдән җил-җил атлап кереп барганда, туктатып: «Сез кая?» – диләр. Минәйтәм, как кая – укырга кирәк... «Соңга калдыгыз, инде өченче имтихан бара»,



*Түбән Каманың йөз күрке – Җәмигъ мәчете. Архитекторлары – Ф.Ханов, Р.Макуев.*

дип ушны алдылар... Утырып килгән пароходым кич белән кире Уфага китә иде – шуның белән авылга юл тоттым. Бөтен план җимерелгән, елыйсы килә. Чөнки башта шушы бер генә хыял бар иде. Иртән ишегалдына кайтып кердем, әнкәй сыер савып утыра. Кыяфәттән күренгәндер инде: «Нәрсә, улым?» дип ике генә сүз әйтте... Вузга керергә теләүчеләр өчен справочник бар иде өйдә – шуны яхшылап актара торгач, КИСИда (төзелеш институты) архитектура факультеты барлыгын, анда керү өчен рәсемнән имтихан бирергә кирәклеген күреп алдым. Кем ул архитектор, нишли – аны белү юк, рәсем булгач рәсем бит! Ничек кермәскә ди, гомер буе художник булып йөр дә... Канатланып тагын Казанга киттем дә... рәсемнән имтихан биргәндә «жирный икеле» алдым. Авыл баласы аның бөтен тәртибен каян белсен, сәнгать мәктәбендә укып килгәнме...

Барлык юллар да Римга илтә, диләр бит... Ул Казанны барыбер алачак әле, тик бераздан, берничә елдан... Әлегә – әнисе ягыннан туган тиешле апасының: «Авылга кире кайтып нишләрсең? Монда заводка эшкә кер, кич курсларда укырсың», – дип акыллы киңәш бирүе яшь егетнең тормыш сукмагын үз юлында калдыра. Казанның фотожелатин заводында слесарь өйрәнчеге булып эшли башлаган Фирдәвис, үҗәтләнеп, бөтен курсларга йөрергә тотына, спорт белән шөгыльләнергә дә вакыт таба (самбо буенча спорт мастерлыгына кандидат титулы да бар!), завод рәссамнары яныннан кайтып керми, алардан бик күп нәрсәгә өйрәнә. Әлеге тырышлыгы бушка китми, армия хезмәтендә дә терәк була: ни әйтсәң дә, штаб рәссамының тормышы гади солдатныкыннан күпкә аерыла. Якутиядә, штабта ике татар егете – берсе Казаннан, икенчесе Актаныштан – гөр килеп татарча сөйләшәләр... Армиядән кайткач та, егет үзенең хыялларыннан ваз кичәргә уйламый: шул ук заводта бишенче разрядлы слесарь булып эшләгән җиреннән әзерлек курсларына йөри башлый, нияте – КИСИны барыбер буйсындыру. Буйсындыра да. Икенче елны, имтиханнарның бөтенесен «бишле»гә генә тапшырып, студент булу бәхетенә ирешә. Шунысы кызык: мәктәп кенә бетергән яшел авызларны – бер төркемгә, ә Фирдәвис кебек акыл утыртып, тормыш тәҗрибәсе туплап килгәннәрне аерым төркемгә җыялар. Һәм ул төркемдәгеләрнең барысы да диярлек, институт бетергәч, сайлаган һөнәрләренә тугры калып, архитектор булып китә...

Ә ул чак – яшьлек дәрте, яшьлек романтикасы белән тулы чак. Яллар җиткән саен, күңелне җилкендергән пятачоклар... Мәктәп елларыннан ук гармунны юлдаш иткән Фирдәвис ул кичәләрдә күз өстендәге каш кебек. Гармун уйнарга өйрәнүе дә үзе бер вакыйга булып истә калган:

– Минем әткәй гомер буе амбарда хуҗалык мөдире булып эшләде, көне-төне накладнойлар белән утыра торган иде. Ничәмә-ничә колхоз рәисе алышынды – гадел, намуслы булганга, әткәйне берсе дә эштән алмады. Әткәй – сугыш ветераны, Ленинград фронтыннан яраланып кайткан. Күргәннәрен бер дә сөйләми иде. Уң як калак сөяге астына пуля кергән, мунча кергән саен, әткәйнең аркасына «авыртмый микән», дип кызганып карый идем... Аның дусты – сугышта бер аягын югалткан Гаяз абый бар иде, икесе дә гармун уйнарга кызыкканнар болар. Шабашка акчасына икесенә бер хромка сатып алганнар. Гаяз абыйның бармакларын күрсәң – бүрәнә юанлыгы диярсең... Гармунның ике теленә берьюлы баса икән. Шуннан, булмаслыгын аңлап,

гармунны әткәйдә калдырган. Әткәй, пыр туздырып уйнамаса да,ипле генә, ятышлы гына уйный иде. Бишенчеме, алтынчымы класста укыганда, мәктәптән малайлар белән сикерешеп кайта идек, егылып, умрау сөяген сындырдым мин. Байтак кына өйдә ятарга туры килде, шулчак гармунның бер ягында уйнарга өйрәндем. Әткәй бер көйнең аккордларын өйрәткән иде, шатлыгымнан йоклый алмый яттым ул төнне... Икенче елны, шаярып кайтканда, тагын умрау сөяген сындырдым. Бу юлы башка ягын. Өйдә инде икенче кул белән гармунның икенче ягын шыгырдатам... Шул вакытларда башта хромкада, аннан баянда абый белән бергәләп җыр-бию көйләрен уйнарга өйрәндек. Безнең авылда гармунчылар күп иде, клубка чыккач, гармунның бушаганын көтеп кенә торалар...

«Гармунчы булсын ярың», дип җырларда гына җырланмый. Апас кызы Розалияне дә шушы гармун моңнары үз дулкынына урап алгандыр әле. Студентларның бик күбесен әнә шул пятачоклар табыштырып-кавыштырып куя да инде – яшьләр соңгы курста укыганда, гөрләтеп туй ясыйлар. Уртак хисләр, уртак оя, уртак хыяллар...

Әнә шул хыяллар яшь гаиләне 1978 елда Түбән Кама шәһәренә алып килә. Фирдәвисне иң кызыктырганы – беренчедән, туган якларга якын, икенчедән, килүгә үк өлкән архитектор урыны, тиз арада бер бүлмәле фатир тәкъдим итәләр. Бирегә киләм дип ашкынып торучылар юк, чөнки халык телендә «зеклар шәһәре» дигән атамасы йөри... «Эшләп карыйм әле, бәлки кире дә китәрмен», дигән уйлар белән аяк баскан егет шушында төпләнеп калырбыз, балалар, оныклар үстерербез дип күз алдына китермәгәндер... Яшьләр башта Фирдәвиснең армиядә бергә хезмәт иткән дусты янында яшәп торалар. Ай үтүгә, үзләренә бер бүлмәле фатир бирәләр. Ни дисәң дә, Казанның кеше почмагында яки тулай торак бүлмәсендә яшәп яту түгел инде!

Яшь архитекторны эш дигәннәре колач җәеп көтеп торган: ничә еллар ташландык яткан тимер юл вокзалын бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек итеп үзгәртеп ясарга кирәк. Бу объектның эшен төгәлләгәнче күпме йокысыз төннәр узгандыр... Эш урынында, повидлолы пирожки белән генә тамак туйдыра-туйдыра, төн уртасына кадәр тоткарланулар... Ташландык ике катлы бетон бинаның уңайлы, заманча автовокзалга әверелүе яшь белгечкә карата ихтирам уята, үз һөнәренең остасы икәнен раслый.

Аннан инде – биш йөз кешелек залы булган Җәмигъ мәчете төзелешенә тотыну. Ул чакта әле шәһәрдә дипломлы дин белгечләре дә юк; мәчетнең эчен ничек бизәргә, анда нииндирәк җиһазлар булырга тиеш – андый белгечләр дә тезелеп тормый. Фирдәвис абый, Уфага барып, барысын да җентекләп өйрәнеп кайта. Алай гына да түгел, гарәпчә рәхәтләнеп яза белгән энисе алдында оят дип, үзе дә гарәп графикасын өйрәнә башлый.

Язылышу сарае да бүген Түбән Каманың гына түгел, республиканың мактанычы булып тора. Элекке тар, кысан бина урынына зәвыклы һәм романтик бизәлешкә, үзенчәлекле проектка ия мәһабәт сарай калкып чыга.

Җәен гөрләп Сабан туе үтә торган «Ильинка» мәдәни-күңел ачу үзәге дә – архитекторның һәм төзүчеләрнең гаҗәеп иҗат җимеше. Хәер, мондый хезмәтләрне берәмләп барлый башласаң, бөтен һәйкәлләрне, Мәңгелек утны, фонтаннарны, паркларны, гомумән, ярты шәһәрне санап чыгарга кирәк булыр иде. Фирдәвис Ханов юкка гына 2004 елда Россиядә уздырылган профессиональ осталык конкурсында «Иң яхшы архитектор» исеменә лаек булмый! Җан җылысын кушып эшләгәнгә күрә, аның хезмәте үз бәясен ала.

Шәһәр үзәгендәге Тукай паркы кемнең генә игътибарын җәлеп итмәс?! Һәрберсе аерым һәйкәл булып «терелеп» баскан Шүрәле, Су анасы, Кәҗә белән Сарык кебек геройлар, китап битләре, ачык сәхнә олысын-кечесен үз янына тартып торучы әдәби бер учакка әверелгән.

– Тукайның һәйкәле 1993 елда ук ачылган иде, шуннан бирле мин монда кайда нәрсә булачагын хыялда күзаллап, берәм-берәм кәгазьгә төшерә бардым. Тик барысы да финансларга килеп терәлә бит... Әзер проектны 2012 елда Мәскәүгә конкурска алып барган идем, «Иң яхшы проект» дипломы алып кайттым, бу хезмәт, иң яхшы



*Тукай паркы – Түбән Каманың гына түгел, республиканың горурлыгы. Проект авторы – Фирдәвис Ханов.*

эш дип, каталогка да керде. Бирим дигән колына – чыгарып куяр юлына дигән шикелле, былтыр Парклар һәм скверлар елы булды бит, шәһәр башлыгы Айдар Рәис улы Метшин үз янына чакырганда, мин инде шушы әзер проектны тотып кердем. Менә шулай, вакыты бик җайлы туры килде, паркны тиз арада матурлап сафка да бастырдык, ул Татарстанда иң яхшы парк дип бәяләнде. Менә быел Кама яр буен төзекләндерү буенча бик зур эш башлап җибәрдек, монда да елның исеме уңайлы туры килде... 2013 елда ук, пляж зонасы проекты белән Мәскәүдә халыкара конкурста катнашып, диплом алып кайткан идем. Быел да шәһәр башлыгы янына әзер эшне тотып кердем. «Нишлибез, нинди тәкъдимнәр булыр?» диюгә, «Миндә инде барысы да әзер», дигәч, ул ышанып та бетмәде, планшетны ачып күрсәттем. Хәзер менә яр буеннан кайтып кергән юк, республикадан акча бирелгәч, анда эш кайный. Елга эчендә зур фонтан булдыру күздә тотыла, шәһәр халкы өчен бик матур, уңайлы, заманча ял итү үзәге булыр дип өметләнәм.

Озак еллар шәһәрнең архитектура һәм төзелеш идарәсе җитәкчесе булып эшләгән, аннан китеп, берара район башлыгының киңәшчесе вазифасын да башкарган, бүгенге көндә янә элекке хезмәтенә кайткан Фирдәвис абыйны мин үзем тынгысыз бал кортына охшатам. Гел эзләнүдә, гел хезмәттә... Түбән Камада инде озак еллар Актаныш якташлар җәмгыятен җитәкләүче, зәвыклы кичәләр үткәреп, якташларына бәйрәм бүләк итүче дә әле ул. (Сүз уңаеннан шунысын да әйтик: бу җәмгыять Актаныш районы җитәкчелеге белән даими элемтәдә тора. Нинди генә чара үткәрелмәсен, аралашып, кулга-кул тотынып эшлиләр.) Туксанынчы елларда милли хәрәкәтнең күтәрелеш чорында актив катнашкан милләтпәрвәр шәхес тә. Шунысы гаҗәп: иҗтимагый үзәк белән җитәкчелек икесе ике якта калгандай тоелса да, администрациядә эшләгән Фирдәвис абый алтын урталыкны таба белә. Бервакыт, милли хәрәкәттәге утызкырык кеше ниндидер дәгъва белән мэрия ишеге төбенә килгәч, ул чактагы шәһәр мэры И.Р.Метшин: «Бар, синекеләр килде, чык, сөйләш», – дип, Фирдәвис абыйны шунда чыгарып җибәрә. Күңеленә «эштән дә куар», дигән шик йөгерсә дә, ишеккә күрсәтүче булмый булуын.

– Милләт дип кычкырып йөрү бер нәрсә, үзеңдә шул рух булырга тиеш. Без гаиләдә гел татарча сөйләштек. Бервакыт балаларның класс җитәкчесе, марҗа хатыны: «Сез, мөгаен, өйдә татарча сөйләшәсездер? Сөйләшмәскә тырышыгыз, телләрендә сизелә», – дигәч, әй ачуым килде. «Сез нәрсә, әллә өйдә үз телебездә сөйләүдән тыймакчы буласызмы?» – дип ярсып киттем... Улыма да, кызыма да гел әйтә килдем: башка милләт кешесенә күзегез төшсә, карагыз аны, ди идем. Балаларым йөзгә кызыллык китермәде. Улым минем сукмакны сайлады, дисәм дә була, ул дизайн өлкәсендә эшли.

Хәзер инде елмаеп һәм тыныч күңел белән әйтелсә дә, бу сүзләр артында күпме тәвәккәллек, ныклык, үз телеңә, милләтеңә никадәр хөрмәт ята! Кызы Айгөл дә, улы

Марат та, оныклары Әминә белән Кәрим дә – Фирдәвис абыйның төп горурлыгы. Иңне иңгә куеп гомер кичергән Роза-Розалиясе исә – сабырлык үрнәге.

– Авыр мәлләр дә булмады түгел... Эш-эш дип йөгергәндә, вакыт белән исәпләшеп торулар юк бит. Җитәкче булып эшләгәч, соңга калып кайткан чаклар була, сәгатьне оныткан... Андый чакта үзеңне үзең беләсең, акланып маташмыйсың – сине гаепле итеп күрсәтәләр икән, «әйе, әйе, соңга калдым», дип ризалашасың инде. Шуннан зурга китми... Өйдә дә төн уртасына кадәр эшләп утырганда, хатыным чәй күтәреп керә, аннан әкрен генә чыгып китә иде, – дип татулык сере белән уртаклаша Фирдәвис абый. Аның: «Алдаган кешене яратмыйм!» дию тормыш девизы кебек яңгырый.

Кыска-кыска җәһәт сорауларга җавап алганда, кешеләрнең эчке дөньясы ихласлыгы һәм еш кына көтелмәгән яклары белән ачылып китә. Язмам герое, сүз уңаеннан, Һади Такташ иҗатына хөрмәт белән каравын да җиткергән иде, үзенә күрә бер сере бар икән: нәсел шәҗәрәсен ясатканда, Такташның икенче хатыны Гөлчирә Мансурованың Фирдәвис абыйга әбисе ягыннан туган булуы ачыклана. Шагыйрь Актанышның ак каеннарына гашыйк булса, Фирдәвис абый яшькелт төскә мөкиббән. Гармунының әле дә кулыннан төшкәне юк, «Язлар җиткәч кайтырмын» дигән җыр – күңеленә иң якыннардан.

«Сайлаган һөнәрегездән туйган, башка эш табарга теләгән чакларыгыз булмадымы?» – дип соравыма Фирдәвис абыйның җавабы әзер һәм кискен икән.

– Юк! Башыма да килмәде! Архитектор – иң-иң шәп профессия ул. Рәссамнан аерыла! Сүз дә юк, рәссам – ирекле кеше, үзенә-үзе хуҗа. Яшәү, киенү рәвеше дә башка. Архитектор үзгәрәк... Бөтен күренешне нәсеннән җебенә кадәр алдан ук күз алдына китерәсең. Материалы нинди булыр, төсе. Кай урында агач утыртылыр. Кеше бу объектка җәяү киләчәкме. Эскәмияләрне кая урнаштырырга. Машина белән килгән очракта, кайдан, ничек борылырга, машинаны кая куярга... Менә шундый сораулар бөтен ваклыгына кадәр күз уңында тора, аларның бөтенесе әһәмиятле. Эшләгән эшең матур да булсын, кешеләргә файда да китерсен.

***

Мәктәп елларында Муса Җәлилнең:

*Син яшәмә җирдә файдасыз бер*
*Түмгәк булып тигез урында.*
*Янып калсын гомрең маяк булып*
*Үзеңнән соң килер буынга, –*

дигән шигъри юлларын фәлсәфәсе турында баш ватмый гына ятлап куябыз. Аңлау еллар узгач килә: чыннан да, кешеләргә кирәкле, файдалы булып, гомер сукмакларын матурлыкка омтылып һәм шул матурлыкны үз кулларың белән тудырып яшәү – җан асрау түгел, чын-чынлап Яшәү дип аталырга хаклы. Фирдәвис Ханов яраткан җырдагыча, кошлар кебек талпынып, ташкын кебек ашкынып, җитез җилләрне узып, тормыш матур булсын дип яшәү иңнәргә хыял канаты куя. Якты хыяллар исә дөньяны да яктырта...

**Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА**

# «ҖИДЕГӘН ЧИШМӘ»ЛӘРГӘ ЙӨЗЕК САЛДЫМ...

Яшьлек каласы Түбән Камада шушы шигъри исем белән аталган әдәби-музыкаль берләшмә оештырырга безне халкыбызның теле, мәдәниятенең киләчәге өчен җаннарыбызның әрнүе этәрде. Әлеге гамәл гасырлардан мирас булып килгән борынгы җырларыбызны, җәүһәрләрдән дә кыйммәтле рухи байлыкларыбызны югалтмас өчен, алар белән яшьләрне таныштыру максатында эшләнде.

Мәшһүр галимебез Шиһабетдин Мәрҗанинең «Үткәнен белмәгәннең – киләчәге юк» дигән, пәйгамбәр хәдисләренә тиң сүзләре безне шанлы тарихыбызны онытмаска, күренекле шәхесләребез белән горурланырга, яшьләребездә дә шундый ук хисләр тәрбияләргә кирәклеген искәртте.



*Күренекле шәхесләр С.Садыйкова һәм Г.Бәширов белән очрашудан соң. 1983 ел*

1981 елның 13 декабрендә зур тантана белән аксакал шагыйребез Сибгат Хәкимнең җитмеш яшьлек юбилей кичәсе үтте. Олуг шагыйрьнең җырлары, шигырьләре белән әсәрләнгән зал кичә ахырында, шәһәр тарихында беренче мәртәбә аягүрә басып «Туган тел»не җырлады. Җыр белән бергә гасырлар буе кимсетелү аркасында канга сеңгән месkenлек кебек авыр тойгылар да юкка чыкты сыман. Аларны озак еллар дәвамында буылып торган хөрлек, милләтең белән горурлану хисләре алыштырды. Ихтыярсыз күпләрнең күзләре дымланды. Бу көн «Җидегән чишмә» туган көн булып тарихка кереп калды.

Берләшмәбезгә исем бирер өчен халык җырлары күп иде, әлбәттә. «Салкын чишмә», «Фазыл чишмәсе», «Бер тауда ун чишмә»... Шәһәребезнең тирә-ягын да чишмәләр чолгап алган: «Чургат» (Красный ключ), «Актүбә», «Чәбия» чишмәләре, посёлоктагы исемсез чишмәләр... Әмма халкыбызның рухи байлыгы хәзинәләренең: җыр ләйсәннәре, шигърият чишмәләре, театр нурлары, сәнгать бизәкләре, тарих моңнары, бию очкыннары, төрле уен үрнәкләре кебек тылсымлы җиде тармагына туры килерлек дип нәкъ менә «Җидегән чишмә» җырына туктaлдык. Һәм ялгышмадык дип уйлыйм.

Режиссёр Наил Нуретдинов, музыкант Флүр Гайнемөхәммәтов, язучы Рахмай Хисмәтуллин кебек энтузиастлар башлап җибәргән игелекле гамәл иде бу. Ә инде аның эшчәнлегенә Азат Зыятдинов, Мәсгут Сибгатов, Шәмси Закиров, Мөнәвир Галимуллин кебек шәһәребезнең хөрмәтле кешеләре дә кушылгач, ул тагын да күтәрелеп китте, масштаблар киңәйде, тора-бара республикабыздан читтә дә танылу алды. Безнең бу кичәләрдә халкыбызның күренекле ул-кызлары – Гомәр Бәширов, Сара Садыйкова, Бакый Урманче, Әмирхан Еники, Әбрар Кәримуллин, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Фәридә Кудашева, Илһам Шакиров, Бәхти Гайсин, Зилә Сөнгатуллина, Марсель Сәлимҗанов, Фәрит Мөхәммәтшин, 1941-1945 еллардагы Ватан сугышында татарлардан иң беренче Советлар Союзы Героена лаек булган якташыбыз Илдар



*Татарстанның Халык язучысы Туфан Миңнуллинның юбилей кичәсеннән соң. 2011 ел.*

Маннанов, Татарстанның һәм Башкортстанның халык шагыйрьләре Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Нажар Нәҗми, Мостай Кәрим һәм башка бик күп, һич арттырусыз, милләтебезнең алтын баганаларын тәшкил итүче шәхесләр белән очрашулар безнең күңелләрдә мәңге җуелмас хатирә булып калды. Яшьләребез сиксән сигез яшьлек Бакый ага Урманче башкаруында музыкасыз-нисез халкыбызның борынгы «Randall Фәхри» җырын тыңлау бәхетенә ирештеләр. Алма-Ата шәһәрендә яшәүче ике бертуган: берсе – Казакъстанның, икенчесе СССРның халык артистлары Рәшит һәм Ришат Абдуллиннарның җырларын тыңлап таң калдылар. Кыргызстаннан чакырылган кунагыбыз, Муса Җәлилнең көрәштәше Рушад ага Хисаметдиновның җәлилчеләр эшчәнлеге турындагы истәлекләре белән уртаклашуы, туган телен белмәү кәсәфәтенең хәтта Колыма сөргенендә дә кешене яшәү белән үлем арасына китереп җиткерүе хакындагы гыйбрәтле хәлләрне бәян итүе залда утыручыларның берсен дә битараф калдырмагандыр дип уйлыйм. Ә инде тугандаш башкорт шагыйрьләре Нажар Нәҗми, Мостай Кәрим, чуваш шагыйрьләре Порфирий Афанасьев, Василий Эндин, Педер Эйзин, халык җырчысы Владимир Чекушкиннар белән булган очрашулар милләтләр арасындагы дуслыкның матур бәйрәменә әверелде.

Хөрмәтле кунакларга истәлекле бүләкләр тапшыру да безнең традициягә керде. Хәтерлим әле, «Җидегән чишмә» җырының авторлары Гомәр Бәширов, Сара Садыйкова белән очрашуда олпат язучыга затлы түбәтәй, ә Сара ханымга «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсе җитәкчесе Мәсгут ага Сибгатов:

*Сандугачым, илһам качып*
*Китсә әгәр хәлләрең,*
*Исеңә ал, җилкәңә сал*
*Түбән Кама шәлләрен, –*

дигән шигъри сүзләр белән шәл бүләк иткәч, зал гөрләтеп кул чапты.

«Җидегән чишмә» кичәләренең тагын бер үзенчәлеге шунда: әгәр тамашачы аның беренче бүлегендә залда утырса, икенче бүлегендә инде ул үзе «артист»ка әйләнә. Фойеда Флүр Гайнемөхәммәтов җитәкләгән «Ләззәт» ансамбленә кушылып җырлый, бии, бер-берсе белән таныша. Кичәләребезнең әнә шулай дәртле, яшьләрне дә күздә тотып оештырылуын исәпкә алып, 1988 елда «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсе республикабызның Муса Җәлил исемендәге бүләгенә лаек булды.

**Фәтхулла АБДУЛЛИН**

# «БАЛАЛАРНЫ... БАШКА ЗАМАН ӨЧЕН УКЫТЫГЫЗ»



2016 елда үзенең ярты гасырлык юбилеен билгеләп үтәргә әзерләнеп яткан химиклар шәһәренең иң беренче төзелгән йортлары арасында бөек Тукай исеме белән аталган урамда урнашкан Түбән Кама педагогика көллияте – махсус урта һөнәри белем бирүче мохтариятле дәүләт уку йорты.

Яңа төзелеп килгән яшь шәһәргә мәктәпләр һәм балалар бакчалары өчен белгечләр әзерләү ихтыяҗы туа. 1981 елның маенда РСФСР Мәгариф министрлыгы Түбән Камада балалар бакчалары өчен тәрбиячеләр һәм башлангыч сыйныф укытучылары әзерләүче педагогия училищесы ачу турындагы карар кабул итә. Әлеге эшне башлап йөрүчеләр ТАССРның мәгариф министры Р.А.Низамов һәм Түбән Кама шәһәре мәгариф бүлеге җитәкчесе Н.Ш.Әхмәтшиннар була, уку йортының беренче җитәкчесе итеп бертуган апалары үрнәгендә укытучы һөнәрен сайлаган, энергиясе ташып, эшләү теләге янып торган Евгения Ильинична Тупикова билгеләнә. Җитәкче алны-ялны белми, коллектив туплау, укыту-тәрбия эшен оештыру, хуҗалык һәм идарә эшләрен алып бару белән шөгыльләнә. Янып-ялкынланып эшлиләр, училище коллективы Татарстан Мәгариф министрлыгының һәм Республика профсоюзлар комитетының, КПСС Үзәк Комитетының, СССР Министрлар Советының Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

1994 елдан педагогия училищесы коллективын РСФСРның халык мәгарифе отличнигы, мәгариф һәм идарә өлкәсендә бай тәҗрибәле, шагыйрь җанлы педагог – Рәфкать Нурулла улы Муллин җитәкли. Педучилище шәһәр һәм районның, төбәкнең ихтыяҗын өйрәнеп, мәктәпкәчә учреждениеләрнең рус телендәге аудиторияләре өчен татар теле укытучылары, музыка, ритмика хореография һәм гамәли сәнгать түгәрәкләре җитәкчеләре, балаларның ялы өчен җаваплы педагог-оештыручы, коррекция педагогикасына кагылышлы өстәмә белгечлекләр дә әзерли. Училищеның офыклары киңәя. Рәфкать Муллин училищеда татар төркемнәренең санын арттыру, татар филологиясе бүлеген оештыру буенча күп гамәлләр башкарды. Училищеда халык педагогикасы, төрле милләт халыкларының үз тамырларын табу – телләрен һәм мәдәниятләрен, гореф-гадәтләрен һәм йолаларын торгызу һәм үстерү, кыскасы, милләтләрне саклап калу юнәлешендә зур эш башкарылды.

2009 елда көллият статусын алган уку йорты бүгенге көндә махсус урта белемле укытучылар, тәрбиячеләр әзерләү, өстәмә белем бирү буенча махсуслашкан. Көллиятнең 35 еллык эшчәнлеге белемнең сыйфатын күтәрүгә юнәлтелгән. Һөнәри яктан үз-үзеңне камилләштерү, булачак педагогларны милли рухта тәрбияләү, студентларда сайлаган һөнәргә тотрыклы кызыксыну булдыру – көллиятнең белем бирү сәясәтендә төп мәсьәләләр. Өзлексез педагогик белем бирү кысаларында укыту программаларын һәм планнарын югары уку йортлары белән килештерү – педагогика көллиятенең төп стратегик бурычы. Шуны исәптә тотып, Түбән Кама педагогика көллияте Казан федераль университетының Алабуга институты һәм Чаллы социаль-

педагогик технологияләр һәм ресурслар институты белән ныклы хезмәттәшлек алып бара.

Көллиятнең бүгенге җитәкчесе, педагогия фәннәре кандидаты Фәйрүзә Яхъя кызы Манихова – укытучылар гаиләсеннән. Һәр укытучы үзенчә талантлы. Берсе ул талантны әти-әнисеннән мирас итеп ала, берәүләре бу сыйфатларга үзенең тырыш хезмәте нәтиҗәсендә ирешә, өченчеләренең таланты исә иҗади коллективта үсә. Ә Фәйрүзә Яхъя кызында бу сыйфатлар бер төшенчәгә тупланган. Тырыш, тынгысыз, талантлы җитәкче ул. Мәгариф системасының барлык нечкәлекләрен төптән аңлаган Фәйрүзә ханым бар көчен бүгенге тотрыксыз заманда көндәшлеккә сәләтле, дәүләт белем стандартларының барлык таләпләренә дә җавап биргән белгечләр әзерләүгә юнәлтә.

Көллияттә үз эшләренең остасы булган, югары квалификацияле, һәрвакыт эзләнүчән, яңа ачышлар ясарга, педагогик камиллеккә омтылган, үз укучыларының мөмкинлекләрен һәм сәләтләрен биш бармак кебек белгән, аларны үз балаларыдай якын күргән укытучылар эшли.

Без яңача фикерләүгә игътибар бирелгән, тормышта әледән-әле яңа ачышлар ясала торган заманда яшибез. Үсеш-үзгәрешләр уку-укыту, тәрбия процессына да кагыла. Укыту-тәрбия өлкәсендә моңа кадәр билгеле булмаган ысуллар, чаралар гамәлгә керә, таныш булган метод-алымнар үзгәреш кичерә, камилләшә. Түбән Кама педагогика көллияте дә заман сулышы белән яши: камиллеккә, яңалыкка омтыла. Бүгенге мәгариф системасында вариативлык принцибы киң җәелә бара. Педагогик процессны камилләштерү максатында теләсә кайсы модельне (технология, авторлык программалары) сайлап алу мөмкинлеге тудырылды. Мәгарифнең алга таба үсеше нәкъ менә шушы юнәлештә алып барыла: аның эчтәлегенең төрле вариантлары төзелә; мәгариф структураларының нәтиҗәлелеген арттыруда хәзерге заман дидактикасының мөмкинлекләре файдаланыла; яңа идея һәм технологияләр фәнни һәм гамәли нигезләнә.

Укытучыга хәзерге заманның күптөрле инновацион технологияләренә, идеяләргә юнәлеш тотарга кирәк. Бүген педагогик яктан грамоталы белгеч булу өчен, яңа педагогик технологияләрне белү һәм аларны нәтиҗәле файдалану сорала. Бу җәһәттән Риза Фәхреддиннең сүзләрен искә төшерү бик тә урынлы булыр иде: «Балаларны үзегезнең заманыгыздан башка заман өчен укытыгыз, чөнки алар сезнең заманыгыздан башка бер заманда яшәү өчен дөньяга килгәннәр». Чынлап та, XXI гасыр укытучысы, булган белемнәре белән генә чикләнеп калмыйча, яңадан-яңа үрләргә омтылырга, киләчәкне күздә тотып эш итәргә тиеш. Җәмгыять бездән шуны таләп итә.

Шуларны исәптә тотып, бүгенге көндә Түбән Кама педагогика көллиятендә дүрт инновацион педагогик мәйданчык эшли. Болар – Ә.З.Рәхимовның иҗади үсеш технологиясе; Ш.А.Амонашвилиның шәхескә хөрмәт белән карау технологиясе – «Тормыш мәктәбе» концепциясе; Сингапур мәгариф системасы технологияләре; Яңа федераль дәүләт белем бирү стандартларының нигезе – укыту тәрбия эшендә системалы-эшчәнлекле юнәлеш.

Әлеге мәйданчыклар булачак педагогларга мәгариф системасының асылына төшенергә, көллиятне тәмамлаганда, педагогик эшчәнлекне дөрес оештыра алучы, көндәшлеккә сәләтле белгеч булырга өйрәтә.

Кыскасы, 35 еллык тарихы булган педагогика көллияте, бай тәҗрибә туплап, яңадан-яңа үрләргә омтылып яши. Мәктәпләребезне һәм балалар бакчаларыбызны югары культуралы, зыялы, зәвыклы, белемен даими күтәрүче педагогик кадрлар белән тәэмин итүне максат итеп куя. Заман таләпләренә туры килгән, инновацион юнәлешкә корылган укыту системасы булдырып, мәгариф системасы алдына куелган бурычларны уңышлы үтәрбез дип уйлыйбыз.

**Люция ГАЛӘВЕТДИНОВА,**
*фәнни-методик эшләр буенча*
*директор урынбасары*

# ЯШЬ ШӘҺӘРНЕҢ ЯШЬ ТЕАТРЫ

Чулман елгасының текә ярында гигант нефтехимия комбинаты төзелеше белән беррәттән, 1966 елның октябрендә шәһәр статусына ия булачак Түбән Кама да дөньяга килә. Еллар үтә, акрынлап ул заманча матур, яшел шәһәр булып үсеп җитә. Тик анда, әллә ни зур булмаган Халык иҗаты йортыннан тыш, халыкның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек театр гына булмый.

Нинди дә булса яңалыкны тормышка ашырыр өчен, һәрвакыт инициативалы кешеләр, энтузиастлар, бу очракта шәһәрдә театр булдыру зарурлыгы мәсьәләсен күтәрердәй башлап йөрүчеләр кирәк була. Һәм алар – Түбән Кама театрының нигезен төзүче шәхесләр – табыла да. Болар – «Нефтехим» оешмасының генераль директоры Гаяз Сәхәпов, Минзәлә театрының элекке директоры, Түбән Камага күчеп килеп, Халык иҗаты йорты директоры вазифасын башкаручы Анатолий Богатырёв, күптән түгел Казан театр училищесын тәмамлап, Әлмәт театрында актёр булган Рөстәм Галиев һәм төзеләчәк театрның булачак директоры Фәнис Чабатов. Һәм менә 1989 елның 26 декабрендә Түбән Кама шәһәр советы Президиумы Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсе каршында эксперименталь яшьләр татар театр-студиясе булдыру турында карар кабул итә.

1990-2000 еллар башында театр төрле үзгәрешләр кичерә, төрле исемнәр белән атала. 1994 елда ул шәһәрнең Мәдәният идарәсенә тапшырыла. Шул елдан – «Түбән Кама татар шәһәр яшьләр театры»; 1997 елда – «Түбән Кама татар драма театры»; 2000 елда – «Түбән Кама татар драма театры коммуналь оешмасы (учреждениесе)»; 2002 елда – «Дәүләт оешмасы (учреждениесе)»; 2007 елда – «ТР Мәдәният министрлыгының «Түбән Кама татар дәүләт драма театры»; 2009 елда «ТРның Дәүләт автономияле мәдәният учреждениесе» дип атала, ә 2012 елның 25 октябрендә ТР Министрлар Кабинеты карары белән театрга күренекле татар драматургы, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллин исеме бирелә. Хәзер коллектив «Туфан Миңнуллин исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театры» исемен йөртә.

Театр үз алдына зур максатлар куйса да, беренче елларда яшәү җиңел булмый. Беренчедән, театр-студия ачылганнан соң, аңа нигез салучылардан – Г.Сәхәпов белән А.Богатырёв эштән китәләр, режиссёр Рөстәм Галиев белән директор Фәнис Чабатов кына кала. Театр авыр хәлдә: үз бинасы юк, акча юк. Р.Галиев труппаны махсус театр белеме булган профессиональ актёрлардан гына тупларга керешә. Мәсәлән, Әлмәт театрыннан сәләтле Рәис Галиев килә һәм, табигый ки, труппада әйдәп баручыга әверелә. Минзәлә театрыннан ирле-хатынлы Ания белән Мәүҗит Фатыйховлар күченеп килә. Алар уйнаган сәхнә геройларына хисләрнең тулы ачылышы, драматик көч, юмор хас. Мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлап кайткан чибәр, талантлы Айдар Кәримов яшь, романтик, трагик һәм драматик образларны гәүдәләндерә башлый, тик, ни кызганыч, фаҗигале рәвештә фани дөньядан бик иртә китеп бара. Сәхнәдә яшь энтузиастлар – Гөлгенә Зәйнуллина, Олег Фазылҗанов, Илшат Мостафин, Фарил Вафиев, Гөлназ Фәхразыева, Гөлнур Галиева, Дилә Карпова, Альберт Ибраһимов, Физалия Гыйниятуллина, Гөлназ Кашаева, Наил Сәйфетдинов эшли башлый. Театрның пионер актёрлары белән беррәттән, анда талантлы һәм зыялы гаилә – Булат Насыйхов һәм Фәридә Мөхәммәтшина да (ул костюмнар буенча рәссам) аңа чын күңелдән хезмәт итә. Аларның тандемы

спектакльләрнең бизәлеш сәнгатенә зур өлеш кертә.

1990-1996 елларда театрның баш режиссёры Рөстәм Галиев була. (1996-2002 елларда баш режиссёр – Рөстәм Фатыйхов, 2002 елдан бүгенге көнгәчә – кабат Рөстәм Галиев.) Аңа репертуар сәясәтен төгәл ачыклау, тамашачыны театрга җәлеп итү бурычы йөкләнә. Яшь шәһәрнең гади, әле театраль булмаган эшчесе өчен шундый ук гади, аңлаешлы сюжетлы тормышчан спектакльләр куярга кирәклеген аңлый ул. Шуңа да Галиев беренче елларда катлаулы булмаган комедияләр, көнкүреш драмаларын сәхнәгә чыгара.


*Театрның ачылу тантанасына килгән кунаклар. 1989 ел*

1990 елның 7 июнендә «Кызлар кызык итәләр» (Т.Миңнуллин)комедиясе белән (беренче исеме «Ак тәүбә, кара тәүбә») Түбән Кама татар театрының пәрдәсе ачыла. 1976 елда язылган бу комедия студентларның совет елларында популяр булган төзелеш отрядлары турында сөйли. Әмма 1990 елда андый отрядлар булмый инде, һәм режиссёр, бу теманы читләтеп үтеп, пьесадан музыкага, җыр-биюгә, үзеннән-үзе туып торган мәзәкләргә, ул чакта модага кергән чупа-чупс, стиморол һ.б. шуның ише сүзләргә бай җиңел, күңелле тамаша ясый. Сүз уңаеннан, «Кызлар кызык итәләр» озын гомерле булып чыга. Ул бүгенгәчә куела, тик актёрлары гына башка. Беренче спектакльнең нәкъ менә Туфан Миңнуллинныкы булуы да символик мәгънәгә ия, чөнки еллар үткәч, театрга аның исеме бирелә.

Шул ук елларда Галиев Т.Миңнуллинның тагын бер пьесасын – «Яшьлек белән очрашу»ны сәхнәләштерә, анысы да бүгенгәчә үзенең актуальлеген югалтмаган. Анда кешеләрнең шәхси мөнәсәбәтләре турында сүз бара. Пьесаның герое Гыйльфан 25 ел элек ниндидер сәбәпләр аркасында сөйгән кызы Равиләгә өйләнмәгән, авылдан Казанга китеп барып, башка кыз белән тормыш корган. Ә бирердә аның Айдар исемле улы үсеп җиткән. Гыйльфан беренче мәхәббәтен онытa алмый һәм истәлекләрендә әледән-әле яшьлегенә кайтып тора. Р.Галиев тарафыннан гәүдәләндерелгән Гыйльфан образы гаять тәэсирле килеп чыга. Инде урта яшьләрдәге бу кешенең тышкы яктан хисләргә саранлыгы, тотрыклылыгы, серле сүзсезлеге артында борчу-сагышлары, беренче мәхәббәтен оныта алмавы ярылып ята. Улы Айдарны актив, эмоциональ, заманча хәрәкәтчән (пластик) егет итеп А.Кәримов уйный. Ф.Вафиев уйнаган Зөфәр, кай ягы беләндер мәгълүм комедия актёры Р.Шамкаевны да хәтерләтеп, тамашачыны көлдерә.

Иң мөһиме – беренче уйналган комедия һәм драма спектакльләре тамашачыны җәлеп итә, һәм ул инде театрга даими йөри башлый.

Беренче унъеллыгында театр үзенең репертуарын төрле авторларның – З.Хәкимнең «Зәхмәт», Г.Каюмовның «Адашкан чәчәкләр», Ю.Сафиуллинның «Йөзек һәм хәнҗәр», Г.Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш», Х.Ибраһимовның «Мөхлис һәм иблис», Ф.Яруллинның «Каракның бүреге яна», К.Тинчуринның «Ил» пьесалары һәм башка комедияләр, драмалар белән баета. Алар арасыннан Һ.Такташның «Җир уллары трагедиясе», И.Юзеевның «Соңгы төн», М.Кәримнең «Ай тотылган төндә» дигән фәлсәфи трагедияләре аерылып тора.

Р.Галиев сәхнәләштергән тәүге фәлсәфи, трагик пьесаларның берсе – башкорт шагыйре, драматургы Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» әсәре. Спектакль кешенең рухи коллыгы турында сөйли. Бирердә сүз пьесаның героинясы – ыруның



*Театрның 25 еллыгы. 2014 ел*

көчле ихтыярлы, буйсындыручан нык холыклы җитәкчесе Тәңкәбикә (Г.Зәйнуллина, Г.Фәхразыева) турында бара. Тик күптәнге яшьлек хатасы – җилдән туган улы Дивана – ахырда фаҗигале вакыйгаларга китерә. Күп еллар узганнан соң, аның гөнаһына шаһит кеше – Дәрвиш пәйда була. Аны искиткеч итеп Рөстәм Галиев үзе уйный. Бу – өлкән яшьтәге, чәнечкеле рәхимсез карашлы, гомерен Аллаһыга коллыкка багышлаган, ләкин ахырда мәгънәсез яшәгәнлеген аңлаган ямьсезрәк кеше була. Ул көчле эчке энергетикага ия, тормышка ашмаган ирлек асылы аны эчтән кимерә. Һәм Тәңкәбикә, бер уйласаң – таш-хатын – аның ихтыярына буйсынырга мәҗбүр. Кайбер вакыйгаларны карап кичергәннән соң, аның ырудагы борынгы, искереп беткән кануннарны уза алмаячагы ачыклана. Ул шушы кануннарның колына әверелгән. Һәм анасы (!) үзенең улы Акъегетне, сөйгән кызы Зөбәрҗәт (Ф.Гыйниятуллина) белән бәйләп, далага үлемгә озата. Ягъни бу – кешенең вакыт белән үлчәнми торган рухи коллыгы турындагы спектакль.

Озакламый тагын бер көчле фәлсәфи әсәр – «Җир уллары трагедиясе» куела. Пьеса, мәгълүм булганча, 1920 еллар башында язылган һәм шуңа күрә заман рухына туры килеп, актив, пафослы рәвештә Аллаһыга каршы көрәш мотивында яңгырый. Җир уллары трагедиясе Аллаһыга сукырларча ышану нәтиҗәсендә килеп чыга. Әсәр кую өчен бик тә катлаулы диярга кирәк. Асылда ул – поэма, шигъри диалог. Сюжет өчен Такташ Кабил белән Һабил турындагы сюжетны, аның мәгънәсен үзенчә үзгәртеп язган. Сүз уңаеннан, пьеса Байронның «Каин» трагедиясен хәтерләтә. Анысында да, монысында да сүз җирдәге беренче үтереш турында бара. Каин, Такташта – Кабил, Аллаһыга каршы ярсулы көрәшчегә әверелә. Моннан тыш, татар авторының пьесасы монологка корылган, фәлсәфи яктан кискенләштерелгән, бүгенге көндә Аллаһыга каргышлар яудыру үзенең актуальлеген югалткан.

Спектакльне куючы Р.Галиев оригиналь чишелеш тапкан – аның фикеренчә, трагедия XX гасырда СССРда һәм Германиядә диктаторлык, тоталитар режим барлыкка килү сәбәпле туа. Бу идея Б.Насыйхов сценографиясендә төгәл чагылыш таба. Таулы караңгы җир өстендә вакытны, җирне символлаштырган зур тәгәрмәч әйләнеп тора. Шунда ук, кинәт кан-кызыл төскә керүче тәгәрмәч өстендә әле Сталин, әле Гитлер портретлары күренеп кала.

Пьесада һәм спектакльдә катнашучы затлар күп. Әмма төп герой – Кабил. Аны А.Кәримов уйный. Аның герое көчле темпераментлы, эчтән табигый, тыштан хәрәкәтчән, пластик. Иң мөһиме – актёр геройның фаҗигале халәтен, тиранлыкка каршы көчле протестын төгәл күрсәтә.

Театрның шундый ук юнәлештәге эшләренә И.Юзеевның «Соңгы төн» әсәрен кертергә мөмкин. Р.Галиев – үзенчәлекле режиссёр, ул комедия, мелодрама, психологик драма кебек күптөрле жанрдагы пьесаларны сәхнәләштерсә дә, аның аеруча яратканы – катлаулы, метафорик, фәлсәфи трагедия. Һәм менә «Соңгы төн» дә, «Җир уллары трагедиясе» кебек үк, диалоглардан торган поэма. Пьеса аз күренешле, аз хәрәкәтле. Дөрес, андагы фикер бик җитди һәм мәгънәле. Ул Муса Җәлилнең җәзалану алды төне, андагы уйланулар, сагышлар, ә иң мөһиме – аның рухи ныклыгы,

туган җиренә мәхәббәте, кайнар патриотизмы турында. Автор һәм режиссёр конфликтны чынбарлыкка тәңгәллек линиясе буенча түгел, фәлсәфи яктан коралар. Мусаның камерасына Мефистофель керә (Гёте трагедиясендә Фауст янына Мефистофель килгән кебек). Анда да, монда да сүз яшәү мәгънәсе турында бара. Әмма, Гётедан аермалы буларак, Юзеевның иблисе хыянәт өчен Мусага җәннәт вәгъдә итә. Шунысы кызык: Мефистофель ролен, мөгаен, беренче тапкырдыр, ир-ат түгел, хатын-кыз – актриса Г.Зәйнуллина уйный. Куелышның үзенчәлеге дә шунда. Хатын-кыз иблис тагын да кызыклырак.



*«Яра» (Мансур Гыйләҗев инсценировкасы) спектакленнән бер күренеш*

Мусаны ул пьесада Шагыйрь дип атый. Рольне А.Кәримов башкара. Актёр үз героеның характерын төрле яклап һәм төрле очраклар аша ача. Ул фаҗигале, сагышлы, һәлакәткә дучар ителгән, әмма ирләрчә башбирмәс, наз белән үзенең сөеклесен (артистка Г.Кашаева) искә ала, уйларында моңланып әнисе (Г.Фәхразыева) белән очраша, Мефистофель белән кыю көрәшә. Шагыйрь шәхесен күпкырлы итеп ачу образны киң күләмле, тамашачыга кызыклы итеп күрсәтә.

Спектакльдә Тиран образы (Рәис Галиев) беркадәр читкәрәк куелган иде. Актёр аны сатирик плакат рәвешендә тасвирламады. Тиран йөзендә, аның әйткән сүзләрендә Гитлер шәйләнә. Әмма Галиев, аның манераларын җиңелчә генә кабатлап, Тиранның, гомумән, тиранияннең гомумиләштерелгән образын булдыра. Тыштан ул бөтенләй явыз да түгел, хәтта елмаючан, күпмедер дәрәҗәдә мәче сымак йомшак кеше.

Б.Насыйхов иҗат иткән караңгы абстракт бизәлеш өч төрле күренеш урынын күздә тоткан: уңда – Шагыйрь, сулда – Тиран, уртада – Мефистофель, Палач, лаборантка кызлар. Үзгәреп торган яктыртылыш, әлбәттә, режиссёр трактовкасы, актёрларның эше белән беррәттән, бөтен спектакльнең трагик атмосферасын булдырырга ярдәм итә.

Театр даими үсә, күтәрелә бара, һәм күпмедер вакыттан соң аңа сәхнә сыман корылмасы булган иске бер бина бирелә. Ничек кенә булмасын, бу инде сәхнәне һәм хәтта кайчакларда залны да файдаланып, репетицияләр ясарга, спектакльләр куярга мөмкин булган үз бинаң дигән сүз! Ә тагын берничә елдан бинага реконструкция ясала һәм ул ярыйсы гына уңайлы (бигрәк тә тамашачылар залы), күркәм, театр бинасына әверелә. Дөрес, ул әле дә театр җитәкчесен, коллективны канәгатьләндереп җиткерми, алар, хаклы рәвештә, махсус үзләре өчен төзелгән заманча театр бинасына ия булырга тели.

Чирек гасыр вакыт эчендә труппа коллективы ныклап оеша, мактаулы исемнәр алган актёрлар да барлыкка килә. Алар – ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе Булат Нәсыйхов, ТРның атказанган артистлары Д.Карпова, А.Ибраһимов, Р.Галиев, Г.Зәйнуллина, Г.Фәхразыева; күпләргә Дамир Сираҗиев исемендәге театраль премияләр бирелде, С.Батыршина «ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә лаек булды; яшь актриса Гүзәл Шәмәрдәнова «Тантана» фестивалендә ике тапкыр «Иң яхшы хатын-кыз роле өчен» (А.Ивановның «Гөнаһлы мәхәббәт өрәге» спектаклендә Мария – 2015 ел, Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры»нда Ана – 2016 ел) лауреат булды. Рөстәм Галиев исә – ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТРның халык артисты, Дамир Сираҗиев исемендәге премия лауреаты һәм, мөгаен, Марсель Сәлимҗанов шәкерте өчен иң кадерлеседер – Марсель Сәлимҗанов исемендәге премия беренчеләрдән булып аңа бирелде.

Театр игътибарга лаеклы спектакльләреннән Туфан Миңнуллинның шулай ук



*Нәбирә Гыйматдинованың «Бүре каны» әсәре буенча куелган спектакльдән күренеш*

билгеле, гадәти булмаган пьесасы «Ай булмаса, йолдыз бар»ны китерергә мөмкин, театрда ул «Мәдинәм-гөлкәем» дип атала. Күптәнге бу пьеса беренче тапкыр Әлмәт театрында 1978 елда куела һәм аның өчен драматург Т.Миңнуллинга, режиссёр Г.Хөсәеновка, актриса Д.Кузаевага Тукай премияләре бирелә. Соңыннан бу пьеса башка театрларда да берничә тапкыр уйнала, һәм менә – Түбән Камада да.

Конфликтның асылы автор тарафыннан беркадәр уйлап чыгарылган. Миңнуллин драмага Автор образын керткән. Дөрес, дөнья драматургиясендә андый мисаллар очрый. Авторны спектакльдә ышандырырлык итеп Альберт Ибраһимов уйный. Нәкъ менә Автор, үзенең героинясын язмыш сынаулары алдында башын идерү, елату максатын куеп, аның өчен бер-бер артлы авыр, драматик очраклар уйлап чыгарып тора. Бу максатның чишелеше – кешенең ныклыгын күрсәтү. Драманың һәм спектакльнең мәгънәсе һәм җәлеп итү көче дә әнә шунда төенләнгән.

Спектакль төгәл һәм ачык – кешенең, бу очракта Мәдинәнең батырлыгын, сыгылмас характерын күрсәтү. Мәдинәне Г.Кашапова уйнады, актриса үз героинясының характер үсешен – мәхәббәтен, бәхетен, институтта укуын, ахырда гаиләсенең җимерелүен, иренең хыянәтен, кызының һәлакәтен, күзләре сукыраюын – төгәл җиткерә алды, героинясының төрле тормыш этапларын, һәм драматик басымнарны. ныклы корыч характерын саклаган хәлдә, сынмый-сыгылмый үткәрүен ышандырырлык итеп уйнады. Әмма эчке асылының ныклыгы Мәдинәне хатын-кыз йомшаклыгыннан, кешелеклелегеннән мәхрүм итми. Нәкъ менә төп героиня образы аша сәхнә әсәренең образлы-шигъриятле мәгънәсе ачыла да инде.

Әсәрнең конфликтында Мәдинәнең әйләнә-тирәсендәгеләр – аның авыру, сукыр, авыр характерлы әнисе Разыя (Г.Фәхразыева), күренешләр барышында үзгәрәчәк Мирзанур (А.Кәримов) катнаша. Соң чиккәчә нерв киеренкелегенә ия актёр героеның асылын – Мәдинәне ихлас яратучы яшь кешедән башлап, хатынына хыянәт итүгә һәм ахыр чиктә эчүчегә әверелгәнгә кадәр һәрьяклап ачып күрсәтә. Мәдинәнең туганы Исхак персонажы да (Рәис Галиев) шактый кызыклы иде. Тыштан елмаюлы йөзе артында үзенең комсыз, юньсез асылын яшергән оятсыз, шома, җирәнгеч тип. Актёр, үзенчәлекле кабахәтлек фәлсәфәсен тормышчан итеп ачкан чагында, СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеровның танылган рольләренең берсен – Ш.Хөсәеновның «Әни килде» спектаклендәге Ислам образын хәтергә төшерде.

Соңгы ун елда труппага Казан театр училищесын тәмамлаган яшьләр төркеме – Роза Аникина, Гүзәл Шәмәрдәнова, Юрий Павлов, Рафил Зәйнуллин, Раушан Асатов килеп кушылды. Р.Вәлиевнең «Әйдә барыйк, кызлар карыйк» комедиясендә, нигездә, гел яшьләр уйнады. Гадәттәгечә, Р.Галиев комедияне үзенчә куйды. Рәссамы – Б.Нәсыйхов. Беренче актта ниндидер тәгәрмәч-караватта егетләр йоклый. Алар төшләрендә үзләренә бишек җыры җырлаган кызларны күрә. Тәгәрмәч-караватт тормышны, җир әйләнешен символлаштыручы хезмәтен үти. Икенче актта бу карават бәйрәмчә Яңа ел өстәленә әверелә, аның тирәсендә гадәти булмаган киемле егетләр-кызлар җыела. Бу – күп музыкалы, җырлы, яшь актёрларның дәртле биюләре белән тулып торган, шук-шаян, күңелле, фантазияле, оптимистик спектакль булып чыга. Т.Миңнуллинның «Кияүле кызлар кияве» комедиясе, соңрак Л.Леронның «СССРда эшләнгән» комедиясе дә шундый ук рухта уйнала. Алар режиссёр яраткан синтетик театрның махсус төрен тәшкил итә, һәм ул үзенең актёрларының күптөрле




*Театр коллективы Төркиядә гастрольләр вакытында. 2012 ел*

символик метафораларда, пластика, музыка кулланылган сәхнә әсәрләре төрләрендә уйный белүләренә, үз геройларының характерларында тормышчан дөреслекне чагылдыруларына ирешергә тели.

Түбән Кама театры, өлкәннәргә куелган спектакльләр белән беррәттән, нәниләр өчен дә, шул исәптән, Яңа ел тамашалары да әзерли. Моннан тыш, 2006 елда театр каршында бүгенгәчә эшләүче эксперименталь Курчак театры булдырыла.

Әмма шул ук вакытта Рөстәм Галиевнең төп эшчәнлеге – җитди, драматик спектакльләр кую. Шуңа дәлил буларак, соңгы еллардагы игътибарга лаек эшләре – М.Гыйләҗевнең Аяз Гыйләҗев романы буенча куелган «Яра» спектакле һәм Н.Гыйматдинова повесте буенча куелган «Бүре каны».

«Яра» спектакле узган сугышның фаҗигале хатирәсе буенча көчле реквием булып яңгырады. Димәк, ул Казан яшь тамашачы театры Хәрби-патриотик темага оештырган спектакльләр фестивалендә юкка гына Гран-прига лаек булмаган. Сәхнә әсәрендә сугышта гарипләндерелгән, йөзе җәрәхәтләнгән улларын атасы белән анасының да танымавы тамашачылар йөрәген соң чиккәчә сыкрандырды. Спектакльдә актёрлар Айдар Кәримов (Габдулла), Рәис Галиев (Сөләйман), Гөлгенә Зәйнуллинаның (Зөләйха) талантлары ачык күренде. Сабыр, аз сүзле, күзләре тулы яшь, җаннарында әрнүле яра булган картлар янәшәсендә аларга баккан күзләрендә тетрәндергеч сүзсез сорау саклаган, танылмаган уллары йөри.

Шундый ук фаҗига – шулай ук Ватан сугышы темасына Чыңгыз Айтматовның күренекле «Анам кыры» әсәрендә. Спектакль Советлар Союзының фашистлар Германиясен җиңүгә 70 ел тулуга багышланган иде. Гүзәл Шәмәрдәнова баш рольне – Тулганай ана ролен уйнады. Яшь актриса сугышта ирен, улын югалткан ананың трагик образын ышандырырлык итеп тудыра алган. Аның, кисеп төшергәндәй, җиргә авуы һәм чиксез газап белән: «Әйт, туган җирем, кайчан, нинди заманнарда ананың, улын бер мизгел генә күреп калу өчен, шулкадәр газапланганы, интеккәне бар?» – дип инәлеп соравы тамашачыны тетрәндерми калмый.

Башка тематика, вакыйгаларның бүгенге заманда баруы белән аерылып торса да, проблеманың җитдилеге белән шушы ук сафта «Бүре каны» (Н.Гыйматдинова) фәлсәфи спектакле тора. Әсәрнең сюжеты гадәти түгел. Авылда бер гаилә яши. Гомере буе улы булу турында хыялланган гаилә башлыгы Аю Кәрим (Рәис Галиев) картайган көнендә, ниһаять, теләгенә ирешкәч, улын бүре кебек көчле һәм усал итеп тәрбияләргә тели. Үзе бүре аулаучы буларак, чираттагы бүресен үтергәч, улын бүре канын эчәргә мәҗбүр итә.

Ике төп герой – атасы белән улы – спектакльдә кызыклы үсеш кичерә. Башта

Аю Кәрим кырыс һәм тупас булып күренсә дә, соңрак үз гамәле өчен үкенүче сыйфатында гәүдәләнә. Ә аның улы Рамазан (Рафил Зәйнуллин), киресенчә, балачак елларында йомшак күңелле булса – атасының аңа бүре канын эчерүе дә шул сәбәптән – үскәч һәм шәһәрдә җитәкчелек вазифасына да керешкәч, явыз, тупас һәм рәхимсез кешегә әверелә. Монда яшь актёрның сәләтен билгеләп үтми булмый, ул Рамазанның төрле якларын, холкындагы үзгәрешләрне һәм, иң мөһиме, үзенең кырыс усаллыгы белән беррәттән, икенче планда беренче мәхәббәте Гөлнараны сагынуын чагылдыра.

Спектакльдә тагын бер гайре табигыйлек – бүреләрнең үз дөньясы, ул беркадәр «Чыңгыз Айтматовның «Ахырзаман»ы белән дә аваздаш булып тоела. Бүреләр, үз туганнарын харап иткән өчен, Аю Кәримнән үч ала. Бу үзенчәлекле сюжет бию куючы Рөстәм Фәтхуллин тарафыннан тәэсирле итеп эшләнгән. Куәтле, кыю, явыз, динамик, актив пантомимик чагылыштагы бүреләр көтүе фикерне, бумеранг образын – хаксыз гамәл өчен үч барлыгын символлаштырып, бөтен спектакль аша диярлек үткәрә.

Бурятлар «фэнтези» дип исемләгән әлеге сәхнә әсәрен «Казандагы «Нәүрүз», Улан-Удэдагы (Бурятия) «Золотая коновязь», Коньядагы (Төркия) «Мең сулыш һәм бер тавыш», Санкт-Петербург Халыкара фестивальләре тамашачылары алкышлады.

Әле күптән түгел, 2015 елда, Р.Галиев үзен яңа өлкәдә – драматург буларак күрсәтте. Ул «Кадер кичәсе» дигән драма язып, сәхнәгә чыгарды. Әсәр – авылның үлеме, кешенең рухи нигезләре җимерелү, аның ялгызлыгы, ата-бабалар турындагы хәтере, тарихи хәтере югалу турындагы сагышлы бәян (Аяз Гыйләҗев, Фёдор Абрамов, Василий Распутин романнары, повестьлары, Илдар Юзеев пьесаларындагы кебек). Зират Козгынының сәеррәк ролен үзенә хас дулкынланулы кайнарлык белән, балаларча беркатлылыкка картларча зирәклекне кушып, Ю.Павлов уйнады. Йөзләрчә еллар буе яшәүче һәм үткән замандагы кешеләрнең лаеклы тормышларын күзәткән бу кош үз тарихын, тамырларын, рухи көчен югалткан бүгенге буынга куркыныч диагноз куя.

Җитәкче буларак, Рөстәм Галиев яшьләргә үсәргә булыша. Ә режиссёр буларак, К.Станиславский әйтмешли, «режиссёр-бакчачы булып», актёрлар фантазиясенә ирек бирә. Яшь артистларның кайберләре, мәсәлән, Ю.Павлов, үзен режиссёр буларак та сынап карый. Ул М.Байҗиевның «Назлыгөл» драмасын куя, ә чуваш язучысы Н.Угаринның «Каһәр суккан мәхәббәт» пьесасын Казанда яшь режиссёрларның «Һөнәр» фестивалендә күрсәтеп, уңай бәя ала.

Түбән Камалыларның спектакльләрен Татарстанда гына түгел, – Башкортстан, Чувашиядә, Самара, Ульян өлкәләрендә, Мәскәүдә, Санкт-Петербургта да яратып карыйлар. Театр «Нәүрүз», «Тинчурин» фестивальләрендә актив катнаша. Театр залын тутырып килгән тамашачылар коллективны юмарт рәвештә үзенең алкышлары белән бүләкли. Спектакльләрне татар тамашачысы гына түгел, рус телле татарлар да яратып карый. Театр социаль юнәлешле, анда ташламалар һәм аз керемлеләр өчен хәйрия спектакльләре системасы да каралган.

...Метафораларга бай сәхнә теле, үзенчәлекле кую алымнары, музыкаль һәм пластик бизәлеш, ансамбль куелышында актёрларның тормышчан дөреслеге режиссёрның да, шулай ук бөтен коллективның да иҗади өлгергәнлеге турында сөйли. Шушы иҗади кайнарлыкның еллар буе дәвам итүен Аллаһ насыйп итсен.

**Ильтани ИЛЯЛОВА**

# МАЭСТРО



Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында Халыкара хатын-кызлар бәйрәме – 8 нче Мартка багышланган хөкүмәт концерты бара. Сәхнәдә Рафаэль Сәхәбиев җырлый.

*Ай, кызлар, йолдызлар,*
*Яныгыз яктырак!*
*Яныгыз сез, чолгагыз сез*
*Безне көчле ялкынга!..*

Ходай Тәгалә чибәрлекне җәлләмәгән егеткә. Һаман шул сокланып туймаслык кыяфәт! Җитмешенче елларда ук беренче мәртәбә шушы сәхнәгә чыгып җырлаган әлеге җыр чарланган тавышта тагын да көррәк, тирәнрәк аһәңдә яңгырый. Язучы Марсель Галиев тасвирлаганча: «Аяз зәңгәрлектәге, кабарынкы, яһүди күзләр. Көрәнсу-соргылт чәче маңгай турыннан өскәрәк калкып, сизелер-сизелмәс кенә бөдрәләнеп тора. Унтугызынчы гасыр аксөякләре – граф, бөек кенәз рольләрен сәхнәләрдә менә дигән итеп уйнарлык.

Кием шәп. Кылыч йөзе кебек үтүкләнгән чалбар, костюмнары дисеңме, якасы чыңлап торган күлмәкләре, зәвык белән сайланган галстуклары дисеңме – бар да «кайнар килеш». Париждан кайтартылган кебек».

*...Яныгыз сез, чолгагыз сез*
*Мәхәббәт ялкынына!*

Җыр тәмамланып, артистның аһәңенә өнсез калган халык бераздан дәррәү кул чабарга тотынды.

Алкышлар, алкышлар, алкышлар...

Янәшәмдә утырган өлкән яшьтәгерәк абзый сорап куйды:

– Кайда туган җырчы бу?

Мин аңа, зур горурлык белән, үземне дә катыштырып:

– Безнең туган яктан – Түбән Каманың Шәңгәлче авылыннан! – дип җавап бирдем.

Ул артыгын сораштырмады, озакка сузылган алкышлар шавына кушылып, кул чабучыларга иярде дә «бис» кычкыра башлады.

– Бис! Браво!

Мин дә, залда утырган Сибгат абый белән Аяз Гыйләҗевны күргәч, әлеге абзыйның тавышыннан югарырак тональностьта:

– «Өянкеләр»не җырласын! «Өянкеләр»не!.. – дип залга котны яңгыраттым.

Беләм бит, бу минем генә теләк түгеллеген. Таләбемне, һичшиксез, куәтләп алачаклар... Һәм шулай килеп чыкты да. Зал «Өянкеләр»гә тотынды.

– «Өянкеләр» давай, «Өянкеләр»!..



*Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсыннан күренеш (сулдан уңга): Идеал Ишбүләков, Рафаэль Сәхәбиев.*

Абзый да «өянкеләр»нең нәрсә – агачмы, җырмы икәнен белмичә, халык соравын кабатлап, кычкыргалаган булды.

– Абзый, син үзең кайдан?

– Чиләбедән, ә нәрсә?

– Бернәрсә дә түгел, аңлашылды, – мәйтәм.

Рафаэль «Өянкеләр»не башлады.

*Сезгә эндәшми, мин кемгә*
*Эндәшим, өянкеләр?*
*Житте минем дә сезнең кук,*
*Картайдым, дияр көннәр.*

Бу җырның музыкасы ишетелүгә үк, Аяз Гыйләҗевның күзләреннән яшь бәреп чыга, дип чордашларының сөйләгәннәрен ишеткәнем бар иде. Аннан соң «Минем таныш өянкеләр, сезгә баш ияр кемнәр?» дигән җиренә җиткәч, сулкылдап җылый да торган булган ул. Инде бу юлы үзем дә күрдем. Тамагыма ачы сагыш төене утырды, тынлык, Рафаэль залны елата. Ирексездән әлеге дә баягы абзыйга карыйм, ул да кулъяулыгы белән битен каплаган да:

– Өянкеләре дә калмаган шул авылымның, өянкеләре дә... – дип, күзләрен сөртеп утыра иде.

Хәзер, олыгая төшкәч, без Рафаэль белән ешрак очрашабыз. Туган авылыбызга да бергә кайтулар күбәйде. Сабантуйларда бергә булабыз. Сөйләшүләребезнең күп темасы, нинди чирдән интегүебездән кала, шул сәнгать һәм шул өлкәдәге хәлләр, кешеләр турында бара. Аяз абыйны Оперныйда җылатып җырлаганнан соң да бит инде 25 елдан артык вакыт узган, чүтеки.

– Син, Рафаэль, – дип башлыйм мин сүземне, – опера җырчысы булу белән бергә, теләсә кайсы концертта теләсә нинди җырны бик теләп һәм зур осталык белән башкарасың.

– Рәхмәт, Алмаз.

– Минемчә, мондый сәләт һәр җырчыга да бирелми.

– Җырчы өчен музыкаль жанрлар аерып куелмаска тиеш, дип саныйм мин.

– Җырчының төрле жанрларга: ягъни операга, халык җырларына, эстрада әсәрләренә тигез каравы аның талантының иксез-чиксез булуын раслый түгелме? Италиядә бит бер генә җырчы да аерым жанрларга бүленеп иҗат итми. Анда хәтта тембрларны бүлеп сөйләүләр дә гадәткә кермәгән. Син нәкъ шундый карашны яклыйсың бугай?

– Әлбәттә.

– Синең күпьяклы репертуарыңа сокланмый мөмкин түгел.

– Минем радиога яздырган йөзләрчә әсәрләрем, халык күңеленә кермичә, кайдадыр ята. Алар арасында романслар да, опералардан арияләр дә, төрле композиторларның әсәрләре дә, халык җырлары да, рус һәм чит ил классикасы үрнәкләре дә – һәммәсе бар.

– Минем аларның «Өммегөлсем»нән башкасын ишеткәнем юк. Ә кайда соң ул язмалар хәзер?

– Кем белгән? Радиолар күп, ә шуларны яңгыратучы юк.

– Радиолар хәзер коммерцияләнгән, төп максатлары – акча эшләү, ахрысы.

– Шулайдыр...

– Хәтерлим әле: композитор Луиза Хәйретдинованың Равил Фәйзуллин шигыренә

язылган «Менә без дә үсеп җиттек, әни» җырының авылыбыз урамнарында яңгыравын. Багана башындагы динамиктан тарала, малай, синең тавыш. Авылда туып үскән егетнең әнисенә һавадагы кыр казлары очып җылы якка китүен үзенең китүе белән чагыштырып җырлавы... Ух! Шуңа ничек әнисенең йөрәге түзде икән?..

– Ул миңа: «Җырлама әле, улым, шул җырыңны! Үзең ешрак кайтып йөр!» – дия торган иде.

– Бер тапкыр син миңа Рөстәм Яхин белән булган иҗади дуслыгыгыз турында сөйли башлаган идең, оныгың Нариман телефоннан шалтыраткач, сүзебез өзелеп калды.

– Әйе шул. Җыр буенча мин бик күп композиторлар белән эшләдем. Сине Рөстәм Яхин кызыксындыра икән, шуны рәхәтләнеп сөйлим. Мин аның дистәләрчә җырын, романсларын беренче башкаручы булдым. «Романтика» (Р.Байтимеров шигыре), «Иделкәем минем», «Өянкеләр» (С.Хәким) исемле җырларын, Ренат Харис шигырьләренә язылган романслар циклын үзе белән бергә радиога яздырдык. Рөстәм аганың җырларын башкару бик җиңел, ноталарын күрү белән үк, алар күңелгә табигый рәвештә агылып керәләр. Үзе рояльдә уйнаганда, аның белән җырлау бигрәк тә рәхәт һәм җиңел иде. Бик атаклы композитор булса да, ул яшь башкаручыларга зур хөрмәт белән карый иде. Аның әсәрләре җырчылар өчен бер зур мәктәп булып тора. Юкка гына аның романсларын М.Глинка исемендәге конкурсның мәҗбүри программасына кертмәгәннәрдер. Шуңа күрә аларны Е.Серкибаев, А.Днишевлар җырлый. Композитор Рөстәм Яхинны белмәгән рус һәм башка милләт җырчылары юктыр.

– Мин сине күбрәк Фасил абый Әхмәтов янында очрата идем.

– О-о! Ул бит бик юмор яратучан кеше иде. Без аның белән гел дус булып яшәдек. Фасил абый мине консерваториядә гармония буенча укытты. Ул фән шундый авыр, бездәй авыл малайларының теше үтәрлек түгел. Шуңа күрә ул аны безгә йомшак кына итеп аңлата, йә үзе эшләп күрсәтә, йә булмаса, класстан чыгып китә дә үзара күчерешергә ирек бирә иде. Аның музыкасы үзенә генә хас, бүтәннәргә охшамаган. Мин аның «Җитен чәчәк» (Разил Вәлиев шигыре), «Тәрәзә юа кызлар» (Әхсән Баян) җырларын, Равил Фәйзуллин шигыренә иҗат ителгән «Юатма син мине» романсын бик яратып башкардым.

– Ә Мирсәет Яруллин белән мөнәсәбәтләр ничек иде?

– Аның белән дә мин бик дустанә мөнәсәбәттә булдым. Ул иҗат иткән «Казан утлары» җыры белән без икәүләшеп бөтен СССРны әйләндек. Мин шунда Рәсәйнең мәшһүр композиторлары Ян Френкель, Оскар Фельцман белән таныштым. Мирсәет абый һәрвакыт пөхтә, матур итеп киенеп йөрүе белән безгә үрнәк булды. Ул, гомумән, дөрес кеше иде, кыек-мыек сөйләшмәде.

– Опера җырчысы буларак, сиңа шуларның берәрсе йогынты ясадымы?

– Беркадәр булгандыр инде, чөнки аларның җырлары белән тавышны чарлау файдага киткәндер. Бу мәсьәләдә миңа Нияз Даутовның ярдәме зур роль уйнады. Хәтерлим, әле мин театрда стажёр булып эшләгән вакытта ул Чиләбедән Казанга кайтып төште. Театр шундук башкача эшли башлады. Остаз безне сәхнәдә ничек йөрергә, образны ничек тудырырга өйрәтте. Уйнаган ролеңә ничек ышанырга? Монысын да аңлатты. Без яшьләргә зур партияләрне ышанып тапшырды. Нияз Даутовка безнең буын артистлары барысы да зур рәхмәтле.

– Оныгың Нариман бу араларда күзгә чалынмый әле. Телевизордан да күрсәтмиләр.

– Күрсәтмәү – анысы табигый нәрсә инде ул бездә. Аптырашлы түгел, күнегелгән. Аннан соң аның берара тавыш алышыну чоры барды. Үзем дә җырларга рөхсәт итмәдем. Ә хәзер музыка училищесында әйбәт кенә укып йөри.

– Ул синең дәрәҗәңне тагын да югарырак биеклеккә күтәрде. Аның Австриядә, Чехиядә, Мәскәүдә үткәрелгән халыкара фестиваль, бәйгеләрдә лауреат исемен яулавы, Мөслим Магомаев исемендәге конкурста Гран-при алуы, шулай ук Татарстан, Рәсәй Мәдәният министрлыклары, халыкара Владимир Спиваков фонды стипендиаты булуы миндә дә зур горурлык хисе уятты. Спиваков ярдәме белән Нью-Йорк, Төркия, Франциянең затлы концерт залларында чыгыш ясап, дан казанды.



*Оныгы Нариман белән «Сәйдәш аланы» сәхнәсендә.*

– Рәхмәт. Мин бик шат. Рәхмәт әйтердәй дуслар бик аз инде хәзер.

– Нигә алай дисең?

– Менә мин хөрмәт иткән, аның җырларын яратып башкарган Рәшит Абдуллин да якты дөньядан китте. Аның Разил Вәлиев сүзләренә язылган күп җырларының байтагын миңа башкарырга насыйп булган иде. Ярый әле 14 җырын язып, бер диск чыгарырга өлгердек.

Хәйдәр Бигичев та юк инде. Ул консерваториягә керергә соңга калып килде, ләкин тавышын тыңлап карагач, аны берсүзсез укырга алдылар. Нияз Курамшевичның театрга кайтуы аңа да зур бәхет китерде. Ул Хәйдәргә зур өметләр баглап, эшкә кереште. Чыннан да, «Алтынчәч»тә Җик Мәргәнне аның шикелле җырлаучы булмагандыр. Ул тыштан карап торганда тыныч кына күренсә дә, эчтән әллә нинди драматик хисләр кичереп башкара иде бу образны.

«Җәлил» операсы – Нәҗип Җиһановның бөек әсәре. Ул елларда Хәйдәр Бигичев булмаса, «Җәлил»не сәхнәгә куя алмаслар иде, минемчә. Хәзер «Җәлил» бармый, чөнки Хәйдәр юк. Бу спектакльдә мин Канзафаров ролен башкардым. Аңа карап, үзең дә бирелеп уйный башлыйсың, җырлавың белән дә аннан калышмаска тырышасың. Операның азагында ул «Сау бул, Казан!» ариясен башкарганда, мин сәхнә кырыеннан Хәйдәрне елап тыңлап тора идем. Оркестр белән җитәкчелек иткән Фуат Мансуров та: «Җәлилне еламыйча тыңлап булмый», – дия иде.

– Рафаэль, син үзеңне һәрвакыт түбәнрәк сыйфаттагы опера җырчысы итеп тасвирлап сөйлисең сыман. Моны синең артык тыйнаклыгың дип кабул итәргәме? Әллә бу чыннан да шулаймы? Син бит, югарыда әйтеп үтелгәнчә, «Җәлил» операсында шактый катлаулы Канзафаров образын тудырган артист, «Севильский цирюльник»та төп рольләрдән – Фигаро, «Евгений Онегин»да – Онегин, «Снегурочка»да – Мизгирь, «Фауст»та – Валентин, «Пиковая дама»да – кенәз Елецкий, «Алтынчәч»тә – Хан Колахан, «Җиһангир»да – Ислам, «Самат»та – Нургаяз һәм «Башмагым»да Вафаны уйнаган кеше. Гомумән алганда, утызлап операда шулхәтле образ тудырдым дип әйтә аласың.

– Минем эшемне, осталыгымны, иҗат мөмкинлекләремне башкалар бәяләсен. Мин бит үземне үзем мактап, миннән дә шәп артист юк дип әйтә алмыйм. Бу минем эчке дөньяма, халәтемә туры килми. Ә менә дусларым, иҗатташларым турында рәхәтләнеп сөйли алам. Алар минем сыйфатнамәмә мохтаҗ түгелләр, аларны халык болай да белә, хөрмәт итә, тыңлый, ярата. Мөнир Якупов, Зилә Сөнгатуллина, Хәйдәр Бигичев, Руслан Дәминов, Клара Хәйретдинова, Сәет Рәинбәков, Равил Идрисов – без бер буын җырчылары операбызның гөрләп эшләгән чагында танылу бәхетен татыдык.

Беркөнне мин аңа көтелмәгән сорау бирдем, ахрысы, ул аптырабрак калды.

– Рафаэль, син – опера җырчысы. Бөтен күзәнәкләрең опера белән сугарылган, опера белән тукылган. Сине берәр дөньяви дәрәҗәдәге җырчы белән тиңләмиләр идеме? Тавышыңны чагыштырып, кыяфәтең, манераларың буенча? Әйтик: «Син – Карузо!» – дип җиппәрмиләр идеме? Миңа сине кемдер шулай атагандыр кебек тоела.

– Юк. Азат Аббасов белән чагыштырдылар. Драматик рольләрне башкару мәсьәләсендә Азат абый шәп иде. Манераң, тавышың шуныкына охшаган дип әйткәләделәр. Ул – драматик тенор, ә мин – лирик баритон. Шул бер тирә инде. Яшьрәк вакытта Эмиль Җәләлетдинов, диләр иде. Мин үзем дә аңа тартым икәнлегемне белә идем. Әмма ул булып җырларга омтылыш юк иде, һәрвакыт үзем булып калдым. Кемдә юк инде ул андый охшашлыклар?.. Күп бит алар, мәсәлән, Илһам тавышлылар.

– Сиңа оперетталарда уйнау бик килешә.

– О-о, мин анда йөзәм. «Сильва»дагы бер кызык моментны әйтеп үтим әле. Анда мин отставной генерал булып уйныйм – спектакльнең башыннан ахырына кадәр коляскада утырып йөрергә тиешмен – инвалид. Иң ахыргы күренештә бокалымны тотып торып китәм. Әйе, үз аякларым белән.

Шул хәлне күргәч, залдагы бөтен тамашачы тәгәрәп көләргә тотына. Мондый эпизод классик күренешләрдә юк. Мин моны үзем уйлап чыгардым. Петербургтан килгән режиссёрга әлеге мизансцена бик ошады. Һәм ул аны башка чакта да шулай итәргә кушты.

Әйе, мин оперетталарны, музыкаль комедияләрне яратам. Анда рәхәтләнеп уйнарга мөмкинлек бар. Операда кысалардан чыгып булмый. Оперетталарда «отсебятина»ны кушарга җай чыга. Азат Аббасов шулай иткәнне яратмый. Аңа үзеңнән уйлап сүз әйтсәң, гримёрныйга чыккач: «Ты, твою мать, прекращай!» – дип сүгә башлый иде.

«Башмагым»да кияү Вафа булып уйнаганда, ниләр генә эшләмим, автор сүзен бөтенләй кулланмыйм. Бер көнне – бер сүзләр, икенче көнне – икенчеләре. Сәхнә артындагы артистлар, бүген нәрсә әйтер икән, дип кырыйдан көлеп карап торалар иде.

Мизансценаларны да үземчәрәк эшләдем. Шуңа күрә мине консерваториягә режиссёр-педагог итеп алдылар. Ул болай булды: Светлана Нәҗиповна – Нәҗип Җиһановның кызы, кафедра мөдире – беркөнне миңа әйтә:

– Кил әле, әйдә, режиссёр бул! – ди.

– Мин эшли алмам бит, – дим.

– Юк, юк, эшлисең! – ди бу миңа, ышаныч белән.

Шулай ул мине консерваториягә укытырга алды. Шуннан бирле мин – режиссёр-педагог, доцент. Хәзер минем бер студент кыз Лондонда җырлый – Влада Баравко. Беркөнне «Культура» каналыннан күрсәттеләр. Уфада, Ижауда, Саранскида, Волгоградта минем опера классын бетергән студентлар. Менә хәзер миндә бер татар егете укып йөри – Яромир исемле. Бик өметле! Тавышы, кыяфәте, диапазоны, тембры шулхәтле шәп!

Күптән түгел телевизордан Ободзинский турында кино карап утырдым. Әйбәт җырчы иде, мәрхүм. «Эти глаза напротив» дигән фильм. Мин хәзер кинода эчпошыргыч әшәке кешеләр булса, телевизорны сүндерәм. Менә монысында да андый персонаж бар – Сафонов дигән бер артист. Бик әшәке кешене уйный – партком секретарен. Ободзинскийның хатыны артыннан йөри ул анда.

Менә шундый заразалар каян килеп чыга? Тормыш юлымда күп күрдем аларны. Әле күбесен белеп тә бетереп булмый. Сәнгать дөньясында көнчелек, астыртын этлек эшләү күп бит. Хәер, бүтән өлкәдә дә, бүтән мохиттә дә байтактыр Сафоновлар...

Ләкин аларга игътибар биреп кәефемне бозып йөрмәдем. Алдагы юлым ачык иде – җырлыйсым булды. Вак-төяк интригаларга бирелеп, нервы бетереп йөрергә вакытым да юк иде.

Аннан соң хәзерге операның хәленә борчылам. Үземне үзем тынычландырып йөрим. Миңа: «Нигә шулхәтле борчыласың?» – диләр. Хәзер төрле өлкәдә, тармакта гаделсезлек күп. Сәнгатьтә дә. Зур урында эшләгән кешенең гаебе күбрәк, дию дөресрәк булыр. Булса да, әллә ни еракка алып атмыйлар, икенче җылырак урынга утыртып кына куялар. Юк, юк – чыгарып атмыйлар. «Карга карганың күзен чукымый». Номенклатурный кеше, диләр дә җайлыйлар. Нинди номенклатурный булсын, мәйтәм, макулатурный ул.

– Опера кирәкме соң ул? – диләр. – Нәрсә өчен файдасы бар аның? – дип өстәп тә куялар.

– Опера бөтен халыкларда да бар. Татар гына аннан мәхрүм калырга тиеш түгелдер. Җырлы-биюле уеннар татар милләтенә хас күренеш бит. Дөрес, татарча опера спектакльләренә тамашачылар азрак йөри, ә театр ачылган елларда халык агылган гына. Казанда да, башка төбәкләрдә дә милләттәшләр, әйтик, «Башмагым» спектаклен бик ошаталар.

Опера – драма, җыр, бию, рәсем сәнгатьләреннән тупланган чәчәк бәйләме кебек матур бер сәнгать бит ул. Эстрада кырыкка төрләнәчәк, ә опера барыбер яшәячәк. Әмма опера сәнгатен үстерүдә дәүләт ярдәме зарур. Бөтен илләрдә дә опера театрлары хөкүмәт булышлыгында яши. Аннары милли кадрларны барлыйсы, күтәрәсе иде.

Бервакытны мин «Молодые голоса России» дигән  фестивальдә катнашкан идем. Анда Марусиннар, Сметанниковлар да бар иде. Безне сәхнәгә тезеп куйдылар. Бу – «Россия» залында булган хәл. Шунда безнең каршыга Иван Семёнович Козловский чыгып басты – бөек тенор. Аңа соңгы сүзне әйттерәләр. «Опера ул шундый сәнгать, бер вакытта да үләчәк түгел, гомумән, сәнгатьне операсыз күз алдына китереп булмый, – диде дә: – да здравствует Русский наро-о-о-д!» – дип, бик югары нотаны тотты. Озак сузып торды. Һәм бөтенебезгә кул биреп чыкты.

Аның бу гамәле «опера сәнгате мәңгелек» дию булгандыр.

Әйе, һичшиксез, татар опера җырчысына мәйдан кирәк. Ул мәйданны безгә кем булдыра? Әйтик, миңа каядыр еракка сикерү өчен, таяну ноктасы кирәк – трамплин.

Шул уңайдан, уйларымны көлкелерәк рәвештә исбатлап, бер мисал китерәм.

Минем бер уртача җырлый торган җырчы студентым, Бельгиягә китәм, ди. Хәтта уртачадан түбән дәрәҗәдә җырлый ул. Син Мамадышка барам, дисеңме, дим, ишетеп бетермәгән булып. Үпкәләде. Ләкин шунда барып, шундагы җыр конкурсында икенче урынны алып кайтты. Котлыйм, дидем инде.

Кайчагында уйлап ятам, нигә безнең менә дигән «Алтынчәч» операбызны, үзебезнең талантларыбызны, чит илгә алып чыгып, дөньяны шаулатмаска? Грандиоз опера! Музыкасы искиткеч. Нәҗип Җиһановның даһилыгы бу.

Максат куеп, Ауропага алып чыгарга кирәк Татар операсын. Безнең дөньякүләм танылган җырчыларыбыз бар: Альбина Шаһиморатовалар, Аида Гарифуллиналар, Эльмира Кәлимуллиналар, егетләр арасыннан санап бетерерлек түгел талантлар, тагын-тагын әллә кемнәребез!..

Менә шуларны зур сәхнәгә тезеп, Иван Семёнович Козловский кебек, алларына чыгып җырлар идем.

*«Сез кайсы халыктан?» – дисәләр,*
*Батырлар исемен атадым.*
*Батырлар утларга керделәр,*
*Тик исән булсын дип Ватаным...*

**Алмаз ХӘМЗИН**

# РӘССАМ



Сиксәненче еллар азагы, туксанынчы еллар башы. Дөньялар буталырга тора. Халык нишләргә белми. Кыйбла кайсы якта? Кай тарафка китәргә? Менә шундый вакытта зирәк кешеләр кирәк. Үзләренең сүзләрен акыллы гына әйтеп, халыкны әйдәргә, аның гореф-гадәтләре, йолалары, милли аңы, милли акылы, милли моңы аша юл күрсәтергә!

Түбән Кама шәһәрендә шундый шәхесләрнең берсе рәссам, сынчы Әхсән Фәтхетдинов иде. Аның иҗаты – ул халыкның юлы, көн күреше, яшәеше, үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге... Түбән Кама халкы башта аны «Рәсем ясаучы» дип атады. Чөнки ул Түбән Кама шәһәренең байтак кына урыннарын: паркларын, мәйданчыкларын, олуг тау-чишмә («Кызыл чишмә») урыннарын, аэропортларын, бина диварларын үзенең иҗаты белән бизәде – баетты. Әхсән абый тоташ актан тора иде: тузгып торган ап-ак чәчләр, беркайчан чалбары эченә тыгылмаган ак күлмәк, ак күңел. Халык күңелендә дә шулай булып калды.

Сабый балаларныкыдай гөнаһсыз күзләре шаулы дөньядан игелек, әхлак, хаклык, матурлык таләп итте. Һәрбер әйткән сүзе диярлек – фикер. Фикер иясенә «Ияләр иясе» дигән исем тагылды. Җеннәр ясаучы рәссам. Бу – аның икенче кушаматы. Кешеләр ни генә димәсен, «Рәсем ясаучы»мы, «Ак бабай»мы, «Җеннәр ясаучы»мы, «Ияләр иясе»ме – болар халык белән бергә яшәүнең, аннан аерылгысыз булуның билгеләре, символлары. Ул туган халкының нинди булуын, аның асылын, тарихын, җыр-көйләрен, моңын, телен рәсем аркылы билгели алды. Үзәк калада яшәмәсә дә, үзенең зурлыгын, чын рәсем ясаучы икәнен олуг җәмгыять алдында исбатлый алды. Тукай, Җәлил, Такташ, Сәйдәш, Сара, Бакыйлар белән бер рәткә басты. Иҗаты, калкулыклар гына булып калмыйча, тауга әйләнде.

Үзенең остаханәсендә Әхсән абый гел халык җырларын көйли торган иде. Аның җырларыбызга мөнәсәбәте үзенчәлекле. Алар турында сөйләргә тотынса, фәлсәфи фикер белән, үзенең эчке кичерешләре аша ялкынланып озаклап сөйли иде.

*Иһ, тала-а-а, тала-а-а, тала-а-а,*
*Тала ике беләгем...*

Бу җырны ул бүгенге көн эстрадасы җырларын җырлаган кебек җырламый, борынгыча, ниндидер ыңгырашу белән, халыкның борчуларын, зарларын үз тавышы аркылы ишеттерә кебек иде.

*Нигә тала, нигә яна-а-а*
*Икән минем йөрәгем?..*

Кешедә бит бер генә йөрәк, ә аның фәлсәфәсендә, әйтерсең, ике. Берсе – аның гадәти яшәеше, ә икенчесе – халык моң-зарын үзенә сыйдырган рәссам йөрәге.

Бер рәсемендә ул гармун тотып җырлап утыра.

*Ай былбылым, вай былбылым...*

Бу да – халыкның күңеленнән чыккан моңлы җырларның берсе.

*Казан юлының маягы,*
*Уртасынды аның таягы.*
*Шул юлларда йөри-йөри,*
*Ямь тутырды яшь йөрәккә.*

Мин башта уйлый идем: «Нинди мәгънәсез җыр җырлый Әхсән абый», дип. Тора-бара, иҗат кешесе буларак, аңлый башладым, читтә яшәүче татарларга мөнәсәбәте турында язган, күңелгә тигән мәңгелек җырларның берсе икән.

Әхсән абый бик уңган кеше иде. Ул тәүлекнең 24 сәгатен эшләп уздырыр. Күбрәк бакчасында эшли, остаханәгә ул килгәләп кенә китә. Ияләргә шул бакчада чыктым, дия иде. Әлбәттә, Әхсән абыйның иҗаты турында мин бүген яңа сүз әйтә алмам. Аның иҗаты барыбызның да күз алдында. Кызыксынучыларга күргәзмә залларында эшләренең барысы да бар. Әхсән Фәтхетдинов иҗатын яктырткан китап та дөнья күрде. Түбәнкамалылар аны зурладылар, бик матур урында, үзе суларын эчкән чишмә янында, Кама елгасына терәлеп торган гүзәллек кочагында йортын булдырдылар. Болар өчен җитәкчеләргә рәхмәтле иде ул. Юбилей көннәрендә бу йорт Әхсән абый рухына зур мәртәбә булып халык карамагына тапшырылачак һәм «Әхсән Фәтхетдинов йорты» дип аталачак.

Әдәбият һәм сәнгать әһелләре дә аны ярата иде. Шагыйрь Зөлфәт Маликов «Остаханә» исемле олуг шигырен аңа атап язган.

*Ул хәлләрне син аңларсың инде...*
*Әхсән туган, тамырдаш ла син! –*
*Күктән ишеп яуган кардаш та син,*
*Таңда койган яңгырдаш та син!*
*...Фикерең хак, дустым...*
*Бу дөньяның*
*Юк-бар җилләрендә җиллибез! –*
*Җир астына кереп*
*Сеңеп яткан*
*Тамырларны гына белмибез...*

Әхсән абый үзенчәлекле шәхес иде. Мин озак еллар аның белән аралашып яшәдем. Аның төрле чакларын күрергә туры килде. Усал, шаян, йомшак, балалардай сөенгән чакларын... Иҗатка тотынса йомыла, дәшми торган булып кала. Эше беткәч тә бик тиз генә игә килә алмый торган иде. Бервакыт шундый хәл булды: Әхсән абый югалды. Беркайчан да эшенә, бакчасына хилафлык китермәгән кеше бакчада да күренми, остаханәдә дә уты сирәк яна. Беркөнне шулай очраклы рәвештә юлда очрады бу, бер кызны җитәкләгән. Авызы ерылган, чүпрәк сеткасы кулында, остаханәгә юл тоталар. Озак вакытлар бу матур күренеш дәвам итте. Җәй үтеп, көз җитте. Әхсән абый моңсу гына бакчага йөри башлады. Бу аның шушы кызга гашыйк булып йөргән көннәре икән. Кызыбыз Мәскәүдә сәнгать белгечен укып бетереп, ялга кайткан булган, көз көне китеп барган.

Әхсән абый юмор ярата иде. Шундый мәзәк тә йөри: бервакыт «Җидегән чишмә» кичәсеннән соң Илһам Шакировлар машинасына утырып Казанга китеп бара бу. Юлда барганда, болар «дөньяны матурлыйлар». Әхсән күбрәк сөйләргә яратканга, сөйли дә сөйли. Күп сөйләргә яратмаган Илһам, күрәсең, тыңлый-тыңлый йокымсырап киткән. Уянып китсә, Әхсән «Кара урман»ны җырлый, ә машина элдертә. Илһам: «Тукта, җырлама!» – ди Әхсәнгә. Әхсән: «Нигә, әллә сиңа гына җырларгамы?» – ди. Соңыннан бу хәлне Мөдәррис Әгъләмовка Илһам Шакиров: «Мамадышка килеп җитәбез. Йокыдан айныбрак китсәм, ишетәм, кайдадыр таулар ишелә, сулар шаулап ага, сыерлар мөгри, сарыклар кычкыра. Нәрсә булган, ахырзаман мәллә дисәм, Әхсән «Кара урман»ны җырлап бара икән», – дип көлә-көлә сөйләгән.



Әхсән Фәтхетдиновның «Ияләр»еннән күргәзмә.

Туганнарын зурлап яшәде ул. Нәрсә сөйләргә тотынса да, «безнең әти» (Сарим), әни (Мәгъмүрә), Мидхәт абзый, Әкълимә, Әхтәм, Әсхәтләрне гел исендә тотты. Аларга багышлап әсәрләр иҗат итте: «Әти», «Әни», «Умарталык иясе» (Әхтәмгә багышланган). Әхтәм Фәтхетдинов Әлмәттә яши. Озак еллар газета мөхәррире булып эшләде, язучы, шагыйрь, берничә китап авторы.

Бервакыт халыкта шундый сүз тарала: «Теге рәсем ясаучы Тукай булган икән!» Бу исем аңа дәүләтебез Тукай исемендәге премияне биргәч таралды. Халык бик шатланды.

Әхсән абый теләсә ничек, теләсә кайсы темага кулын тыкмады. Ул җәмгыятебезне борчыган сорауларга җавап эзләде һәм аларны халык белән уртаклашырга тырышты. Иҗатына күз салыйк әле:

Беренче цикл: Шүрәле. Халкыбызның мифологиясе, әкиятләре.

Икенче цикл: Ияләр. Аның иҗатында алар зур урын алып тора. Һәрбер нәрсәнең иясе булырга тиеш, бу – табигать законы. Адәми затларның әлеге законнарга буйсынасылары килми. Табигать, чишмә-урманнар, болын-елгаларның иясе булганда гына, матурлык сакланыр.

Өченче цикл: Портретлар. Бакый Урманче, Әти, Әни, Шукшин, Әгъләмов, Фәйзуллин һ.б.

Дүртенче цикл: Атлар. Татарның яшәеше атлар белән нык бәйле булганга күрә, атлар темасы аның иҗатында зур урын алып тора. Ботаклы-чатаклы такта кисәкләреннән күп атлар ясады ул. Марсель Сәлимҗанов әйткәндәй, ул атларның күзләре барысыныкы да татар күзләре.

Бишенче цикл: Баганалар. Гомеренең азагында иҗат иткән җансыз баганаларга җан кертеп, дөньядан китеп барды. Аның фәлсәфәсе – бу дөньядагы багананың да үз язмышы бар.

Әхсән Фәтхетдиновның үз баганасы.

Сынлы сәнгатебезнең биек, нык, какшамас баганасы!

**Рөстәм ГАЛИЕВ,**
*Туфан Миңнуллин исемендәге*
*Түбән Кама Татар дәүләт*
*драма театры җитәкчесе*

# ЭЛЬМИРА КӘЛИМУЛЛИНА: «МИН – ТҮБӘН КАМА КЫЗЫ!»



2012 елның декабре исегездәме? Беренче каналның «Голос» телепроекты меңнәрне, миллионнарны зәңгәр экраннар тирәсенә җыйды! Татарстан кызлары Динә Гарипова белән Эльмира Кәлимуллинаның зур җиңүләре! Котлау телеграммалары. Чәчәкләр белән каршы алулар. Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның җырчы кызларга «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исемнәр тапшыруы…

(«Голос» проектында 1,7 миллион шалтырату һәм смс хәбәрләрдән 33,6% телевизор караучы, ягъни 463 697 кеше Эльмира Кәлимуллина өчен тавыш биргән.)

Түбән Кама кызы Эльмира Кәлимуллинаны бөтен ил «Көмеш тавыш» дип таныды. Аны «Кармен», «Безнең Одри Хепберн» дип йөртә башладылар. Кайберәүләр социаль челтәрләрдә: «Пелагея белән нинди татар җырын башкарды ул Эльмира?» – дип кызыксынды. Әлбәттә, яраткан җыры «Син сазыңны уйнадың» белән таң калдырды!

Ә хәзер, әйдә, җиңүләрен, үсешләрен барлап карыйк әле.

Ул – илче. Җәйге Универсиада – 2013, Су спорты төрләре буенча Дөнья Чемпионаты – 2015, Туплы хоккей Дөнья Чемпионаты – 2015, Казан марафоны – 2015... Барысында да – Эльмира! XVII Бөтендөнья Җәйге Универсиадасын әзерләүгә һәм уздыруга керткән өлеше өчен РФ Президенты В.В.Путинның шәхси бүләгенә лаек булды! Гастрольләр, турлар, уңышлар…

Ул – актриса. Константин Хабенский куйган «Поколение Маугли» балалар музыкаль спектаклендә Эльмира матурлыкка, яхшылыкка өйрәтүче Багира роле аша бик җаваплы миссия башкара: котылгысыз авыруга дучар булган яшь тамашачыларга төрле кыен хәлләрдән чыгу юлы барлыгын, һәркемнең үз тормышын үзе теләгәнчә үзгәртә алырга сәләтле икәнлеген күрсәтә. Кояшка, тыныч күк йөзенә, яңгыр тамчыларына, янәшәңдә якыннарың барлыгына сөенә белергә кирәклекне искәртә.

Ул – җырчы. 2016 ел, март. Эльмира Кәлимуллинаның Татарстан буенча беренче концерт туры. Түбән Кама, Чаллы, Әлмәт, Казан алкышлый яшь җырчыны. Гастрольләре алдыннан социаль челтәрләрдә якташларын концертына дәшә: «Түбән Камада яшәүчеләрне һәм шәһәребез кунакларын чын күңелдән үземнең беренче аерым зур концертыма чакырам. Халык иҗаты йортына тормышымдагы зур вакыйганы минем белән бүлешергә килсәгез, бик шат булырмын!»

Ярата ул Түбән Камасын! Сагына!

«Ул минем туган шәһәрем! Әти-әнием, минем өчен бик кадерле булган туганнарым яши анда. Җай чыгу белән үк кайтачакмын. Түбән Камам, көт мине!»

«Талантлы балаларны, яшьләрне һәрчак күреп ала һәм үстерә, алар өчен төрле конкурслар оештыра, җиңүләргә канатландырып тора белгән Түбән Камадан мин. Илсур Рәис улы Метшин шәһәребез мэры чагыннан ук шундый инде ул Түбән Кама!»

Түбән Кама... Эльмира өчен ул гел якты, гел кояшлы. Һәр яктан яшел урманнар белән әйләндереп алынган күпкатлы ак шәһәр – әйтерсең, зур ак корабль! Яңа микрорайондагы зәңгәр, фирүзә йортларга карап, зәңгәр күзле Түбән Кама диясе килә. Наратлары да наратлары! Якташы, атаклы пейзаж остасы Иван Шишкин

картиналарында да шул наратлар бит инде! Эльмира ясаган рәсемнәрдә дә! Күп рәсемнәре туган йорты диварларын бизи хәзер. Алмагачлары ак чәчәкле майда да, алмалары пешеп утырган көзләрдә дә матур шәһәре! Киң урамнар, аллеялар, чәчәкләр… Алары да – күңелендә һәм… рәсемнәрендә. Түбән Камада урам исемнәре дә үзенчәлекле: Яшьлек урамы, Химиклар, Шинниклар проспектлары…Эльмираның әтисе Рамил дә, әнисе Лилия дә нефть химиясе шәһәрен төзүчеләр. Александра Пахмутова белән Николай Добронравов «Смелость города берёт» дигән җырны яшьлек каласы Түбән Камага багышлап язган, диләр. Эльмира кайткан саен Чулман яры буйларыннан, Красный ключтагы Изге чишмәләр тирәсеннән урый. Баскычлар, фонарьлар, беседкалар... Әллә нинди сихри бер почмак. Ай тулганда, әйбәт уйлар, изге ният белән килүчеләрнең теләкләрен чынга ашыра торган серле урын, диләр аны.

Мин тагын бер яңалык ишеттем: Эльмира Кәлимуллина «Бигеш» халыкара аэропортының «тавышы» булачак икән! Аның матур тембры озаклмамый пассажирларга игъланнар җиткереп, хәерле юл теләп торачак. «Сере бик гади: Эльмира – Түбән Кама кызы. «Бигеш» аэропорты да – Түбән Каманыкы. «Ил үзенең геройларын белергә тиеш», – ди аэропортның коммерция директоры.

Ул – шахматчы, телләр өйрәнә, велосипедта йөри, парашюттан сикерергә хыяллана, сәяхәтләр ярата (Америкага баргач, Сан-Францискода прокатка машина алып, бөтен Калифорнияне аркылыга-буйга әйләнүләрен, серпантин юлларны, гаҗәеп хайваннар дөньясын көлә-көлә искә төшерергә ярата ул. Исландиядә бензин беткәч, нинди маҗараларга очраулары хәзер көлке тоела...) Автомобиле тәгәрмәчле кечкенә өй кебек. Үзенә күрә бер дөнья, кызыклы хәлләрнең шаһиты. Концерт костюмнары, туфлиләр дә шунда. Ә «бөке»ләрдә – җырлый Эльмира. Мин аны менә шундый итеп тә беләм хәзер.

...Шактый еллар узса да, минем өчен ул һаман кара бөдрә чәчләрен ике толым итеп үреп салган, шомырттай күзләреннән очкыннар чәчеп торган 15-16 яшьләрдәге шук-шаян кызый. Иң беренче тапкыр аны 2003 елда Кырымда узган «Сөембикә варислары» фестивалендә күргән идем. Тере, үзсүзле, кызыксынучан, шат күңелле булып хәтергә уелып калган. Атаклы «Нәүрүз» балалар бию ансамбле, Илнара Хуҗиева, Марат Фәйрушин, Эльмира Кәлимуллиналар Түбән Каманың мактанычы иде ул чакта ук. Эльмира чия кызыл күлмәге белән әллә каян күзгә ташлана: кипарислар күләгәсендә дә, диңгез дулкыннарына кушылып җырлаганда да, уттай кызган йомры ташлардан ялантәпи йөгергәндә дә… Тәненә шоколад төсе дә кунгач, кырымтатар кызлары Алие, Әмине, Айшелар белән бутадылар үзен. «Мин – Эльмира, Түбән Кама кызы», – диде ул шул чакта, елмаеп. Ялтаның диңгез яры буе мәйданындагы концертта Эльмира, «Әдрән диңгез»не җырлап, халыкны таң калдырды.

Хәер, музыка аның тормышына бала чагында ук ныклап кереп урнаша анысы. Җыр дөньясына тартылуы Болгар авылында яшәүче әби-бабасыннан килә, диләр якташлары. Әтисе Рамил ягыннан әбисе – укытучы Мөнәвәрә апа – мандолинада, бабасы Мидхәт гармунда уйный. Әнисе Лилия ягыныкылар – Тимербаевлар да искиткеч музыкаль халык! Аларга башкорт далаларының, Урал тауларының моңы күчкән, күрәсең. Кыңгыраулы яшел гармунда уйнаган, вальска биергә яраткан Лотфулла бабай, моңлы тавышлы «тәти әби» Зәйтүнә, спектакльләрдә җырлы рольләрдә уйнаган Маһиҗиһан әбекәйләр… Ә әнисенең сеңлесе – Алия апасы музыка мәктәбендә Эльмираның беренче укытучысы. «Хәтерлим, Алия апа өйгә килеп, абый белән мине музыка мәктәбенә бирү турында сөйләшүләр алып бара башлады. Әнинең, билгеле инде, безне шәһәрнең бер башыннан икенчесенә йөртәсе бик килеп тормый. Болай да гимнастикага, биюгә чабам бит. Бәхеткә, шул елны икенче фатирга күчендек. Ә аннан музыка мәктәбенә биш минутта барып җитмәле. Шулай итеп, балалар музыка-хор мәктәбенең фортепиано классына йөри башладым. Пианистка булып музыка училищесына керәсем килә иде. Классик музыка, хор музыкасында тәрбияләндек без. Вокал классында Ольга Михайловна Сапёровадан дәресләр алдым. Әти белән әни миңа башлаган эшне ахырынача җиткерергә кирәген бик яхшы сеңдерделәр. Әй, бу ялкытты, кызык түгел, дип, әле бер эшкә, әле икенчесенә тотынып, берсен башлап, икенчесен ташлап йөрсәң, тормышта үз-үзеңне таба алмыйсың, дип аңлаттылар».

(Быел февраль аенда «Мечта» музыка-хор мәктәбен төрле елларда тәмамлаучыларны

С.Сәйдәшев исемендәге Түбән Кама музыка көллиятенә юбилейга чакыралар. Эльмира да кайта. Ак күлмәктән, дулкын-дулкын чәчләрен иңсәсенә таратып салган… «Умырзая», «В горнице», «Адажио» яңгырый.)

Шул бөтерчек кебек кыз ун яшендә үк, Түбән Кама шәһәре хакимияте призына үткәрелгән вокалистлар конкурсында катнашып, дипломант була. «Сандугач сайрар илем» гала-концертында исә Гран-прига лаек булуы аның юридик лицей тормышын 180 градуска борып куя! Бөтенроссия «Көмеш тавыш» конкурсында (Иваново), «Көмеш эдельвейс» халыкара конкурсында (Мәскәү) лауреат исемнәрен яулый. Югыйсә, милиция формасыннан иртәнге җидегә ничек тә гомуми тезелүгә соңга калмаска дип ашыккан, капитан приказын ялгыш кына үтәмичә, нарядтан тыш идән юган, хокук белеме, криминалистика, сугышчан көрәш төрләрен өйрәнгән, хәтта Макаров пистолетыннан да ата белгән, мәктәптә укыганда ук автомобиль йөртеп караган кыз. (Балачактан ук руль артына утырып йөрергә, зур «Джип»та Түбән Кама юлларыннан җилдерергә хыяллана ул.) Тугызынчыдан соң юридик лицейга түгел, музыка училищесына керәсе килә. Тавышың юк, дип кабул итмиләр. (Тавыш түгел, акча кирәген каян аңлап бетерсен соң кыз бала!) Музыкага бөтән борылып та карамыйм, дип, күз яшьләре белән кайтып кергән кызын тагын әнисе тынычландыра. «Кызма, әйдә, тормышыңны бер сәгатьтә үзгәртеп атмыйк. Фортепиано дәресләренә дә йөр, вокал, сольфеджио белән дә шөгыльлән, хорны да ташлама. Тормыш барысын да үз урынына куя ул. Иң кирәген генә сайлап алырсың ахырдан», – ди.

Максатчан кыз Казан университетының икътисад факультетын, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте академиясен тәмамлый. 2007 елда инде Казан дәүләт консерваториясенең эзерлек бүлегенә укырга керә. Менә шунда укытучысы Гөлнара Мурзиева күреп ала аны! Эчке темпераментын тоеп, тиешле юнәлештә үстерә. Тырыш, үҗәт, бик тә җаваплы бу кызга ышаныч белдерә. «Голос» проектында җиңгәч тә, иң беренче булып Гөлнара Рәгъде кызы смс-котлау юллый укучысына.

Без Эльмираны «Алканат» рок төркемендә «Бушлык патшалары» җыры белән хәтерләп калдык, Җәүдәт Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясендә Җиһан карчык такмаклары өчен яраттык, Эльмир Низамовның «Алтын Казан» мюзиклында сокланып тыңладык. Бүген композитор Эльмир Низамов белән уртак альбом яздыралар. Дискка исем уйлап тапканнар инде – «Рәхмәт сиңа» дип атала. Хыялы, тырышлыгы, максатчанлыгы, тәвәккәллеге белән Эльмира үзенең матурлыгын, талантын күрсәтә ала. (Инстаграмда Эльмираның elmiramatur аккаунтын искә төшереп, елмаеп куям.) Соңгы арада радиостанцияләр аның «Төнге учак», «Аксылу җыры»н, «Бәллүр чыклар» композициясен кат-кат яңгырата.

Сайтында ул үзе турында, шаяртып, «Сихерче» дип язып куеп, фанатларын шаккатырган иде. Серен болай аңлатты: «Сихерче – ул мистик образ. Тормышымда чынлап та шундый хәлләр булгалап тора: бер нәрсә турында уйлап кына куясың, нәкъ шулай килеп тә чыга! Мәсәлән, «Рубин» матчында миңа өч тапкыр Татарстан гимнын җырларга туры килде – өчесендә дә «Рубин» җиңде! «Голос» проектында да конкурстан узуны бик нык теләп йокларга яттым. Төшемдә коридор буйлап үтүемне, сәхнәгә чыгуымны, софитлар яктыртуын һәм… миңа бер кресло борылуын күрдем. Өндә нәкъ шул кабатланды! Уйлар материальләшә шулай…»

Яраткан язучысы Пауло Коэльо сүзләрен көндәлегенә тикмәгә генә күчереп алмагандыр инде: «Ахыргача үз язмышыңа буйсын. Һәм исеңдә тот: нәрсәнең дә булса чынга ашуын бик-бик теләсәң, бар Җиһан сиңа ярдәмгә киләчәк».

Шулайдыр, бик-бик тырышсаң, бик-бик теләсәң, шул уй-хыялларың белән янсаң, бар Җиһан синең якка борыладыр. Эльмира Кәлимуллинаның һәр көне, сәгате-минутлары үзенең тормыш шигаре күчәрендә әйләнә. Әнә бит нәрсә ди:

– Үз-үзеңә ышанырга, үзлегеңнән үсәргә кирәк. Кеше башка берәүдән түгел, кичәге «мин»еннән яхшырак булсын. Бүгенге Эльмира кичәге Эльмирадан бер карышка гына булса да яхшырак булырга тиеш!

**Эльмира ЗАКИРОВА**

# ИЛҺАМЛЫ ЕЛЛАР

...1965 елны Түбән Кама районында рус телендә «Ленинская правда», татарча «Ленин нурлары» газеталары чыга башлый. Шул ук елны «Ленин нурлары» газетасы каршында әдәбият түгәрәге оеша. Җитәкче итеп үзе дә шигырьләр язучы Камил Гыйльмуллин билгеләнә. Ә инде шәһәребезгә тынгысыз җанлы, ярсу йөрәкле Рахмай Хисмәтуллин, Айдар Хәлимнәр килгәч, күңелләрендә иҗат оеткысы булган яшь каләм тибрәтүчеләр, әдәбият сөючеләр саны бермә-бер арта, әдәби мохит түгәрәк кысаларына гына сыймый башлый, ул 1968 елның сентябреннән «Кама таңнары» әдәби берләшмәсенә әверелде. Җитәкче итеп Рәшит Юнысов сайланды. Җаваплы секретарь вазифасы Айдар Хәлимгә йөкләнде. Протоколлар язып баручы секретарь итеп Фәннүр Сафин билгеләнде. (Гаделлек өчен әйтеп үтәргә кирәк: бер ел чамасы эшләгәннән соң, Р.Юнысовны «Нефтехимик» газетасы редакторы булып эшләүче Минвәгыйз Зәйнетдинов алыштырды. 1970 елның 10 октябреннан 1987 елга кадәр бу мәшәкатьле вазифаны Рахмай Хисмәтуллин тартып барды.) Берләшмә әгъзаларының күбесе шәһәр төзелешендә, химкомбинат цехларында эшләүче гап-гади хезмәт кешеләре иде. Матур-матур шигырьләр язучы Мизхәт Хәбибуллин, Мөхәммәт Шәйхи – тимерләрне эретеп беркетүче; Фәннүр Сафин, Рифкать Имаев – Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсендә слесарь, аппаратчы; очерклар һәм хикәяләр остасы Мөслах Таҗи, Фәтхулла Абдуллиннар – прораб; Фәния Хуҗиәхмәтова кранчы булып эшләделәр. Кыскасы, әдәби берләшмә әгъзалары язылачак әсәрләренә «түл» җыеп, булачак геройлары арасында кайнап йөрделәр. Ә журналистлар Рахмай Хисмәтуллин, Айдар Хәлим, Минвәгыйз Зәйнетдиновлар турында әйткән дә юк. Бер караганда, аларны төзүчеләр арасында, икенче караганда, укытучылар яисә табиблар тирәсендә күрәсең. Шуның нәтиҗәсе буларак, Айдар Хәлимнең «Беренчеләр» һәм «Биктырыш», Рахмай Хисмәтуллинның «Үземне таптым», Фәтхулла Абдуллинның «Көмеш тәңкәле нигез» дип аталган, шәһәрнең елъязмасын тәшкил итүче китаплары дөнья күрде. Аларны шәһәр тарихын яктыртучы беренче карлыгачлар дип әйтергә кирәк. Ялкынлы публицист Айдар Хәлимнең «Беренчеләр» поэмасында шул чордагы романтик һәм шашкын хисләрнең ташкын булып ургылуын тоясың.

Әдәби берләшмә әгъзалары шигырьләр, хикәяләр язу белән генә чикләнмиләр, хезмәттәшләре турында мәкаләләр, очерклар язалар, мәктәпләрдә укучы балалар белән очрашулар, клубларда әдәби-музыкаль кичәләр үткәрәләр.

Ул чорда берләшмә утырышларына җырчылар, музыкантлар, рәссамнар да йөрде. Берсе – нефть-химия өлкәсендә булачак галим, икенчесе – режиссёр, өченчесе – инженер-конструктор Азат Зыятдинов, Наил Нуретдинов, Нил Садыйков; киләчәктә Г.Тукай премиясе лауреаты һәм халык рәссамы исемнәрен алачак Әхсән Фәтхетдинов кебек егетләр дә берләшмә әгъзалары белән бер казанда кайнады. Аларның төпле фикерләрен, акыллы киңәшләрен, сәяси бәхәсләрдәге саллы бәяләмәләрен без яратып тыңлый идек. Кыскасы, үткән гасырның сиксәненче-туксанынчы елларында шәһәребездә үсеп чыккан иҗтимагый хәрәкәт, төрле кичәләр «Кама таңнары»нда бөреләнде дип әйтергә тулы нигез бар.

Шәһәребездә Г.Тукай һәйкәле янында шигырь бәйрәме үткәрүне дә «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе башлап җибәрде. Хәзер бу чара шәһәребезнең мәдәният һәм мәгариф идарәсе белән берлектә ел саен үткәрелә.

Баштарак мәктәпләрдә, тора-бара шәһәр күләмендә Халыкара туган тел көнен, патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең туган көнен билгеләп үтү, һәйкәленә чәчәкләр салу да безнең традициягә керде. Шунысын да куанып өстәргә кирәк: бу чараларда

шәһәребездә көн күрүче башкортлар, таҗиклар, азәриләр дә катнаша. Татарлар белән бергә алар да шагыйрьгә чәчәкләр китерә.

Баштагы чорда рус телле язучылар да безнең берләшмәгә йөрде. 1975-1976 елларда алар мөстәкыйль «Данко» исемле берләшмә оештырдылар. Аерылышсак та, без иҗатташ дуслар булып калдык. Алар безнең шигырьләрне русчага, без аларның әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү гадәти хәл иде. Бу җәһәттән Лев Воздвиженский, Михаил Федосенко, Мөхәммәт Шәйхи үзләрен талантлы тәрҗемәчеләр итеп таныттылар.

Халкыбызга хезмәттә без «Ләззәт» һәм «Илһам» ансамбльләре белән кулга-кул тотынып эшлибез. Ансамбль җитәкчеләре Флүр Гайнемөхәммәтов, Илһам Хисмәтуллин һәм музыкант Азат Нәҗмиевләр безнең күп кенә авторларыбызның сүзләренә көйләр язды. Ралия Кәримова сүзләренә Илһам Яриев язган көй «Яланаяклы кыз» телевизион фильмында яңгыраса, Гөлчирә Ибәтуллина сүзләренә Вил Усманов язган «Төшемә керәсең» җыры Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы буенча төшерелгән фильмда уңыш казанды.

«Кама таңнары» әдәби берләшмәсендә канат ярган күп кенә шәхесләр дәүләт бүләкләренә һәм мәртәбәле исемнәргә лаек булдылар.

Кызганыч, «Кама таңнары» «мәктәбе»н узып, оста каләм ияләре булып өлгергәч һәм тагын да яңарак үрләргә күтәрелер вакытта арабыздан бик иртә китеп барган талантлы шәхесләребез турында үткән заманда гына сөйләргә туры килә.

Шунысы күңелне юата: «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе югалтулар кичерсә дә, югалып калмады. Үткән 50 ел эчендә әдәби берләшмәдә 200дән артык автор каләм тибрәткән. Шулар арасыннан 24 авторыбыз Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булу дәрәҗәсенә ирешкән. Журналистлар тагын да күбрәк. 200дән артык китап нәшер ителгән. Бу – зур байлык.

Бүген «Кама таңнары» әдәби берләшмәсендә утызга якын иҗат әһеле. Шулар арасыннан Фәтхулла Абдуллин, Рифкать Имаев, Илдар Хәйруллин, Марс Хафизов, Хөсәен Ягъфәр, Фәрит Имамовлар Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булып тора. Ике дистәгә якын китап авторы, 95 яшьлек Галимҗан ага Вәлиев, балалар өчен язылган 4 китап авторы, шигырьләре дәреслекләргә кергән Камил ага Гыйльмуллин һәм күптән түгел 80 яшьлек юбилеен билгеләп узган Һәдия Хәбибуллиналар исә шәрәфле әгъза булып исәпләнә. Гомерен яшь буынга аң-белем бирүгә багышлаган Галимҗан ага авыллар, мәктәпләр тарихын чагылдырган китаплары белән танылу алса, Һәдия апабыз шәһәр тарихын яктырткан китаплары белән укучылар күңелен яулады.

**Фәтхулла АБДУЛЛИН,**
*«Кама таңнары» әдәби берләшмәсе җитәкчесе,*
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе*

## Төзәтми тор!

Күпме шәһәрләрнең нигезенә
Без таш булып
Бу дөньядан күчтек!
Октябрьның давыл көннәрендә
Кызыл җилләр булып без ул истек!
Әмма һаман:
Ул – тарихның яман хатасы, дип,
Аны бары ваклап сатасы, дип,
Саттылар.

Галимнәрен артык акыллы, дип,
Шагыйрьләрен артык давыллы, дип, –
Аттылар.
Ә без һаман,
Мең-миллион корбан бирә-бирә,
ҖӘЛИЛ булып ташны комга теттек,
Төрмә диварларын тиштек!
Үлеп бетәр чорны күптән үттек!
Йөрәктәге үчне, нәфрәтләрне
Тау менгәндә без ат итеп җиктек.
Тегермәннән хәтта үткәрелдек,
Ә без һаман өскә күтәрелдек!
Кем әкияти Салсал көчен белә?
Уйнамагыз безнең исем белән!

**Рахмай ХИСМӘТУЛЛИН**

## Васыять

Тәкъдир әйдәп, язмыш куып йөрткәч,
Чит якларны бик күп таптадым.
Тик шуны бел: кайда йөресәм дә,
Синнән гүзәл җирне тапмадым.

Иң беренче баскан туфрагым син,
Син өйрәттең мине йөрергә;
Хәтфә болыннарда чәчәкләрдән
Матур такыялар үрергә.

Җиләк җыйдым хозур урманыңнан,
Зәйгә төшеп йөзеп уйнадым,
Җанга якын алсу таңнарыңны
Күз алдымнан мәңге җуймамын.

Энҗе чыклар элгән чәчәкләрең
Елмайдылар миңа, үз күрдең,
Йомшак җилләр белән иркәләдең,
Җырчы булсын дипме үстердең?

Моңлы сазым чирткән аваз килсә,
Җырларымнан мине танырсың.
Васыятем бу:
Гомер шәмем сүнгәч,
Куеныңа мине алырсың...
Яме, Туган Җирем?!.

**Мөслах ТАҖИ**

## Түбән Кама

Дөрес эшләгәннәр алдагылар,
Төзеп сине шушы урында.
Чишмәләрең җырлый тау астында,
Күп җырлары синең турында.

Мәхәббәтем синдә чәчәк атты,
Син шуңа да миңа бик якын.
Канатланып көн дә эшкә барам,
Яратырга, димәк, бар хакым.

Якты булыр синең киләчәгең,
Кичәгедән матур бүгенең.
Горурлыгы булсаң зур илемнең,
Син йолдызы – татар күгенең.

Түбән Кама һич тә түбән түгел,
Даны белән күпкә югары.
Минем кебек сиңа гашыйгы да
Дөньясында башка юк әле.

**Нурзия МИРХАЗОВА**

## Мин авылда яшәп ятам...

*Мин авылда яшәп ятам...*
Ленар Шәех

Мин авылда яшәп ятам,
Кибеттән шаккатып кайтам,
Бүген дә бәяләр арткан,
Гаепләп әйтү түгел.

Кануннар бар – үз көчендә,
Тигез кебек кем өчен дә,
Күпме халык зар эчендә,
Гаепләп әйтү түгел.

Телевизор сөйләп тора,
Сабырлыкка өндәп тора,
Тынычландыра һәр түрә,
Гаепләп әйтү түгел.

Пенсия күтеп ай уза,
Яшим шуны тарта-суза,
Кризис үтәр, китмәс нужа,
Гаепләп әйтү түгел.

Ничек табибка барырмын,
Ничек дарулар алырмын,
Ахры, ыштансыз калырмын,
Гаепләп әйтү түгел.

Басуларда билчән билдән,
Хуҗасызлык кайдан килгән,
Бәрәңге кайта чит илдән,
Гаепләп әйтү түгел.

Рекламалар һаман димли,
Татарстанныкын ал, ди,
Әллә дөрес, әллә алдый,
Гаепләп әйтү түгел.

Мин шәһәрдә яшәп ятам,
Шулдыр минем яшьлек хатам,
«Кара сакал» калмый арттан,
Гаепләп әйтү түгел.

**Никифор ТУКМАЧОВ**

## Тәгәрмәч

Кая бара
Мин яшәгән фани дөнья?
Кайчак башта
Шундый сәер уйлар туа.
Җир түгәрәк –
Әйтерсең лә зур тәгәрмәч,
Бөтенесе хәрәкәттә ул әйләнгәч.
Машинаны тәгәрәтә шул тәгәрмәч,
Очкычларны күккә чөя шул тәгәрмәч,
Орлык тарта,
Су чистарта шул тәгәрмәч,
Йөкләр ташый,
Акча ясый шул тәгәрмәч,
Сабый көлә шул тәгәрмәч тәгәрәгәч.
Сәгатьләрдә вакыт саный тәгәрмәчләр,
Җир йөзендә әйләнәләр тәгәрмәчләр,
Тәгәрмәчләр алып барыр дәверләргә,
Тәгәрмәчләр илтеп тыгар кабергә дә.
Кайвакытта туктап кала тыны чыгып,
Кыршау атып, сазга батып, теше сынып.
Куып җитә,
Узып китә кайсылары.
Хәйран калам бу тизлеккә
Һай, чыдармы?!
Күккә менеп, җиргә карыйм –
Вәт, пәрәмәч!
Әйләнә дә әйләнә бит
Шул тәгәрмәч.

**Гөлчирә ИБӘТУЛЛИНА**

## Туган телем – татар теле

Иман белән иңдерелгән,
Туган телем – татар теле.
Болгар бабамнар яшәгән
Татар җире, татар иле.

Синдә чишмә чылтыравы,
Сандугачлар сайравы.
Кичен бишек тибрәткәндә
Әнкәемнең җырлавы.

Син яшәсәң, татар яшәр,
Онытылмас җырлары.
Буыннан буынга күчәр
Халкыбызның моңнары.

Яшә, татар, бердәм булып,
Артсын милләтнең саны.
Бөтен дөньяга таралсын
Татарстаным даны!

**Рәфыйк ӘХМӘДИЕВ**

## Кайтып бара балачакка

Исәрләнгән диеп уйламагыз,
Җитмәгән дип яки айнып та.
Көтүгә дип, кеше торганчы ук,
Су чәчрәтеп йөрсә сайлыкта.

Сандугачлар җырын тыңлый-тыңлый,
Йә кочаклап торса талларын,
Чалбар балакларын чыкка манчып,
Каршыласа алсу таңнарны.

Зәй суына яссы таш ыргытып,
Ничә сикергәнен санаса,
Сәер карамагыз, чәчкә өзеп,
Күлмәк якасына кадаса.

Турылатып Калатауга менсә,
«Ни нужасы төшкән?» – димәгез.
Йөрсен, әйдә, арып-алҗып бетсен,
Тик җанына, берүк, тимәгез.

Таң сутында, ярлар яңгыратып,
Бер җырласын, әйдә, тыймагыз.
Сагынуын төяп, балачакка
Кайтып бара диеп уйлагыз.

**Фәнүзә САБИРОВА**

## Яшәп туймадым

Күзләр сагышлардан торса да,
Күз яшьләре битне юса да,
Һич китәсе килми дөньядан,
Мин бит әле яшәп туймаган.

Килер көннәр көйсез булса да,
Сабыр канатларым сынса да,
Өметемне әле җуймадым,
Мин яшәүдән һич тә туймадым.

Бу тормыштан артта калсам да,
Ялкынланмый гына янсам да,
Каләмемне читкә куймадым,
Юк, яшәүдән әле туймадым.

Күктә очкан соңгы торналарга
Саубуллашып яулык болгадым.
Сезгә атап җырлар язасым бар,
Мин яшәүдән әле туймадым.

**Рәсимә НӘБИУЛЛИНА**

## Кызыкмадым кеше малына

Тормыш юлын намус белән үттем,
Эшләдем мин йөрәк кушканны.
Җенем сөйми көнчел кешеләрне,
Әләкчене һәм дә куштанны.

Гадел булып яшәү тормышымда
Яшьтән сеңгән минем каныма.
Куштанланып мин дан яуламадым,
Кызыкмадым кеше малына.

Гөнаһларны, Аллам, ярлыка дип,
Сорамам мин үләр алдыннан.
Күпме булса даным, малым – бар да
Хәләл көчем белән табылган.

**Илдус ГОБӘЙДУЛЛИН**

## Мин яшим шигъри галәмдә

Мин яшим шигъри галәмдә,
Көз – алтынга күмеләм.
Язның сихри чәчкәләре –
Сиреньнәргә уреләм.
Телим икән, болытларда
Йөзеп йөрим утырып.

Авылымның чишмәсеннән
Су эчәм, уч тутырып.
Мин яшим шигъри галәмдә,
Җил булып очып китәм.
Тәүге сөйгән җан ярыма
Иртән сәламнәр илтәм.
Телим икән, җәйдә йөрим,
Каен җиләге җыеп.
Гаҗәпләнмә, шигъри җанны
Буламы әллә тыеп!
Мин яшим шигъри галәмдә,
Телим, тауларга менәм.
Серле шигърият илендә
Бер туам да бер үләм.
Мин яшим шигъри галәмдә,
Кояшка, айга очам.
Әй, шигърият сөючеләр,
Барыгызны да кочам!

**Рәмзия ВӘЛИЕВА**

## Миләшем

Тәлгәш-тәлгәш кызыл миләш,
Әче, диләр, тәмнәрен,
Җил-давылда, суыкта да,
Юк, югалтмый ямьнәрен.

Төсләрен дә һич үзгәртми,
Якын дус сыман миләш,
Авырлык басса иңнәрне,
Бирә күк изге киңәш.

Бар җиһанның матурлыгы,
Дәвасы сыйган – тоям.
Килеп сөялгәч кәүсәңә,
Бер җиңел сулап куям.

**Әлфия СИБГАТУЛЛИНА**

## Тузганаклар оча җитәкләшеп

Якты яз килүгә, җылы тоеп,
Сөю вәгъдә иткән бер таңда,
Юеш керфекләрен җилгә куеп,
Тузганаклар җирдә уяна.

Күз ачуга, нәфис ул йомгаклар
Сукмак буйлап йөгерә, еракка;
Аланнарга капкан сары уттан
Җылы назлар тоя йөрәк тә...

Баллы чәчкәләрне бар да сөя;
Ах, дигәнче үтә ул чаклар...
Төсләр уңып, чәчләр агарганда,
Парсыз калсаң, сине кем яклар?..

Тузганаклар оча җитәкләшеп;
Тузгыта җил тузгак башларын...
Сөенәмен шуңа язмышымда
Яр итмәдем Синнән башканы.

Бирсен Ходай, гомер көзләренә
Җитәкләшеп, бергә барырга;
Иңне-иңгә куеп атлаганда,
Җиңә алырбыз, кышын, карын да.

**Асия САФИНА**

## Тукай язы

Язлар белән ел да Тукай кайта,
Үзгәрмичә һаман яшь калып,
Сокланырлар килер буыннар да,
Яшәү өчен аннан көч алып.
Һәр ел саен язлар кабатлана,
Искә алып Тукай язмышын,
Яшьли киткән газиз Тукаебыз,
Бу, минемчә, язмыш ялгышы.
Зарланмаган Тукай, еламаган,
Бала чактан ятим калса да,
Асрамада яшәп, чит-ятлардан
Каһәрләү һәм каргыш алса да.
Таш бәгырьгә Тукай әйләнмәгән,
Күрмәсә дә сөю-назларны.
Әллә инде Тукай тугангамы,
Көтеп алам ел да язларны.
Укыган саен Тукай язганнарны,
Җанда туа яңа шигырьләр.
Тукай җаны белән сугарылып
Туа җирдә яңа шагыйрьләр.

**Гөлүсә НӘБИЕВА**

***

Кыш җиттеме, безгә яз кирәк.
Язы гына килсен – җәй кирәк.
Ул да үтсен – алтын көз кирәк.
«Кирәкми», диюче бик сирәк.
О, нинди ачы бу чынбарлык!
Сөенә-сөенә
Әҗәлгә каршы йөгерә кеше.
Бу да – чынбарлык.

**Камил ГЫЙЛЬМУЛЛИН**

**Илдар ХӘЙРУЛЛИН**

# ГАИЛӘ КРИЗИСЫ

Ишектән кереп килүче иренең хәлен хәләл җефете Гөлбәдәр бер карауда аңлап өлгерде. Эшләгән җиреннән акча күчермәгәннәр! Узган айда нәкъ шундый хәл килеп тугач, аннан йолкып, моннан бурычка алып, ике кредитларын ничек тә ерып чыга алганнар иде. Тик бу юлы алай булырга охшамаган, акча юк һәм тиз генә булмаячак та. Нишләргә?! Гөлбәдәр ачу белән: «Син – ир кеше, нишләп берәр әмәлен тапмыйсың? – дип, тыныч кына чәй эчеп утырган ире Фәндәрис ягына карап куйды. – Җитте, гарык, болай кредитка батып яшәп булмый. Ай башлануга, каян акча юнәтергә дип баш ватарга кирәк. Моңарчы тунсыз яшәдем әле, сораучы булганда иртәгә үк чыгарып сатам, сатам да, шул каһәр суккан банктан котылам. Мин ичмасам тормыш турында кайгыртам, барып чыкмый дип, бәргәләнгән булам, ә син менә нишлисең? Читтән карап торышка, машинага алган кредитыңа аз гына да борчылмыйсың кебек»!

Фәндәрис авыр сулап куйды. Иренең эчтән нидер уйлап йөрүен Гөлбәдәр күптән сизеп өлгергән иде инде. Фәндәриснең шулай берни дәшмичә, яшерен план корып йөрүе моңарчы юньлегә китермәде. Әмма ир инде ныклы карарга килгән иде булса кирәк: «Нишлисең дип, башыңны эшләтсәң, җае чыга аның. Беркөнне классташым Филария белән сөйләшеп тордык. Ул хәзер кайдадыр сату-алу эшендә, машинасы кибән хәтле, баеп беткәне әллә каян күренеп тора. Зарымны тыңлагач: «Синең кредитың минем өчен чүп кенә, әгәр сүземнән чыкмасаң, күз ачып йомганчы түләп бетерәм», – ди. Шуңа, карчык, миңа Филария янына китеп бераз яшәп алмыйча булмас, ахры. Нишлисең, бизнес – катлаулы нәрсә, әгәр акча эшлисең килсә, андый гына авырлыкларга түзми кая барасың».

Өстәл тирәсендә чәй ясап мәш килгән Гөлбәдәр, моны ишетүгә, кулындагы чынаягын идәнгә төшереп җибәрде. «Нинди авырлыклар ул, ни сөйлисең?! Беразга дигән булып, бай хатын янына бөтенләйгә таярга чамалыйсыңдыр әле, оятсыз?!» – дип, хәлсезләнгән хатын лап итеп артындагы урындыкка утырды.

Фәндәрискә: «Юк, бөтенләйгә түгел, машинага алган кредитымны түләп бетерүгә, шундук борылып кайтам. Илдә кризис, әнә депутатлар әйтүенчә, аннан чыгу юлын һәркем үзе эзләп табарга тиеш», – дип акланудан башка чара калмады.

Кичен киемнәре белән тулган зур сумкасын күтәреп чыгып киткән ире артыннан Гөлбәдәр озак кына уйга батып утырды. «Китте, кайтырмы, юк, кайтмастыр. Филария бай, үткен хатын, кулына килеп эләккәнне ычкындыра торганнардан түгел. Кредитын да түләр, Фәндәрискә яңа машина да алып бирер. Чит илнекен, иң кыйбатлысын. Ирләрнең яңа машина күрүгә күзләре яна башлый, димәк, мужикның кире кайтуы икеле. Ярар, кайтмаса кайтмас, төкереп бирә ул андый сатлыкҗаннарга! Монда кредитны ничек түләргә, менә күңелне нәрсә борчый. Их, бер уйласаң, бар инде ул акчалы ирләр. Туктале, нигә юкка баш ватарга, бар ул андый кеше, хәзер аның беренче ире кайларда йөри икән? Заманында берне түгел, өч тун алырга да риза иде. Алар кайчандыр, юк кына сәбәп белән, ду кубып аерылыштылар. Имеш, кемдер аның ирен яшь нәмәрсә белән ресторанда утырганын күргән. Күрмәгәйләре тагын, бер-ике кычкырышырлар да, шуның белән онытылыр иде. Ярар, әле дә соң түгел, Гөлбәдәр бармагы белән чакырса, йөгереп килеп җитәчәк. Дөрес, анысы мүкләкнең мүкләге

булды. Аның каравы, кесәсе калын. Гөлбәдәр дигәндә үлеп тора. Монда баш ватасы юк, менә кем аның кредитын каплаячак.

Бая гына чарасызлыктан интеккән хатынга җан кереп киткәндәй булды. Ул кәефләнеп, бар булган тавышына телевизорын акыртып җибәрде һәм ялгызы гына коймак белән тәмләп чәй эчәргә утырды.

Тик менә... Фәндәрис Филариядә озак тормады. Әйләнеп кайтты. Гөлбәдәр беренче ире янына китәргә өлгермәде.

Кредитны алар бергәләп түләп бетерделәр.

**Инсаф КАШАПОВ**

# АПТЫРАР ДИП УЙЛАМА...

Өстәге күршеләр атнага бер мәртәбә идән паласларын, башка чүпрәк-чапракларын, минем балкон тәрәзәләренә шыпылдатып бәрә-бәрә, рәхәтләнеп болгый-болгый, тузаннан арындыралар. Шул мәлне якты көн караңгыланып киткәндәй була. Саф һавага кытлык булса да, ачылган тәрәзә форточкаларын ябып куярга мәҗбүрсең. Күрәләтә тузан иснәп ятып булмый бит инде! Әле аның күзгә күренми, борынга гына сизелә торганнары да күп...

Күршеләрне әйтәм, болай карап торуга интеллигентный гына күренәләр. «Ник шулай кыланасыз?» – дип әйтергә телем кычытып тора торуын – әйтмим. Күршеләр бит, уңайсыз, тешләремне кысып булса да түзәм инде...

Болары – өстәгеләре, ә менә астагы күршеләр көн саен, аталы-уллы, балконда тәмәке көйрәтәләр. Иснең кайдан килгәнлеген чамалап, тәрәзә форточкаларыңны япканчы, башың авырта башлаган була инде. Болары да бик культурныйга охшаганнар. Хуҗа кешене, аталарын әйтәм, ике-өч тапкыр күзәтеп торганым бар: башта бармаклары белән борынын тотып сеңгерә дә аннан кесәсеннән кулъяулык чыгарып сөртеп куя. Культураның бер күрсәткече инде бу! Боларына да: «Ник балконда тәмәке тартасыз?» – дип кычкырасы килә килүен, кәнишне. Күрше хакына түзәм инде...

Сул як күршеләрнең алтынчы класста укучы малайлары бар. Шул малай мәктәптән кайтып, өйгә бирелгән эшләренә тотынгач, тагын бер мәхшәр башлана. Сабыйны әнисе ачы, тупас тавыш белән, бөтен подъездны яңгыратып орыша башлый. Бу тавышка беркем дә түзә алмас иде! Малай, мескен, чыдый – әнисе бит. Мин – күрше булганга түзәм.

Уң як күршене әйтәм, чүплектән фанера, такта, борыс кисәкләре җыеп кайта да, көне буе пычкы выжылдатып, электр шомарткычын гөжелдәтеп, шак-шок чүкеч тавышлары чыгарып, базарда сатар өчен тартмадыр, урындыктыр ясый. Үзе, болай, укыган кеше, эш кенә таба алмый. Аңар да күзләрен тишәрдәй итеп карап, каты гына: «Бу тавышлануыңны ташла син, энем!» – дип әйтәсе килә килүен, күрше шул – түзәм...

Бу дөньяның асты-өскә килгән заманда, күңелне тынычландырыр өчен, минем дә үз хоббием бар. Өч бүлмәле фатирымның бер бүлмәсендә көймә, скутер, мопед моторлары ремонтлыйм мин.

Моторларны җыеп бетерүгә, кабызып җибәреп, аларга обкатка ясыйм. Глушительгә, ягъни төтен чыккан торбага, шланг ялгап, күршенең балконына төтен җибәрәм. Дөпе-дөпе итеп эшләгән мотор тавышына кушылып, җырлап та җибәрәсе килә башлый:

*Үзең ничек, мин дә шулай,*
*Аптырар дип уйлама!..*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Камил ШӘЛЕ**

## Уйланыгыз, наданнарым!

БЕРКЕТМӘ

Мөхәммәт Мәһдиевтән башлап Фатих Хөснигәчә тезелгән утыргычларда берән-сәрән генә язучылар күренә. Илдар Юзеевның өстәл тартмасыннан бер бит чиста кәгазь табып алдылар. «Беркетмә өчен шушы җитәр», – диде Марсель Галиев һәм каләмен йодрыклап тотты. Ул проза секциясенең секретаре, күп язарга күнекмәгән, бүгенге сүз чамасын үзе беләдер... Секция җитәкчесе Атилла Расих, ачык форточкага төбәп, тамагын кырып куйды.

Атилла Расих. Тагын бераз көтеп карыйк, килүчеләр булмаса, утырышны башларбыз.

Мансур Вәлиев. Белдерүне ачыграк язасыгыз калган. Яшь язучыларныкын тикшерәбез, дигәнсез... Кемнекен, ни булган... аңлашылмый.

Атилла Расих. Җыелышсак әгәр, сөйләшер сүз беткәнме!.. Егетләр, менә мин, һөнәрем буенча мал врачы буларак, бүгенге әдәбиятта күзгә төртелеп торган бер төгәлсезлекне әйтеп үтәргә телим. Билгеле, һәр язучының берәр яраткан хайваны бар: Айтматов этләр ярата; Фатих абыйның да эте бар; Гарәфинең кош-кортлары; минем үземнең дә яраткан бер кәҗәм бар иде. Хәер, сүзем атлар турында. Бик күп яздык инде. Тик ат организмын белеп бетермибез бит. Әйтик, без чабыш вакытында атның кулкасы суга дигән уйдырманы еш кулланырга өйрәндек. Ләкин бит, җегетләр, атның эч куышлыгында шап-шоп иткән тавыш чыгаручы нәрсә кулка түгел... ул... ул айгырның... домкраты, йөгергәндә, күкрәк куышлыгында як-якка суга. Бияләрнең кулкасы суга, дип язу – бик зур наданлык ул!

Мөхәммәт Мәһдиев. Атилла абый, сез хайваннар буенча бик зур белгеч инде, әйтегез әле, эчүгә сабышкан язучыларның калак сөяге астына нindidер тимер кыстырып калдыралар ди. Дөрес сүзме бу?

Атилла Расих. Әйе, киң таралган ысул. Тимер кисәге нindidер исерек ионнар бүлеп чыгара дип беләм, шуңа күрә аракының үзен күрүгә үк күңел болгана башлый ди.

*(Җыелыш башын аска иде.)*

Мөсәгыйт Хәбибуллин. Көн тәртибенә күчик инде.

Фәрваз Миңнуллин. Бүлдермә, Мөсәгыйт, сөйләсеннәр, тоже бик важный тема бит бу безнекеләр өчен.

Фатих Хөсни. Әйдәгез, башлыйк утырышны, юкса бөтенләй йокы качты.

Атилла Расих. Пожалысты... Бүгенге утырышка 46 прозаик килергә тиеш иде, барысына да чакыру кәгазе җибәрдек. Шуларның сигезе бирердә. Тәкъдимнәрегезне әйтегез...

Мансур Вәлиев. Бер сәгать утырдык бит инде. Башласак та була.

Атилла Расих. Без яшь язучылар Кояш Тимбикова белән Разил Вәлиевләрнең яңа повестьлары турында сөйләшергә дип җыелдык.

Марсель Галиев. Авторлар үзләре дә юк бит. Разил – командировкада.

Кояш: «Әйтер сүземне «Тәңкәле тау»да әйтеп бетердем, тикшерүгә килеп йөрмим», – диде.

А т и л л а  Р а с и х . Тем лучше. Исегез китмәсен, Разил өчен, әнә, Әхәт Гаффарга карап сөйләрсез, ә Кояш урынына, әнә – Ләбибә бар. Йә, кайсысын башлыйбыз.

Р е п л и к а л а р . Разилне, Разилне!

А т и л л а  Р а с и х . Түрдәгеләр, сүз сезгә бирелә.

М ө х ә м м ә т  М ә һ д и е в . Мин әле Разилнең кулъязмасын укып өлгермәдем, шулай да сөйләргә була... Мәсәлән, исеме – «Яшисе килә» дип куелган. Бик ялтыравык исем. Исемнәр... *(Исем фигыль, атау исемнәр, исемнәрнең килешләргә төрләнеше турында ярты сәгатьлек чыгыш*).

А т и л л а  Р а с и х . Рәхмәт, Мөхәммәт, үзеңнән соң сөйләүчегә сүз дә калдырмадың. Мин, шәхсән, бу повестьны җентекләп укып чыктым, шуңа күрә болай иркенләп сөйли алмам. Әсәр үзенең темасы белән ошады миңа.

М ө с ә г ы й т  Х ә б и б у л л и н . Повестька романтика җитми.

М а р с е л ь  Г а л и е в . Геройның әти-әнисе исән, шуңа күрә дә авторга ирек җитми.

М а н с у р  В ә л и е в . Әсәрнең документлары чиста.

А т и л л а  Р а с и х . Фатих абый, сез дә әйтегез инде!

Ф а т и х  Х ө с н и . Кояш турындамы?

А т и л л а  Р а с и х . Юк, Разил турында.

Ф а т и х  Х ө с н и . Син, Ләбибә, яклап маташма!

Л ә б и б ә  И х с а н о в а . Нишлисез, Фатих абый?! Тик кенә утырам ич, ләм-мим!

Ф а т и х  Х ө с н и . Ләбибә түгел – Ләм-мимә син! Ә Кояш турында әйтергә кирәк. Ник Болгар шәһәрендә казынып йөри ул? Нәрсәсен югалткан?!

М а р с е л ь  Г а л и е в . Болгарны яклап чыкмасак, бүген-иртәгә чувашлар аны үзләренеке итәчәк.

Ф ә р в а з  М и ң н у л л и н . Көн тәртибенең башланган пунктын түгәрәкләп куяргадыр: «Яшисе килә» повестен тулыландырыр өчен авторның үзенә кире кайтарырга кирәк.

М а р с е л ь  Г а л и е в . Соң инде. Ул повесть «Казан утлары»ның апрель санында чыгып килә.

Ф ә р в а з  М и ң н у л л и н . Димәк, өлгереп була.

М а р с е л ь  Г а л и е в . Наданнарым, аңлагыз! Разил Вәлиевнең бу повесте инде Җәлил премиясенә тәкъдим ителде. Банкетында утырганда, йөзегез кызарыр бит. Лапа!

А т и л л а  Р а с и х . Марсель, бу сүзләреңне беркетмәгә өстәмәсәң дә була... Җәмәгать, ике сәгать утырдык, әйдәгез, тәнәфес ясап алыйк!..

*Язучыларның «Тынгысыз каләм»*
*дивар газетасыннан.*
*Март, 1982 ел*

Сәхифәне **Марсель ГАЛИЕВ** әзерләде.

**Игътибар!**

Хөрмәтле абунәчеләребез! 1 сентябрьдән 2017 елга газета-журналларга, шул исәптән «Казан утлары» журналына язылу башланды. Басмабызга элемтә бүлегендә **73210 (Татарстаннан читтә яшәүчеләр өчен), П2365(Татарстанда яшәүчеләр өчен)** индекслары белән язылырга мөмкин. Юридик затлар өчен индекслар – **16262 (Татарстаннан читтә яшәүчеләр өчен), П2368 (Татарстанда яшәүчеләр өчен)**.

Киләчәктә дә бергә булыйк!



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу – безнең сәхифә!



*Мин, Хәерова Ләйсән Ринат кызы, 1998 елның 1 октябрендә Әлмәт районының Мәмәт авылында туганмын. 6нчы сыйныфка кадәр Мәмәт урта мәктәбендә белем алгач, 7нче сыйныфка Әлмәт шәһәренең Ризаэтдин Фәхретдин исемендәге татар гимназиясенә укырга килдем. 6нчы сыйныфтан шигырьләр һәм кечкенә хикәяләр яза башладым. 2016 елда «Ак җилкән» Бөтенроссия әдәби әсәрләр конкурсында Гран-прига лаек булуыма, танылган әдипләрдән киңәшләр алуыма бик шатмын. Мондый чаралар яшь каләм ияләренә җилкәннәр куя, иҗатка үсендерә.*

*Быел, мәктәпне тәмамлап, КФУның Г.Тукай исемендәге Татарны өйрәнү һәм тюркология югары мәктәбенә укырга кердем. Биредә татар әдәбиятын үзләштерүне һәм иҗат эшен дәвам итәрмен дип өметләнәм.*

# КОЯШ ХАЛКЫ

ХИКӘЯ

## Кышкы кич

Су буеннан чана тартып үтеп киткәндә, авылга төн юрганы ябылган иде. Салкын һаваны хәтта тотып карап була сыман. Сәфинә борынын бияләйләре арасына яшерә дә: «Әнкәй, салкын ич!» – ди. Аның чеби тавышы аяк астындагы кар шыгырдавы аркасында ишетелми дә. Ләкин ана сизенеп борылып карый: «Төн безнеке, кызым, төн безнеке!» – ди. Алар тагын атлыйлар, авыл башында урнашкан өйгә кадәр – ләм-мим. Сәфинәнең йокысы килә, авыр күз кабаклары ябыла, ә нәни аяклар һаман кар ера. Тыкрыктан үткәндә, кайсыныңдыр печәнлегендә кыштырдаган тавыш ишетелә. Ул тавыш үзенә чакыра, ул тавышка барсаң, җылыга эләгерсең сыман.

Кая баралармы? Өйләренә кайталар. Авылның түбән очындагы өйгә таба атлыйлар. Үткән тормыштан качарга маташып, әнисе тиз-тиз атлый. Сәфинә исә, берни аңламыйча, аның артыннан йөгерә. Артта әби-бабасының буш йорты кала. Салкын җил, күрәргә кеше юклыгын белгәндәй, өйнең кирпеч диварларына, ишек төбенә кар себерә. Ана белән кызны юлдан яздыра, күзне томалый.

Фаягөл апаның ире юк. Күптәннән инде узган яшьлекнең хатирәсе булып Сәфинә тора, хатынның бөтен эш-гамәле кызын кайгыртуга юнәлгән…

– Әни, салкын ич! – дип тагын дәшә кечкенә Сәфинә.

– Атла әйдә! Мин нишләтим! – Фаягөлнең тавышы артык кырыс килеп чыкканга, кызчык тынып кала. Үпкәли.

Ә әнисе, аның тирән итеп тын алуын тыңлап, авыр бер сулый да, иренен тешләп, искә төшкән хатирәләр белән көрәш башлый…

Йорт капкасыннан килеп керүгә, Фаягөл белән Сәфинә телсез калдылар. Бозланып каткан тупсада бер ир-ат утыра иде. Өсте-башы кап-карадан, үзеннән бераз зуррак пәлтә, киң бүрек, һәм шул бүрек астыннан ялтырап торган күзлек пыялалары. Кайтып кергән хуҗаларны күргәч, ир-ат сикереп торды, карны шыгырдаткан ике адым ясады.

– Ник кайттың? – Фаягөлнең кырыс карашы ирне туктатты.

– Менә… Прәннекләр алып кайттым… Сәфинәгә…

Хәлилнең үз гаиләсе юк. Фаягөл белән аерылганнан бирле, ул теләсә кайда эшләп, яшәп йөри. Яңа гаилә табарга кыюлыгы җитмәдеме, әллә кире кушылуга өмете бармы – монысын үзе дә белмидер ул, мөгаен. Тик кайтып йөри менә шулай, кызын күреп, гаилә учагында җылынып, кире салкын кышка таба чыгып китә. Фаягөл жәлли дә аны, аңлыйдыр да, тик кабул итә алмый. Читкә этәрә. Хәлил калдырган яралар инде тартылса да, бу очрашулар хатынның шул яраларына бармак белән күрсәтеп көлү иде. Төнне Хәлил залдагы диванда кунды. Фаягөл аны чәй эчерде дә Сәфинә өчен генә куна калдырды. Кызчык исә әтисе белән уйнарга керешкән. Әниләре, бу икәүнең бергә курчак уйнатканына карап, кайнар чәйнеккә кулын пешерде. Урамдагы җил тына төште, ләкин иртәгәсе көнгә ул тагын кубачак…

## Буран

Иртәнге аш вакытында Хәлил, кыюланып, төп сүзен башлады.

– Фаягөл дим… Миңа, алиментлардан баш тартам, дигән кәгазь язып бир әле!..

Хатын кулындагы алмаларны буш савытка ыргытты. Үпкә тулы күзләрен яшерде дә тирән сулыш алды. Аның һәрбер буыны каткан, йөрәге тагын яна башлаган иде.

– Шуңа гына кайттыңмы? Кичә әйтергә кирәк иде аны!.. Нигә шулхәтле озак көттең? Бала кирәкмәсә килеп йөрмиләр аны! – Хатынның үз тавышына исе китте. Елан ысылдавы, мәче мырнавы ишетелә иде кыскан теш арасыннан чыккан тавышта.

– Шулай дип әйтәсеңне белдем, Фаягөл! Кирәк миңа бала, кирәк! Ләкин эш табып булмый бит! Мин акча җибәрермен! Ләкин вакыты мөһим булмасын!..

– Кит! Югал күземнән! Бүген үк кит! Язып бирәм, кая каләм?! Йөрмәс идең, ичмасам, баладан да оялмыйча! Ник котыртасың аны?!

– Фаягөл! Ник кычкырасың?! Булышам, дидем бит! – Хәлил берни аңламаган гаепле кыяфәт белән утыра бирде. Ә хатын инде кабынып, тузынып киткән иде. Күңеленә мәңгегә сеңгән үпкә Хәлилгә яхшы мөнәсәбәттә булырга ирек бирми, хатынны телгәләп тора.

– Безгә синнән берни кирәкми!!! Ычкын! – Фаягөл гариза язган кәгазь битен Хәлилнең каршысына ыргытты, ирнең киемнәрен тутырган сумканы ишек төбенә чыгара башлады. – Кит! Баланы котыртып йөрмә! Кит!

– Фаягөл! Ни булды соң әле?! Нигә кешечә сөйләшә алмыйбыз без! Бәлки, миңа да гаилә кирәктер?!

– Нинди гаилә-ә-ә?! Нинди гаилә?! – хатын Хәлилнең өс-башын күздән кичерде дә, сәләмә киемнәре, иске бүрегенә бармагын төбәп: – Үзеңне дә карарлык хәлдә түгел ич син! Нинди гаилә-ә-ә! – дип җикеренде.

– Син гомер буе шулай иттең!!! – Ирнең дә сабырлыгы чигенә җитте: – Гомер буе мине битәрләдең! Минсез китә идең җыелышларыңа да, корпоратив кичәләргә дә! Нинди ир идем мин сиңа?!

– Хәзер син миңа беркем дә түгел! Ничек итеп мин сине дусларыма күрсәтим соң?! Син бит… син бит!.. Хатын-кыз җыелган җиргә ничек алып барыйм сине?! Юк! Бетте! Бар, ычкын!..

Ишегалды тутырып акырган ике кеше тавышын күрше-фәлән дә ишетмәслек түгел иде. Фаягөл тузынып өйгә кереп киткәч, Хәлил урам як эскәмиягә чыгып утырды. Салкын кар аркасын өшетте, аякларын өтеп алды. Күрше Сафа бабай, килеп:

– Хәлил, болай акырып йөрмә! Килешми ул! – дип әйтеп карады. Хәлил исә, күзлеген төзәтеп, кире өйгә кереп китте.

Тавышка Сәфинә дә уянган иде. Җылы юрган астыннан аны ачы тавышлар чыгарды, йокымсырап, аш бүлмәсенә таба атларга мәҗбүр итте.

– Бар, ят! Кереп кит! – дигән сүзләр коелды Сәфинәгә, ул акрын гына кире йокы бүлмәсенә керде дә киенергә тотынды. Әтисе белән әнисе тагын кычкырыштылар, әллә нәрсә ишелеп төште. Куркынып, җиде яшьлек бала бүлмәдән чыгып йөгерде.

– Сәфинә! Бар, кереп кит! Йөрмә монда! Хәзер китә ул! – дип кычкырды Фаягөл.

– Юк! Син миңа шуны гына әйт: мин сиңа ни эшләдем?! Эшләгәнмендер, булгандыр, тик нигә син кичермисең?! Барыгыз өчен дә начар мин! Сәфинә! Синең өчен дә мин начар! – Хәлил дә күкрәгеН салкын һава белән яра-яра кычкыра иде.

– Бетте, Хәлил! Бетте! Талак! Без аерылышкан! Без чит кешеләр! Менә гариза – кит, зинһар өчен, кит! – Фаягөлнең тавышында күз яше ишетелде.

– Китмим! Без әле сөйләшеп бетермәдек!..

Фаягөл утынлыкка таба атылды да пүләннәр арасыннан чүкеч алды!

– Кач! Ыргытам! Кит! – дип яный башлады.

– Әйдә, ыргыт! Үтерүче булырсың! Чирле бит син! – Хәлил капкага таба чигенде.

– Юк! Мин хәзер участковыйны чакыртам! – Фаягөл Хәлилнең беләгенә барып ябышты, аны ишегалдына өстерәп кертмәкче булды.

– Кит! – дип, Хәлил хатынны этеп җибәрде. Анысы исә бирешмәде.

Бер-берсенә ябышып, ир белән хатын тартыша башлады. Бу тамашаны баядан бирле карап торган кызчык икесе арасына атылып барып керде, бала көче ике зур кешене аеру өчен җитмәде. Куркуыннан, әнисенең сугышуыннан, атасының үз йөзен җуйганыннан куркып, Сәфинә кычкырып җибәрде. Фаягөл:

– Бар, ычкын!!! Кереп кит! – дип ырылдады.

Сәфинә, әнисенең ялкынлы карашыннан куркып, өйгә атылды, тупсага абынып егылды, торды, икенче тупсада да идәнгә очты... Күз яшьләре инде күптәннән аның карашын томаладылар, егылгач бәрелгән башы әйләнеп китте. Сәфинә үпкәдән, куркудан тагын кычкырып җибәрде. Юк, бу бала-чага чинавы түгел, бәби чәрелдәве дә түгел иде. Бу – бала күңеленең өзгәләнүе, кыргый җанварның тавышына охшаган бер тавыш иде. Сәфинә туктый алмады. Сулкылдый-сулкылдый елап, тагын бер кычкырды. Тамагы ярылырдай, күзләре атылып чыгардай булды кызчыкның... Ләкин ул туктый алмады. Әллә кайдан, тамак төбеннән килгән тавыш тәрәзләрне дерелдәтте, хәтта ишегалдында талашучы ике кешене дә бермәлгә тынып калырга мәҗбүр итте...

## Битлекләр

Кыш үтеп, язларга аяк басканда, Сәфинәнең хәле авырая төште. Яшәргә шәһәргә күченеп килгәннәр иде. Әнисе аны хастаханәләрдә йөртте, психологик ярдәм күрсәтте, иң яхшы табибларны эзләде. Ләкин кызчык инде адашкан, югалган иде.

Әллә инде кышкы буран алып китте, әллә тавышы белән бергә чыкты Сәфинәнең ачык аңы. Әллә баш мие күзәнәкләре хыянәт итте, күзләре алдый башлады кызның, тик кешеләр үз тышкы кыяфәтләрен җуйды. Әнисе генә үз кыяфәтен саклап калды.

Урамдагы гади кешеләрдән дә читкә тайпыла башлады кыз. Каршыга килгән хатын-кызның ул матур күлмәге белән җирән чәчен генә түгел, ә, мәсәлән, муенына сарылган еланны да, кул сөякләренә ябышкан тәңкә акчаны да, аякларына уралган авыр ятьмәләрне дә күрә иде.

Ә кешеләр төрле була. Сәфинә гади кешедән күбрәк күрде, күргән саен тагы да сәеррәк, тагы да авыру булып тоелды. Үз табибы да аңа кара чәчләрен ат койрыгыдай җыеп куйган, куллары ниндидер ак буяуга манылган, күзләре исә рентген утларыдай янып торган килеш күренә иде. Әгәр дә аңардан сорасалар, Сәфинә моның барысын да сөйләп бирә, аннары әнисенең елаганын тыңлый.

Шул ук елның язында Сәфинәнең әбисе үлеп китте. Кызның берничә айга телсез калуы Фаягөлне тетрәндерде, елатты, табиблар эзләп йөгерергә мәҗбүр итте. Сәфинә

исә кайбер табибларның куллары беләгенә кадәр канда икәнен дә күрә иде. Кыз алдында бөтен кешеләр дә битлекләрен салдылар. Сәфинә туп-туры аларның күңеленә карады, ә менә үзенекенә күз салырга куркып яшәде.

## Мәктәп

Сәер, газиз баласын Фаягөл мәктәпкә җибәрергә курыкты. Өйдә генә укытмакчы иде, табиблар аңа, бәлки үтәр, диеп, кызны барыбер яшьтәшләре янына җибәрергә тәкъдим иттеләр. Сәфинә исә, көненә йөзләгән кешене гадәти булмаган рәвештә күрә башлагач, башы әйләнеп, арып беткән иде. Укытучыларның калак сөяге каләмнән икән, канатлары китаптан икән, дип сөйләде ул әнисенә.

Бәлки, классташларына да мондый серләрне сөйләмәсә, Сәфинәгә тискәре мөнәсәбәт булмас иде. Ләкин ул бик тиз «башсыз» исемен алды. Дусларыннан аерылды, шулай унбиш яшькә кадәр үсте.

Беркөнне партадашының җилкәсенә сәләмә кара курчак кунуын күрде ул. Курчак әрсезләнде, егетнең муеныннан кочты, колагына нидер пышылдады... Соңыннан гына Сәфинә ул егетнең исерткеч эчемлекләр белән мавыгуын белеп алды. Кычкырды, курыкты, егетне кисәтте... Көлкегә калды. Өенә кайтып елады. Күзләрен чытырдатып йомып, тасма белән бәйләп куйды. Арыды ул. Кирәкмәгәнне күреп бик нык арыды... Бөтен балачагы «яңа» күзләргә ияләшеп үтте баланың. Фаягөл исә, моны күреп, төннәрен йокламады, гаебен сизеп, үзен битәрләп туя алмады.

Кызның табибы, Сәрия Хәйдәровна, баланы «социальләштерү» кирәк, дия иде. Инде савыга алмагач, авыруын яшерергә өйрәнсен, кешеләрнең тышкы кыяфәтен генә күрсен, диде. Ләкин Сәфинә тагын булдыра алмады.

Тарих дәресе алдыннан Сәфинә Лилия исемле классташының кулларына, күкрәгенә, җилкәсенә карамый булдыра алмады. Кыз аны кулыннан тотып коридорга алып чыкты. Сәфинә Лилиянең кулындагы канлы яраларны, һәм иң мөһиме – күкрәгендәге кап-кара яраны күрми калмады.

– Ни булды, Лилия? – дип дәшкән иде, классташы башта көлде, аннан елап җибәрде. Үги атасы кыйнаганмы шунда...

Лилия бик озак елады. Сәфинә аның күкрәгендәге яраның читләре киңәюен күреп куркуга калды. Юатты, башка чакта миңа дәш, дип киңәш бирде... Эх! Күргән яраларны дәвалап та булса иде!

## Әби

Күкләр безнең тормышны карап торадыр, мөгаен. Киресенчә булса, Сәфинәгә ярдәм күктән төшмәс иде. Иң туры мәгънәсендә. Әллә Сәфинәнең күзләре тагын алдады, әллә инде, чыннан да, әбисенең өрәге күренгәли башлады.

Сәфинәнең аңа хәзер исе дә китми. Менә беренче очрашу, әйе, кызык килеп чыкты... Кыз салкын тидереп, күтәрелә дә алмыйча чирләп китте. Көннәр буе өйдә берүзе утырып, берни кыла алмагач, тышка чыкмакчы булды.

Муенын яулык белән урады да, ишеккә таба килгәч: «Чирле килеш кая барасың?» – дигән сүз ишетте. Кыз сискәнеп китте, баш авыртуын авырта да, ләкин буш өйдә тавышлар ишетерлек булгач инде... Ул тизрәк ишеккә таба юнәлде. Һава кирәк.

– Кая киттең, дим?! – Сәфинәнең тезләре калтырап куйды, йөрәге чәнчеп алды.

– К-кем? – дип дәште ул. Бәлки, күрше-фәлән кергәндер...

– Әбиең, – дигән гади генә җавап ишетелде.

Әбисе инде күптәннән юк иде Сәфинәнең, ул аны хәтерләми дә ич...

– Кем?! – Сәфинәнең башы әйләнеп китте, ул ишек тоткасына гына тотынып калды.

– Мин синең белән булырмын, – диде йомшак тавыш. Сәфинә ышанды...

Нигә ышанмаска? Аның тормышында гади әйбер юк ич!

Җәйге кичләрнең берсендә Сәфинә әбисенә шулай дип дәште:

– Синең кимчелегең беләсеңме нәрсәдә?

– Соң? – ап-ак киемле карчыкның шәүләсе кызга төбәлеп карап тора башлады.

– Син уйлап чыгарылган. Син юк, – диде Сәфинә, буш урындыкка карап. Ләкин анда, һичшиксез, кемдер утыра иде, чөнки куе эңгер-меңгер эченнән тавыш ишетелә.

– Ярар соң, берүзең утыр! Мин киттем. Әнә, кояш чыккан, түбәләрне әйләнеп килим, – дип сөйләнде кемдер, һәм ашыкмыйча гына ишеккә таба юнәлде.

– Юк! Тукта! Мин нишлим берүзем? Син миңа кирәк! – дип дәште Сәфинә.

Ишеккә таба юнәлгән тавыш туктады. Ул калачак. Һичшиксез, бүген кояш соң чыга бит.

Әллә кайдан килеп чыккан әбисе яшүсмер Сәфинәгә дус булды. Кыз инде үзен, бәлки, авырудыр, дип тә уйлады, күземә дә күренә дип уйлады. Ләкин соңгы чиктә килеште. Әбисе шәүлә сыман килеп чыга да аның янында утыра, сөйләшә иде. Сәфинә ышанды.

Сәфинә өй эшен эшләргә кереште. Бүген тагын классташы белән талашты ул. Әллә ни генә килеп чыкты да, ырылдаша-ырылдаша, Сәфинәгә пычрак сүзләр ишетергә туры килде. «Мондый кыз берәүгә дә кирәк түгел, Сәфинә!» – дигәне генә истә калган. Ак дәфтәргә яшьләр тамды.

– Ни өчен алар минем белән шулай?! Нишләдем мин?! Булыштыммы?! Ә мин күрдем! Ул малайның җилкәсендә сәләмә чүпрәктән тегелгән курчак утыра! Аны миннән башка беркем күрми! – Сәфинәнең күзләреннән яшьләр тамды.

Карчыкның йөрәге әрнеде. Ул оныгын килеп кочты. Сәфинәгә исә салкын җил искән кебек булып китте.

– Кызым, алай димә. Әйтмә син беркемгә дә ни күргәнеңне!

– Сиңа әйтүе җиңел ул! Үзең минем урынымда булсаң!.. – дия-дия өзгәләнде Сәфинә...

Кыз әнисенең ишек ачып кергәнен сизми калды. Фаягөл кызының тавышын ишетеп бүлмәсенә керсә, исәнләшергә дип ачкан авызын яба алмады. Сәфинә үксеп-үксеп кемгәдер нидер сөйли иде. Аннары йөгереп барып һаваны кочып алды. Әнисе селкенә алмыйча кызын күзәтте. Тезләре калтырап, диварга тотынып, хатын акрын гына идәнгә шуып төште.

– Җиңеләйгән!.. – дигән уй үтте ана башында.

Икенче көнне бөтен бүлмәне яктыртып кояш чыкты. Сәфинә уянып тәрәз янына килгәндә, әбисе тәрәзә пыяласына маңгаен терәп басып тора иде. Өрәк кояшта җылынып маташа. Диварларда пәрәвездәй шәүләләр йөгерешә, ә идәннең кояш төшкән җире җылынган инде.

– Әби, син гел минем белән булырсың бит? – дип дәште Сәфинә, зәңгәр күкне төрле төскә буяучы кояшка карап. Ул үз эченнән генә нидер уйлап куйды. Өрәкләр генә кояшка шулай карыйдыр, мөгаен...

– Әлегә сине якларга кирәк. Сине кайгыртып торучы җан дустың табылганчы, мин синең белән булырмын...

Сәфинә дәшмәде. Сөлгесен алып, юынырга чыгып китте. Әбисенең ябык гәүдәсе кояш нурында югала кебек тоелды аңа. Кыз йөгереп барып әбисен кочып алды...

## Таһир

Таһир белән алар ялгыш кына очраштылар. Сәфинә тугыз катлы йортның түбәсенә менеп, шәһәрне күзәтеп утыра иде. Юк, ул бер дә кырмыска хәтле кешеләргә карамый, ул күккә, кояшка карый. Шундый зур, якты кояш аның күзләрен нурлар белән сыйпый, дәвалый сыман.

Тузан оча, кояш йорт түбәләрен эретә, сизелер-сизелмәс җил антенна чыбыкларына бәйләнә. Шәһәр кызу май кояшы астында эри иде. Ләкин Сәфинәгә яктылык кирәк. Аның кебекләрне «кояш балалары», диләр бугай. Аңа да кояш кирәк, биеклек кирәк, канатлар кирәк!

Кинәт кенә түбәгә чыга торган люк шапылдап ябылды. Бетон плитәләр өстеннән тагын бер кеше атлады. Кеше Сәфинәне күрмәде дә. Куенында нидер качырып, ул түбәнең капма-каршы ягына китте. Бер читкә утырды. Сәфинә тыныч кына люкка таба атлаган иде, ләкин кеше кинәт борылып, аны күреп калды. Кыз үзенә төбәлгән зәңгәр күзләргә бик озак карап торды.

– Менә... Күгәрчен очырам, – диде егет, көлемсерәп.

Бу Таһир иде. Ул кичне кыз белән егет ак күгәрченне күккә очырдылар. Таһир аның каерылган канатын дәвалап маташкан икән. Шул көннән ул Сәфинәне дәваларга кереште. Ике йөрәк арасына сөю чаткысы да чәчрәде бугай. Ак күлмәкле кызны Таһир үзенең күгәрчененә охшатты. Ләкин бу кошны инде ул җибәрмәс!..

Кыз бу егет янәшәсендә үзенә куркыныч янамавын аңлады. Таһир аның яшәү мәгънәсенә, нурларында җылынып кояшына әйләнде. Таһирның җилкәсенә еш кына кошлар куна, күзләре исә кояштай яна – шуны күрә Сәфинә.

## Ул – минем профессия

Кояш! Кыз бу тормышны кояшта күрә. Ул җылыта, ул зур, ул – яктылык!

– Улым, Сәфинәң белән кайчан таныштырасың? – дип дәште Айрат абый, улының хат язып утырганын күреп. Ата йөрәге үзенең яшьлеген исенә төшерде.

Таһир көлемсерәп кенә куйды. Аның әле бу серле кызны чит кешегә күрсәтәсе килми. Сәфинә ул – сер, чәчәк, кояш.

Беркөнне әнисе, аш пешереп йөргән җирдән, улына ымлап:

– Сәфинәңне ташла, улым, – дип сүз башлады. Таһирның карашы әнисенә төбәлде, йөрәге ике тибешен төшереп калдырды, тыны кысылды.

– Нәрсә?

– Мин ул кызны бик яхшы беләм. Ул – минем профессия, – диде Сәрия Хәйдәровна. – Син аның күзенә тузга язмаган әйберләр күренгәнен беләсеңме, улым? Миңа авыру онык кирәк түгел!

Әнисе табиб Таһирның. Педиатр. Психолог.

Егетнең башына пүлән белән китереп суктылармыни, аның карашы томанланып китте. Әнисе Сәфинәнең серен кире яктан, ышанырга теләмәгән яктан ачты. Аның нурлы йөзен ямьсез төскә буяп куйды.

– Юк. Юк! Нинди «авыру онык!» Нинди «авыру Сәфинә?» Ул сәер булса да, мин аны... аны...

– Гомерең буена интегеп яшисеңме аның белән?! Күзенә әллә ниләр күренә аның! Кояшка текәлеп утыра ул!

– Мин дә күрәм аның кояшын, – диде егет тыныч кына.

Ананың кулындагы кашыгы идәнгә килеп төште. Таһир инде ишекне ябып чыгып киткән иде.

Әйтергә кирәк Сәфинәгә! Бик кирәкле, бик мөһим сүзләр әйтергә кирәк! Аның күңелен кояш яктысыннан аерырга ярамый!..

– Сәфинә! – Әбисе елаган оныгына төбәлгән.

– Нигә?! Күрәм! Бар! Аның... Җилкәсендә... Курчак... Кара... Курчак... – дип кычкырды Сәфинә. – Ул... начарлыкка... өйрәтә... Ул...

Кыз һаман классташының җилкәсендә яман курчак күрә иде.

Әбисе дә андый курчакларны бик яхшы күрә. Юк. Кызда чир түгел. Кызда – сәләт. Ул яман өрәкләрне күрә, кешенең начар якларын белә!

– Таһирның гына җилкәсендә ак күгәрчен! – дип үкседе кыз, озын чәчләре белән яшен сөртеп. Аның яшьләре кояш нурында энҗе бөртегедәй җемелдәп алды.

– Кызым! Булды! – дип дәште карчык. Кызны кочып алды. – Мин сиңа ышанам! Ләкин син кешегә сөйләмә андыйны! Сереңне белдертмә!

– Алар ышанмый! Мин чирле түгел! Алар! Бу җәмгыять чирле! Кояш баласы, имеш!

Кояш җылы! Алар исә боздай салкын бер таш кисәге! Кешеләр! – дип нәфрәт белән кычкырды кыз. Тавышы утырганчы өзгәләнде.

– Китмә, әби, – дип елады аннары. Кызга кеше кирәк. Дус кирәк. Ышанучы кирәк.

...Дүшәмбе көнне алар Таһир белән тагын түбәгә менделәр. Егет кызга әйтәсе сүзләрен үз эченнән генә күп тапкыр кабатлады. Бетон плитәләр, кич җитүгә карамастан, һаман җылы. Кояш, түбә читенә кунгандай, бер ноктада эленеп тора.

– Сәфинә, мин сине яратам, – дип дәште Таһир.

Сәфинә моны белә. Үзе дә өзелеп сөя. Ләкин егет тагы нидер әйтергә тели. Мәхәббәт – иң мөһиме түгел.

– Мин гел синең белән булырмын! Мин сине ташламамын! Мин синең кояшыңны күрәм, Сәфинә! Мин сиңа ышанам!

Сәфинә елмайды. Кулын күтәреп, Таһирның җилкәсендәге күгәрченне сыйпады. Егет исә кызның һаваны капшаган кулын гына күрде.

– Сәфинә! – Кыз кинәт борылды. Күкрәгендә әллә ни болганды, чәлпәрәмә килде.

Әбисе! Ул бит хәзер китәчәк!

– Нигә әйттең миңа?! Нигә?! Ул китә! – дип кычкырып җибәрде кыз, Таһирның кулларын этеп җибәреп. Егет берни аңламады.

Чөнки Таһир табылды! Хәзер аны кайгыртучы бар! Ә әбисе китә!!!

– Ул гаепле түгел, кызым! Ул – синең кояшың, терәгең! Бәхетле бул, кызым! – диде Әнисә карчык, түбә читенә таба атлый-атлый.

Аның ябык гәүдәсе кояш нурында ялтырап тора. Назлы йөзе әллә нигә елмая, ак яулыгының очларын җил тарткалый.

– Юк! Кал! Син миңа кирәк! – дип кычкырды кыз, өрәк артыннан йөгереп.

Сәфинәнең күзләрендәге яшьләр әбисенең күзендә дә пәйда булды.

– Хуш!

Әнисә карчык борылып китте. Ул туп-туры түбә читенә кунаклаган кояшка таба атлады. Ераграк киткән саен, аның гәүдәсе яктыра барды. Сәфинә күзләрен куллары белән каплады, яктылыкка түзә алмыйча, күзен ачмады. Инде ап-ак нур гына калганда, кыз түбә читенә, әбисе киткән якка таба йөгерде. Ул үзенең тугызынчы катта икәнен бөтенләй онытты...

Сәфинә өрәктән калган ак нурда адашты, як-ягына каранды, һавадагы энҗе бөртекләрен учларына җыйды. Түбә читенә йөгерде. Тизрәк! Куып тотарга! Калдырырга! Әби!

Таһир кызны түбә читендә тотып калды. Аныңча, кыз сикермәкче иде.

Сәфинә аңа яшьле күзләрен күтәреп карады. Кызның иреннәре калтырады, нидер пышылдады.

– Син! Синең аркада китте ул! Таһир! – дип кычкырды Сәфинә, егетне этеп җибәреп.

Таһир берни дә аңламады. Кызның нигә елаганы да, кем белән хушлашканы да аның өчен сер иде. Ул Сәфинәне, башыннан сыйпап, берсүзсез кочып алды.

– Син! – дип һаман кычкырды кыз, кайнар яшьләрен сөртеп. – Син!

– Тынычлан.

Кыз Таһирның кочагында озак елады. Үзе яратты ул аны бу минутта, үзе күрә алмады. Егет үзенең кояшын кочагында качырды. Бөтен кешедән, бөтен кайгыдан, бөтен сагышлардан качырды.

– Кояшым минем! – диде Таһир, Сәфинәнең күзләреннән яшьләрен сөртеп. – Кояшым!

Кояш нуры белән тулган түбә читендә Сәфинәдән кала беркем дә юк. Ул берүзе, кемнедер кочаклаган кебек, кулларын сузып, үксеп елый иде.

# БӘЛӘКӘЙ РӨСТӘМ*

## Туган як яме

Мин үземнең туган авылыма, аның тирә-ягына, кешеләргә гашыйкмын. Безнең яктагы чыпчыкларның чырык-чырык килүләре башка җирдәге сандугачларның чут-чут сайравыннан матуррак, ягымлырак, назлырак тоела миңа. Җилләре дә, нинди генә булсалар да, көчлеме, талгынмы – мине танып, битемә кагыла төсле, иркәли сыман. Каргасының карылдавы да күңелгә рәхәтлек биреп тора, билләһи. Авыл тыкрыкларында безнең ялан тәпиләрнең эзләре күптән җуелган инде. Ләкин күңелемдә, хәтеремдә алар бар да саклана әле.  Кайларда гына булсам да, бик еракларда йөрсәм дә, сыер мөгрәүләре, сарык бәэлдәүләре, эт өрүләре, әтәч кычкырулары, тавык кытаклаулары, каз каңгылдаулары колагымда һаман яңгырап тора.

## Дөньяга күз ачу

Мин – Чаллы районының Чыршылы авылында 1952 елның 2 февралендә туып үскән малай. Шунда укый башладым. Әнием дә, әтием дә укытучылар иде. Әтине Үзбәкстанга укытучы итеп җибәргәннәр. Ни өчен шулай иткәннәрдер – анысын белмим инде. Шуннан сугышка да алганнар. Сталинград сугышына эләгеп, каты гына яралана да госпитальдә ята. Башына күп яралар алып, контужен булып, бер кулын юньләп күтәрә алмыйча кайтып кергән кеше ул. Шул контузиясе аркасында аңа инде укытырга рөхсәт итмәгәннәр. Сугышта аның башыннан кичкән хәлләрдән берсен миңа Бәкер бабайның улы Бәширов Равил сөйләде – ун ел чамасы элек бу. Мин шуннан ирләр арасындагы чын дуслыкның нинди булганлыгын белдем.

Бәкер бабай – безнең авыл кешесе. Аның унбер баласы бар иде. Сугышка хәтле ундүрт яшьлек кызга өйләнеп киткән кеше ул.

Сугышта, алгы сызыктагы гаскәрне тулыландыру өчен, яңа солдатлар алып киләләр. Әтине госпитальдән соң алгы сызыкка җибәрмәскә булалар. Ул, araларында якташлар юк микән дип, боларны карап йөри дә күрә: Бәкер бабай! Күрешәләр. Кочаклашалар. Шуннан соң әти Бәкер бабайны, безнең частьта калсын әле дип, сорап калдыра.

Бер атакадан соң Бәкер бабай кайтмый. Әти, күңеле ниндидер афәт сизеп, эзләргә чыгып китә. Яу кырын байтак таптый ул. Бер заман караса, ярты гәүдәсе күмелгән Бәкер бабай ята. Алып кайта инде әти… Алар фронттан да бергә кайталар…

## Балык булу рәхәт түгел икән!

Без гаиләдә өч бала үстек. Мин – уртанчысы. Миннән олысы, апам – Энҗе, кечесе – Алсу исемле.


Туганнан туган бер абыебыз гаиләсе белән Камчаткада яши иде. Авылга еш кайткалыйлар һәм алар миңа бервакыт кармак алып бирделәр. Балык тотарга ярата идем мин. Малайларның күз явын алырдай кармак иде бу. Балыкка төшкәндә ничек итеп кармакны еракка атарга кирәклеген өйрәнеп барабыз. Болай итеп аталар, юк, менә болай итеп, дип осталык күрсәтеп бара торгач, берсенең кармагы минем борынга килеп эләкмәсенме! Чыгарып кына булмый бит. Җебен кисеп, мине күрше авыл амбулаториясенә алып киттеләр. Анда кармакны келәшчә белән кисеп чыгардылар. Врач апаны «Патыйма апа» дип йөртәләр иде.

* Ганиев Рөстәм Мәҗит улы — *Бөтендөнья Татар конгрессының Түбән Кама бүлеге рәисе, Россиянең һәм Татарстанның атказанган физкультура хезмәткәре, Түбән Кама шәһәр советы депутаты, «Шинник» спорт комплексы директоры.*

## Эшкә ярый башладым

Элек, без үскән вакытта, печән бик юк иде бит. Бар иде ул, ләкин кеше малны күп тота иде. Печәнне гел сатулашып бүләләр инде. Ул чорларда урман чистарту эшенә йөрде кеше. Май урталарында ук китәләр дә аннары процентка печән чабалар. Мин аларга виләсәпид белән ашарга ташыйм. Менә аларның андагы чәйләренең тәмлелекләре! Аннары инде чүмәләләр өеп куялар да, монысы кемгә, монысы кемгә дип, мине артка борып әйттерәләр иде. Бүлеп бетергәч, Бәкер бабай тальянын сызып җиппәрә. Әй, матур да уйный инде! Күңелнең әллә нинди җепләренә хәтле дерелдәп куя.

Анда аларның, патшадан калган дип әйтәләр, зур өстәл кебек бер ташлары бар. Имеш, патша шул тирәдән үткәндә туктап, шуның өстендә чәй эчкән. Булгандыр, булгандыр – бик матур таш ул, өсте тигез, шома. Тарихта билгеле бит, патшаның юлы Минзәләгә барганда шушыннан үткән, Минзәлә янындагы күперне дә «Әби патша күпере» дип йөртәләр ич.



Печән чабучыларның өстәл кырыенда шалашлары да бар иде. Шул агач ботаклары һәм печән түшәп ясалган шалаш эчендә яту рәхәтлеген сөйләп аңлату мөмкин түгел.

Мин хыялга чумам. Күктә йөзсәң дә, җиргә төшәсең шул.

Урманчыдан калган процент өлешен төяп, бастырыклап өйгә алып кайтасың. Мин печән өстендә. Уйланам, күктә ак болытлар, әнә самолётның ак юл эзләре калган, менә шул күренеш минем күңелдә очучы булу теләген кабызып җибәрде. Их, ак юл сызып авыл өстеннән узасы иде бит бер!

## Печән өстендә

Печәннең мәшәкате күп бит аның.

Аны иң элек чабасы бар. Чалгыны мин сигез, тугыз яшьләрдә тота башладым. Ә менә тырманы, сәнәкне печәнне әйләндереп киптерергә яшьрәк чакта ук тоттыралар иде. Мин бу эшләрне бик яратып эшләмәдем, әлбәттә, ләкин ашыйсы килә бит. Әти-әнигә булышу– куанычлы гамәл. Әйткән сүзне тыңларга кирәк. Эшләмәсәң, уйнарга да чыгармыйлар бит. Каймагы да эләгә, сөтен дә мул чөмерәсең, маен да калын итеп ягып ашыйсың. Эшләсәң, баштан сыйпап мактыйлар: «Улыбыз булдыра!» – диләр. Рәхәт.

Аннан соң печәнне абзар түбәсенә тутырасы бар бит әле. Безнең түбә өчпочмаклы. Шунда мине менгерәләр. Почмакларына тыгызлап тутырырга кушалар. Белсәгез иде андагы печән тузанын. Борынга, авызга гына түгел, колак тишекләренә хәтле тула иде. Төчкертә, йөткертә, тончыктыра. Әле сәнәк очыннан да сакланырга кирәк. Астан ыргыткан печән кире төшеп китмәсен өчен бик зур осталык сорала анда. Бу эшне гел мин башкардым. Апам белән сеңлемә кушыйммыни инде?! Таптап өй, таптап өй, диләр. Малай гына булсам да, егетлек күрсәтәсем килә – кушмыйча да үзем түбәгә менәм.

Шулай эшләп үстек.

Аннары бит әле шунысы бар: печәнне алып кайтасың, түбәгә тутырырга өлгерми каласың – яңгырга эләгә. Яңадан таратып киптерәсең инде!

Әй ул печән әзерләүләр!..

## Чатаклы шаянлыклар

Яз көне малайлар белән боздан бозга сикерешле уйный идек. Елга буйлап бер-берсенә бәрелә-сугыла бозлар ага. Каршы якта – чирәмлек. Без анда учак көленә күмеп бәрәңге пешерергә чыга торган идек. Шунда боз өстендә сикереп ярышабыз. Шулай бер тапкыр елга уртасында суга төшеп киттем. Әмма ләкин ничектер бозларга ябыша-ябыша үрмәләп чыктым барыбер малайлар ягына. Нишләп көләсез дип әйтмәкче идем, тагын чумдым. Ярый әле йөзә беләм. Тагын чыктым да өйгә йөгердем. Бөтен киемне салып ыргыттым да мич башына менеп утырдым. Эштән кайткач, әни бик яхшы гына эләктерде үземә. Әти әллә ни кул күтәрми иде, әни бирә инде кирәкне. «Чукынмыш!» – дип каты итеп чеметә иде ул. «Әйттем бит мин сиңа, әйттем бит мин сиңа!» – диеп үтерә иде чеметеп.

## Хоккей уйный идек

Безнең кырыйда сиксән гектар алма бакчасы бар иде. Шуның җиде гектарын әтигә сакларга бирделәр. Җилкәсенә ау мылтыгы да астылар. Тоз белән ата торган патроны да бар. Шул мылтык күңелне гел кытыклап торды, ләкин мин аңа, иң өстемә асып йөрүдән гайре, кагылмадым.

Ул вакытта Чаллыдан Минзәләгә юл салалар иде. Без икенче сменада укыйбыз. Ут юк. Кнәз дигән авылга йөреп укый идек ул вакытта – анда урта мәктәп. Биш километр ара. Моңа хәтле дүрт классны укыган идек, шунда тагын дүртенчегә барып кердек, авыр булмасын дип. Бишенче класста укыган чак булгандыр, белдем, юл салучыларның прожекторлары бар. Караңгы булгач, без икенче сменадан соң хоккей уйный алмыйбыз бит инде. Юлчылар миннән алма сорыйлар. Мин әйтәм, бер капчык алма бирәм, прожекторга алмашып, дим. Нәрсәгә сиңа прожектор, диләр. Безгә хоккей уйнарга кирәк, дим. Ә Рафаил дигән дус малайның абыйсы электрик иде. Кайткач, куя баганага, төне буе уйныйбыз.



Шулай иттереп мин бер капчык алманы прожекторга алмаштырдым. Сөйрәп кайттым шуны авылга. Ара ике чакрым чамасы. Әни, мине күрде дә:

– Сине бит утырталар, – ди. – Бар, илтеп бир кире.

– Юк, – мин әйтәм, – илтмим, бу безгә хоккей уйнарга кирәк!

Менә шундый көчле иде бездә уйнау дәрте! Аннары елга өстендәге бозны да үзебез чистарта идек.

Без шул елларны Чаллы командасын 15кә 8 исәбе белән җиңдек. Безне чүт кыйнап кайтармадылар. Туганнар гына саклап калды.

## Һавалы хыяллар

Элек авылда машиналар аз иде бит инде. Машина күренсә, артыннан чаба идек. Берсенең ике көпчәге арасына шешә кысылган булган. Мин куып җитә алмадым да, инде кире борылган гына идем, башыма шул шешә килеп бәрелмәсенме!.. Аның хәтта төбе дә чәлпәрәмә килгән иде. Мин исә аңсыз егылдым. Арбага салып алып киткәннәр. Озакламый айнып, күземне ачтым. Күрәм, зәңгәр күктә ак болытлар... Менә шунда тагын очучы буласым килү исемә төште.

Ниһаять, 10нчы классны тәмамладым һәм лётный мәктәпкә киттем. Анда барганчы комиссия үтәсе әле. Комиссия үтеп йөрим – минем ангина бар, гландалар. Наил дигән дус малай белән Чаллыга барып, операция ясатып, тамак төбендәге гландаларны алдырдык. Ә 28 апрельдә соңгы көн – Казанда комиссия үтәргә кирәк. Кыскасы, өчме-дүртме генә көн өйдә яттык та, безгә проезднойлар бирделәр, Казанга киттек, Бөгелмә аша. Юлда үтереп ашыйсы килә бит. Поездда андый нәрсә юк. Плацкарт вагонда барабыз. Шунда мин шыгырдап каткан коржик ашап, тамак төбендәге яраны ачтым. Гөбердәп кан ага башлады. Туктамый гына бит! Инде проводница да күрде, алдыма чиләк куйды, тыштан кар алып керде. Карны муенга куеп катыралар, янәмәсе. Инде болар, элемтәгә кереп, мине Ульяновскидагы Тимер юл больницасына озаттылар. Врач әйтә:

– Сынок, что ты делаешь над собой? – ди. Сүгә инде.

Мине анда әлләниләр кыландырып бетерделәр дә, боларга әйтәм:

– Минем бит бүген соңгы комиссия үтәсе көн...

Шуннан соң кулыма әллә нинди пичәтле кәгазьләр биреп, самолётка утыртып җибәрделәр Казанга. Шулай итеп, Татвоенкомат врачларына күренеп, комиссия уздым.

Авылга кайттым. Шулвакыт Бәхтегәрәев Тәлгат абый – ул «Урожай» спорт оешмасында безне йөгертүче, чаңгыда чаптыручы – миңа, ди, Казанга команда җыеп барырга кирәк, ди. Әйдә, син бар әле анда, училищега җитешерсең, вакыт күп, ди. Инде хәзер мин «Урожай»да ярышка барырга проезднойлар, билетлар, командировочныйлар көтеп

утырам. Берзаман мине эзләп таптылар. Син бит инде Оренбургта, лётное училищеда булырга тиешсең, диләр. Мин бу ярышны ташладым да, Наил дигән малай Чаллыга матай белән йөри иде, утыртып китте мине. Военкоматта юл документларын бирделәр, Оренбургка киттем. Училищены таптым. Гагарин укыган училище ул. Комиссия уздым. Тикшерделәр. Анда биш километр биеклектәге атмосфера басымын барлыкка китерәләр. Синең колакларың, припонкаларың кызармаска тиеш. Шул шартларда 45 минут утырасың. Минем уң як колак сынатты. Димәк, ангинаның чалымнары үзен сиздергән иде. Шулай итеп, мине сыздылар. Әлбәттә, бик борчылдым. Проезднойларның көче беткәнче дип кайтып киттем. Кайтышлый Әлмәт физкультура техникумына кердем. Анда минем белгән кеше, халыкара спорт остасы Фирдәүс абый Шәимов укыта. Сөйләштем. Шуннан соң без, Чыршылыдан дүрт малай, аның булышлыгы белән техникумга укырга кердек. Бөтенебез дә чаңгы буенча специальләштек.

Без бит инде ул вакытта даими рәвештә хәрби комиссариатта тикшерелеп торабыз. Шундагы майор Чумаков әйтә: «Сиңа Сызраньга барырга кирәк иде, анда колак зур роль уйнамый, – ди. – Әйдә, син техникумыңда бер курс бетер, мин сине армиягә алам да, хезмәтеңне тутыргач, Сызраньдагы очучылар әзерли торган училищега керерсең, вертолётчик булырсың», – ди. Мин аның бу сүзләрен хәтергә салып куйдым.

Инде менә физкультура техникумының бер курсын бетердем. Майор Чумаков мине хәрби комиссариатка чакыртып алды, сөйләшкән буенча армиягә җибәрергә дип. Мин, техникумдагы имтиханнарны алдан биреп бетердем дә, бер айга Чумаковтан повестка алып, авылга кайтып киттем. Армиягә әзерләнәм. 20 май. Килеп төштем Казанга. Иртәнге сәгать унда стройга бастырдылар да, кемнәрнең парашютта сикергәннәре бар, дип сораштырганнан соң (32се сикергән булып чыкты), теләгәннәр десантныйга бара, диделәр. Бөтенесе дә риза булгач, мин дә аларга ияpдем. Безне Бакуга алып киттеләр. Килеп җитүебез булды, шунда ел ярым хезмәт иткән солдатлар:

– Сигезәр кеше үлә парашют белән беренче мәртәбә сикергәндә, – дип котны алды.

Учебкада без парашюттан өч тапкыр сикердек. Беренче мәртәбә сикергәндә, миндә курку булмады. «Ан-2»дән сикердек – «кукурузник»тан. Самолётка ун кеше кереп утырдык, берсе артыннан берсе күтәрелеп, сикерә торалар. «501, 502, 503, 504, 505» дигәчтен, божраны тартасың. Авызны ачарга ярамый. Сикергәч, һава агымы, авызыңа тулып, күкрәгең кабарып шартларга мөмкин. Мин теге саннарны санап тормадым, божраны тартып та җибәрдем, стабилизирующий парашют ачылып та китте. Һәм бөтенесеннән дә биек булып һавада калдым.

Андагы дөньяның матурлыгын күрсәң – шаккатырлык, зур парашют та ачылып китте бит әле – шатлык. И, ул Кавказ тауларының очындагы карлар, андагы зәп-зәңгәр күк! Ә аста, ә аста мәк кырлары – кып-кызыл. Нинди ләззәт, нинди хозурлык! Менә моны үзеңә күрергә кирәк, үзеңә!

Икенче, өченче сикерүләр – уйландыра. Җиргә төшкәч, җил парашютны үз уңаена тарта башлый, син аны тиз генә җыясың да, җыйгачтын, күккә карап ятасың. Күпләр әле һаман самолёттан сикерә торалар. Ә бит синең парашютың ачылмаска да мөмкин иде... Менә шуны уйлау сикергәндә икеләнү тудыра башлый инде. Аннары үзем дә бер мәртәбә сикергәч, елга яры кырыена эләгеп, аякны кайшалттым.

Бер заман шундый хәл булды. Чабаксардан бер малай бар иде. Самолёттан сикердек, парашют ачылды. Матурлыкка сокланып, зур рәхәтлек тоеп, дөньямны онытып төшеп киләм. Карасам, минем аяклар теге малайның парашюты өстендә. Нишләргә, бетәбез бит. Ул, мине күреп алды да:

– Что ты делаешь, ненормальный татарин?! – дип кычкыра.

Купол өстеннән тиз генә ычкынырга кирәк бит инде миңа. Стопорны тартып, үзеңнең парашютны кырыйга чыгарырга кирәк. Һәм шулай итә алдым да.

Бер ел үтте дигәндә, безне Рязаньдагы десант училищесына алып киттеләр. Минем балачак менә шунда тәгәлләнде…

**Рөстәм ГАНИЕВ**

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

## Дамир әнисен кочып алды

**– Әни, мин күрше Сәлимәгә өйләнәм! – диде Дамир.**

**– Юк! Юк! Юк! – диде әнисе.**

Сәкинәнең уйлары егерме ел артка, яшь чакларына әйләнеп кайтты. Ул медучилищены бетереп, апасы янына Үзбәкстан якларына китеп тормышка чыкты. Ире белән биш ел торып та бәби алып кайтмагач, кире туган ягына кайтып урнашты. Язмыш шулай кушкангамы, күршесе, беренче мәктәп еллары мәхәббәте Наилгә сөю хисләре сүрелмәгәнен аңлады. Наил дә Сәкинәне күргәч, бөтен дөньясын онытып, үзен тыеп кала алмады. Алар сөю дөньясында йөзеп, аңнарына килгәндә, зур гөнаһ эшләгәннәрен аңладылар. Тугыз айдан Сәкинә тап-таза малай алып кайтты.

– Әни! Әни! – дип малайның эндәшүеннән Сәкинә уянып, айнып китте.

– Юк, улым, синең укып бетерәсең, эшкә урнашасың бар, – дип каршы төште. Чөнки Сәлимә Наил кызы иде, әүвәл Наил белән сөйләшергә кирәк дип уйлады ул.

Очраштылар, егерме ел вакыт узганын алар бер-берсенең күзенә карагач кына сизделәр. Икәүдән икәү калганнары юк иде әле.

Сәкинә сүз башлады:

– Син мине гафу ит, тик балаларны бер-берсеннән аерырга кирәк. Чөнки Дамир – синең улың. Наил аптырап калды, аның башы әйләнеп китте.

– Ник дәшмисең, нишлибез?

Наил исә әкрен генә:

– Сәлимә минем үз кызым түгел. Балаларга каршы килмик. Калганын соңрак сөйләшербез, – дип әйтте дә китеп барды.

Киләсе ялны Сәкинә түземсезлек белән көтте.

Дамир кайтып керү белән: «Кыз сорарга әзерме син, улым?» – дип әйтте ул. Дамир шатлыгыннан әнисен кочаклап алды…

## Аңа болытлар елмайды

**– И, зәңгәр күк! Утыз яшемә җитеп тә, үземә пар таба алмадым бит җирдә! Ай кызын булса да төшер инде, ә! – Шулай дип әйтүе булды, нәрсәгәдер сөртенеп, мәтәлепләр китте Гафур!**

**– Хәлең ничек, абзый? «Скорый» чакырыйммы? – Бик тә матур иде бу тавыш!**

Аның алдына иелгән чибәр кызның йөзенә кагылуы Гафурны аңына килергә мәҗбүр итте. Ул берни булмагандай тиз генә сикереп торды һәм, рәхмәт әйтә-әйтә, өстен какты.

– Уйга батып киткәнмен, зәңгәр күккә, болытларга карарга яратам, абынганымны сизми дә калдым, – дип сүз башлады Гафур. – Бу паркка гел киләм, монда тыныч, күңелем ял итә.

Кыз да, аңа кушылып:

– Мин дә паркка гел килеп уйланып утырырга, агачларга, болытларга карап музыка тыңларга яратам. Кайтырга дип кузгалган гына идем, сез килеп бәрелдегез. Мин Зөһрә булам, – дип шаян гына кул сузды.

– Гафур булам! – дип, кызның кулын кысты тегесе, аңа Зөһрә якын бер зат, күптәнге танышы кебек тоелды. Кызның сылу гәүдәсе, яшькелт күзләре, толымга үргән кара чәче аны шунда ук үзенә гашыйк ите.

Алар икәүләшеп парк буйлап атлап киттеләр. Гафур кызның сөйләвен тыңлый-тыңлый паркны чыгып тукталышка якынлашуын сизми дә калды. Ул артына борылып зәңгәр күккә бакты. «Рәхмәт, Ходаем!» дип әйтергә җыенганда, болытлар кеше сурәтенә кереп, аңа елмаялар иде…

**Вәсилә ФӘЙЗЕТДИНОВА.**

*Түбән Кама районы Калмакчы авылы*

**Редакциядән.** *Башламнар 7нче санда бирелде.*

# İctimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### САЙЛАУ

«Бердәм Россия» партиясе сайлау алды кампаниясе уңаеннан «Көчле Татарстан! Бердәм Россия!» патриотик эстафетасын уздырды. Анда Дәүләт Думасына депутатлыкка кандидатлар, төрле дәрәҗәдәге депутатлар, иҗтимагый оешмалар активистлары, җитәкчеләр катнашты. Алар Татарстан шәһәрләрендә һәм районнарында халык белән очрашты. Сәфәрнең максаты – һәр кешене ишетергә, проблемаларны чишү юлларын табарга!

Татарстан Республикасы Президенты, «Бердәм Россия» партиясенең республика төркеме исемлеге лидеры Рөстәм Миңнеханов Дәүләт Думасына депутатлыкка кандидатлар белән очрашуда патриотик эстафетаны хуплады. «Безнең бурыч – халык арасында булу», – диде ул.

### ТҮБӘН КАМАГА – 50 ЕЛ

Түбән Кама шәһәре 50 еллык юбилеен бәйрәм итте. Кала аңа бик җитди әзерләнде. «ТАИФ» компанияләр берлеге юбилейга зур бүләк белән килде. Чулманның яр буе, пристань, пляж төзекләндерелде. Чулманда 50 метрлы фонтан пәйда булды. Бәйрәмдә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты. Башта ул «ТАНЕКО», «ТАИФ-НК», «Түбән Кама Нефтехим» акционерлык җәмгыятьләрендә булды. Яңалыклар, төзелешләр белән танышты.

Юбилей киң колач белән үткәрелде. Халык көн буена паркларда, төрле мәйданчыкларда концертлар карады, ял итте. Бәйрәмнең иң югары ноктасы Тынычлык проспектындагы парад иде.

### МӘСКӘҮДӘ ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Мәскәүдә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре «И Казан, син моңым һәм яшәү көчем! Нур сибүче Казаным!» дип аталган поэтик спектакль – әдәби-музыкаль тамаша белән башланып китте.

Россия башкаласының татар мәдәнияте үзәгендә (Әсәдуллаев йорты) драматург Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган әдәби-музыкаль кичә үтте. Ул нигездә Туфан Миңнуллин сүзләренә язылган җырлардан төзелгән иде. Кичәдә «Әниләр һәм бәбиләр», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Җанкисәккәем», «Гөргөри кияүләре», «Галиябану», «Диләфрүзгә дүрт кияү» һ.б. спектакльләрдән җырлар яңгырады, өзекләр күрсәтелде. Җырларны Зилә Сөнгатуллина, Римма Ибраһимова, Айгөл Хәйри һ.б. башкарды.

Мәскәүнең халыкара музыка йортында «Ашкынамын мәңгелеккә: Габдулла Тукай һәм аның мирасы» дип исемләнгән күргәзмә ачылды. Анда ТР Милли музее, ТР Милли архивы, ТР Фәннәр академиясе, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондларыннан алынган сирәк документлар, фотосурәтләр, шагыйрьнең шәхси әйберләре, үзе исән чакта чыккан басмалары, китаплары, шуларга ясалган иллюстрацияләр куелган.

### КИҢӘШМӘ

Быел мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең республикакүләм август киңәшмәсе Лаеш бистәсендә үтте. Анда мәгариф системасын камилләштерү, аның үсеш юллары турында зур сөйләшү булды. Киңәшмәдә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. Ул мәгариф хезмәткәрләре алдында яңа бурычлар куйды, республика мәктәпләренә 78 автобусның ачкычларын тапшырды.

Шушында ук укытуда милли мәсьәләләргә багышланган секция утырышы да булды. Анда Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары – мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Лаеш муниципаль районы хакимияте башлыгы Михаил Афанасьев, шәһәр һәм районнарның мәгариф идарәләре җитәкчеләре, мәктәп директорлары, татар теле укытучылары, балалар бакчалары мөдирләре катнашты. Утырышта милли мәгарифне үстерү турында зур сөйләшү булды. Бу җәһәттән байтак эшләр эшләнгән. Мәсәлән, 2016 елда милли мәгарифне үстерү концепциясе әзерләнгән. Хәзер ул раслауны көтә. Татар теле һәм әдәбиятын укыту максатында 64 дәреслек федераль исемлеккә кертелгән, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Россия төбәкләрендә татар телен өйрәтү өчен 11200 дәреслек сатып алган.

### СЕМИНАР

Традицион август киңәшмәләре кысаларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан оештырылган Россия Федерациясе төбәкләре милли мәгариф кураторларының, укыту татар телендә

алып барыла һәм татар теле өйрәнелә торган мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, татар теле һәм әдәбияты укытучыларының семинар-киңәшмәсе үткәрелде. Аның ТР Халыклар дуслыгы йортында узган пленар утырышында катнашучыларны ТР Премьер-министр урынбасары – мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, РФ Дәүләт Думасы депутаты, Федераль татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Илдар Гыйльметдинов, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров сәламләде. Пленар утырышта ТР мәгариф һәм фән министры урынбасары Илдар Мөхәммәтов, Яшел Үзән муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рәйсә Афанасьева, Удмуртия Республикасының татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Рәмзия Габбасова, Самарадан аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган Яктылык мәктәбенең директор урынбасары Инзилә Гыйззәтуллина, Төмән шәһәрендәге 52нче мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Халидә Кирамова һ.б. чыгыш ясады. Семинар-киңәшмәдә катнашучылар татар теле һәм әдәбиятыннан укыту-методика комплекты күргәзмәсе белән танышты.

Семинарда «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре һәм авторлары катнашында «түгәрәк өстәл», очрашулар уздырылды. Казан шәһәрендәге 2нче лицей-интернатта үткәрелгән чараларда журналның баш мөхәррире Илфак Ибраһимов (шагыйрь Мөхәммәт Мирза), Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин, журналның бүлек мөхәррире, яшь шагыйрь Фәнил Гыйләҗев катнашты. Казандагы 33нче урта гомуми белем бирү мәктәбендә журналның баш мөхәррир урынбасары Рамил Ханнанов, проза бүлеге мөхәррире Камил Кәримов, шагыйрь Газинур Морат чыгыш ясады.

### ҖӘЛИЛ ҺӘМ ҖӘЛИЛЧЕЛӘРНЕ ИСКӘ АЛУ

Казандагы 1 Май мәйданында Муса Җәлил һәм җәлилчеләрне искә алу мәрәсиме булды. Анда ТР мәдәният министрының беренче урынбасары Эльвира Камалова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, шагыйрьләр Зиннур Мансуров, Рәмис Аймәт, Алёна Кәримова, Валерий Тургай (Чувашия), Анчы Самойлов (Алтай Республикасы) һ.б. чыгыш ясады. Чыгышлар М.Җәлил һәм җәлилчеләрнең шигырьләре, җырлар белән үрелеп барды. Аларны республикабыз сәнгать осталары, театрлардан артистлар башкарды. Искә алу мәрәсимендә Җәлилнең кызы Чулпан ханым да катнашты. Ул Җәлил иҗатын пропагандалауга өлеш керткән бер төркем язучыларга каһарман-шагыйрьнең тууына 110 ел тулуга багышланган Истәлек медален һәм Рәхмәт хатлары тапшырды. Бу бүләкләргә шагыйрьләр Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Мөхәммәт Мирза, Ләбиб Лерон, Рәмис Аймәт, Луиза Янсуар, прозаик, тәрҗемәче Рөстәм Галиуллин лаек булды.

### ЖУРНАЛИСТЛАРГА – БҮЛӘКЛӘР

ТР «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов 2014 елда XXII кышкы Олимпия, XI Паралимпия уеннарын, 2015 елда спортның су төрләре буенча XVI Дөнья чемпионатын үткәрүгә, шулай ук ТР массакүләм мәгълүмат чаралары үсешенә өлеш керткәннәре өчен 39 журналистка бүләкләр тапшырды.

### СӘЙДӘШСТАНГА СӘФӘР

Югары Ослан районы Кызыл Байрак авылында татар профессиональ музыкасына нигез салучы композитор Салих Сәйдәшев истәлегенә багышланган «Сәйдәшстанга сәяхәт» дип аталган бәйрәм үткәрелде. Анда Г.Камал исемендәге театр артистлары концерт-тамаша, шул исәптән Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» спектакленнән өзекләр күрсәтте. Бәйрәмдә шулай ук ТРның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, җырчылар Хәмдүнә Тимергалиева, Георгий Ибушев, Эмиль Җәләлетдинов, Искәндәр Биктаһиров, Айгөл Хәйри һ.б. катнашты. Күренекле композиторның музыкасын Анна Гулишамбарова җитәкчелегендә камера оркестры ирештерде.

### ЯЗУЧЫ ТУРЫНДА КИТАП

Язучы-прозаик, Фатих Хөсни исемендәге әдәби премия лауреаты Мәгъсүм Хуҗинның тууына 80 ел тулу уңаеннан Татарстан китап нәшриятында аның турында истәлекләр тупланган китап (төзүчеләре – язучы Ләбиб Лерон һәм Татарстан китап нәшриятының «Мирас» редакциясе мөдире Венера Камалиева) басылып чыкты. Әдипнең туган ягында – Саба районы Юлбат авылы мәдәният йортында әлеге китапны тәкъдим итү булды. Аңа чаклы Казаннан кайткан язучылар, кунаклар Байлар Сабасы зиратында Мәгъсүм Хуҗин каберенә чәчәкләр салды. Бу чараларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, язучылар Камил Кәримов, Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Рәдиф Сәгъди, Фәйрүзә Мөслимова, галимә Гүзәл Насыйбуллова, Мәгъсүм аганың сеңлесе Нурания Рәхимова, кызлары Ләйсән белән Наилә катнашты.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен язучы **Ибраһимов Хәбир Кәбир улына** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Статья А.МЕТШИНА «Нижнекамск – наш родной дом».*
*«Проза, драматургия и поэзия»: драма З.ХАКИМА «Ля бемоль», фантастическая повесть Ф.ИМАМОВА «Талисман любви», документальная повесть Р.КАРИМОВОЙ «Песчаная почва», повесть А.ХАМЗИНА «Поцеловал бы пальцы твои…»; стихи Р.ВАЛИЕВА, Р.ИМАЕВА, М.ХАФИЗОВА.*
*«100-ая страница»: З.ХАКИМ. «Предчувствие беды».*
*«Публицистика»: очерк А.АХМЕТГАЛИЕВОЙ об архитекторе Ф.ХАНОВЕ.*
*«35-летию Нижнекамского педагогического колледжа»: статья Л.ГАЛЯУТДИНОВОЙ.*
*«Искусство»: статьи – И.ИЛЯЛОВОЙ, посвящённая деятельности Нижнекамского театра, А.ХАМЗИНА «Маэстро», Р.ГАЛИЕВА «Художник», Э.ЗАКИРОВОЙ, посвящённая творчеству Э.КАЛИМУЛЛИНОЙ.*
*«В литературных объединениях»: стихи членов Нижнекамского литературного объединения «Камские зори» (с предисловием Ф.АБДУЛЛИНА).*
*«Юмор»: рассказы И.ХАЙРУЛЛИНА, И.КАШАПОВА.*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*«Белый парус»: рассказы Л.ХАЕРОВОЙ, В.ФАЙЗУТДИНОВОЙ.*
*«Маленькие»: Р.ГАНИЕВ. «Маленький Рустем».*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Нижнекамск – город юности»; Святой ключ г.Нижнекамска.*

## IN THIS ISSUE:

*Article by A.METSHIN «Nizhnekamsk is our native home».*
*«Prose, drama and poetry»: drama by Z.HAKIM «A-Flat», fantastic story by F.IMAMOV «The love mascot», documentary story by R.KARIMOVA «Sandy soil», story by A.HAMZIN «I would kiss your fingers…»; poems by R.VALIEV, R.IMAEV, M.HAFIZOV.*
*«100th page»: Z.HAKIM. «Trouble presentiment».*
*«Journalism»: sketch by A.AHMETGALIEVA about the architect F.HANOV.*
*To «35th anniversary of the Nizhnekamsk teacher training college»: article by L.GALYAUTDINOVA.*
*«Art»: articles by I.ILYALOVA devoted to activity of the Nizhnekamsk theater, A.HAMZIN «Maestro», R.GALIEV «Artist», E.ZAKIROVA devoted to creativity by E.KALIMULLINA.*
*«In literary associations»: poetry by members of Nizhnekamsk literary association «Kamskie Zori» (with a foreword by F.ABDULLIN).*
*«Humor»: stories by I.HAYRULLIN, I.KASHAPOV.*
*«Pages of humor»: section is conducted by M.GALIEV.*
*«White Sail»: stories by L.HAEROVA, V.FAYZUTDINOVA.*
*«Small»: R.GANIEV. «Little Rustem».*
*From the photo archives of the magazine.*
*Diary of the social-cultural life.*
*On our covers: «Nizhnekamsk is the city of youth»; Nizhnekamsk Holy source.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Түбән Кама – яшьлек шәһәре.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Түбән Каманың Изге чишмәсе.